ISSN 0206—4189

# Казан утлары

5.1997



# «КАЗАН УТЛАРЫ» РЕДАКЦИЯСЕНӘ

«Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләрен, аның авторларын, дистә меңнәрчә укучыларын — барлык әдәбият сөючеләрне журналның чыга башлавына 75 ел тулу уңаеннан кайнар котлыйм!

Илдә Октябрь давыллары тудырган гражданнар сугышы әле тәмамланып бетмәгән, һәркайда җимереклек, Идел буенда, Татарстанда коточкыч ачлык хөкем сөргән шартларда 1922 елның май аенда Казанда татарча әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси басма — «Безнең юл» журналының беренче саны дөнья күрә.

Бу көннән соң үткән еллар журнал өчен искиткеч җимешле булды һәм ул, лаеклы рәвештә, халкыбызның чын мәгънәсендә җан азыгы, тугры юлдашы вә киңәшчесенә әверелде. Журнал татар әдәби хәрәкәтен әйдәп баручы рухи байрагыбыз дәрәҗәсенә күтәрелде.

Татар халкының бердәнбер әдәби журналы буларак, «Казан утлары» озак еллар дәвамында әдәбиятта гына түгел, сәнгатьнең һәр төрендә яңа эзләнүләргә юл ярды, театр, музыка, сынлы сәнгать үсешен эзлекле яктыртып барды, аларның уңышына зур этәргеч булды.

Халкыбызның иҗтимагый-сәяси фикерен үстерү, фән-мәдәният тарихын барлап-теркәп баруны да «Казан утлары» үз өстенә алды һәм бу изге бурычны фидакарьләрчә үтәп килә. Бигрәк тә хәзерге катлаулы чорда — ил зур тетрәнүләр, эзләнү-үзгәрешләр кичергәндә бу аеруча мөһим.

Бөек Ватан сугышы елларында бик күп басмалар ябылып беткәндә дә, «Казан утлары» чыга торды, солдат биштәрендә һөҗүмгә барды, халкыбыз белән бергә җиңү яулашты.

Шул рәвешле, «Казан утлары» әдәбият һәм сәнгатьнең тормышыбыздагы бәя биреп бетергесез зур ролен үзенең күпкырлы, нәтиҗәле эшчәнлеге белән раслады.

Дөнья биеклекләренә күтәрелерлек яңа әдәби әсәрләр тууга булышлык итү, мәгърифәтебезне өр-яңадан үзгәртеп, тагын да югарырак баскычка күтәрү, мәйданга килгән яшь талантларны күрә-үстерә белү кебек мөһим эшләр дә журналның асыл мәсләген тәшкил итә.

Без яңадан тарихи юл башында торабыз. Татар милләтенең язмышы хәл ителәчәк алдагы еллар халыкның өстәл китабы булган «Казан утлары» журналына гаять җаваплы, зур бурычлар йөкли.

Татар мәдәниятенең рухи көзгесенә әверелгән «Казан утлары» хезмәткәрләре журнал нигезенә олуг әдип Галимҗан Ибраһимов салган матур традицияләрне киләчәктә тагын да баетырлар, журнал һәрдаим республика мәдәни, иҗтимагый тормышының үзәгендә балкып торыр дип ышанам. Редакция хезмәткәрләренә, каләм осталарына, әдәбият сөючеләргә зур илһам, саулык-сәламәтлек, бәхет телим.

Татарстан Республикасы
Президенты

Минтимер ШӘЙМИЕВ
15.04.97 ел.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

**1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА**

**5**

**(895)**

**1997**

КАЗАН


## *Бу санда*

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 75 ЕЛ


Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Рухи елъязмабыз ..... 3

А. ШАМОВ, М. ӘМИР, Ф. ХӨСНИ, Ә. ЕНИКИ, Р. ИШМОРАТ, Г. АФЗАЛ «Казан утлары» турында истәлекләр ..... 58

Журналны кемнәр җитәкләгән? ..... 134

Редколлегия әгъзалары ..... 136


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Х. ТУФАН, С. ХӘКИМ, Н. АРСЛАНОВ, З. НУРИ, Р. ӘХМӘТҖАН. *Шигырьләр* ..... 7

Т. ГАЛИУЛЛИН. Элмәк. *Роман* ..... 11

И. ЮЗЕЕВ, Н. НӘҖМИ, Ш. ГАЛИЕВ, Р. ФӘЙЗУЛЛИН, Р. ГӘРӘЙ, Р. ХАРИС, М. ШАБАЕВ, Р. ГАТАШ, ЗӨЛФӘТ, М. ӘГЪЛӘМОВ, Р. МИҢНУЛЛИН, Х. ӘЮП, Л. ШАГЫЙРЬҖАН, Г. РӘХИМ, Р. НИЗАМИЕВ, М. ГАЛИЕВ, К. СӘГАДӘТ. *Шигырьләр* ..... 62

З. ХӘКИМ. Гөнаһ. *Роман* ..... 75

«Чит җирләрдә яшәп гыйбрәт ал...» Ф. ГАБДРӘХИМ, Б. РАФИКОВ, Ә. СИНУГЫЛ, Р. СУЛТИ, Р. ГАТАУЛЛИН, Ф. МОРТАЗИН, Р. РИЯН, Х. МӨДӘРРИСОВА, ИДЕЛБИКӘ, Р. ГАЙФИН шигырьләре ..... 114


ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАР


Татар ПЕН-үзәге колач җәя. *(Татар ПЕН- үзәге президенты Туфан Миңнуллин белән әңгәмә)* ..... 73


БЕР СОРАУГА — БЕР ҖАВАП


Татарстанда беренче. *(Торкиянең Татарстандагы баш консулы Алыпхан Шәлән белән әңгәмә)* ... 113


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Р. СВЕРИГИН. Проза турында сөйләшү ..... 120


ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН


Ә. ЕНИКИ. Матурлык ..... 127


ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ


Равил хәзрәт ГАЙНЕТДИН. Бардыр, бердер... . 138


ПУБЛИЦИСТИКА


Т. ӘЙДИ. Биектау йолдызлары ..... 148

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Хәлим Гайнуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Флүс Латыйфи**
***(баш мөхәррир урынбасары)***
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Нажар Нәҗми**
**Рашат Низамиев**
**Булат Солтанбәков**
**Камил Сәгадәт**
***(җаваплы сәркатип)***
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**



**Безнең адрес:** 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

**Телефоннар:**
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.


ӘДӘБИ МИРАС


И. НАДИРОВ. «Идегәй» дастанының шигърияте турында ............ 163


МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ТАРИХЫНА


Н. ДӘҮЛӘТ. Татар диаспорасы һәм Тукай ...... 168


«КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН


Әдипләр хат алыша ............ 173


ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...


М. САТТАРОВ. Җырлыйк Арча көйләренә. *Шигырьләр* ............ 186

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ............ 190


## In this issue

«Kazan utlari» is 75»: R. PHAIZULLIN. «Spiritual chronicle», A. SHAMOV, M. AMIR, PH. KHOSNI, A. YENIKI, R. ISHMORAT, G. APHZAL'S memoirs about «Kazan utlari»; «Who was the editors of the magazine», Editorial board.
«Prose and poetry»: T. GALIULLIN'S novel «Loop», Z. KHAKIM'S novel «Sin»; the verses various generation poet's.
«Literary relations»: «Tatar center of PEN club is expanded».
«One question — one answer»: the conversation with Turkish consul general in Tatarstan Alipkhan SHOLAN.
«Literary criticism»: R. SVIRIGIN'S article «The talk about prose».
«Tatar story possessions»: A. YENIKI «Beaty».
«Publicism»: Ravil khazrat GAINETDIN. «Heis, and he is the one», T. AIDI «The stars of Biektau district».
«Literary heritage» I. NADIROV'S article «Literary style of «Idegai» poem».
«To the history of culture»: N. DAULAT'S article «Tatars and Tukai».
«From archives of «Kazan utlari»: Writers are in correspondence with each other».
The diary of the social and cultural life.
In our covers: the collective of the magazine «Kazan utlari».


● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Марс Шабаев, Тәүфикъ Әйди**

*Гамәли хезмәткәрләр:* Тәслимә Сибгатуллина, Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.



Производствога бирелде 2.04.97 ел. Басарга кул куелды 5.05.97 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 13 158. Заказ Н-155.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1997 ел.

Казан утлары

# РУХИ ЕЛЪЯЗМАБЫЗ

Гасыр ахыры җиткәндә төрле фаразлаулар күбәя, диләр. Моннан йөз ел элек — ул чор өчен милләт буларак тәмам формалашкан татар халкының зыялы акыл ияләре безнең бүгенге хәятне ничек күз алдына китергәннәрдер, тәгаен әйтүе кыен. Әмма шунсы билгеле: берәүләр татарга инкыйраз юраган, икенчеләре үсеш-тәрәккыятькә ымсындырган. XX гасырда безнең милләт бәддогалы махмырны да, хыялый өметне дә мулдан татып яшәде шикелле...

Журналыбызның нәүбәттәге юбилей бәйрәмен әзерләгәндә, архив исе сеңгән төпләмәләрне актарганда, каләмдәшләр һәм хезмәттәшләр белән үзара әңгәмәләшкәндә, безнең күңелләрдә дә еш кына сорау катыш шомлы уйлар өермәсе бөтерелеп ала. Тагын йөз елдан әдәбиятыбыз нинди хәлдә булыр? Ана телебездәге матбугат нишләр? Галәми катаклизмнар, «ахыр заман» гарасатлары чыгып, бүген без күз нурын түгеп чыгарган гәҗит-журналлар, китаплар көлгә яки тузанга әйләнеп юкка чыкмасмы?..

Без быел «Казан утлары» журналына 75 ел тулды дибез. Әмма бу — шартлы дата. 75 саны татар әдәби журналларының тик совет дәверен генә үз кысасына ала. Әгәр дә без хисап очын гасыр башында чыга башлаган «Әлгасрел-җәдид», «Шура», «Аң» басмаларыннан санасак, татар әдәби-иҗтимагый журналының чыга башлавы 100 елга якынлашыр. Ә инде милли журналлар яралгысы рәвешендә үткән гасырның икенче яртысында ук чыга башлаган татар календарьларын да игътибарга алсак, тарихи офык тагын бик күпкә ерагаер иде.

Хәер, 75 ел да — байтак вакыт. Тарих өчен бер мизгел генә булса да, адәм балалары хәятендә өч буын алышынырлык озын гомер бит ул! Бер кояш астында янәшә-күрше яшәүче халыклар белән уртак язмыш үтеп, безнең татар халкы да ниләр генә кичермәде дә, нинди генә сынаулар үтмәде бу гомер эчендә! Инкыйлаб-революция зилзиләләре дә; аклар-кызылларга аерылып пычакка килүләр дә; ачлыктан яки үләт чирләреннән нәсел-ыру белән кырылулар да; яңаны тозим дип, булганны юк итүләр дә; сыйныф-классларга бүленә-бүленә, диннәр белән көрәшә-көрәшә, алфавит-имляларны кат-кат алыштыра-алыштыра кыйблаcыз, имансыз калулар да; сәяси авантюристлардан культ ясап, үзләре «шөрепвинт» хәленә калып, миллионнарның яуларда, лагерьларда һәлак булулары да; табигать кануннары һәм мәнфәгате белән исәпләшмичә, җир-суны мәсхәрә итеп «бөек» төзелешләр, хәрби-промышленность комплекслары корулар да; утопик хыял — коммунизмга фанатикларча ихлас ышанып, хакыйкатькә хилафлык кылакыла, физик көч һәм акыл сәләтен кирәкмәгәнгә исраф итүләр дә; үзгәртеп корабыз дип, ил байлыгын урлап-юллап, җәмгыятьне бай һәм ярлыларга кисеп аерып куюлар да... һәммәсе, һәммәсе булган һәм булды бу дәвердә!

Тарих — канлымы ул, шанлымы — барыбер халык хәтеренә чигелә барган. Телефон-радио яңа кирә башлаган, телевидение дигәннәреңнең әле эзе булмаган ул ерак елларда әлеге тарих кайда чигелеп, чор-дәвер кардиограммасы кайда сурәтләнеп калган соң? Әлбәттә, беренче нәүбәттә, басма сүздә. Китапларда, гәҗит-журналларда. Һәр басманың, һәр журналның — үз биографиясе, үз язмышы. Мәгълүм нәрсә: гасыр башында — халык рухының көчле бер уяну чорында татарча байтак журналлар чыгып алган. Өлкәннәр өчен дә, балалар өчен дә, хатын-кызлар өчен дә... Диниләре дә, һөҗүле-көлкелеләре дә... 20 нче еллардан

соң да, бик нык идеологияләштерелгән булса да, милли матбугатыбыз тарихында янә бер күтәрелеш булып алган. Әмма бу хәл озакка бармаган шул. Репрессия еллары башланган, сугышлар кабынып киткән. Кайбер журналлар туктап калган, кайберләре ябылган... «Казан утлары»ның бәхете шунда: язмыш тарафыннан нәселне саклап калырга тиешле таза күзәнәкле зат кебек, ул, сәяси катаклизмнарга бирешмичә, күпмедер компромиссларга барып, исемнәрен алыштыра-алыштыра булса да, җисемен-рухын саклады, халык тарихы елъязмасы рәвешендә өзелмичә яшәвен дәвам итә алды.

Журналның тарихи биографиясенә күз салыйк. «Казан утлары» — 1922 елдан алып 1930 елга кадәр гарәп шрифтында «Безнең юл» исеме белән чыккан. Утызынчы елдан икегә бүленеп, «Яңалиф» (Татарстан Мәгариф халык комиссариаты һәм Совет язучылар оешмасы органы) һәм «Атака» (Татарстан пролетариат язучылары ассоциациясе органы) исемнәре белән басылган. Ә 1933 елдан 1965 елга кадәр — «Совет әдәбияты», ә соңгы дистә елларда хәзерге «Казан утлары» атамасы белән дөньяга чыгып килә. Заман сәясәте һәм аның шаукымнарына бәйле рәвештә журналның оештыручылары да (Татар социаль Шуралар җөмһүриятенең Мәркәз Башкарма комитеты һәм халык комиссариаты Советы; Татарстан халык мәгарифе комиссариаты, РКБ(б)ның Татарстан өлкә комитеты, Совет язучылары оешмасы; ТАПП һәм Кызыл Армия-флот язучыларының Татарстан оешмасы; Татарстан Язучылар берлеге, Татарстан Министрлар Кабинеты, редакциянең хезмәт коллективы...), титул билгеләмәләре дә (гыйльми-сәяси, әдәби-иҗтимагый журнал; сәясәт, сәнгать, экономика һәм тәнкыйть журналы; әдәби-гыйльми, иҗтимагый басма; әдәбият, сәнгать һәм тәнкыйть журналы; әдәби иҗтимагый-политик журнал; әдәби-нәфис һәм иҗтимагый-сәяси журнал), структурасы да һәм редакциянең эш урыннары да үзгәреп, алышынып торды. Билгеләмә-атамалар төрле чорда төрле сүз тезмәләрендә бирелсәләр дә, аларда төп ике төшенчә һәрчак сакланып килende — «әдәби» һәм «иҗтимагый». Ягъни иҗтимагый әһәмияткә ия булган иң яхшы нәфис әсәрләрне бастыручы әдәби журнал ул — «Казан утлары».

Гадәттә, «Казан утлары»н — татар халкының баш журналы дип әйтәләр. Төптән уйлап карасаң, дөрес бәяләмә бу. Ничә дистә еллар буе совет халыкларының әдәбияты һәм сәнгате көннән-көн чәчәк ата дип әйтелсә дә (дөрес, кайбер милләтләр өчен хосусан шулай булды да ул), безнең ни фән, ни сәнгать, ни тарих, ни музыка, ни тарих буенча аерым журнал-газетләребез булмады диярлек. (Гәрчә китап чыгару буенча инкыйлабка кадәр Рәсәй империясендә иң алдынгы урыннарда торсак та). Шуңа күрә, әдәбият-сәнгать, театр-музыка, фән һәм иҗтимагый фикер буенча ирешкән казанышларыбызны шушы журнал, хәл кадәри үзендә урын биреп, халкыбызга җиткерә килде. Тоталитар режимның «Тимер пәрдәле» елларында да, алдыру мөмкинлеге бик чикләнгән булса да, чит төбәкләрдә һәм мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дә шушы журнал аша татар халкының рухи тормышы турында беркадәр мәгълүмат ирешә алды. Шуңа күрә дә, «Казан утлары»н — XX гасыр дәвамында татар халкының рухи дөньясын: тарихын, әдәбиятын, сәнгатен чагылдырган энциклопедик басма дип авыз тутырып әйтә алабыз.

Үткәне һәм киләчәге турында тулырак күзаллап булсын өчен журнал шәҗәрәсенең бүгенгә караган кайбер контурларын анкета рәвешендә шәрехләп китик. Бу мәгълүматлар укучыларыбызның зиһененә кереп калса, аларның һич тә зыяны булмастыр.

- **Журнал 16 басма табак күләмендә (400 битле уртача форматтагы китап чамасында) һәр ай саен даими чыгып килә. Журнал редакциясендә, техник хезмәткәрләрне дә кертеп, нибары дистә ярым кеше эшли.**

- **Журнал дөньяның барлык кыйтгаларында диярлек тарала (Россия, БДБ илләре, АКШ, Алмания, Финляндия, Төркия, Франция, Япония, Австралия һ. б.).**

- **Тиражы — элеккеге СССР, хәзерге Россиянең төп әдәби журналлары — «Новый мир», «Дружба народов» журналлары белән бер дәрәҗәдә.**

- **«Татар энциклопедиясе»нә кергән совет дәвере язучыларының һәммәсе диярлек «Казан утлары»нда иҗади хезмәттәшлек иткән. Бүген дә редакциядә күренекле язучылар, шагыйрьләр, әдипләр эшли.**

- **Бу елның ахырында журналның 900 нче саны дөнья күрәчәк. Әгәр 75 ел буена уртача тираж айга 20 мең булган дип исәпләсәк тә (журналның тиражы 100 меннән арткан чорлар да булды), җәмгысы — 20 млн. данәгә якын булыр.**
- **Бүгенгесе көндә журналның дүрттән бере (элегрәк — өчтән икесе иде) Татарстаннан читтә тарала. Татарстанда «Казан утлары»н иң күп алдырган районнар — Актаныш, Саба, Арча, Әлмәт, Азнакай...**
- **«Казан утлары»н оештыручылар һәм чыгаручылар: Татарстан Министрлар Кабинеты, Язучылар берлеге, редакциянең хезмәт коллективы. Журнал — Татарстан хөкүмәте биргән һәм әбүнәчеләрдән кергән акча хисабына чыгарыла.**
- **Матбугатка язылу мәгълүматларына караганда, быел «Казан утлары» журналына язылучыларның саны 2 меңгә артты.**

Әйе, гомумән алганда, хәлебез бүгенгә шөкеранә итәрлек. Журналның иҗтимагый абруе шактый югары. Редакция даирәсенә татар әдәбиятының төп интеллектуаль көчләре — иң талантлы әдипләре тупланган. Тиражы — алда әйтелгәнчә — чагыштырмача югары, димәк яздырып алучылар, укучылар нишле. Редакциянең хезмәт коллективы да уртак максатны аңлауда бердәм, тырыш...

Һәм, мөгаен иң мөһиме — кульязма хәзинәбездә сайлап алырлык әсәрләр күп... Болары — бүген. Хәзерге юбилей елында. Миңа калса, һәр истәлекле дата, һәр тантана, шул исәптән безнең 75 еллык та, күкрәк сугып мактану яки канәгать тынычлануdan бигрәк, киләчәк язмыш турында җитдирәк уйланыр өчен бер унай форсат бит ул. Ә уйланыр өчен сәбәпләр җитәрлек. Елганың төп агымы — фарватерны яхшы белгән лоцман кебек, без дә, үзенә күрә, әдәби диспетчерлык вахтасында. Татар әдипләренең әле каләме дә суынмаган әр-яңа әсәре иң әүвәл безгә керә. Әсәрләрнең «биографиясен һәм анатомиясен» өйрәнгәндә, анализкүзәтүләрдән соң билгеле бер нәтиҗәләргә дә юлыгасың. Кайберләре белән уртаклашып узыйк.

- **Татар халкы күпләп яши торган ерак төбәкләрдән ана телебездә иҗат итүче перспективалы яшь авторлар соңгы елларда килми диярлек. Авторларыбыз, нигездә, Татарстанда һәм Башкортстанда туып-үскән кешеләр.**
- **Әдәбиятка килүче яшьләр туган телебез мөмкинлекләрен бар куәтендә файдалана алмый, дөресрәге, тел мирасын тиешенчә белми. Аларның күбесе халык авыз иҗатында тәрбияләнеп үсмәгән... Шиксез, 50—60 елларда татар мәктәпләренең тоташ диярлек ябылып, урыс теллелеккә күчүнең «уңай нәтиҗәләре» бу. Соңгы 5—6 ел эчендә мәгариф өлкәсендәге уңай үзгәрешләр күңелдә өметләр уята уятуын. Бәлки, халкыбыз яши торган ерак төбәкләрдән дә яңа талантлар калкып чыгар? Ир-егет яшьләрнең күбрәк килүен көтә әдәби мәйдан. Талантлы, булдыклы егетләрне әлегә коммерция «йотып» бара. Соңгы елларда каләм хезмәтенә күбрәк кыз балаларның гына тартылуы да табигый ук түгел.**
- **Әдәбиятның төп жанры саналган прозаның киләчәге дә уйландыра. Киң эпик планда «мамыклы» итеп яза белгән өлкән буыннар әкренләп арабыздан китеп бара... Сирәкләнгән сафларны тутырырлык лаек алмаш бүген үк бар, әзер дип кистереп әйтү кыен.**
- **Гомумән, соңгы елларда әдәби хезмәтнең абруе кимеде. Язучы хезмәтенең түбән бәяләнүе бер күңелсез хәл булса, иң авыры — иҗатчының иҗтимагый бәясе төшүе, ягъни нәфис сүз сәнгатенә ихтыяҗ кимеде. Максатларны, хыялларны кискән рухи кризис шаһитләре без бүген.**

Кыскасы, хәлләр бар Әдәби Йортыбызда. Хәер, бездә генә түгел, бүтән халык әдәбиятларында да шундый ук борчулы мәсьәләләр... Юбилеебыз турында янә искә төшереп, бу очракта, алар турында әлегә җитеп торыр. Уйланган уйланыр.

Гомумән, уйлану-борчылу, сынау һәм сыналу чорында яшибез. Ныклыкта, максатка тугрылыкта, иманда сыналабыз. Заман нурланышында һәм хәрәкәтендә

һәркемнең асылы — кемнең кемлеге бик ачык чагыла. Кемнәр кемгә генә әйләнеп бетмәде бу чорда! Матбугатта да шул ук хәл. Нинди генә гәҗит-журналлар, нинди генә басмалар чыкмады бу соңгы елларда! Дөресен әйтергә кирәк: байтагы, укучылар күңелен яуламак булып, искерәк атама белән әйтсәк, «бульвар яки вульгар» басмалар булып киттеләр... Бу яктан, шөкер, «Казан утлары», үзенең күркәм традицияләрен дәвам итеп, вакланмыйча, очсыз рекламадан, түбән инстинкт уята торган язмалардан өстен булып, халкыбызның әхлак кодексына лаек әдәби-академик журнал статусын саклап кала алды.

Тагын бер нәрсәне ассызыклап үтик: әдәби генә түгел, иҗтимагый һәм сәяси басма буларак, «Казан утлары»ның төп бурычларының берсе — Татарстанның дәүләт бәйсезлеген яклау, ныгыту, аны тормышка ашыруга өлеш кертү. Моны без уртак стратегик максатка хезмәт итү дип саныйбыз. Казан — бөтен дөньяга сибелгән татар балаларының өмет кыйбласы. Әгәр без «Казан утлары»н — бөтентатарның төп калын журналы, дип әйтәбез икән, исеме җисеменә туры да килергә тиеш. Ягъни төрле кыйтгаларга таралган татар халкы тормышын объектив анализлап, активрак чагылдырырга, милләттәшләребезне үзара якынайтырга, берләштерергә, цивилизация дөньясында халыкның үзенә лаек урынын алуда булышырга тиеш булабыз. Моннан дүрт гасыр ярым элек үзенең дәүләтен югалткан безнең халык тарихында, аның рух дөньясында Әдәбият үзгә бер миссиягә ия булып килгән: ул, рәсми беткән, ә күңелдә гомер бакый яшәп килгән ил-дәүләт эшләргә тиеш булган кайбер рухи функцияләрне үти алган. (Безнең шартларда әдәбиятны югалту халыкны югалтуга бәрабәр иде). Чөнки Әдәбият эчтән күмерләнеп көйрәп яткан Милли Берлек идеясенә сулыш өреп килгән, аны сүндермәгән һәм сүндермәячәк. Җәй ахырында үтәчәк Бөтендөнья татарларының II Конгрессы да бу фикернең дөреслеген раслар дип ышанабыз. Бөек шагыйрь Мөхәммәдьярның 500 еллыгы һәм безнең журналның 75 еллыгы бәйрәмнәре дә әлеге Конгресс программасының табигый бер сәхифәләре булачак.

Юбилей уңаеннан, гадәттә, тарихи елъязманы тудырган әдәби әсәрләр, аларны иҗат иткән олуг шәхесләрнең исемнәре телгә алына. Бу очракта, кемнәрдер гафу итсен, очына чыга алмам дип куркам. Алда әйтелгәнчә, әдәбиятыбызның алтын фондын тәшкил иткән барлык язучылар катнашып килде бу журналда. Исемлекне санап китсәң, тулы бер журнал бите дә җитмәс иде, мөгаен (бу санда журнал тарихында эз калдырган бик күп шәхесләр телгә алына, әсәрләре мисалга китерелә. Ул сәхифәләрдән укучыларыбыз мәмнүн калыр дип ышанабыз). Әш исемнәр санында түгел, иң мөһиме — алар халык җанында, укучылар күңелендә. Шулай ук, журналның көндәлек авыр хезмәтен башкаручы хезмәттәшләребезне дә хөрмәтләп узарга тиешбез бүген. Кем булып эшләсә дә — типографиядә хәреф җыючымы, әллә баш мөхәррирме, бүлек мөдире йәки корректормы, машинисткамы, җаваплы сәркатипме, редколлегия әгъзасы йә хисапчымы, бүгенге яшь хезмәттәшебезме йәки ветеранмы, исәнме, әллә гүр иясеме — барыбер — барчагызга-барчагызга олуг рәхмәт! Сезсез журнал тарихы булмас иде, Сезсез бүгенгебез булмас иде!

Юбилеебыз уңаеннан Язучыларыбыз юллаган тәбрикнамәдә мондый юллар бар: «Татар дөньясының бердәнбер саллы журналын, милләтебез рухының кабатланмас елъязмасын, халыкның әдәбе сагында торучы каләм әһелләренең төп иҗади мәйданы булган басманы һәм аның тырыш хезмәткәрләрен олуг бәйрәмнәре белән ихлас күңелдән тәбрик итәбез!» Үз чиратыбызда, без дә эшебездә төп таянычыбыз булган хөрмәтле язучыларыбызны һәм күпсанлы укучыларыбызны тәбрикләп, рәхмәт әйтәбез һәм зур тәҗрибәгә, якты сәхифәләргә ия булган «Казан утлары»ның халкыбызның XXI гасырдагы яшәешенең дә гадел елъязмачысы, килер буыннарның рухи юлдашы булып калыр дип ышанабыз.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
**«Казан утлары» журналының баш мөхәррире.**
*Казан. 1997 ел, апрель.*

# ШИГЪРИЯТ

«Әдәбият Әнкәсе, шиксез, Шигърият» дип ышанганыбыз кебек, журналыбыз тарихы да шагыйрьләрдән аерылгысыз: алар редакциянең мөхәррире, хезмәткәре булдылар, һәр дәвердә редколлегия әгъзасы вазифасын башкардылар (бу хәзер дә шулай!), үзләренең иң яхшы яңа шигъри әсәрләре белән әүвәл журнал аша укучыга танылдылар да. Сугышка кадәр, 1934—1937 елларда, журналның җаваплы сәркатибе булып, атаклы шагыйрь Хәсән Туфан эшләсә, 1938—1941 елларда исә аны, редакциянең бүлек мөхәррире буларак, Сибгат Хәким дәвам итә... Соңгы өч дистә елны гына алсак та, журналның баш мөхәррире булып шагыйрьләр (димәк, Шигъриятебезгә, шагыйрьләребезгә олуг ышаныч һәм мәхәббәт билгесе бу!) эшләвен күрербез, әйе, 1968—1971, 1974—1982 елларда бу зур вазифаны Зәки Нури, 1982—1989 елларда Ренат Харис башкарды; ә 1989 елдан исә журналыбызның баш мөхәррире булып Равил Фәйзуллин эшли... Төрле елларда баш мөхәррир урынбасары булып эшләгән шагыйрьләребез дә булды: мәсәлән, Әхсән Баян бу вазифаны дистә еллар башкарды; байтак еллар Рашат Низами эшләде. Шулай ук, җаваплы сәркатип булып, шагыйрьләрдән Марс Шабай, Роберт Миңнуллин, Наис Гамбәрләр эшләделәр (бүгенге җаваплы сәркатип — Камил Сәгадәт тә шагыйрь)... Сибгат ага Хәкимнең кулы җиңел булып, шигърият бүлеген төрле елларда исемле-абруйлы шагыйрьләребез җитәкләде: Нури Арсланов (1964—1972 елларда), Рәшит Гәрәй (1959—1963), Илдар Юзеев (1973—1975); 1975 елдан исә шагыйрь Рәдиф Гаташ эшли.

Төрле бүлекләрдә төрле елларда мөхәррирлек вазифасын башкарган шагыйрьләребез Рәшит Әхмәтҗан, Гәрәй Рәхим, Марсель Гали, Зиннур Мансур, Нияз Акмал, Шамил Маннап, Шаһинур Әхмәтсафа исемнәрен дә атау урынлы булыр; ә инде редколлегия әгъзасы сыйфатында Шәйхи Маннур, Нәҗар Нәҗми (Уфа), Шәүкәт Галиев, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Харрас Әюп кебек олуг шагыйрьләр журналның якын дуслары — киңәшчеләре булдылар.

Ә даими авторларыбыз булган шагыйрьләр? Төрле төбәкләрдән, төрле еллардан зур бер дөнья булып күзалдына баса, шигъриятебезнең данлы тарихын сөйли аларның исемнәре. Әйе, җанлы, шигъри тарихын...

Бу санда тәкъдим ителә торган сәхифә әнә шуларны искә алып төзелде. Без аны — журнал юбилее уңае белән тәкъдим ителә торган нәни шигърият антологиясе итеп, мөхтәрәм укучыларыбыз игътибарына җиткерәбез.

Әйе, Сезнең хозурыгызга, шигърият сөюче замандашларыбыз!

## Хәсән Туфан
1900—1981

### Уралда

Быел да мин
Кайттым әле сиңа,
Сагындымдыр синдә чагымны...
Әйләндереп җибәр әле, әйдә,
Тыңлыйм әле җырын валынның.

...Күрәм, сизәм, кызлар-хәчтерүшләр
Уегызны... күзегез аша да:
«Рәтле генә малай иде, имеш,
Шигырь моның... башын ашаган...»

Бездә дә шул
Җүнсезләр бар, бәгырем,
Анда да бар булмыш мастерлар.
Маташалар ап-астыртын гына
Җаныбызга хәнҗәр салырга.

Кара йөрәк, ала җүнсезләргә
Ташландык без өйрәнчек килеш.
Яраланыр хисләр, канар бәлки,
Ә чыгарбыз барыбер җиңеп.

*1927*

*



*Шагыйрьләр Хәсән Туфан һәм Сибгат Хәким.*

## Сибгат Хәким,

Татарстанның халык шагыйре
1911—1986

* * *

Күңелем булмый иде, өй түреннән
Тальян уйнап, җырлап үтмәсәм.
Йөрәгемне борчу баса иде,
Син сөялеп мине көтмәсәң.

Киртәләнә иде вак болытлар
Тамчыларын җиргә сибәргә.
Таң йокысын татлы була диеп,
Таралыша идек өйләргә.

И беренче ялкын, учак кебек,
Яна-яна артта калдың син;
Сүрелмәдең, еллар узган саен
Тик көчәя генә бардың син.

Күгәрченнең тамак асты кебек
Батист яулык салып иңенә
Төшә идең суга, онытылмаслык
Эз калдырып киттең син миндә.

*1939*

*

## Нури Арсланов

1912—1991

### Сөйдең—көйдердең

Башларымның, акылын җуеп, әйләнгән чагы.
Яшәреп, җаным егеткә әйләнгән чагы.
Тел сөяксез—сөйләсеннәр, ни сан аларга!
Бүген минем көлисәмдә бәйрәмнәр чаңы.

Сөйдең—көйдердең йөрәкне, ут иткән җаның,
Мәңге айнымастай итеп исерттең, ярым.
Иярсез, йөгәнсез килеш, бәхетле таңда,
Далаларга алып очтың, чая толпарым.

Кайда тынгы, кайда ирек?!—Күр, мин богаулы.
Әгәр дә син әмер итсәң—аударам тауны!
Тәңресеннән вәхи алган пәйгамбәр сыман
Кояш иңде күкрәгемә, йолдызлар яуды!..

*1967*

*

## Зәки Нури

1921—1994

### Мин үзем сәер икән...

Сиздем, дуслар, сәгатемнең,
Сиздем сәер гадәтен;
Сиздем сәер гадәтен мин —
Соңга кала сәгатем.

Ни дип тә әйтергә белмим,
Ни булды, нәрсә сәбәп:
Тибешеннән йөрәгемнең
Ник артка кала сәгать?

Йөрмидер кебек телләре,
Карыйм да кабат борам.
Очрашу көткән көннәрне
Гел шуңа карап торам.

Сәер ашкыну бар миндә —
«Көтәм!» дигәндә иркәм,
Сәгатем соңгарыр дим дә,
Өч сәгать алдан китәм...

Сәгатьне юкка борганмын,
Аңлатты, хәер, иркәм:
Үләрдәй гашыйк булганмын,
Мин үзем сәер икән...

*1970*

*

## Рәшит Әхмәтҗан

1941—1995

### Җил

Бу җиде юл чатында
Җиде яктан җил исә.
Йомшак җил, җылы җил...
Артыннан давыл килсә —

Исем китми аларга.
Җил белән ниләр килсә,
Барсы да җилгә китә,
Җиде диңгез артына
Җил белән барып җитә.

Әйдәгез,— ди бу җилләр,—
Сезне алып китәбез.
Китәсегез килмәсә —
Капкагыгызны бикләгез.

Эндәшәләр бу җилләр:
— Сез дә юлда идегез.
Хәерле юл телибез —
Юллар буйлап китегез,
Имин барып җитегез...

Ә мин әйтәм: — Гомернең
Беләм җилдәй үтәсеп.
Җилләр чакырган җиргә
Килми барып җитәсем...

*1978*

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР



**Тәлгат Галиуллин**

# ЭЛМӘК

(РОМАН)

## 1

**К**өяз көзнең соңгы аенда үтәли җилләре, карлы яңгырлары белән табигатьтә тымызык салкынлык урнашты. Хәятның сөенече, тукландыручысы Кояш, кемгәдер үпкәләгәндәй, авыр болытлар юрганы эченә яшеренеп, күк йөзендә бөтенләй күренмәс булды.

Бәйдән ычкынган буйдак, шук җил — җиһанга тулысынча хуҗа... Шәһәр читендә, шау-шулы, сасы төтенле тормыштан читтәрәк урнашкан ике катлы хастаханәгә ул аеруча бер явызлык белән каныга. Күптәннән сипләнмәгән, каралмаган түбәнең бер читен каерып алып, күк улы үзенә кызык таба: әүвәл, алып китәргә җыенган угры мәсле, калайны урам ягына суырып чыгара, шунда ук аңына килеп, явыз ниятеннән кире кайткандай, нечкә тимер кисәген шап иттереп урынына китереп куя, читкәрәк китеп, көч туплап, янәдән гайрәтле ачу белән, һөҗүмгә күчә. Калайны пычрак җиргә ташлап, котылмакчы була, күрәсең, бахыр. Мохитның ноябрь аенда шул рәвешкә керәсен, шулай булырга тиешлеген тәгаен белгән, аңлаган хәлдә дә тимер калай тавышы, җил улавы, җепшек кар күңелсез, ямьсез тәэсир итә, җанны ашый, төшенке уйлар тудыра, кешенең ахыр көчсезлегенә, яшәешнең фанилыгына, язмышның көченә һәм табигатьнең мәңгелегенә инандыра.

Баш табибка, аның хуҗалык шөгыльләре өчен җаваплы ярдәмчесенә хастаханә хезмәткәрләре һәм авырулар түбәне ямау, һич югында, җилнең «сөяркәсе» — калай кисәген урынына утырту кирәклеге турында каткат әйттеләр. Җавапка кесәгә кереп тормый хуҗа кешеләр:

— Акча юк!

— Кадак бирмиләр.

— Башка хәсрәтегез беткәнме? Су үтми ич әле!

Агач караватында үҗәтләнеп, үлем хәсрәтләре белән тарткалашып яткан ир-ат кына табигать фасылындагы үзгәрешләрдән хәбәрдар түгел.

---

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН (1938) — *әдәби тәнкыйтьче, прозаик, филология фәннәре докторы, РФ гуманитар фәннәр академиясе академигы, КДУның татар филологиясе, тарихы һәм кончыгыш телләр факультеты деканы.*

Ярсулы ачуы чигенә җиткән җил белән сугышып миңгерәүләнгән түбә калаена да исе китми. Ул инде өченче ай берни ишетми, берни күрми, ни, нәрсә сизгәнен әйтә алмый. Тормышы ике яклы үткен пәке өстендә торганны аңларлык хәлдә дә түгел. Кечерәеп калган гәүдәсе, мәрмәр ташка югарыдан килеп төшкән бәллүр савыт кеби, вак кисәкләргә ualгандай аның. Бөтен тәне, барча күзәнәкләре томан диңгезе эчендә йөзә. Ак марляга төрелгән башы умарта күчедәй гөжли.

Кешедән берәү дә соңгы сулыш өчен көрәш хокукын тартып ала алмый. Әле кендек каны җиргә тамганчы, анасының карынында чакта ук илаһ аңа яшәү рухын, әҗәлгә җиңел генә бирешмәү кодрәтен өрә. Газазил көчләр белән бил алышуга соңгы көчәнешен биреп, яшәү, терелү, аякка басу өчен тартышканын хаста үзе шәйләмәскә дә мөмкин. Бу омтылыш-ниятгә милли, җенси, матди, хакими аерымлыклар, яшьлек, картлык, байлык, хәерчелек кебек төшенчәләр юкка чыга. Өч аршын җир ыржаеп үзенә «чакырып» торганда хокуклар тигезләшә.

Ике олы тәрәзәле, алан кебек зур почмак бүлмәдә, канатлары каерылып ташланган аккоштай, Сәет берүзе ята. Өстендә ак төстәге җиңел киҗе-мамык юрган. Җәрәхәт эчендә яткан кешене, үз эшенә бирелгән яхшы көтүче кебек, көне-төне диярлек, матур түгәрәк, кара-тут битле, зур кара күзле, кабарынкы, тойгылы иренле, төз гәүдәсен, биленең эчкә кереп киткән уемын халаты да яшерә алмаган яшь ханым саклый. Күзләрен чирледән алмый, ярты сәгать саен кан тамырының тибешен тикшерә, маңгаена назлы гына итеп кулын куеп ала. Хастаханәдә озак утырудан агарынган, шуның нәтиҗәсендә тагын да мөлаемләнеп, зыялыланып киткән йөзе, уфылдап, сыктанып, чын күңелдән сызланып алуы, энә кадау белән система куюны гел алыштырып торуы хатынның яралының сәламәтләнүен теләвенә, үз саулыгы белән бүлешергә әзер булуына дәлил кебек.

Хәер, ханым бүлмәдә үзе генә түгел. Ишек янында, чүпрәк тышлы урындыкта, сары балчыкта озак ятып тутыккан кадак кебек җиз башлы, сипкелле, йөнтәс куллы таз ир утыра. Өстендә ала-кола сыер тиресе төсле кием. Кесәләре бүлтәйгән. Ул кереп-чыгып йөргән табибларны, аларның эш-хәрәкәтләрен игътибар үзәгендә тота, кизүдә торучы шәфкать туташын да күз уңыннан ычкындырмый. Махсус бурыч йөкләтелгән, өйрәтелгән, сактагы нәселле эт кебек тота үзен. Төнлеккә аның урынына шундый ук таза, елгыр егетләр килә.

Бүген ханым яралының хәл-әхвәлендә уңай якка авышу сизде. Бер мизгелгә аңы уянгандай тоелды. Хәтеренең бер почмагы ачылып, тернәкләнеп алгандай тоелды. Үзе илә нәрсә булганлыгы, кайда ятканлыгы белән кызыксынгандыр, бәлки.

Иреннәрендә су тәмен тойды ир-зат. Күз кабакларына берәр подаукалы гер асып куйганнар, диярсең, күтәрә генә алмый. Гәүдәсенең, тәненең үзенә буйсынмыйча эрүен, сүнүен тойды, офыкта кызыл тамчылардан торган үлем шәүләсен күргәндәй булды. Йөрәге көчкә-көчкә, сулык-сулык тибә, колагында матәм маршысыман музыка чыңлый...

Кысык кына ачылган күзләренә утлы күмердәй эссе, чем кара шар эленде. Кулга аласы килә. Мәгәр ул кулларын сизми. Аның ягына шар җибәргән утлы дулкын әкрен генә башына, тәненә үтеп керә, яндыра башлый. Куркудан авыр итеп, сыкранып, сызланып, ыңгырашып ала.

Кабарып, шешенеп, кызыл балчыклы җир кебек шартлап, яргаланып беткән иреннәрен ачарга тырышып карый. Кыймылдатудан ары китә алмады. Колагына адәми тавыш инде.

— Сәет Яруллович, уяндыгызмы? Күзегезне ачарга тырышыгыз. Хәзер су каптырам.

Сүзләр әллә каян еракган, диңгез, Каф таулары артыннан килгәндәй тоелды. Моңы, әйтелеше таныш булмаса да, якын, ягымлы, раушан, йөрәккә моңлы наз булып ята торган аваз. Кем тавышы? Зөлфиянекенә охшамаган кебек. Шулдыр, аныкдыр, бераз үзгәргәнгенәдер.

— Зөлфия,— диде Сәет, мөмкин чаклы катырак әйтергә тырышып.— Зөлфия!

Җавап килмәде. Чөнки сузылып, өстерәлеп килгән ымы авазга көчмәде, аны бик теләгән, сүзенә сусаган кеше дә ишетмәде. Тешне ямаганда авызны озак ачып торган кешенекедәй, теле кипкән, аңкавына ябышкан иде. Су каптыручы ханым, иреннәрнең калтырануыннан, авыруның нидер әйтергә теләгәнен аңларга тырышты.

— Нәрсә дисез? Кем кирәк? Тынычланыгыз.

Авызына агач кашык белән чираттагы суны агызгач, Сакмановның тамагы ачылып киткәндәй булды. Иреннәре, янәдән йозакка утырудан курыккандай, бер тын белән, шул ук алты хәрефтән торган сүзне кысып чыгардылар. Бу юлы аны аңладылар бугай.

— Хәзер килә ул. Әйдәле, тагын татлы ширбәтне эчеп җибәрик. Менә шулай. Болай булгач, алла боерса, тереләбез. Дәҗҗал үлемгә әрәм итәрлек кешебез юк.

Сәетнең башын мендәре-ние белән күтәреп, су коя-коя, берүзе озак яшәгән ялгыз карчык-кәмперләр кебек, ханым сөйләнүен дәвам итте: «Ничек диләр әле, эттән калганны арслан ашамас... Явызлардан исән калдың, дусларың коткарыр».

Аң төпкеле ачылып киткәндәй булды. Яралы хатынның сүзләрен тәгаенләргә тырыша: «дәҗҗал, арслан, эт, әрәм итү, явызлар, дуслар...» Кәлимәләр зиһенгә буйсынмый, баш бирми, тәсбих төймәләредәй уртак җепкә тезелергә теләми. Бар ихтыярын төйнәп, сүз-җөмләләрнең мәгънәләренә төшенергә тырышып, чирле хәлдән тайды, арыды, кайта килгән аңын җуйды...

Мәрткә китеп күпме яткандыр, ул хәтлесен янында утыручы белән җирән сакчы гына белә булыр. Икенче уянганда үзен яхшырак хис итте. Күз кабакларына элгән тимерләрне җиңеләйткәннәр кебек. Ир-ат тавышын ап-ачык аңлады.

— Ташны ярып чыккан үлән икән үзе. Куш йөрәкле. Яшәвенә сукыр тиенлек ышанычым юк иде. Кирәк булсам, чакырырсыз.

Табибның, чирлегә иелгән булып, урындыкта утырган чибәргә бөтен гәүдәсе белән орынуын, аннан җил-җил атлап чыгып китүен Сәет күрмәде. Аның йөзенә янә кара кояш төште. Зур түгел иде бусы. Ни хикмәттер, аңардан эсселек, алҗыту килмәде, киресенчә, ул тарафлардан җылы, татлы, хуш исле, тормышчан сулыш бөркелде. Көтеп алынган җиләс саба җиле исеп куйды, диярсең. Шәфкатьнең хатын-кыз затыннан иңгәнен аңыштымы, сизендеме Сәет, әйтүе кыен. «Кем бу, нинди алиһә аңа җан өрә, Зөлфиясеме? Тәме, исе, рухы аныкына охшаган. Ник дәшми үзе? Аңа ни булган?»

Ханымның йомшак, җылы сулышыннан колагына төшкән сүзләрне акыл казанында берләштерергә, җыярга тырышты.

— Менә шулай, тулырак ачыйк күзне. Дошмани караңгылык чигенсен! Без әле озын-озак итеп яшәргә тиешбез.

Сәет сискәнеп куйды. Очкын булып аң чаткысы кабынды. Болай да учтагы каз бәбкәседәй көчкә леп-леп итеп утырган йөрәгенә энә белән кадагандай булды. «Кем соң ул дошман? Кая чигенергә тиеш. Качарга кирәк аңардан. Болай ярамый...

Нәрсә булды соң минем белән, берни хәтерләмим. Баш чатный, коточкыч тавышка түзеп булмый. Металл савыт-саба, кашык-аяк белән тулы кибеттә фил йөргән тавышлар чыга.

Авырту кызыл вә кара гына була ала икән. Һәр нерв күзенә кайнар кургаш тама. Ни өчен шундый газап, иза, сызлау, зәхмәт җибәрде соң миңа тәңрем? Һәр күзәнәк — авырту. Кеше шундый газапка түзә алмас. Мин әллә кеше түгелме? Минем — җаным гына исән калгандыр инде. Анысы алла кулында».

Төш белән өн арасындагы халәтендә ятканда янына урынбасары Хәлил килде. Ресторан ишеген саклаган замандагы мәсле таушалып

беткән, иске-москы киемнән. Тик чәчләре генә юк. Читкәрәк карап әйтеп куйды:

— Сәет, үлгәннән соң тәүбә юк. Шуны онытма!

— Ник алай дисең әле, Хәлил? Мине рәнҗетергә килдеңме?

— Соң, мин үлдем бит.

Сакманов сүзне гадәтенчә, шаян юлга төшерергә булды.

— Тагын үлдеңмени?

Хәлил иренен чалшайтты. Ямьсез килеп чыкты. Шул арада өсләренә буш калай мичкәләр өеме ишелеп төште. Алар шулчаклы күп. Иптәше шулар астында калды. Сәет буш, шалтыравык савытларны як-якка төртеп, котылырга тырышып карый. Берничәсеннән котылса, яңалары, әшәке тавышлар чыгарып, өстән иңгән, җил-давыл кебек, өемнәре белән агылалар... Шул мәлне өстән ап-ак ефәк элмәк төште. Ят, карлыккан, тупас тавыш колагына эленде: «Башыңны тык шунда. Син аңа лаек. Котыл сызлануларыңнан!» Бу хаким тавышлы әмергә буйсынып, тәвәккәлләп башын элмәккә тапшырырга әзер иде инде яралы.

Көтмәгәндә, котылу күктән иңде. Сөйләсәң кеше ышанмаслык могҗиза булды. Җилдән, хезмәттән яргаланган, гадәти бер кул элмәкне, мичкәләрне җиңел генә читкә алып атты. Шәфкать иясендә Сәет әнисен таныды. Ана нинди хәлендә дә, беркайчан да күкрәк сөтен имезеп үстергән баласын ташламый икән. Куе томанга төренгән, мендәр өстендә утыра, дөресе, һавада эленеп тора. Кәшемир яулыктан.

— Әни, синме? Мин сине таныдым, әни. Кил яныма!

Анасы Сәет янына очып төште. Кулыннан сыйпады. Тәненең сызлануы бермә-бер кимеде.

— Әни, нәрсә булды минем белән.

— Балам, ник мине күмәргә кайтмадың? Мин рәнҗедем.

— Менә бит, килдем яныңа.

— Юк, үзем килдем сиңа. Дөрес яшәмисең, балам.

— Ялгышым нәрсәдә соң? Мәчет салырга акча бирдем. Мәктәпләргә ярдәм итәм. Дини, тарихи китаплар чыгарырга булышам. Химаяче мин.

— Кеше юлыннан йөрисең. Үз юлыңны тап! Хак юлда йөргәннең йөзе ак.

Шул җөмләсен әйтте дә ак мендәренә утырган килеш очып та китте. Кызыл шарга әйләнде.

Берничә көннән соң Зөлфиясе белән «күрешеп» алды. Сәет өстәл артында, яраткан урындыгында эреләнеп утыра имеш. Өлеш тәлинкәләренә төрле-төрле яшелчәләр куелган. Күрше бүлмәдән, үзенә ифрат килешле кызыл бәрхет халаттан мәхбүбәсе килеп чыкты. Мамыктай җиңел очып килеп урынына утырды. Йөзе йокыдан айнып бетмәгән. Гамьсез, уйсыз күренә.

— Әллә юынмадың инде, Зөлфия,— дип, Сәет хатынына ягымлы карашын ташлады. Шул хәлендә дә нәзбереге гүзәл гамь, илаһилык үрнәге иде.

Хатыны исе дә китмичә:

— Юк шул, Сәетҗан. Һәркөнне юынырга дигән закон юк. Черкидән фил ясап бәйләнергә яратасың инде.

— Соң, тәһарәт алмыйча, өстәл артына утырырга ярамый дигән Коръәндә.

— Ә мин, песи баласы төсле, сусыз гына юынам,— диде дә, тырнаклары җиңелчә генә буялган җыйнак куллары белән битен иркәли башлады һәм эреп юкка чыкты. «Нишләп кешене көчләп юындырдым, килешмәде»,— дип әрләп алды Сәет үзен. Аң очкыны кунды миенә. Янәдән хатынын дәште.

Зөлфиясе һаман күренми. Димәк, үпкәләгән йә укудан кайтмаган, әллә авылга әниләре янына китеп барганмы? Мунча керергә. Шунда юыныр.

Бар көчен туплап, күз кабакларын каерып ачып, бүлмәне иңләде. Кара кояш юкка чыккан. Ак халат күзенә чалынды Шәфкать туташы нишли биредә, аңа нәрсә кирәк? Зөлфия килеп керсә, өйләрендә чит-ят хатынның утыруын бер дә өнәмәс.

Ничәмә айларга үзенә сыендырган палатаны тәүге күрүе иде. Олы-олы тәрәзәләр, биек түшәмнәр. Урамда елак көз икән. Юеш кар тәрәзәләргә сыланган. Кайсы җир соң бу? Аларның өенә охшамаган. Ак халатлы ханым кем? Ишек төбендә ят ир утыра... Ханымның иреме?

Соңрак, чүл ташыдай эссе зиһененең бер читенә шундый күренеш сеңеп калды. Күз кабаклары, йозактан котылган сандык кебек, ачылып китте. Янында мөлаем түгәрәк йөзне, ак халатны тапмады. Күз алмасы әрсезләнеп сулга борылды, «акны» ишек янында шәйләде.

Гадәттә сакчы утырган урындыкта халат аңа арты белән чүгәләгән — ирне үзе белән каплаган бөдрәләндерелгән чем кара чәч Сәетнең күзенә «керде». Бүлмәдә ике кеше булырга тиеш иде кебек? Кая олакты соң берсе? Сәетнең бу табышмакны чишәрлек хәле юк иде. Ул янәдән аңын югалтты. Тик ике адәми затның бергә укмашып утыруы, начар төш кебек, хәтереннән чыкмады. Бу манзараны ул беркайчан да оныта алмады.

Шул мәлдә аңы, зиһене хуҗасына ярдәмгә килсә, ул язмыш сынавының кайбер баскычларын әйләнеп үтәр, бәлки, дуамал котылгысызлык упкынына тәгәрәмәс тә иде. Әйе, булачак матуры, сөйгән яры Фәридә Сәетне сакларга куелган, чынында элеккеге КГБда армый-талмый хезмәт иткән, хәзер дә тәүге хуҗалары белән җылы мөнәсәбәтенә хилафлык итмәгән, яңа байлар «җирәнкәй» дип, үзләренчә мыскыл итеп йөргән кешенең аягы өстендә утырып, гәүдәсен, иреннәрен омон киеменә тапшырган иде. Әдәпле кыз сәдәпле, ди халык. Халатының ак төймәләре чишелгән иде. Тәңре баласы күрәзәче түгел шул. «Игелек» ширкәте хуҗасы үзенең киләчәге, язмышы күпмедер күләмдә менә шул үзара чуалышкан, сөю-сәгадәт дөньясына, ләззәт дәрьясына чумган иреннәрдән, үзара буталышып беткән аяклардан, куллардан торачагын белми иде.

Иреннәрендә калган чәй тамчысы, Әбелхаят суы кебек, авызын ачарга ярдәм итте. Ул янәдән сөекле хатынын, бердәнберен, Зөлфиясен дәште.

Аны ишеттеләр. Җавап килде.

— Хатыныгыз килеп җитмәде әле. Йомыш белән киткәние.

Тавышта элеккеге ямь, нурлы, назлы ягымлылык сизелмәде. Хәтта дошмани кырыслык та бар иде кебек. Чит-ят аваз, таныш булмаган дулкын төрле хәтәр борылышларга өйрәнгән әфисәр вә тәртип сакчысы Сәетне айнытып җибәрде, рухына, тәненә көч, дәрт өстәде: «Болай булмый, терелергә, аякка басарга кирәк. Күпме ятарга була боламыктай изрәп. Әйе, бу гөнаһлы хәятта берәү дә мәңгелек түгел, бүредәй исәнлекнең дә чишмәсе саега, кибә, яшь чакта сәламәтлекнең кадерен белмисең икән. Терелеп, моннан исән-имин чыга алса, яши белер иде. Собственно, ул начар яисә гел ялгыш-кәкре яшәдеме? Юктыр. Аның кылган изгелекләре җитәрлек түгелме соң?»

Бу — Сәет Сакмановның хастаханәгә эләккәннән соң, беренче җитди уйлануы, үзенә мантыйкый бәя бирүгә омтылышы иде. Гәп корып утырырлык куәсе, дәрманы булмаса да, аңа зиһене, хәтере кайтты. Ул үзен бу хәлгә китергән вакыйга-хәлләр йомгагын сүтәргә, үзе өчен нәтиҗәләр ясарга тиеш иде. «Кайда, кайчан, нигә шулай килеп чыкты соң әле? Нигә ул, ир уртасы, гакылы тупсага утырырга тиешле кеше әбер-чебер, малай-шалай уеннарына катнашып, юлларда атышып йөри? Чүт-чүт теге дөньяга олакмады. Кызык булса да көләсе килми. Нәфесне тыя алмаудан килеп чыкты бугай бу афәтләр. Мәетләр, үлемнәр... Иң изге ниятләр белән Казанга килгән энесе Рафаэль дә, артыннан мөрк-мөрк килеп, зарланып йөрергә Хәлиле дә юк инде. Алар инде җирдә яшәп киткән инсаннар. Кара йомгак артыннан тәгәри дә тәгәри... Күз алдыннан бере

артыннан бере олы һәм кечтеки вакыйгалар, соңгы берничә ай эчендә башыннан кичкән фаҗигале хәлләр уза. Ярый әле адәм баласының хәтере бар. Үзе белән бергә туфракка китә торган, берәү дә ала алмый торган байлыгы ул аның. Истәлек-хатирәләрне иңләмичә, Сәет үзенең хәзергене, киләчәген кабул итә алмасын аңлады. Үткәнгә юл — берьяклы урам. Ул синеке генә... Туганнан туганының язмышы бөерендә, юк, бәгырендә чуер таш кебек утыра. «Умырзая» дагы көтелмәгән күңелсез нәтиҗәдә кем гаепле? Андагы хәлләр зәңгәр экрандагы төсле күз алдына килеп басты. Үзаңы тернәкләнеп китте...

## 2

«Уеннан уймак чыгар» гыйбарәсен ишеткәне дә, әйткәне дә бар иде Сәетнең. Ә менә мәгънәсенә килгәндә... Тәфсилләп торырга вакыты җитмәде. Шаян фигыльле берәве теленә килгәнне җилгә ураган, халык аны хәтеренә алган. «Уйлап табучы» мәкаль турында күптәннән оныткан да булырга мөмкин. Әмма... Үз башыңа төшкәч кенә башмакчы буласың икән.

Ахыры фаҗига белән беткән әлеге тамаша гадәти бер «уеннан» башланды. Иртәдән «Игелек» хуҗасын мәгънәсез, тәмсез, тозсыз уйлар борчый. Кара карга тавышлары чыгарып урынында сикеренгән телефонны алмаска булды. «Чәнчелеп китсеннәр шунда, кирәкле кишер яфрагы түгелдер әле. Берәр әшәке хәбәр әйтергә җыена торгандыр». Мәгәр «кара карганы» кычкырткан зат ифрат әрсез вә тәрбиясез булып чыкты. Тагын шалтыратты. «Гомере озын булыр мөртәтнең, әле генә үзен искә төшергән идем»,— дигән уй башыннан яшен тизлегендә узды, Салих Гаяров тавышын таныгач.

— Мин әле бу! Сәет Яруллович, мин берни аңламыйм?

— Нәрсәне? Аңламасаң, кат-кат укырга, белмәсәң, оялмыйча сорарга, дип язып калдырган пәйгамбәребез.

— Минем өскә шул чаклы проблема өйдең, үзең чыбык аша гына булса да хәлне дә белешмисең. Ну яшьләр, ну яңа байлар китте. Бер мән калмады дөньясында.

— Алай ук зарланма инде. Гел көрешеп яшәү заманасы түгел,— диде Сакманов, сукыр тиенгә тормаган начар кәефен тышка чыгармаска тырышып.

Хәер, Салихның андый ваклыкларга төшеп тора торган гадәте юк. Үз килесе ярма төйсен. Шулай да, ихтыяҗ булганда, сарык тиресенә төренә белә бүре.

— Хәлләрең ничек соң, Сәет ахири? Кайгың зур, конешно, ну безгә бирешергә ярамый.

— Сезнең хәер-догада яшибез әлегә.

— Безнең дога белән Пановкадан, иң яхшысы — Бутыркадан ерак китә алмассың. Карале, Сәет Яруллович, әзиең полковник булды, бүлек мөдире итеп расланды, халык массалары ягыннан иңгән шатлык хисләрен сизмим,— дип, юри үпкәләгән булып, кыланып такылдады теге.

— Хисләр йөрәктә, бүләкләр юлда. Команда көтәбез.

— Мин шаяртам. Абзый (укы: Ваһапов Нургали) офисындамы икән? Телефоны җавап бирми.

— Машинасыннан эзләп табармын бик кирәк булса.

— Бүген мин сәгать өчтә бушыйм. Замминга Биектауга чыгып керәм, дидем. Бер утырып алыйк әле.

— Бик теләп,— диде Сәет, зиһенендә төрле вариантларны әйләндереп.— Әллә шыпырт кына берәр частный ресторанда ашап алабызмы? Сухомятка ялкытты.

— Ваһаповны табарга иде...

— Сагынуларың баштин аштымы, әллә канлы эзенә төштеңме?

— Ни файда. Аңа барыбер тел-теш тидертмиләр. Синең «якын дустың» Җәүдәт Габдуллович ничә тапкыр аны кулга алырга рөхсәт сорап рапорт язды.

— Нәтиҗә,— дигән булды Сәет, рухи халәте нигәдер бераз җиңеләя барганны сизеп.

— Нәтиҗә ачык: отставкадагы полковник абзаң пенсия оформляйть итеп йөри.

— Неужели?— дигән булды «Игелек» хуҗасы, бу сөенечле хәл-әхвәлләрдән күптәннән хәбәрдар булса да.

— Не телефонный разговор,— дип, Гаяров коры чыбыкны шырт иттереп сындырды.— Өчебезнең күрешүен матур итеп бизәү турында уйлан! Фантазияң үзеңә кирәккәндә яхшы эшли. Артык шаһитлар булмасын. Өстәле дә инде... Йөзгә кызыллык китермәсен.

Шунда ук мутланып алырга булды әле генә «чыжлап торган майлы табадан төшкән» полковник иптәш.

— Һәммә нәрсәң «к» хәрефенә башлансын... Әһә... кызлар дип, уйлап алдың инде бозык кеше, мәңгелек буйдак буларак... Минем башта гапгади нәрсәләр: кызыл икра, кызыл балык, кыздырылган тана ите, коньяк... кебек чүп-чар. Ладый.

Кем икәнлеге җәһәт исенә төшеп, Салих эреләнеп алырга булды.

— Короче, абзый белән үзегез хәл итегез калганын. Бу пычрак эшкә мине катыштырмагыз. Ярты сәгатьтән хәбәр көтәм.

Арада иң яше буларак, оештыру шөгыльләрен үз өстенә Сакманов алырга тиеш иде. Китны эзләп тапты, «Умырзая» атлы шәхси ресторанга шылтыратып, өстәл әзерләүләрен сорады. Нәкъ сәгать өчтә, агач яңаклы, керү ишеге буяулы тимер тышлы хананең чакыру төймәсенә бастылар.

Ишекне егерме биш-утыз яшьләр тирәсендәге озын буйлы, чыраена караганда, безнең халык вәкиле ачты. Өстендә бер сәдәбе генә каптырышлы чем кара кәстүм. Күлмәгенең якасын озынча муенына «күбәләк» белән беркетеп куйган. Күптәннән чәчтараш остасы кулына эләкмәгән озын чәчләрен, элеккеге фильмнардагы сәүдә хезмәткәрләредәй, нәкъ баш уртасында туры эз ясап, ат ялы кебек, як-якка салындырып куйган. Тынгысыз, усал төртмәле кара күзләре кунакларны кармалап, өтеп алды. Сәеттә озаккарак тукталды. Сакманов текәлеп карагач, чәнечкеләрен читкә алды.

Каядыр күргәне бар иде шикелле бу спай, көяз егетне Сәетнең. Берәр танышына гына ошаганмы? Әллә аш-су сәүдәсендә бизнес ясаучы «типовой» әрсезләр шулай бер-берсен хәтерләтәме? Кунакларны таныганын сиздермәскә тырышып, билен бөгеп, кушы хәрәкәт белән залга чакырды ишек ачучы.

— Рәхим итегез! Бүген бездә кеше күп түгел, теләсә кайсы өстәлне сайлап алыгыз. Күңелле ял телим,— диде дә, тагын ялагай, арзанлы жестлар ясап, чыгу ишеге янындагы тар коридордан кереп югалды. Тавышы да таныш тоелды Сәеткә. Колагында, миендә чыңлап тора. Таныш көй төсле эзәрлекле.

Чыннан да халык күп түгел залда. Түр башында, берничә өстәлне кушып урнашкан, араларында кызык өчен булса да бер ир заты да булмаган, хатын-кызлар кампаниясе бәйрәм итеп ята. Күптәннән кәефләнәләр бугай. Шәрабның «җиңел холкы» йөзләренә, күзләренә чыккан, телләренә менгән.

Чегән базарда ат сайлаган кебек, кергән кешеләрне үзләренчә бәяләделәр дә мәҗлесләрен дәвам иттерделәр.

Мәрмәр белән тышланган дүрт кырлы калын багана артына урнашкан өстәлне якын иттеләр кадерле кунаклар.

Сәет диварга арты белән утырды. Хатын-кыз урнашкан төбәк тә, пешерү бүлмәләреннән керү-чыгу юллары да уч төбендәге шикелле. Махсус шулай урнашты. Күңеле ни өчендер тынычсыз иде. Бәгырен билгесезлек тырный.



Татарстан Җөмһүрияте Милли китапханәсе Национальная библиотека

Аның урын сайлавын Гаяров үз каланчасыннан чыгып бәяләде.

— Хатын-кыздан туймадың инде, Сәет Яруллович. Очлы күзле карчыгадай, чираттагы корбаныңны эзләп кенә торасың. Да, малай, болар арасыннан майлы калҗаны сайлап алып булыр иде. Берәр тегү фабрикасыннандыр әле. Бераз төшергәч, белешербез.

Акланып маташуны бөртек кебек ваклануга санап, Сәет җавап кайтарып тормады. Тарттырсын сөяксез тегермәнен.

— Нәрсә эчәбез? Корынымы, юешенме? — дип, мәҗлестәшләренең фикерен сорашкандай булды Сәет. Бу — күптәннән хәл ителгән мәсьәлә буенча җитәкчеләрнең парламент фикерен соравы кебегрәк буш бер шөгыль иде. Гаяровның «кырыклыдан» түбән төшмәсен, ә Ваһаповның тузанын каккандай, йөрәк тирәсенә суккалап, «мотор шалит, бүген, Сезгә уважение йөзеннән аз гына эчәм», — дип зарлана-зарлана, иң ким дигәндә бер ярты йә әрмән, йә молдаван коньягын кәгеп куясын һәр кулында бишәр бармак барлыгына инангандай тәгаен белә иде Сәет. Урыслар әйтмешли, вопрос на засыпку.

— Гомергә бер ял итәргә җыенганбыз икән, тамакны яхшылап чылатыйк инде. Микроблар тончыгырлык булсын, — дигән тәкъдим кертте Салих җитди кыяфәт белән. Көнүзәк мәсьәлә тирәсендә кабынып китә алмаган бәхәс шуның белән тәмамланды.

Яннарына каршы алган ир заты килер, тагын бер искә төшереп, ныклап карармын үзен дип фараз кылган иде Сәет, әмма өстәл кырына зәңгәрсу алъяпкычлы, урта яшьләрдәге ханым очып килде.

— Нәрсә ашыйбыз! Нәрсә эчәбез? — дип, саф татарча эндәшеп, меню-ны ни эчендер, өр-яңа аксыл соры кәстүмнән, купшы әтәч коерыгы кебек чуар галстуктан утырган Гаяров каршына куйды. Мондый хөрмәт-ихтирамны кабул итмичә, Салих гөнаһсыз китапчыкны, югары тыйнаклык үрнәге күрсәтеп, Сәет алдына озатты. Язылмаган канун яши: исәп-хисапны заказ урнаштырган кеше ясый.

Салихның утлы күмерне үзеннән ераккарак озатканын Ваһапов сизеп алды.

— Котың очтымы, подпол... полковник әфәнде. Гомердә бер тапкыр син кунак итсәң дә ярасы иде тарих өчен. Фәлән-фәлән елны, фәлән көнне кеше ышанмаслык вакыйга булган иде дип, оныкларыма сөйләп калдырыр идем.

Үзе затлы, нәселле эт тавышлары чыгарып көлә. Аңа килешә, гафу ителә. Гаяровка генерал дәрәҗәсе бирсәләр дә шулай ук, үзе белгәнчә, дусларча мәсхәрә итәчәк, төрттерәчәк. Читләтеп әйтүне, кинаяне, эзоп телен танымый. Чын ир беркайчан да чын йөзен битлек, буш сүз артына яшермәс, дигән иманда яшәргә мөмкинлек бирә аңа артында торган байлык. Шул алым белән әле ул үзенең саранлыгын да яшереп кала ала.

Салихның тиресе кайрак киндере кебек калын. Пәке үткерләргә була. Мондый шаярту-төрттерүгә борын яфраклары да селкенми. Кесәдән акча чыгарасы гына булмасын. Башкасына кыен булса да түзә.

— Бер шешә яхшы коньяк, бер «Смирновское» куегыз. Капкаларга, ашарга үзегез белеп, иң тәмле дип тапканнарыгызны китерегез. Кызыл балыгы, уылдыгы, яшелчәсе — барысы да өелеп торсын. Кыскасы, соңыннан ашказанын борчырлык булмасын. Сезнең ресторан турында мактау сүзләре ишеткәнем бар, — дип, эт күңеле бер сөяк мәкаленнән чыгып, Сәет ханымның салпы ягына бер уч салам кыстырып куйды.

Мактау — сатып алынган мал түгел. Юкка гына саран тотабыз бу байлыкны.

— Мондый чибәр ханым кулыннан мин агу салынган болганчык шәраб эчәргә, аны кара ипи белән төртеп төшерергә дә риза, — дип, теленә салынды яңа «пешерелгән» полковник.

Аш китерүче мондый арзанлы тел шомартуларны күп күргәнгә ошый. Ай шикелле салкын, битараф елмайды да, Сакманов әйткәннәрне кәгазьгә төшерүен дәвам итте.

Тиз арада япан кебек зур өстәлдә чәүкә кунарлык буш урын да калмады. Бер-берсен макташкан, шаярткан, төрттергән булып, дуслар «эшкә»ябыштылар. «Ашау-эчү белән бәйле нәрсә бары тик шәхси була ала»,— дигән иманда торган Нургали, чөгә балыгы шулпасын, бер дә тартынып тормыйча, ат казылыгы белән «куертты».

Ресторан пешекчеләре әзерләгән барча нигъмәткә, берсен дә рәнҗетмичә, игътибар күрсәтә торгач, өчесе дә, сабаннан хәлсезләнеп кайткан кешеләрдәй, авыр сулый, уфылдый башладылар. Калган ризыкны хет Хуҗа Насретдинның халат җиңенә тутыр!

Бераз хәл тартканнан соң, Нургали Ваһапов каядыр ишеткән хикәятен бәян итте: «Авыл егете милициягә эшкә урнашып ята икән. Милиция бүлеге хуҗасы аңа шундый бурыч куя:

— Синең каршыңда телеграф баганасы. Син аны җинаятьче итеп расларга, кулга алырга тиешсең! Бәйлән шуңа!

Әлбәттә инде Лаеш шулпасын аз эчкән егетебез аптырап, югалып кала. Баганага ничек бәйләнәсең, ди. Багана, хохол салосы мәсле, Африкада да шул ук инде ул. Авызын ачып, башын кашып тәк басып тора.

Шунда нәчәльник кул астында эшләүче ефрейторга әмер төшерә: «Бәйлән».

Ефрейтор, баганаңы өч кат әйләнеп чыга да, чын-чынлап кызып китә: «Нишләп әле син минем каршыда, уклау йоткандай, арканңы катырып басып торасың? Аягыңны җиргә тыккансың имеш? Муеныңны торна төсле өскә сузып, һаваланып алыргамы исәбең, сасы көзән? Колакларыңа әллә нинди ак чынаяклар таккан булып кыланасың. Бәлки син череп таркалган буржуа файдасына безнең илгә каршы мәгълүмат җыеп, шуларны тапшырып ятасыңдыр? Монысына инде сәяси статья булыр, «Черек күлдә» шөгыльләнерләр синең белән, мур кыргыры! Әнә инглиз шымчысын да каптырдылар, сиңа да барып җитәрбез. Халык безнең белән! Яхшылап тикшереп карасаң, синең ул чынаяк-чыбыкларың да урлангандыр әле. Тикшерүне шуннан башлыйк! Сатып алганга документларың бармы? Булса, күрсәт! Әһә, эндәшмисең, значит, тиешле кәгазьләрең юк. Тегендә, моннан әлләни ерак булмаган җирдә, телеңне ачарлар, бездә телсезләр дә сөйли. Анда гаебен танымый калган кеше юк. Хәзергә беркетмә төзибез... Тәк, исемең, фамилияң, туган елың... Эндәшмисең. Как миленький җавап бирерсең. Влачны санга сукмаган, хатаңны үзең танымаган өчен бер-ике ел өстәрләр. Әйдәле, марш минем арттан...»

Мәзәккә ихластан, дөньясын онытып көлгән кеше берәү генә булды өстәл артында. Ул — Ваһапов үзе иде. Сәетнең уе башкада, йөрәге борчулы, күңеле әшәкелек сизә. Электромагнит кыры үзенә тартып, агулы дулкыннарын җибәреп тора диярсең.

Гаяров куе кашларын уйнатып алды, калын иреннәрен бәйдән ычкындырмыйча гына көлгәндәй итте. Ачуы тернәкләнде. «Үзен дөньяның кендеге санап, башкаларны түбән баскычта яшәүче туземецлар дип уйлый инде бу бәндә. Посмотрим, дөнья күләсә. Ә Сакмановы нишләп өреп тутырылган күркә төсле утыра? Икрага өстәмә заказым ошамадымы? Юктыр, саран мужик түгел ул. Үлгән хатынын сагына торгандыр. Бармактан яларлык иде шул. За все надо платить... Башымны ашый инде бу мафия. Бер тамагыма хуҗа була алмадым. Җиңел генә котылып та булмый үзләреннән. Киемгә ябешкән ак чәч кенә түгел шул болар. Котыласы да килми бит әле үзләреннән. Бүре куйга юлдаш була алмаса да». Кемнең куй, кемнең бүре булуын ачыклап тормады. Болай да билгеле ич.

Сәет бу спектакльдә катнашмады, үз кайгысы үзенә җиткән иде. Ничек кенә күңелле утырмасыннар, ул эчке киеренкелектән, борчудан арына алмады. Иләннән, өстәлдән, коңгырт күн тышлы утыргычтан калтыравыклы, яман рухлы дулкын һаман агыла. Ишек ачкан егетнең ялтыравык, зәһәр фетнәле күзләре баганаларга беркетелгән шәмдәлләр-

дә эленеп торгандай... Ул комсыз бәбәкләр аны һаман капшый, кармалый икән. Кая күрде, кая очрашты соң ул аның белән? Вильсур янында, сакта тормадымы икән? Мәче тырнаклы күзле Замиры биредә булса, шунда ук танып, яктыга тартып чыгарыр иде. Сәет тавышны күңелендә калдыра, йөзләргә хәтере начар. Тиз оныта.

Ишек ачучы ирнең, урынын алыштыра-алыштыра, Салихлар компаниясен мушкада, даими күзәтү астында тотканлыгында шик юк. Азыктөлек әзерләү бүлмәсе ягыннан кара көпшә юнәлтелгәндәй тоелды аңа бер мәлне. Нургалинең ишек янындагы өстәл артында утырган җирән газие дә нидер сизенә бугай, күзләрен, сиздермичә генә, гел шул якта тота. Ресторан ризыгын тамагына алудан баш тартты. Тәүлегенә ике тапкыр, үзе пешергәнне яисә сөтле ашамлыкларны гына куллана икән. Тозлы су эчеп утыра.

«Ризык чыгара торган яктан ата алмас. Ерак та, баганалар да каплый. Ишектән чыкканда бер-бер хәл кылуы мөмкин шашкын күзле тиленең». Шактый җылынган, күзләрен хатын-кыз ягында калдырган күрешеләренә сиздерми генә, Сәет җирәнгә: «әзер тор»,— дигәнрәк ым какты.

Сәетнең кәефен аракы да уңай якка бора алмады. «Умырзая»ның иң шәп ризыгы — яшелчә белән бизәлеп, бөтен килеш өстәл уртасында сузылып яткан, очлы авызлы чөгә балыгы да тиешле ләззәтне бирмәде. Ике сәгатьтән артык өстәл артында утырып, ни нәрсә хакында гәпләштегез дип сорасалар, Сәет: «Билләһи, берни хәтерләмим»,— дип җавап бирер иде. Зиһенен, миен, барлыгын шул дуамал күзле егет биләде. «Хуҗасына, безнең монда икәнлекне хәбәр итеп, кирәк булса, киллерләрен чакыртып, мылтыкны корып, пычакны үткәреп куярлык вакыт бирелде. Хәзер барысы да Алла кулында. Күңеленә шик-шөбһә төшүгә, «миңа биредә ошамый, һава исерек хатын-кыз исе белән бозылган», дип, башка җиргә алып китәсе булган да, татарга акыл төштән соң инә шул. Башы эшләп җитмәде. Хәзер соң булуы мөмкин».

Бәлки, аның шикләнүе «курыкканга куш, коерыгы белән биш» кенәдер әле. «Отыры нечкәреп киттең әле, абзыкай, «абруй»лар белән көрешкәли башлагач, сиңа һәр җирдә дошман, атыш, үтереш, суеш, тапаш, тураш, гел подвох күренә... Алай ярамый».

Гаяров хатын-кыз янына барып, өр яңа кәстүменең матурлыгын, гәүдәсенең тулырак булса да, әле төзлеген күрсәтеп, кемнедер кочаклап, пышылдашып биегән мәлдә, Сәет ашатучы ханымны чакырып исәпхисап ясады да, ахыр арып, йокымсырап киткән Нургалинең йорт нигезе имәнедәй җилкәсенә кагылып, җылы урындыгыннан аерылды.

— Гафу итегез, дусларым, онытып җибәрә язганмын, бүген Әхмәдиша бабайның дөньяга килгән көне. Булырга обещайть иткән идем. Кирәк нәрсә булса, үзебез белән төреп алыйк.

Ваһапов кул кабыргасын ияге астына куйды: янәсе, ул тулы. Авыр бәдәнен көчкә күтәреп урамга атлады. Тәмам өлгереп җиткән Салих кына шау-шулы хатын-кыз өере ягына кызганулы, ымсыну-үкенечле караш ташлады: «маллар әрәм кала». Шунда ук үзенең кем икәнлеге исенә-ятенә төште. Башын югары күтәреп, аркасына куна тактасы куйгандай, эрерәк атларга тырышып, ишеккә узды. Нургалинең сакчысы да күтәрелде. Кулын чыгу ишегенең уң җиз тоткасына салгач, Сәет тар коридор тыкрыгында, ояларыннан чыгып китәр хәлгә җиткән шашкын күзләрне һәм хуҗаларының кулыннан ычкынган ялтыравык кара бер нәрсәнең, агачтан сикергән елан төсле, күкрәге тирәсенә очып килүен шәйләде. Һөҗүмне күңел тоемы белән алдан санап чыгарган «Игелек» хуҗасы, йөрәк турысын сул кулы белән каплагандай итеп, ерткычтан курыккан кыр кәҗәседәй, читкәрәк сикерергә өлгерде. Һәрхәлдә аңа шулай тоелды. Мәгәр үз эшенең остасы һәм нәфрәт угы белән ташланган коралдан ул бөтенләй ычкына алмады. Үткен хәнҗәрнең очы кулбашына эләкте, кием һәм киеренке хәлдәге мускул катылыгына орынып, хәлсезләнеп, әмма канга җитеп, җәрәхәтләп, бурычын өлешчә үтәп, шап итеп

шома идәнгә төште. Шул ук мизгелдә ике тоныкк шартлау яңгырады. Аяклары Сәетне урамга алып чыкты.

Нургалинең «чит ил җилбәзәге» — машинасы ишек төбендә үк торган икән. Ваһапов белән Салих арабага кереп урнашырга өлгергәннәр. Сәет белән җирән яугир гәүдәләрен исәр җил тизлеге белән арткы утыргычка, полковник кырына ташладылар. «Киттек, тиз!»,— диде Сакманов еш-еш сулап. Тәгәрмәч шыгырдады, асфальт гүя сыкранды, машина уникенче трамвайның борын төбеннән узып, елга порты ягына очты. Шунда гына Сәет сул кулбашында авырту сизде. Көрән пинҗәктә бик күренмәсә дә, шарлап бәреп яткан канны, кесәсеннән кульяулыгын алып, каты итеп кысты. Машина халык йөрми торганрак җиргә барып туктады. «Шайтан алгыры, йә «пушкадан» атасың, йә салкын корал белән һөҗүм итәсен сизеп торып, шул хәлне булдырдым бит»,— дип үзен битәрләде Сәет.

Ваһаповның тән сакчысы белән машина йөртүчесе пинҗәген салдырып, кызгылт төскә кергән ак күлмәгенең җиңен кисеп атып, кан юлын кысып куеп, яраны йода белән эшкәртеп, бәйләп үк куйдылар. Яра куркыныч түгел иде.

Алданрак чыгуы сәбәпле, тамаша шаһиты була алмаган полковник Гаяров егетләрнең маташканын күзәтеп торды да, сорау бирүне, анык-лауны кирәк тапты: «Ни булды, кем атты?».

— Атмады, чәнчеде,— диде Сәет яралы кулын пинҗәк эчендә калдырырга тырышып.

Ваһапов та дулкынлануын яшерә алмый.

— Кара син аны каһәрне. Безне каршы алган егет һөҗүм иттеме? Нәрсә кирәк аңа?

Тавышы тагын да ныграк калтырана. Эт өрүенә ата күркә куәт биргәндәй авазлар чыга бугазыннан.

— Аңа минем мәет кирәк иде. Шул гына. Исән калдым менә...,— диде Сәет, гаепле кешесыман. Йөзенә көл төсе чыккан.

— Кай арада яралап өлгерделәр. Пулясы калмаганмы? — дип сорашуын дәвам итте кит.

— Пуля башка тәндә калды. Ә миндә пычак эзе,— дип, аңлатуын дәвам итте Сакманов. Шул мәлдә җиңеннән «чукрак» яугир тартты. Аның «мент алдында җәелеп китү хәерлегә булмас, шул урында тукталып калу дөресрәк булыр»,— дигән ымы иде. Кызулык, тизлек, исән калу шатлыгы белән сизелмәгән тән авыртуы йөрәгенә, нерв үзәкләренә барып җитте, Сәет ыңгырашып алды.

Гаяров шәхси йомышы белән читкәрәк киткән мәлдә, Нургали «авыртмыймы?» — дип, буш һәм урынсыз сорау бирергә җыенган иде дә, үзен тыеп калды. Җитдирәк сорауларга вакыт тар иде. Ярата иде «кит» Сакмановны ихласлыгы, йомшак күңеле, ирләрчә кыюлыгы һәм үзе мәсле тымызык карун булмавы өчен. Үзенең юмартрак булырга тиешлеген, шуңа хакы барлыгын аңлый, белә. Аны ач күзле, комсыз, сәләмә Плюшкиннар нәселеннән дип тә булмый. Хатын-кызга бүләк биргәндә, мәчет картлары ярдәм сорап килгәндә, берәр олы түрәкәйне үз тарафына аудару хаҗәте булганда, «дуңгыз канын» кызганып тормый. Үзен юри, максатлы мактаганны шәйләми калса, түгәрәк сумманы чыгарып ташларга да мөмкин. Бу очракта инде бик нечкә, чишмә суы өстендәге гүелдекләрне сыйпаган, каз бәбкәсен иркәләгән шикелле назлы, кулының тидерер-тидермәс кенә саклык белән эш итү таләп ителә. Шул очракта гына ул, төлке комагайлыгына алданган карга мәсле, сырны авызыннан ычкындырып җибәрергә мөмкин.

Күрәктән сәнәк булган яңа татар байларының вак-төяктә кысынкылыгы «милли» үзенчәлегедер шәт. Хәер, ресторанга чакыргач ук, Ваһапов: «Бүген үзем түлим әле, Сакмановта еш кунак булам, юмартлыгымның шаһиты да җайлы-яңа әвәләнгән полковник, безнең кем икәнлекне күреп-белеп торсын»,— дип күңеленә киртләп куйган иде. Ул кашынган арада Сакманов әзер акча пачкасын өстәлгә ташлап өлгерде.

Артыгын кире алмады, киноларда күрсәтелә торган һавалы «бәй»ләрдәй, кулын гына селтәде.

Кыскасы, ул Сәеттә үзендә булмаган, аңа җитешмәгән берише сыйфатларны, үзенең дәвамын күреп, артык «мот»лыгы өчен әрләсә дә, аның яралануы өчен чын күңелдән кайгырды.

— Ат дагасыз, батыр ярасыз булмас,— дип шаяртырга булды «кит». Шунда ук җитди тәкъдимен кертте.— Пычак атучыны тотып алырга, милициягә тапшырырга иде.

— Соң инде. Аның урыны мазарлыкта.

— Минем егет хәл кылдымы?

— Тегенең тук тәненә ике бакырны сылады бугай. Әүвәл тәрәзә төбенә тотынуын, аннан идәнгә шуышып төшүен генә күреп калдым. Юкса, чыгып китмәгән булыр идем. Үземнең наганым да кесәдә. Аны исән калдырырга ярамый иде.

— Молодец, җирәнкәем.

Бушанып-җиңеләеп килгән полковник та сүзгә катнашып китүне мәслихәт тапты.

— Нинди инцидент булды соң анда? Мин берни күрми-белми калдым. Сезнең белән бәйләнсәң, берәр историягә эләкми калмыйсың.

— Берни булмады, иптәш полковник. Борчылма! Менә Сакманов, аракы эчмичә ураза тотып кыланды да, күбрәк салып ташлаган, ишекне әчкәндә чайкалып киткән, официантка пычак белән ашыгып чыгып бара икән, шуңа орынган. Пинҗәге жалко, кем әйтмешли.

— Каны күп аккан. Чалбары, машина утыргычы кан гына,— дип, Салих бәйләнергә, төпченергә тотынды.

Онытылып китеп, тавышына баз бозы салкынлыгы өстәде.

— Егетләр, таралыштык. Мин ашыгам. Матур апагыз янына кереп чыгасы бар,— дип, кыбырсынды Ваһапов. Эздән милициянең килеп җитүеннән шикләнеп ашыктыруы иде аның. Сәет үз «Волга»сына күчеп утырды. Полковник Сәет белән кайтырга булды. Ул — чын-чынлап борчулы иде.

«Умырзая» да кителмәгән, уйламаган җирдән килеп чыккан «уймак» хакында Гаяровка сөйләмәскә булган иде Сәет. Уеннан кире кайтты. Авыруын яшергән тизрәк үләр, диләр. Кешене үз «өендә», кояш баткančы ук атып үтерү вакыйгасының тавыш-тынсыз, гаугасыз-өнсез генә калмасын, әгәренки, егет ресторан хуҗасы булып чыкса (Сәетнең фаразы раска килде), ясалма, купшы күмүләрне, кайнар нотыкларны, матбугатта күтәреләчәк тавышларны шактый төгәл күз алдына китерде ул. Үз иленең әхлакый-сәяси дәрәҗәсен җилкәсендә һәрдаим татып яшәгән затка күрәзәче яисә фәрештә булуның ихтыяҗы юк иде.

Әлеге вакыйганы һәрьяклап, тирәнтен тикшергәннән соң, тәвә кошы кебек, башны канат астына яшереп кенә котылып булмасын аңлады ул. Кот очу, курку, шөлләү кебек хисләр юк иде күңелендә. Ул инде үз язмышына күнеккән, аяк басып торган җирнең һәрдаим убылып төшү ихтималына әзер иде. Әле менә исән калды. Ресторанда кәеф-сафа корып алган өч дусның эзенә төшү өчен Шерлок Холмс, комиссар Мегрэ йә Катани кебек бөек шымчыларың кирәк түгел. Ничәмә-ничә күз аларны хәтерләп калды. Фотога алу мөмкинлеге дә бар. Җенси кытыкларын шәраб уяткан хатыннар таза, мәһабәт ирләрне гел күзәтеп утырдылар.

Алардан сорау алып, рәсемнәрен ясатсалар? Битләрендә кара оек юк иде. Фото-робот буенча Нургали абзыйны эзләп табуы кыен булмастыр. Кыскасы, хөкем оешмаларына аларны «на чистую воду» чыгару өчен берничә көн җиткән. Милиция бүлекләрендә, урамнарда нурлы йөзләрен элеп куя башласалар? Бик үк кызык булмас, авызны ерасы килмәс. Салихка булган хәлне сөйләп бирергә һәм мәсьәләне үз өстенә алуны сорарга булыр.

Шактый юл үткәннән соң, машинаны бер тыкрыкка кертергә кушты да, Замирны азык-төлек кибетенә җибәрде.

— Яшерәсе әйбер юк. Ничек әле ул сезнең телдә: «Безгә ресторанда бандитское нападение ясалды».

Зур күзләрен теннис шарыдай түгәрәкләп, Салих тыңларга җыенды.

— Безгә ишек ачкан, муенына кара бабочка таккан, янар күзле егетне хәтерлисең булыр?

— Мине ир-ат күзе борчымый. Син мине «зәңгәрләр» белән бутама.

Сәет, полковникның чытыклануын игътибарга алмыйча, сүзен дәвам иттерде:

— Менә шул адәм, чыгып барганда, миңа пычак ыргытты, йөрәккә тимәде. Мин капланып, читкә китеп өлгердем. Кан шуннан бәреп чыкты.

Салих сүз алды. Тавышы үпкәчел, үкенечле, хәтта әрнүле.

— Ничә тапкыр сезнең белән бәйләнмәскә, халык арасына чыкмаска дип ант суы эчкәнем бар. Һаман хаталанам. Сезгә акыл керер дип ышанам. Иске гадәтләрегезне ташлый алмыйсыз. Ни пычагыма, синең вәсвәсәгә бирелеп, бер авызыма хуҗа була алмыйча, лашманга ияреп, көпә-көндез ресторанга киттем инде? Намуслы башымны тәки сез генә ашарсыз инде? Ну нәстә инде, ашадым, әзрәк эчтем. Теләсә кайсы гражданин абзагызны кунак итәргә әзер торган заманда...

Полковник үзен-үзе битәрләп, парын чыгарды, күңелен бастырды. Ресторанда Сәет калдырган өч «лимон» аны борчымый иде. Үз кесәсеннән чыкмады ич.

Сүз — сөйләү барышы мизгелендә туа да, сандугач баласыдай оясыннан очып чыгып та китә. Аны кире кайтарып булмый. Сәет полковникка үпкәләргә тиеш иде кебек. Шунда күңеленә сугыштан соңгы елларда, туган авылында колхоз рәисе булып эшләгән Сөләйман Диннурович турындагы мәзәк исенә төшеп, елмаеп куйды. Ул чорда авыл халкы тулысы белән колхоз хуҗасына бәйле иде. Бу хәлне тәгаенләгән Сөләйман ага күмәк хуҗалык әгъзаларыннан үзен чират буенча ашка алдырта: бүген Гыйльметдинга, иртәгә Хәнифкә, берсекөнгә Гавазга барасы... Мәгәр рәис кунакта озак утыра алмый. Берничә чәркә аракыны ашказанына озатып, тегене моны капкалый да, янында кукраеп утырган хатынын «сагына» башлый: «Халисә, тиз генә җыен, өйгә кайтабыз». Әле утын китерү, печән аланын бүлешү, сөте азайган сыерны колхозныкына алыштыру турындагы мәсьәләләрен хәл итеп өлгермәгән өй хуҗасы белән Халисә ханым Сөләйманны үгетләргә ябышалар. Файдасыз. «Бераз утырыйк инде, хәзер токмач чыга, мичтә бәлеш пешеп ята»,— кебек сүзләр рәиснең кызышкан миенә барып житмиләр. «Киттек булгач, киттек»,— дип, полный пырдымсызлана, тәртәгә тибә, тавышлана ук башлый.

Өенә кайтып, күмерен сүндергәч, Диннур улына сәламәт акылы әйләнеп кайта. «Вәт дурак, хатын качкан булыр идеме, нәрсәсе бар инде, кешеләр тегендә бәлеш төбе уртлап утыра. Хет яңадан бар. Юк, больше болай эшләмим. Кунакка чакырылган исем күтәргәч, хуҗага аз-маз булса да материал зарар китерергә дә кирәк бит. Болай ярамый. Мин прсидәтел кеше, һәр яктан үрнәк күрсәтергә тиеш».

Ләкин бүре Хәнифендә дә, кызыл танау Гатауллада да шул ук хәл кабатлана. Берни дә эшли алмый Сөләйман Диннурович... Гаяровның тукран тәүбәсен кат-кат ишеткән Сәет полковникның чәпченүен житди кабул итмәде.

— Хаталанганнан соң үзен битәрләгән хатын-кыз булмыйк инде. Үткән эшкә салават. Хәзер киңәш-табыш итик,— диде Сәет, юри ваемсыз тавыш илә.

— Сакманов официант пычагына орынып, яра алды дип, гауга чыгарып, этләр котыртып йөрү килешмәс анысы.

Ул язмыштан узып булмасын аңлаган иде инде. Төенне барыбер аңа чишәргә туры киләчәк. Күзе алдагы утыргыч кесәсен «капшап» алды. Карашы үзен «сатып», тырпаебрак торган әйбердә тукталды.

— Берәр рәтле нәстәң бармы, кәгазь калынлыгы гына кой әле. Баш эшләми, эч поша. Буза чыгарып йөрисез бер дә юктан.

«Игелек» хуҗасы әрмән конъягының колагын каера-каера җитди белдерү ясады: «Ул егетне атып үтердек. Һәрхәлдә, ул мәет булырга тиеш».

— Шаяртма, Сәет Яруллович! «Минем исәп буенча, буаз булырга тиеш» дигәндәй, башыңны юләргә салма! Бу очракта шомартып, алдашып котылып булмас. Без бер йодрык булырга тиешбез бәладән исән-имин котылу өчен.

Сакманов килештереп, шартын китереп, сабыйларча көрсенеп куйды.

— Шулайрак килеп чыкты шул. Бу хәл көн тәртибенә кертелмәгән иде. Гафу ит!

Гаяров Сәетнең яңа акшарланган мич төсенә кергән йөзенә игътибар итте. Хәлнең җитди борылыш алу ихтималына ышана барды. «Кем атты, ничә пуля китте, егылганын үз күзең белән күрдеңме, егетнең кулында башка корал юк идеме?» — кебек сораулар биреп, үзе үк җавапларын әзерләп, төпченеп, каны саркып яткан Сәетне интектереп бетерде. Сакманов аның фикер сөрешен аңлады. Кәефләрен эчемлек капкалап күтәрергә тырышасалар да, бер-ике сәгать элек булган борчусыз, күтәренке рухның эзе дә калмаган иде инде.

— Салих дус, син бу эшне үз кулыңа ал инде. Бәлки, берни белмәгәндәй, форма белән ресторанга кереп чыгарга кирәктер? Милиция, ашыгыч ярдәм килеп җиткәндер инде анда?

Сәет шунда, хискә бирелеп, үз ялганына үзен ышандырырга тырышкандай, вакыйгага үз бәясен тәкъдим итте.

— Пычакны безнең якка ташласа да, егетнең начар нияте булмагандыр? Аны без чыгып киткәч, атып үтергәннәр, дип фараз кылсак. Мылтык тавышын мин машинада ишеттем. Кемдер, җайлы вакытны тотып, тегене кухня ягыннан сылаган.

Гаяров күзләреннән усал очкыннар көлтәсе сибелде.

— Син бу әкиятне балалар бакчасына барып сөйлә. Ышанмасалар да, манный боткасы белән сыйлап җибәрерләр. Гомерен шундый шөгыльләргә багышлаган полковникка уйдырма сөйләп утырма!

Еракгагы йолдызлар кебек җемелдәп, үзенә тартып торган эчемлекне йотып куйды Салих. Шоколад сындырып капты.

— Мин нәтиҗәнең нинди булырга тиешлеге турында сүз алып барам. Кемнең атуының нинди әһәмияте бар? — диде Сакманов.

Эшнең шактый мәшәкатьле юнәлеш алу мөмкинлеген күзаллаган Гаяров бәясен күтәреп алырга булды. Шунда күңеленә: «Бу жмотлардан шактый нәрсә каерып калып булыр», — дигән «позитив» фикер килде. Дәртләнеп китте.

— Сезнең юеш эзләрне сөртә-сөртә яшь гомерем узып бара инде. Ничәнче ел коттедж белән интегәм. Шул үләтне корып бетерә алмыйм.

— Чүп-чар белән башны катырма әле. Ике айдан яраткан хатының белән шунда яши башларсың! Тәңребез кушкан булса.

— Сүз — суган кабыгы, аңардан тәрәзә рамасы ясап булмый, кәбәм.

Горурлык, абруйлык кебек, мәми авыз зыялылар уйлап тапкан төшенчәләрне читкә ташлап, полковник һөҗүмне көчәйтә барды.

— Тере кешеләр белән шыгрым тулы өйне яндыру эше дә ябылмаган әле.

— Миңа ни! Мәңге шулай ачык торсын. Фал китабы төсле. Ул афәткә катнашым булмагач, сул күземнең керфеге дә селкенми.

— Башыңны юләргә салма, Сәет Яруллович. Мин белгәнне син дә беләсең. Анда кимендә җиде-сигез кеше янып үлде. Синең бухгалтерың Северцев үзе, уртак сөяркәгез... Һәм башкалар. Мин сине ул эш өчен гаепләмим. Хатының өчен үч алдың. Андый чибәр ханым өчен стоило.

Салих Сәетне фаш итүеннән, шунда ук чигенә белүеннән канәгать калып, яңакларын кабартып алды. Сул күзенә кызыллык төште. Артында аны шуның өчен «үгез күз», дип йөртәләр иде.

— «Умырзая»дагы криминал өчен дә мине гаепләргә җыенасыңмы?

Полковник «төп мәсьәлә»дән җиңел генә читкә чыгуны бер дә өнәмәде.

— Коттедж турында сүзеңне үлчәп әйттеңме? Эш күп әле анда. Штукатуркасы да бетмәгән.

— Кайчан алдаганым бар.

— Иртәгә үк шөгыльләнә башлармын бу эш белән. Тәк... Теге хатыннар танып калган булса безне?...

— Син формада түгел идең. Ян белән утырдың. Кайгылары синдә түгел иде.

Салих янә кәнфитләнеп, артистланып алырга булды.

— Соң абзаң хатын-кыз затының күзе төшмәслек мени инде? Табадан чыжылдап төшкән ничәмә кайнар кабартма әрәм калды...— дип сөйләнеп китте.

Чүпрәле камырга төшкән коньяк тел ачкычы бирде полковникка.

Үз хәлен үзе генә белгән Сәет шактый арыды. Яраны эшкәртәсе, рәтләп бәйлисе, берсен-берсе кысрыклап килгән уйларны тәртипкә китерәсе бар иде.

— Ярый, Салихҗан, сине өеңә кертеп калдырыйк та, бүгенгә аерылышып торыйк. Иртәгә туачак яктыкүзнең ни алып киләсен белгән юк.

Сакмановны өе янында сакчылары көтеп тора иде. Замир хуҗасының ярасын ифрат белдекле кыяфәт белән, нәрсәләрдер сөрткән булып карады, юка тукыманы лейкопластырь белән тарттырып куйды. «Туйга чаклы төзәлер»,— дип өстәмәкче иде дә, кире уйлады, алтын тешләрен ялтыратып алу белән чикләнде.

Сәет ял итү, тынычлык турында хыялланды. Миен ниндидер билгесезлек тойгысы кымтырыклады.

— Тиз генә таралышмагыз әле. Элемтәдә булыгыз,— диде Замирга, аста көткән тән сакчыларын да күздә тотып.

Бәла берүзе йөрми икән шул. «Хатының чирләсә, әби килеп төшә», дип юкка гына тел чарламыйлар икән.

## 3

Ярасының сызлавын оныту өчен генә Сәет чәй кайнатып эчкән булды. Бераз тынычланып, газета-журналлар алып, күн диванга чумәшкән генә иде, ишек шакыдылар. Яшереп куелган сәдәпнең тавыш бирмәве, чакырылмаган биләмченең хәбәрдарсызлыгына ишарә иде. Һәрхәлдә, еш килеп-китеп йөри торган адәм түгелдер. Сәет чыраен сытып, күперенке келәмгә басты, йомшак кына атлап, күзчәдән «тышкы дөньяга» бакты. Ишек төбендәге таш мәйданчыкта, утыз биш-кырык яшьләрендәге ир-ат яны белән басып тора иде. Йөзе күренми. Олы чемоданы белән зур соры чантасын аяклары янына урнаштырган. Тоемы көчле икән, үзен күзәткәнне шәйләп, балаларын саклаган ата каздай урында таптанып алды да, карлыккан тавыш белән сөрән салды:

— Миңа Сакмаров, Сәет Яруллович кирәк иде?

Шул арада көтелмәгән кунак йөзен-битен Сәет ягына борды. Күзәтүен дәвам иткән хуҗа имәнеп китте, гәүдәсе бизгәк тоткандай тартышып, калтыранып алды. Таш баскычта нәкъ аңа ошаган кеше, аның көзгедәге күчермәсе, сыны басып тора иде. Ирексездән, күзләрен челт-челт итеп, ачып-йомып алды. Янә ишек төбендәге затка күз салды. Буе озынрак, яшькә дә олырак булса, аны Сәетнең игезәге дип булыр иде. Аптырап китте.

Коралы-мазары күренми, усал нияте сизелми. «Хәзер ул сиңа маузерын кулына, хәнҗәрен авызына кабып, ишек төбенә килеп басар. Таптың унҗиденче ел диваналарын! Вильсур Садыйковның киллеры дисәң? Яраннарына тантаналы рәвештә: «Сакмановның баш сөяге өчен

әҗере түләнгән, үзен үлекләр аймагында санасын»,— дип хәбәр салган, ди. Шул гозерен үтәве микән? Тәкъдирем эзләп килгәнме? Әллә «Умырзая»да һөҗүм ясаган егет исән калып, ул киллерен җибәргәнме? Миңа шул чаклы охшаган әрвахны кайлардан чокып чыгарганнардыр? Гаҗәп».

Мәгәр дошмани көчләр Сәетне олтанлы итек кебек арзанлы һәм тупас алым белән «алырга» хыяллансалар, бик нык ялгышалар. Шунда ук аңына да килде: «туктале абзый, вакытны сузма, хәрәкәттә — бәрәкәт, әгәренки, ул күтәреп менгән йөкләрдә динамит, бомба, мина ише шартлаткыч булып, ул аларны шунда ташлап, чыгып сызса? Син көтек булып көтеп утырасың да, тәкатең корып, үз үлемен үзе эзләп, сунарчы пәкесе белән шаярган мәхлук кәҗәдәй чемоданга килеп орынасың һәм ишегең, түшәмең ниең белән фәрештәләр янына очасың».

Бу уйлардан аңа эсселе-суыклы булып китте. Ул җәһәт кенә машинасына шалтыратты.

— Замир, синме?

— Әйе, Сәет Яруллович.

— Егетләр синең беләнме?

— Бирәдә утыралар. «Хуҗаның йоклап киткәнен көтик инде»,— диләр.

Йортүчесенең, әбисендә коймак ашап утыргандай, җәелеп сөйләшергә исәбе бар иде (чыбыксыз телефон Сарман егетенең күңеленә бик хуш килде), Сәет аны бүлдерде.

— Машинаңны бу якка бора башла! Тиз килеп җитегез, минем ишек төбендәниндидер тип пәйда булды. Кулында чемоданы, тагын нәрсәседер бар... Шартлаткыч булуы ихтимал. Шыпырт кына янына менеп, сугып егып, кулын бәйләсеннәр, тик үтерә күрмәсеннәр... Әүвәл кем икәнен ачыклыйк. Сиренаңны кабыз!

Сәет янә күзчәдән коридорны «сукалый» башлады. Йөрәге жу итеп китте. Фикере раска килә бугай. Әйберләрен ишеккә үк терәп куйган, үзе күренми. «Игелек»нең генераль директоры олы дәрәҗәсе, абруе турында онытып, читкә сикереп, почмакка посып, шартлау көтте. Ярый әле бу хурлыклы халәтен кеше-мазар күрми. Соң, Зөлфиясе исән булып, бүлмәдә утырса, әтәчләнеп, күптәннән ишекне каерып ачкан булыр иде. Адәм баласына куркаклык, ялгызлык, билгесезлек белән бергә иңә икән.

Ошбу адәм читкәрәк китеп тәмәке генә пыскыткан бугай. Бу юлы тәкате корып, ишеккә катырак какты.

— Сезгә кем кирәк? — диде Сәет, вакытны сузу, үзен тынычландыру нияте белән. Ни өчендер тавышын үзгәрткән булды.

— Өйдә кеше барын сизенгән идем. Әйттем ич инде. Сакмаров... Сәет Яруллович кирәк миңа.

Вак-төяк ялганның ир дип аталуга дәгъва иткән кешене бизәмәвен, куянлыкка тартым сыйфат булуын таныган тәкгъдирдә дә, Сәет хәрәмләшергә булды. Үзен, «башка хутым юк»,— дип, акларга тырышты.

— Ул эштә әле,— диде ул.

— Кайчан кайтыр икән? Соң бит инде.

— Үзе белә торгандыр?

— Миңа бик кирәк иде.

Агач белән эчләнгән тимер ишек аша начар ишетелсә дә, сүзләрнең мәгънәсен аңлап була. Тавыш хикмәтле нәрсә. Ул пуля тишә, бомба вата алмаган тимер ишекләрне, таш диварларны кешегә дә санамый, үтә дә керә. Бәгырьгә, җанга иң үткен, ике яклы Дәмәшк хәнҗәре үтеп керә алмый; йә явызлыкка, мәкергә, йә җылылыкка төренгән сүз исә адәм баласы күңеленең иң яшертен почмакларына барып ирешә.

— Сезне кем дип белик инде? Хуҗа кайтса, кем килгән иде дип әйтәсе?

— Мин аның туганы булам. Абыйсының малае.

— Туганнарының күбесен күреп, ишетеп беләм, сезне хәтерләмим,— диде Сәет ялганын дәвам итеп. Кешенең үзе аңлап житкермәгән сәерлекләре бинһая шул.

Килмешәк бутала-сөрлегә аңлатуын дәвам итте.

— Мин Сәет Ярулловичның бик якын туганы. Ну ул бу хакта үзе белми... Аның мине күргәне юк. Безгә әүвәл аңлашырга кирәк.

— Кызык хәл, якын туганы булсын ди, ул аны белмәсен дә, ди. Чистый әкият,— дип өченче затта сөйләнүен дәвам итте фатир хуҗасы.

Килмешәк беркадәр икеләнеп торды. Күрмәгән-белмәгән кешегә аңлатып, вакыт уздырып торыргамы, юкмы? Кötәсе була барыбер, аның башка китәр урыны, таяныр кешесе юк. Хәзер кунакханәсендә дә яшәп булмый.

— Мин аның Магаданда туып-үскән туганы. Әтисенең абыйсының... энесенең...

Шунда тавыш киселде. Егетнең өстенә кемдер, нәрсәдер сикерде, идәнгә кысты, кулын артына каерып бәйләде. Яраннары чемодан белән сумканы баскычтан аска йөгерттеләр.

Сәет ишекне ачты. «Туганын» күн куртка якасыннан сөйрәп өйгә алып керделәр. Кесәләрен тикшерделәр. Бумажнигыннан күпмедер акча, паспорты чыкты. Ипи кисә торган кечтеки пәкесеннән башка коралы табылмады.

Сәет документка күз салды. Чепи күзле кешедәй, керфекләрен челт-челт ачты, япты.

— Сакмаров Рафаэль Ахсанович, родился в Магадане, татарин...— дип, ни өчендер шыр ярып кычкырып укыды.

Берни аңламыйча, калын келәмдә аунап яткан егеткә күз салды. Үзенә тышкы охшашлыкка игътибар итте янәдән.

— Авызыннан чүпрәкне алыгыз, кулларын чишегез.

Ир-зат аягына торып басты. Читлеккә утыртылган кыргый җанвар мәсле, үзен чолгап алган әзмәвердәй егетләргә күз салды, кулларын уды, янтавын, кулбашын, аркасын капшады.

— Йодрыклары таза егетләрнең.— Паспортын өйрәнеп торган Сәеткә күзләрен текәде. Үзара охшашлыктан, ул да югалып калды бугай.

— Сез... сез... Сәет абый буласызмы? Кайчан кайтып кердегез соң әле! Минем белән кем сөйләште ишек аша?

Тынлыкны бозучы булмады. Янында басып торган нукәрләрне ходай тәгалә сөйләшер, аңлашыр, аралашыр, зиһенләшер өченнән бигрәк, кыйнау, дөмбәсләү, үтерү өчен махсус яраткан, бугай. Үзгә калып, башка мантыйк кешеләре алар.

Шул арада Замир белән Гөмбә кушаматлы газие кунакның әйберләрен күтәреп керделәр.

— Тикшердек,— дигән хәбәр төшерде Замир.— Куркыныч әйбер юк.

Шунда ук башы-күзе белән ымлап, Сәетне икенче бүлмәгә алып чыкты, калын имән ишекне иплап япканнан соң, кесәсеннән пычрак алама чүпрәккә төргән, киң учка сыярлык әйбер чыгарып, Сәеткә тоттырды.

— Ярчекме әллә? Хатын-кыз пистолетымы?

— Алтын, Сәет Яруллович,— диде Замир. Гади итеп әйтергә тырышса да, тавышын тантаналы төсмердән азат итә алмады.

— Алтын кисәге. Слиток диләрме әле? Магаданнан килүче хактыр бу кешенең.

Сәет йөртүчесенең сөйләнүен тыңламыйча диярлек, төргәкне чишеп җибәрде. Кимендә берничә дистә граммлы саф алтын җәйрәп ята иде. Чынлыгына ышану өчен зәркән булуның кирәге юк. Мондый зур коелманы аның Мәскәүнең алтын фондында күргәне, табигать могҗизасына сокланып, тәэсирләнеп кайтканы бар иде. Алтын ялт-йолт килеп, тирәюньне ямьләндереп, нурландырып тора. Бүлмә эче алсуланып, яктырып киткәндәй булды.

— Тегеләр күрдеме?— диде Сәет, олы якка күрсәтеп.

— Гөмбә генә... Дөресе, ул тапты. Без бит чемоданны, сумканы читкә, шактый еракка алып китеп ачтык. Сез бомба дигәч...

— Ишкәнсез! Әгәренки, анда чын-чынлап динамит, граната мазар булса. Һавага очкан булсагыз!

— Соң монда басып тора алмаган булыр идек,— дип, үзендә шаяртуга көч тапты Замир, алтын тешләрен ялтыратып.— Әйберләрен актарганда, озын бармаклы Гөмбә бу нәрсәгә төртелде. Носкилары белән бергә төреп, җеп белән чорнап куйган. Сүтеп карасак, эчендә менә шул зәхмәт ята.

Чит-ят кешегә күрсәтергә ярамый торган, оят шөгыль белән тотылган баладай, гафу үтенүле тавыш белән дәвам итте: «Алтын эзләвебез түгел иде, Сәет Яруллович. Сез әйткән берәр шарт-шортлы нәстәкәй булмасын дип капшануыбыз иде. Сары шайтанга юлыктык. Гөмбәнең кулыннан тартып алып, кесәгә тыктым».

— Үзегездә генә калдырасы булган, сезнең гомергә җитәр иде,— диде Сәет, йөртүчесен юри ирештереп.

— Что сез?...

Сарман егете эченә имән күмере салынган самавырдай кайнап чыкты. Кулларын, пычрактан арындыргандай, бер-берсенә ышкып, селтәп алды: «Минем ике кыз үстерәсем бар, Сәет Яруллович».

— Үзем дә шул хакта әйтәм. Кызларыңа әзер бирнә булыр, кияүләре дә тизрәк табылыр иде.

Замир һаман да хуҗасының кызык табып, шаяртуын аңламыйча, дөресе, кабул итмичә: «Юк инде, газиз балаларыма явызлык теләрлек дивана түгел әле мин. Алтынга табынып бәхеткә юлыккан кеше турында укыганым да, ишеткәнем дә юк әлегә. Хәзинә таптым — чүпкә аттым, алтын таптым — бакырга саттым, дигәнне ишеткәнем бар».

Уйланып торгандай итте дә, нәтиҗәсен ясап куйды:

— Шакалдан калганны арслан ашамас, ди торганые минем әткәй.

Сәет Замирның аек фикер йөртүенә шаклар катып торды. «Тормышчан фикерле. Үзенә тиешлесен каерып ала, артыгына кызыкмый. Аның өчен баранка әйләндерү бик аз шул инде. Фирмадан бөтенләй киткәнче, башка, җитдирәк эшкә күчерергә кирәк булыр. Бу хакта үзе дә сүз каткан иде бермәлне.

Йөртүчесенең сүзләренә ул соңрак кат-кат әйләнеп кайтачак әле. «Чыннан да, кесәгә очраклы килеп кергән, җиңел юл белән табылган алтын кешегә бәхет өсти аламы икән? Бәхет нәрсә ул?» кебек, әлегә чаклы бер акыл иясе дә тәгаен җавабын таба алмаган өнсез сорауга килеп чыгуга да ерак калмас. Джек Лондонның алтын эзләүчеләре рәхәт, тыныч, хәсрәтсез яшәеш ярларын таба алганмы? Баеп, күрше абзый әйтмешли, дуфкумга тилереп, типтереп алучылары булган. Соңрак аларга барыбер иманаңы, шатлыклы мизгелләр өчен бурычны түлисе булган. Үзен, якыннарын үтергәннәр, һич югында кемнеңдер каргышы балаларына төшкән. Хикмәт алтында гына түгел. Зөһрә йолдызы астында туган, балда-майда йөзгән бәхетлеләрне дә тормыш кызганып тормый, гел сыный, тикшерә. Юкка гына язмышны «үги ана», димиләр.

Дөньяда әле бер күрәзәче чегән, алдан күрүче дә аңлата алмый торган хәлләр еш була. Әле кичә генә барысы да ал да гөл, җырлап баргандай күренә, ә бүген бура ишелә дә төшә. Сипләнмәгән, балта тимәгән әрдәнә диярсең».

Алтын коелмасы аңа инде беренче күргәндәге төсле ләззәтне бирми иде, ул аны шул ук чүпрәккә төреп, комод тартмасына куйды, егетләре янына чыкты.

Балталарын суга төшергән осталардай, алар злеккечә сүзсез басыпутырып торалар. Чакырусыз килгән кунак һаман угалана, тиздән күгәреп чыгачак урыннарын капшый. Яхшы эләктергәннәр Сәетнең «игезәге»нә.

— Ярый, егетләр, сезгә рәхмәт минем туганкайны алып кергән өчен. Кайтыгыз, ял итегез. «Бүген үк аны тулай торакка озатып булмас, үземдә кундырырмын», дигән фикергә килгән иде инде «Игелек» хуҗасы.

Тимер ишек Замирлар артыннан шапылдап ябылуга, паспортына ышансаң, Рафаэль атлы ир, авыртуларын онытып, мәче житезлеге белән чемоданына ташланды, дөньясын онытып, күлмәк, чалбар, эчке киемнәрен идәнгә, келәм өстенә ташлый башлады. Мунчада каз йолкый диярсең.

«Адидас» спорт киеменнән астан өскә карап торган Сәет тыныч кына сорап куйды: «Нәрсә, егетем, бераәр әйбереңне чәлдергәннәрме әллә?»

Мыскыллавын, мәсхәрәләвен яшереп тормый. Көчленеке замана.

Егет бик зур үкенечкә, югалтуга дучар булгандай, ыңгырашып куйды.

— Алтынымны, бар байлыгымны урлаганнар. Каһәр сукканнар. Бетте баш...

— Ниткән алтын ул тагын,— дигән булды Сәет илтифатсыз гына.

— Магаданнан алып килгән идем. Әтидән калган бердәнбер байлыгым, ышанычым, өметем шул иде.

Егет тукмалган тәненең авыртуларын, кара тапларын онытып, ишеккә ташланды. Сәет «мәхбүс»нең серле йозакны ачарга маташуына көлемсерәп карап торды да:

— Кая барырга җыенасың?— дигән икенче сорауны «элеп» куйды.

— Соң теге... бандит... тегеләрне туктатырга, алтынны алырга кирәк. Мин... бөтен байлыгым шул.

Сәет кунагын кызганды: мыскыллауны туктатырга карар кылып, күрше бүлмәдән төргәкне алып чыгып, егеткә тоттырды.

— Менә алтының. Чемоданнарыңны җыештыр да, олак минем өемнән!

Рафаэль Сәетне күрми, ишетми, ашыга-кабалана төргәкне сүтте, алтынын тугландыра башлады. Үзгәреш тапмыйча, авызын җыя алмыйча, сабый балаларча елмаеп куйды.

— Мин моны, Сәет абый, беләсегез килсә, сезгә бүләк итеп алып килдем.

— Мин шуңа мохтаж дип уйлыйсыңмы?

— Юк, сезнең бик бай, хәлле икәнегезне беләм. Буш кул белән килмәс өчен генә. Икебезгә дә җитәр,— диде чарасыздан.

— Ярый. Алтынны калдырып торыйк. Үзеңә дә кирәк булыр. Мине ничек таптың һәм кем син? Хәзер дөресен сөйләп бир.

Тәнендәге авырту-имгәнүләрне сизәрлек хәлгә килгән ир сыктанып куйды.

— Сезнең бу адресны авылдан таптым. Мин алдан шунда кереп чыккан идем. Белешмә бүлегендә бөтенләй башка адрес бирделәр. Анысын эзләп барган идем. Андый йорт бөтенләй юк икән.

— Под снос эләккәндер,— диде Сәет, бер дә исе китмичә.— Ярый инде алайса, чишен, юын, хәзер чәйләп алырбыз.

Җаен яуган кар төсле башына килеп төшкән туганы аңарда кызыксыну хисе уятты. Җан тартмаса, кан тарта диләрме әле.

Шактый нәрсәне ачыклагач, сораштыргач, энекәшен табын янына утыртты; бәллүр чәркәләргә «Ак ләкләк» коньягы коя башлаган иде, Рафаэль аракы сорап алды.

— Әгәр булса? Без Магаданда спирт белән ак калай башлыларга өйрәнгән инде.

Каклаган ит, балык, сыр, май кебек дудәкләр ризыгы белән тамакны туйдыргач, Сәет егетнең әтисе, Ярулла абзыйның энесе — Әхсән абыйсы, гомумән, аларның хәләти мәҗмугасы, Рафаэльның үзе турында күбрәк беләсе килүен әйтте. Исенә-ятенә төште: әтисе исән чакта Бөек Ватан сугышында югалып, соңыннан табылган, шактый аянычлы, фаҗигале язмышлы энесе хакында бәян иткән иде. Акыл казанында вак-төяк җентекләмәләре сакланмаган, вакыт шәрифләре байтагын коеп калдырган. Истә калганнары янына Рафаэль авызыннан төшкәннәрне кушкач, шундыйрак хикмәт туды.

Әхсән Ярулладан берничә яшькә кечерәк булса да, сугышның өченче көнендә үк армиягә алына. Генерал Власов армиясенә эләгә. Үз теләгеннән башка инде, әлбәттә. Сугыш тәртәсен ул гына башка якка бора алмый. Хезмәт иткән взводы, өстән иңгән әмерне үтәп, немецлар ягына чыга. Безнекеләргә каршы бераз сугышканнан соң, отрядның исән-имин калган егетләре белән бергә, белорус партизаннарына кушыла. Янәдән, туган җирен яклап, юлбасарларга каршы батырларча көрәшә, орден-медальләргә лаек була. Үз теләк-омтылышларыннан тормаса да, шундый болгавыр хәлгә эләккән адәмнәр, үзләрен аклау, намусларын кара таплардан тазарту өчен, үзләрен аямыйча орышканнар. Күбесе үлем эзләгән. Батырны әҗәл дә кызгана шул еш кына.

Кырык бишенче елның июнендә туган авылына кайтып егылган Әхсәнне бер атнадан эзләп табып, алып та китәләр. Өч ел үткәннән соң гына беренче хәбәре килә: аны халык дошманы, сатлык җан, җасус дип тапканнар һәм Магадан төрмәсенә озатканнар, шунда, шахтада эшли икән. «Халыклар атасы» Сталин үлгәннән соң, азат ителә. Туган якларына ач-ялангач, хәерче-галах булып кайтып төшәсе килми (Сакмаровларның үз горурлыгы үзләренә җиткән), шахтада урнашып кала... Дәүләт җитәкчелегендә утырган бер акыллы башы арзанлы эш кулларын саклау хәстәрен күрә. «Хәстәр» дигәне шул: ирләргә хатын-кыз кирәк. Магаданда ул халык алтыннан да кыйммәтрәк бәядә йөри. Бу «малны» материктан китерү ихтыяҗы туа. «Вербовка» дип аталган хикмәт башлана. Күчеп йөрүгә маһир, чит-ят җирләргә, байлыкка кызыгучан, мавыгучан, алданучан һәм бәхет эзләргә яратучан татар хатын-кызлары бу җимгә алдана... Ирексезләп, көчләп, разнарядка белән озатулары да булгандыр. Үзәктән команда килә, кая барасың, үтәргә туры килә. Мөнирә, Сания, Нәфисә, Асылъяр, Карлыгачлар Алеша, Илья, Андрейларны, иң бәхетле очракта, Рафаэль, Ренат, Робертларны тудырырга дымлы, салкын якларга озатылалар. Арада Балык Бистәсе ягы кызы Сакинә дә була. Ул «сатлык җан» Әхсәнгә кияүгә чыга һәм өч малай бүләк итә.

Әтисенең тагын бер сөйләге Сәетнең күңел почмагына кырмавык кебек ябышып калган. Егетне тыңлаганда исенә төште. Әхсән бер тапкыр авылга да кайтып киткән. Өйләнгәнче булган анысы.

Гайрәтле узаманнарча торткан үзен шахтер. Авыл кибетендәге барлык азык-төлекне сатып алып, халыкка өләшкән: малайларга кәнфит, прәнник, хәлвә тараткан, ир-атны инде, аңлашыла ки, аракы белән сыйлаган. Ул чорда бик арзан бәядә, барча авыл кибетләренә килеп җиткән кара уылдыкны Әхсән мичкәсе белән урамга, авыл советы белән китапханә арасына чыгартып куя. Бер якта закуска, икенче якта әрдәнә итеп өеп куелган аракы. Уртада олы калын стакан белән әсир-шахтер басып тора. Бавыры, бөере «черемәгән», йөрәге сызламаган ир-ат халкы дүрт тәүлек буенча эшкә чыкмыйча, Әхсән Зимагурны мактап, аракы чөмерә. Трактор, машиналар кабызылмый, сыер саву җайланмалары туктаган. Олы дөнья белән ара өзелгән. Элемтә хуҗасы көне буена хромка тарта.

Авыл өстендә бер үк җырулар эленеп тора. Барысы да, табигый ки, сыйлаучы турында, аның хөрмәтенә:

Аккош баласы коена,
Күлләрдә су бетмәсә;
Исән булсак бер кайтырбыз
Илдә ризык бетмәсә.

Зимагурның чалбары,
Буй-буй аның аллары:
Кайда эшләсә, шунда кала
Зимагурның маллары.

Шахтер егет эшкә бара,
Җирдә кала эзләре:
Җир астында җирсегәнгә
Сары аның йөзләре.

Тәмам аптырап, башка чарасы калмаган колхоз рәисе — Әхсәннең жизнәсе — үзе машинага утырып (аны йөртүче дә мәйданда — исерек), каен энесен станцыга илтеп, билет алышып, вагонга кертеп куя: поезд кузгалып киткәнне көтеп тора.

Әхсән Сакмаров туган авылына икенче тапкыр, өйләнгәч, хатыны һәм бер баласы белән кайтып төшә. Яхшылык адәм күңелендә озакка саклана. Шахтер авылдашлары кайту хәбәре, сарафан радиосы аша ирләр колагына барып ирешкәч, һәммәсе аның белән исәнләшергә (дөресе, сыйлану хыялы илә), күрешергә дигән булып, Ярулла йортына агыла. Кире киткәндә берәүнең дә күзе ялтырамый; авызлары чалшайган, сөмсерләре коелган. Ир икәнен оныткан ир ирексез булыр, диләр шул: башлы-күзле булган кече Сакмаровның акча капчыгы Сакинә карамагына күчкән, Әхсән ике куллап күрешүдән, алтын тешләрен елтыратудан уза алмаган. Берничә көн генә торган авылда. Колхоз рәисе озатырга машинасын түгел, атын да бирмәгән бу трит. Станцыга малаен муенына атландырып, чемоданнарын кулына тотып, тәпи-тәпи китеп барган «аккош баласы». Килennең чамасыз карунлыгын, явыз усаллыгын охшатмаган (холкы шундый булмаса, ир эзләп Магаданга житмәс иде) Ярулла да сугышта алган ярасының ялкынсынуын сылтау итеп, ярты юлдан кире борылып кайткан. Кибет тирәсендә чуалган ирләрне җыеп: «Минем энекәшнең «якты истәлегенә» эчик әле»,— дип, булган акчасын калдырып кайта. Шуның белән туганнар арасында бәйләнеш өзелә.

Рафаэльнең сөйләвенә караганда, соңрак әнисе гаиләсен туган авылына алып кайткан. Бөтенләйгә, шунда яшәп калу нияте белән. Без туфрак тартуы, җирсүлек, саба җиленең шифасы, туган якта үскән ипи тәме, адәм баласы кайда гына яшәп, ничек кенә рәхәт-сихәт тормыш кичерсә дә, шул төшенчәләр чакыруына түзә алмыйча, туып үскән ягына тартыла, дибез. Әйе, Әхсән Сакмаров та гаиләсе белән татар иленә кайта. Үз авылына юл тотмаса да, үзенә хатын бүләк иткән төбәккә килеп бөялә. Шул ук Татарстан җире. Барыбер изге туфрак... Шалкан бәясенә генә йорт сатып алалар. Терлек, мал-туар үрчетә башлыйлар. Ике малае күрше авылга, урыс мәктәбенә укырга йөри. Рафаэль әле итәктә.

Авылда туып-үскән кеше булса да, Әхсән колхоз тормышына җайлаша алмый, һаман Магаданын сагына һәм, нәкъ бер елга түзгәч, өеннән чыгып югала. Квартираларын сатыпмы, тапшырыпмы киткән булалар. «Халык дошманы» вакытында, мәхбүслек чорында яшәгән, хәзер бушап калган баракны эзләп табып, бер бүлмәне сипләп, шунда көн итә башлый. Чит-ят төбәкләрдә татарыңа авыр, пычрак эш һәрвакыт табыла.

Сакинә үзе генә яшәп карый. Озакка түзә алмый. Бер яктан, ир канаты астында яшәргә өйрәнгән кешегә тормыш алып баруы кыен булса, икенчедән, Магаданда туып, урыс мохитында тәрбия алган малайлары шул якка сөйри. «Татарин» буласылары килми.

Рафаэль әти-әнисен, олы абыйсы Дамирны да дымлы, томанлы якта калдырган икән. Дамир балыкчылар әртилендә эшләгән, соңгы сыену урынын диңгездә тапкан. Ничек, кайчан, нинди шартларда үлгәнен дә ачыклый алмаганнар. Ренат абыйсы корабльдә пешекче хезмәтендә икән. Елына ике тапкыр гына җиргә аяк баса, хатыны ике баласын багып ята, ди.

Егет ни өчендер үзе турында белешмә бирергә ашыкмый. Яшерәме, оялямы...

— Үзең алименттан качып, Казан тарафларына килдеңме? — дип, шактый кискен сорап куйды, хатирәләр, истәлекләр дәрьясына чумып утырган Сакманов.

— Мөмкин булса, минем өчен иң кыены хакында соңрак... Әмма хикмәт анда гына түгел,— дип, дөресен ярып салды магаданлы.— Әтиәни туып үскән, халкыбыз яшәгән якта урнашып калып булмасмы дип кайттым.

— Киләчәккә планнарың ниндирәк булыр инде?

Төмсе тавыш белән булса да, кунак гаҗәеп аек фикер әйтте.

— Бөтен ышаныч сездә, абый. Мине читкә тибәрмәгез инде? Ни әйтсәң дә, мин сезнең племянник.

Адәм баласы үзенә кирәккәндә, туганлыгын да искә төшерә, якынлыгын да китереп кыстыра белә.

Сәет читтә, бигрәк тә сөргендә туган балаларга, ягъни икенче, өченче буын «мөһаҗирләргә» артык өмет багламый. Татар халкының киләчәген аларга ышанып тапшырып булмый, дигән иманда тора.

Сакманов читтә дөнья көтүче татарларның, чит-ят гаилә эчендә яшәгән ятим бала хәлендә калган кан кардәшләренең хәлен аңласа да, күп нәрсә өчен кичерә алмый. Аларга галәкәсендә кызгану белән мескенлекләре өчен гафу итә алмау хисләре тартыша күңелендә.

Читтә гомер итүче милләттәшләре белән бәрелешүе күңелендә озакка калды. Якын танышы Сәетне саунага чакырды. «Татар диаспорасының күренекле вәкилләре, бик көчле, кызыклы егетләр була, син бәхәс яратасың, кил»,— дигәч, риза булган иде. Мәскәүле Нәриман белән Кемерово өлкәсеннән килгән, кырыклар тирәсендә генә булса да ап-ак чәчле Радик исемле кеше иде «чит ил» вәкилләре дигәннәре. Икесе дә яшәгән җирләрендә татар иҗтимагый тормышында үзәк фигуралар, милләтнең киләчәге өчен җан атып яшәүче затлар икән. Мәгәр Татарстанның бәйсезлеге мәсьәләсендә кунакларның фикер-ниятләре үзгә-үзгә булып чыкты. Мәскәү татары үз ягын каера:

— Сез үз җаегызны көйлисез, үзегезгә мөстәкыйльлек даулыйсыз, безнең турыда онытасыз. Сезгә үч итеп, безне китереп кысулары бар.

— Киресенчә, башкалада үзегез турында гына кайгыртып, сукыр ябалаклар кебек, качып-посып утырасыз. Мәскәү татарлары чаң сугып, безне яклап тавыш күтәрсә, Татарстанга суверенитет юлына чыгарга җиңелрәк булыр иде,— диде Сәет кызмаска тырышып.

— Безгә Ельцин, аның политикасы ошый,— дип, Рәсәй хөкүмәтен якларга тотынды Нәриман иптәш.

— Крылов һәркайсы йөкне үз ягына тарткан кыслалар, балыклар турындагы мәсәлен татарны күз уңында тотып язгандыр әле,— дип, бик урынлы өстәде, шулай ук мунчага чакырылган тарихчы-профессор.

Нәтиҗәсез бәхәскә Кемерево татары килеп кушылды.

— Безнең якта татарлар боевой.

— Нәрсәдә күренә инде бу?—дип кызыксынды Сәет, салкын сулы тазны өстенә каплап.

— Нәрсәдәме? Шахтерларның забастовкасын оештыруда, аларны урамга алып чыгуда татарлар төп йөкне үз өсләренә ала.

— Матбугатта бер дә күренми сезнең исем-фамилияләр,— дип, Сакманов икенче буш бәхәскә керешеп китте.

— Без үзебезне пропагандаламыйбыз. Азрак күренергә тырышабыз. Фамилиябезне дә бик афишировать итмибез.

— Мәчене котыртасыз да, тычкан төсле, ярыкка кереп качасыз түгелме? Моннан татар халкына ни файда?—дип Сәет икенче милләттәше белән дә талашып китте. Ул кыйбланың анык, төгәл булуын ярата.

— Сез андагы җитәкчеләр өчен ашлама гына. Җитди кабул итмиләр. Татарларны барыбер монголлар явыннан төшеп калган килмешәкләр дип санийлар,— дип, фикерен дәвам итте Сакманов.

Чәченә кырау төшкән агай-эненең сүзләре шахтер егетнең кытыгына тиде, авырткан сөяленә эләкте бугай. Бөеренә кантар төшкән кешедәй ярсып, үпкәләп, себерке күтәреп, эссе якка чабынырга кереп китте.

Әүвәл чаж-чыж иткән тавышлар килде. Ташларны кыздырды бугай егет. Шуннан китте Кемерово татары кызып: елау, көлү, ыңгырашу, шыңшу авазлары чыгарып үзен «иркәли» башлады. Йөрәге таза икән. Салкынча бүлмәдә утыручыларны ирләрчә көнләштереп, озак кыйнады үзен мөстәкыйльлек өчен көрәшче егет. Алабай тавышлары чыгарып кычкыра башлагач, әллә шунда кызганып, әллә кызыксынып Сәет

ишекне ачып башын тыкты. Аксыл томан эченнән ләүкәне эзләп тапты. Радик анда юк иде. «Батыр» шахтерыбыз бусага янына, идәнгә, пар килеп җитмәстәй төшкә яткан да, котырынып чабыну имитациясен шуннан оештырып ята икән. Кырык бишкә җитеп, Сәетнең мондый икейөзлелекне, монафикълыкны күргәне юк иде. Күңелсез манзарадан тизрәк котыласы килеп, ашыга-ашыга ишекне япты да сөлгесен алып, кабалана-кабалана сөртенә башлады.

Аерылышулары җылылыктан шактый ерак булды. Кол хадим хәлләренә риза булып яшәгән милләттәшләрнең берсен аю, икенчесен бүре ашаячагы якты көн кебек ачык иде. Кеше кешесе булганчы — этнең көчеге бул. Үзаңы уянды: «Постой, синең ни хакың бар аларга бәя бирергә, рәнҗетергә, һәркемнең үз язмышы. Халкыңның бәхетсезлегендә аның аерым вәкилләренең гаебе зурмы? Ми җыерчыкларыңны эшләтеп ал!»

Ничек кенә булмасын, Магаданда туып-үскән мөһаҗир энесеннән миллипәрвәр чыгуга ул ышанмый. Алар телләрен, диннәрен югалткан, бөтенләй башка мохиттә тәрбия алган халык. Күбесендә иман нуры калмаган. Нахакка сөрелгән әтиләре өчен үч алу, хәтер калу, гарьләнү, рәнҗү, нөктә генә сакланган яралы күңелләрендә. Беришесе матди тарафтан аякка басып, шул якта көнен күрә, башка милләтнең санын арттыра, бик сирәге, демократия җилләре биргән форсаттан файдаланып, ата-ана җиренә кайтып егылу ягын карый. Җирбитләре исә, балалары өчен түләүдән, милициядән, кулга алынудан, эшсез калудан куркып, ата-бабалары илендә сыену урыны эзли.

Яңа табылган, «алтынлы племяше» дә шундыйларның берсе булуында Сәетнең бер мыскал шиге дә юк.

Рафаэльның сөйләвен тыңлап утырганда, «Игелек» сәрвәре ике арадагы тышкы тәңгәллеккә шаклар катып торды. Беренче карашка, белмәгән кешеләр өчен ике тамчы су инде туганнан-туганнар. Дөрес, тәфсилле, бәйләнә башласаң, аерманы, үзгәлекне шәйләве әлләни кыен түгел. Буйга Сәеттән кайтышрак булуы өстенә, магаданлының битен борын куышы янына оялаган шактый зур миң бизи. Кечкенә кара күзләре борчулы, йөгерек. Мәгәр күп яклары койган да куйган. Бер үк җептән тукылганнар.

Шул мәлдә Ярулла агай улының күңеленә шук фикер төште: «Егетне берәүгә дә аңлашылмый торган йомышларны үтәү буенча ярдәмчем итеп алам. Вильсур әфәнденең киллер-этләре башларын катырсын әле икебезне бутап. Әнә бит залим Сталин үзе трибунага сирәк чыга торган булган, аның урынына аңа тач охшаган кешене, двойнигын үрә катырып бастыра торган булганнар. Горбачевның да маңгае тамгалы берничә игезәк пары булган, диләр. Ленин, Брежнев кебек олы түрәләрнең нәкъ үзләредәй күчермә күләгәләре турында да ишеткәне, укыганы бар иде. Әлбәттә, Сакманов мондый алмашка мохтаҗ түгел. Шулай да... Төпле, житди кеше булып чыкса, күз күрер, фатиры да табылыр, машинасы да булыр».

Йортсыз-җирсез, пропискасыз, эшсез кеше өчен шуннан да олы сөенеч була аламы соң?

Рафаэль үзе дә уйсыз утырмый икән.

— Сез, абый, коммунизмда яшисез икән! — дигән хөсетсез нәтиҗәсе белән уртаклашырга булды.— Шәхси охранагыз да бар. Мондый җиһазларны кинода гына күргәнем бар иде.

— Син аны... коммунизмны дим, күргәнең бармы?

— Юк та... Ишеткәнем, укыганым бар. Магаданның хакимият җитәкчеләре шунда яшиләр, ди гади халык.

— Син инде алтын коелмаң белән коммунизмга Казанда чыгасы булдыңмы? Ир-егетнең байлыгы кесәдә түгел, йөрәктә икәнне беләсеңдер.

Егетнең йөзе агарынды, күзләре җайсыз уйнап алды.

— Бөтен өметем сездә, Сәет Яруллович. Әүвәл алтынның тарихын бәян итим әле. Әтиебез, үләре алдыннан, өчебезгә дә берәр кисәк алтын һәдия итте. Ул аларны күптәннән табып, яшереп тоткан булган.

— Миннән сезгә бердәнбер бүләк, истәлек, теләсәгез ничек тотыгыз,— диде.

Дамир абыем аны үзенчә аңлап, икенче көнне үк ломбардка салып, акчасын әрәм-шәрәм итеп, эчеп бетерде. Ренат бер өлешеннән теш куйдыртты, калганын югалтты. Мин генә саклап кала алдым. Аның белән күргән мәшәкатьләремне үзем генә беләм. Элек әнидән, абыйлардан яшерә-качыра аптырадым, аннан хатыннарымнан... Хәзер, сезгә бүләк итеп, котылыйм әле.

— Юк, егетем,— диде Сәет, җитди һәм катгый итеп,— миңа алтының кирәкми, кстати, үзең дә... Синең ифрат авыр тәрҗемәи һәм кәлҗемәи хәлеңә кереп кенә янымда калдырам, хезмәткә алам. Эшсезлек безгә дә килеп җитте. Без ул алтынны, син теләсәң, менә бу сейфның кечкенә киштәсенә бикләп куйыйк. Анда башка әйбер юк. Ачкычы үзеңдә булыр. Тешләрем коелгач, элек бабайлар шакмак шикәрне ваткан каргаборын белән, бер кисәген китеп бирерсең,— дип, тигез ак тешләрен күрсәтеп, тәмләп елмайды.

«Сиңа кәмит, безнең әткәй төсле Магаданга сөрелгән булсаң, хәзер мич авызы кебек буш яисә ясалма тешле авызыңны чәпелдәтеп утырыр идең»,— дип, рәнҗеп алды Әхсән абыйның төпчек оланы.

Сәет табылдык энесенә, тәфсилле итеп, иренмичә, аның булачак вазыйфаларын аңлатты. Эшкә билгеләргә ашыкмады.

«Яхшы ат дагасыз булмас, батыр ярасыз йөрмәс»,— дип, тынычландырды да, йөзендәге күм-күмгәкләре, тәнендәге күгәреп чыккан урыннары төзәлеп чыгарлык вакытка ял бирде. «Казан белән танышсын, үзен күрсәтсен». Буйдак кичләрнең берсендә, туганының «нечкәрәк» кылларын тартып карарга булды.

— Рафаэль, синең начар гадәтләрең бардыр инде, ансыз — дөнья сансыз. Мин адәм баласының ике җитешсезлеген яратмыйм.

Магаданлы чәнечкесен өстәлгә куйды. Кашларын җыерды.

— Урынны чылатканнарны һәм үзе кунган, яшәгән йорттан әйбер урлап чыгучыларны гафу итә алмыйм!

Егетнең битенә кан менде, миңенә чаклы кызарды. Тавышы киселде.

— Сез нәрсә? Магаданнан дигәч тә, анда зеклар, хайваннар гына яши, дип уйлыйсызмы?

Сикереп торды да, чемоданына барып ябышты.

— Гостиницага китәм. Мәсхәрә иттерергә килмәдем мин Казаныгызга.

— Урыныңа утыр,— диде Сәет, шаркылдап көлеп,— кызу канлы икәнсең. Яхшы да, начар да бу гадәтең. Дөнья хәлләре турында, терелгәч, иркенләп гәпләшербез.

## 4

Казан каласына Магадан тарафларыннан иңгән алтын кисәге шактый кешенең тынычлыгын алды. Белүебезчә, Сәет авызын ачса, үпкәсе күренеп торган ярлы-ябага энесеннән сары шайтанны бүләк итеп алудан баш тартты. Алтын тирәсендә ахырзаман ыгы-зыгысы шул көнне үк башланып киткән икән. Хәзер дә аның рәхәтен күреп, бәхет күгендә йөзгән кешене атавы кыен.

Рафаэль Сәет ишеген шакыган төнне Замир машинасы белән бикчура егетләрне өйләренә тарата, салонда озын сыйраклы, нечкә билле, киң җилкәле, хәйләкәр коңгырт күзле Гөмбә генә кала. Йөзе эчке хисләрен тышка чыгармаска өйрәтелгән. Каткан чәер диярсең. Яшь булуына карамастан, сирәкләнеп өлгергән, тырпаеп торган каты чәчләре маңгаена төшкән. Башы гөмбә эшләпәсе кебек, як-якка чыгып, муенын җил-яңгырдан «саклап» тора.

Аның чын исем-фамилиясен, тормыш мәҗмугасын берничә кеше генә белә. Шөреп урынына алган иде аны Сакманов. Казан астындагы калавылда туып-үскән, пычак белән шаярганы өчен утырып чыккан. Гөмбә миһербансызлыгы, кансызлыгы өстенә бик үҗәт булуы һәм малга хирыслыгы белән аерылып тора. Җанын бирер, тәнкәсеннән чукынмыйча аерылмас, диләр аның турында. Курыкканын сиздермәскә тырышса да, ул имансыздан хәтта Замир да шөлли иде.

— Ярый, килеп җиттек,— дип, машина хуҗасы Гөмбә әфәнде белән зыялы гына хушлашмакчы иде дә, урыс әйтмешли, не тут-то было.

— Ашыктырма, сүз бар, Замир дус!

— Тыңлыйм,— диде йөртүче, ләтчәнең ни, нәрсә турында барасын башына да китермичә: «Салып бирүне сорар инде».

— Теге алтынны дим, урталай бүлик.

— Нинди алтынны?

— Әйдә, кәнтәйләнмә. Умыртка баганасын лом белән сындырган шикелле, тач урталайга бүләбез, берсе — сиңа, берсе — миңа... Мин сразы үз эшемне башлап җибәрәм. Ларек ачам, иң зур имиле хатыннарны сатып алам. Ну, үләнмим. Болай рәхәтрәк. Берәрсе миннән бала табарга уйласа, паспортны пычратмыйча гына риза булса, пожалысты... Абзагыз к вашим услугам. Үстерегез минем яхшы породалы малаемны, кызымны...

Чит ил фильмнарында гангстер-үтерүчеләрне уйнаган артистлар кебек, Гөмбә сүзләрен хиссез, тойгысыз, әмма өздереп, мәгънәләрен урынына куеп әйтә. Юк алтынны бүлешү чыннан да киноны хәтерләтә иде.

Аркасы чымырдап, чәнчешеп, каз тәне тимгелләре белән капланса да, Замир Гөмбәнең сүзләрен шаяруга боруга көч тапты үзендә.

— Алтын венгр алмасы түгел ул сиңа. Аны тигез итеп бүлеп булмый.

— Жребий салабыз. Китер монда, үзем кисәм. Алтын йомшак металл ул, минем төрмә хәнҗәренә түзә алмый,— дип, уртасыннан кан агу өчен тирән эз уелган, ике ягы да үткен пычагын чыгарып, һавада уйнатып алды. Чөйде — тотты.

Замир газ пистолетын якынрак куймаганына үкенеп алды. Бу адәми зат белән уйнарга ярамаганны аңлады ул.

— Син нәрсә, якташ, үз акылыңдамы? Нинди алтын булсын ди миндә?

— Чемоданнан тапкан. Теге тинтәкнең... Синдә калды. Кесәңә тыктың.

— Ә син шуны әйтәсеңме? Соң мин аны хуҗасына тапшырдым. Безнеке түгел ич. Ул аны бүләккә, генералга алып килгән.

Гөмбә күзләрен әйләндерде, пычагын Замирның муенына якынлаштырды:

— Тиешле һаваңны чыгар да, алтынны бир. Мин, дурак, әле синең белән бүлешмәкче, пайга алмакчы идем. Китер!

— Юк миндә бернинди алтын!

Иләмсез ямьсез авазлар чыгарып, Гөмбә көлеп җибәрде. Тозлапборычлап, туйганчы сүгенде, Замир ягына явыз итеп карап: «Син нәрсә, мине миңгерәү сарык дип беләсеңме? Андый кисәкне чыгарып бирергә! Бу әкиятне әбиеңә кайтып сөйлә. Ул бит целое состояние. Үзең генә баерга уйлыйсыңмы? Не выйдет. Все равно жить не дадим».

Гөмбә үзен кыздыра барып, пычагының очын Замирның киеренкелектән кабарынып чыккан муенындагы кан тамырына якынлаштырды. Кораллы катыйлны болай гына җиңеп булмаячак. Сугышу, үтерү аның төп һөнәре. Вакытны сузарга кирәк.

— Пычагыңны тегендәрәк ал әле, якташ. Ялгыш тиеп китүе бар. Ышанмасаң, хәзер кесәләрне актарам, миндә булса, беркая китмәс, әнә түгел,— дип, Замир мөмкин кадәр тынычрак булырга тырышып, пинжәк кесәләрен күрсәтте, уң як чалбар кесәсен актарып, кулъяулыгын ике арага ташлады. Кулын сул кесәсенә батырган булып, кечкенә мендәр астын-

дагы пистолетын кулына алды да, киеренке җәядән ычкынган ук тизлеге белән, машинадан атылып чыгып, көпшәне Гөмбәнең бүлтәеп торган чигәсенә текәде. Дошман пычагын Замирга ыргыта алмый калды. Сарман егетенең бәхете бар икән. Шул мәлдә алар яныннан узып барган машина ни өчендер тизлеген акрынайтып алды. Гөмбә ул якка күз салып, кыйммәтле мизгелне югалтты.

— Атам хәзер. Чык машинадан, хайван!

Кәсепләре, яшәү рәвешләре кеше канын агызу булган кабихлар башкаларның бу шөгыльне җиңел хәл кылуына ышанучан булалар икән. Үзенә юнәлгән кара көпшә уртасындагы үлем бушлыгыннан Гөмбә дә шөлләп калды. Ачуы котырынган, курыккан Замирның төймәгә басуында шикләнерлек түгел иде. Буйсынырга мәҗбүр булды. Башында үзен саклау хисе тудырган мәкер. Гөмбә, кабалануын яшерергә тырышып, ашыкмаган булып кына машинадан төште дә, ишекне ябып, җәһәт кенә аска чүмеште. Алдан яисә арттан Замир «пушкасы» белән килеп чыкса, хәнҗәр шул якка очарга әзер иде. Сакмановның йөртүчесе хәйләкәррәк булып чыкты. Чынында аңа Гөмбә кирәк түгел. Бер этне үтерсәң, аның урынына икесе килеп басачак. Йолдыз атылган тизлек белән Замир гәүдәсен утыргычка ташлады, уң як ишекне биккә сала-сала, эшләп торган машинасына газ бирде, тыңлаучан дусты чыжлап урыныннан кузгалып китте. Теге хыялый бәндә чак кына машина астына эләкмәде. Аларның шул көннән җан дошманнар булып китүе табигый иде. Гөмбәнең бер гөнаһсыз Замирны гафу итмәве көн кебек ачык иде.

Бу вакыйга ике кыз атасы, хисле Замир күңелендә авыр тәэсир калдырды. Төне буена йоклый алмыйча, урынында боргаланып, шабыр тиргә батып ятты. Хуҗасына сөйләү-сөйләмәү мәсьәләсендә шактый уйланды. Чирен яшергән иртә үлгән, дигән халык әйтемен исенә төшереп, Гөмбә белән булган шактый пычрак, күңелсез хәлне бәян итәргә булды. Үзенә шулчаклы изгелек эшләгән, солдаттан кайтып кына төшкән авыл малаен фатирлы, төшемле эшле шәһәр кешесенә әйләндергән шефына ул мәңге рәхмәтле, ихластан хезмәт итә. Бер сере дә юк аңардан. Паханның кәефе сихәтле чакта кызларына алган күлмәкләренә чаклы күрсәтә (аның да балалары йә оныклары булыр, кирәге чыгар).

Бүген дә Замир, кабул ителгән тәртип буенча, хуҗасының йорты янына сәгать тугызга килеп басты. Сәет Яруллович соңарып чыкты, гафу үтенгәндәй итеп: «Кунак егетем белән чәй янында бәхәсләшеп кителгән. Яхшы эләктергәннәр үзенә. Алар кулына эләкмәвең хәерлерәк»,— дип, үзе сүз башлап җибәрде.

Шунда ук бөтенләй башка дөньядан сорау элеп куйды.

— Кече кызыңның хәлләре ничек, Замир, теле ачыламы?

Ата кешегә хуҗаның игътибары кадерле. Авызы ерыла, тешләре елтырый.

— Минем әткәй, «бала ул кыяр кебек, акрын үсә, тиз бозыла»,— ди торган иде.— Үзенә кирәген лыкылдый.

Шул арада Сакманов телефонга ябышты, кемгәдер шалтырата башлады. Кызыл утка туктагач кына, Замир хуҗасының игътибарын алырга җөрьәт итте.

— Сәет Яруллович, сездән киткәч, күңелсез бер хәл булды әле.

— Нәрсә тагын? Егетләр салырга таптырып, машинадан төшми интектерделәрме?

— Юк ла, андый финтларга өйрәнгән инде. Ансыз — дөнья сансыз. Әшәкерәге булды. Чүт исән калдым.

— Син нәрсә сөйлисең? — дип Сакманов, трубканы урынына ташлап, йөртүчесе ягына борылды. Замир сөйләячәк вакыйганың канвасын хыялга бай инсан да күз алдына китерә алырлык түгел иде.

Егет авырлык белән төкереген йотты. Кичәге зәхмәт турында сөйләве дә кыен вә куркыныч, бер котылган тәмугка янәдән кергән шикелле иде.

— Егетләрне өйләренә тараттым. Хәтта аракы да сорамадылар. Кусаматов кына калды. Ул бит Караваево ягында тора. Хәнҗәрен чыгарып, минем бугазга китереп терәп, кичәге алтынны таптыра башлады.

— Нинди алтын ул тагын?

Үз фикер дәрьясында йөзгән Сәет Замирның сүз сөрешенә үтеп керә, ни, нәрсә турында әйтергә теләгәнен аңышмый бара икән һаман да.

— Кичә сезгә биргән алтынны. Көчкә котылып калдым. Магадан алтынын Гөмбә үземдә калдырган дип белгән. Давай, икегә бүлик, иначе үтерәм, ди.

— Вон нәрсә? — диде ифрат гаҗәпләнгән Сәет. — Аңа алтын кирәк булган...

Замир кичәге хәлләрне бәйнә-бәйнә хикәяләп биргәч, «Игелек» сәрвәре уйга калды. Йөртүчесенең шаянын-чынын бергә кушып: «Бу сары тимер кисәге берәүгә дә бәхет китермәячәк, аңардан тиз генә котылып та булмаячак», — кебек сүзләре инде аклана түгелме соң?

— Карале син аны, ыштыр битне, бәрәңге кәлҗемәсен. Аңа да җиңел кергән байлык кирәк булган. Кесәңне киңрәк ач, — дип, туган авылында откан сүзләр белән әрләп алды Гөмбәне.

Ул имансыздан барысын да көтәргә була. Кусаматов Романны, өч-ләтә хезмәт хакы түләп, Вильсурдан тартып алган иде. Бу адымы дөрес булмады. Гөмбә аша дошманының серләрен, яшертен очрашу урыннарын ачыклау нияте акланмады. Әллә Кусаматовка ышанмаганнар, тирәнгә кертмәгәннәр, әллә элеккеге патронының үч алу гадәтен белеп, ачылып китмиме, ул хәтлесен кистереп әйтүе кыен. Нәтиҗә күз алдында: Гөмбәдән он суы да юк, тоз суы да акмады. Тиз генә баеп алу мөмкинлеген ычкындырмаган, однако.

Кусаматов оятсыз, вөҗдансыз, сөмсез адәм булса да, курку белмәве, явызлыгы, теләсә нинди корал, бигрәк тә пычак белән эш итүдәге мәргәнлеге аркасында үз даирәсендә абруйлы санала. Дөрес, аңардан куркалар, димәк ки, хөрмәт итәләр. Чамасын белеп эчә, тартмый, әфиюн кебек башны диваналандыра торган матдәләр илә мавыкмый. «Гөмбәне үзеңә алып, Вильсурны азау тешсез калдырдың», — дип үстергәннәр иде Сакмановны ялагайлары. Чынында гөмбә агулы булып чыкты, файдасы чебенгә, зарары филгә тиңләшеп бара түгелме? Ә ихтималның арты киң, диләр... Котсыз еллардан калган гадәт буенча кеше оятсызлыгының чигенә җитте. Миһербанлылык кебек төшенчәләр югала, азгын усаллык, этлек, шәфкатьсез ерткычлык алга чыга. Хуҗаларының авызларына карап, «баш өсте», «ничек әйтәсез», дип торган дәрвишләр чоры үтеп бара шул. Һәркем үз ягына каера. Менә Гөмбә дә... Замир бу җәһәттән соңгы мамонтларны искә төшерә... Ул үзенчә намуслы: урламый, тиешлесен каерып, кирәген сорап, эшләп ала.

Шундый әхлакый-фәлсәфи уйлану-борчулардан соң, Сакманов Гөмбә белән ипләп кенә, ике як та канәгать-мәмнүн калырлык итеп хушлашырга булды. Бу адымны ясауның ихтыяҗы калмады. Кусаматов суга төшкән балта кебек юкка чыкты, офыктан гаип булды. Бераздан ошбу мәнсез бәндәнең янәдән Вильсур Садыковка хезмәткә әйләнеп кайтуы турында хәбәр иңде. Гөмбә элеккеге оясына буш кул белән кайтмаган булып чыкты. Гайбәтне муллдан тараткан. Шәһәрнең абруйлары, текәләре, «тәплә п» калдыклары Сакманов Сәеткә Магаданнан ат башы хәтле алтын коелмасының килеп төшүе турында хәбәр алалар. «Игелек» ширкәтенең дошманнары, көнче көндәшләре арта. Хәтта Ваһапов Нургалиненң дә йөзеннән көләчлек кача. Хәер, аның нөктәсе башка юнәлештән үсеп чыга. Ә Гөмбә белән янәдән очрашу дәкыйкаләре алдарак иде әле...

# 5

Нух пәйгамбәр заманыннан бирле кешечә ял иткәнебез юк. «Иң уңган хатынның да үлгәннән соң ике көнлек эше кала»,— ди торгание минем әни. Тәк. Иртәгә табигать кочагына чыгабыз.

— Шәп фикер,— дип, сикерештеләр янаралның куштаннары, ихластан елмаешып.

Кирәк-яракны алып, шашлыгын-машлыгын килештереп, Идел буена, Имәнлек, дип аталган, үзләренә электән таныш, фикерләренчә, тыныч урыннарның берсенә ике машина белән килеп туктадылар.

Көне ял өчен махсус сайланган диярсең. Көнбатыштан талгын гына җил исә, аста мул сулы, ышанычлы мәңгелек — табигать балаларының барчасына да тигез карый, берсен якын итеп, иркәләп, икенчесен ятимә күреп, читкә тибәрми торган Идел җәйрәп ята. «Сихәтемне татыгыз, саклап, кадеремне белеп тотсагыз, мәрхәмәтем һәммәгезгә җитәр»,— ди кебек кояшлы күге дә. Тик аның акылсыз, пырдымсыз оланнары гына чал тарих өчен болай да бер мизгел гомерләрен кыскарту җаен гына эзләп йөриләр. Озын-озак яшәү, күрәсең, бик мәшәкатьле, низагълы, үзеңне нәрсәдәндер мәхрүм итүне, игелекле, шәфкатьле булуны таләп итә торгандыр? Тук вә хәсрәтсез кунак тормышы кыска булса да рәхәтрәк, күңеллерәктер, бәлки? Җаваплылыгы азрак.

Сәфәрчеләр учак ягып җибәрделәр. Тукталырга урын эзләп йөргән арабалар өч «Т» хәрефле «Волга» белән өр-яңа «Мерседес» машиналарын, аннан да бигрәк, ут янында кайнашкан нечкә сыйраклы, юан муенлы, йомран башыдай бүлтәеп торган беләкле егетләрне күргәч, койрыкны сыртка салу ягын карыйлар: болар белән ял урының түгел, каберең янәшә булмасын. Шулай да бу хәятта адәм баласына барыбер тынычлык җиңел килми. Яннарына милиция УАЗигы килеп бөялде. Болары — һәр тарафта хуҗа. Алар тиз генә китмәячәк.

Машинадан бу сүзнең туры мәгънәсендәге тәлинкә битле, күсе койрыгы хәтле генә нечкә, чем-кара мыеклы, ике як иңен дүртәр йолдыз бизәгән милиция әфисәре сикереп төште. Бармак очларын ялт иттереп, фуражкасына тидереп алды.

— Капитан Рәхимҗанов. Кизү хезмәте. Биредә учак ягарга, машиналар куярга ярамый. Документларыгызны, булса, махсус рөхсәтегезне күрсәтегез!

Әле генә судан чыккан, кәефе әгъла, бодайны кибәктән аера белгән Сәет, хөкем оешмасы вәкиленең күзенә туры карап, җавап урынына үзе сорау бирергә булды:

— Нәрсә, иптәш капитан, төрмәдән сызган угрыларны эзлисезме? Ишеткән идем, стенаны астан казып, җиде бандит качкан дип. Без шуларга охшаганмы әллә?

Җаваплы түрәләргә бирелә торган машина нумерына юри игътибар итми, үзе белән шаяртып сөйләшүне дә кабул итми өченче көн генә капитан дәрәҗәсенә лаек булган Рәхимҗанов. Чәчләренә кырау төшкән, яшьләрчә төз гәүдәле абзыйның сөален җитдигә алмыйча, шундый ук кырыс тавыш илә бәйләнүен дәвам итә:

— Бу — саклаудагы зона. Мәҗлес ясап утыру, әйткәнемчә, утлар яндыру тыела.

Ярты яшьлеген Мангулстан белән милициягә биргән Сакманов бу оешмаларда эшләүче затларның тыңлауны яратуын, үзсүзлелеген, үҗәтлеген яхшы белгәнгә, бу очракта бәхәскә керүнең, Хуҗа Насретдин мәсле, үзең утырган ботакны кисеп төшерү кимәленә тиң икәнне тәгаен белгәнгә, сүз куертып торуны мәслихәт тапмады. Мәмләкәтнең югары оешмаларыннан бирелгән аклангыч кәгазьләре дә бар. Беләкләрен тырпайткан егетләре, рөхсәт бирсәң, капитанны суга ташларга да күп алмаслар (җавапны аларга бирәсе түгел).

Капитан белән ничегрәк тотасын үзе өчен ачыклап, Сакманов адидас спорт костюмен киеп, капитанның җиңенә йомшак кына кагылып, читкәрәк алып китте.

— Сез хаклы, гафу итегез. Учак тиктомалдан гына ягылмады, әлбәттә. Җаваплы кешедән яшерен-батырын түгел, бик олы кеше киләсе барые. Вакыйгасы да саллы.

Әйтергәме икән, әйтмәскәме икән дип, икеләнеп торгандай итте. Тынлыш билгеләренә урын калдырды.

— Полковник Салих Гаяровны беләсезме?

Исемне ишетүгә ирексездән капитанның аркасы турайды, үкчәләре якынайды.

— Беләм. Минем турыдан-туры начальнигем.

Исенә-ятенә килеп: — «Причем монда ул?» — дип өстәде.

— Сер итеп, ышанып кына әйтәм, мин үзем дә сезнең оешмадан капитан дәрәҗәсендә киттем, бүген аның хатынының туган көне. Венера апаңны беләсезме? Безне алданрак җибәрде. Әзерли торырга. Сәгать уникедә булабыз дигәние. Хәзер вакыт күпме әле?

— Уникенче ярты.

— Тиздән биредә булыр.

Хөкем оешмаларында эшләүчеләрнең яхшы гадәте бар. Начальство белән бәйле теләсә нинди хәбәрне шик-шөбһә астына алыш көферлек санала. Юк, өлкәннәр исеме белән шаяртуны башларына да китермиләр.

Иң олы серне чишкәннән соң, ике араларында ышаныч җебе сузылды. Капитанны Сәет, дусларча, дастархан янына чакырды. Тегесе йөртүчесен дәште. Бушлай тамак ялгап алу мөмкинлеген кулдан ычкындыру милиция уставында каралмаган.

— Сез инде иртә таңнан юлдадыр? Арып беткәнсездер? — дип, Сәет кеше хәленә кергәндәй кыланып, кулларына бирәр таяк кыздырылган ит, чәркәләр тоттырды. Рәхимҗанов, тәртип өчен читкә караган булды, ихтыярын авырлык белән сындырган рәвешен китереп, берне аударып куйды. Икенчесеннән баш тартты. «Смирнов» аракысын, әрмән коньягын, ике олы кисәк каклаган ит янына төреп, сары УАЗикның арткы утыргычына куйганны күрмәмешкә салышты яшь капитан.

Рәхимҗанов Сакманов белән иске танышлардай аерылышты. Телефоннарын язып алыштылар.

Милициядә таныш-белешләре күп иде Сәетнең. Мәгәр күбесе «тиражга» чыгып бару сәбәпле, яшьрәк буыннан «түбә» табу нияте болай да көн тәртибендә тора иде.

Ходай яраткан колына чыгарып куяр юлына дип, тикмәгә генә әйтмәгәннәрдер. Җитди сәбәбе булгандыр.

Адәм баласына барыбер тынычлык юк икән бу бер көнлек дөньяда. Капитанны озатып, көлешә-көлешә шул хакта фикер алышып, чынчынлап тын тартырга да өлгермәделәр, яр буендагы куаклык арасыннан, якында гына, хатын-кыз чыелдаган тавыш ишетелде. Ул да түгел, агачлар артыннан, коену әсбабларыннан гына озын буйлы, ап-ак тәнле кыз, куучылардан качкан яшь болан кебек, мәйданчыкка атылып килеп чыкты. Йөгерү уңаена кычкыра үзе: «Ярдәм итегез! Аралагыз!»

Кызый спорт киеменнән басып торган Сәетнең куенына ук иңде. Артыннан куа килгән аксыл җирән, озын чәчле, таза гәүдәле егет чабып килгән уңайга кызга килеп ябышты.

Не дури! Тилермә, киттек! Бездән качып котылып булмый. Үзең килдең, хәзер кыланасың. Соң инде. Хәзер үзе килеп җитәчәк.

Еш-еш сулый-сулый, сөйләнә-сөйләнә, куучы качкынны үз ягына сөйри. Тегесе озын, төз аякларын җиргә терәп карыша, бирешмәскә итә.

Хокук оешмасы әһеле белән очрашу манзарасыннан арынып житә алмаган Сәетнең тынгысыз дөньясына, алама кызга (ни өчен алып килгәннәрен белгәнсен), йонлы күкрәкле егеткә ачуы чыга башлады.

— Нәрсә булды? Яхшылап аңлатыгыз. Табын эченә бәреп керергә кем рөхсәт иткән сезгә? Йолкышлар!

Егет, кулларын кыздан ычкындырып, явыз итеп ысылдады.

— Абзыкай, селәгәең урынына тешләреңне төкерәсең киләме әллә? Заткнись!

Бу хәтлесенә түзеп торырдай кеше түгел иде Сәетҗан. Кызны җәһәт кенә читкәрәк этәреп, ялан аякка киелгән ботинкасы белән егетнең аяк бармакларына басты. Теге аягын тартып алырга ымсынган мәлдә, уң кулының кабыргасы белән муенына сукты. Бәрүе артык каты чыкмады. Хәрбиләр әйтмешли, траектория кечкенә булды. Шулай да кул сугышында башлаучы отышлырак хәлдә була. Дошман муенын саклауга җегәрен сарыф иткән арада, уң аягының очлы тезе белән түбәнге корсагына төртеп өлгерде. Кызны куа килүче урында калса да, авыртуданмы, гарьләнүдәнме, ыңгырашып куйды.

Мондый көтелмәгән очрашуларга, сугышка әзерлекле, реакциясе көчле булса да, егет Сәетнең җилкәсенә төртеп алудан уза алмады, сугарга әзерләнгән икенче йодрыгына Сәетнең тән сакчысы Әскәр сикереп өлгерде. Күз ачып йомган арада куллары артка каерылып бәйләнгән йөнтәс орышчы, сусыл күзләрен усал акайтып, комда аунап ята иде. Барысы да тиз, көтелмәгәнчә килеп чыкты.

Шунда мантыйк кагыйдәләренә сыймый торган бер хәл булды. Рәхмәтләр укыйсы урынга кыз: «Җибәрегез аны, кабахәтләр, кыйнамагыз, ул минем егетем»,— дип шыр яра башлады.

«Ит яхшылык, көт явызлык» шул була торгандыр инде, дип уйлап, Сәет чибәркәй ягына борылса, телсез калып, имәнеп китте. Каршысында, заманында бик якын кешесе Римма кызы Марина басып тора иде. Ул аны зыяраттә, Андрей Северцев белән күргәннән соң очратканы юк иде. Үскән, үзгәргән. Барыбер таныды.

— Марина, синме бу? Таныйсыңмы мине?

Кыз исем белән дәшкән кеше ягына карашын сирпеде. Керфекләре шап-шап ачылды-ябылды. Уйланып торды. Зиһен дәфтәрен актарды.

— Дядя Саит!

Башка сүз әйтә алмады.

— Нәрсә булды? Аңлатып бирә аласыңмы?

Кызның янына килеп, терсәгеннән алды. Курчак керфекләре аска төште. Җирдә яткан адәм колакларын торгызган иде.

— Юк, берни булмады. Җибәрегез безне. Мин... мин сезгә соңрак сөйләрмен...

Йөзе җансыз. Курку хисе канын сыегайткан, акшар төсе өскә чыккан. Бу «кәтүк» белән бергә сөйләшүдән файда юклыгын аңлады Сәет.

— Җибәрегез... Икесен дә.

Күрәсең, егетләр паханнары килеп җиткәнче, табигать җимешен үзләре тәмләп карарга уйлаганнардыр. Кызый шөлдерле булып чыккан, тавыш күтәргән, дип фараз кылды Сәет. «Карале син аны, кай арада үсеп өлгергән, инде «кул астына» керерлек кыз булып җиткән». Сәет күзен алалмый Маринадан. Әйтерсең лә, рәссамның могҗизага ия каләменнән төшкән сын янында басып тора. Артык таза да, бетәшкән ябык та түгел. Аягына басып, комнарын каккалап, ялгыш тозакка килеп кергән җанвардай акаеп карап торган егетнең хәләтен Сәет аңлый. Мондый табигать бизәгеннән үз ирегең белән баш тарту ахмаклык булыр иде.

Озын, төз гәүдә, төклетуранныкыдай нечкә бил, торнаныкы мәсле, йөгереп китәргә торган озын аяклар, алга чыгып, тырпаеп торган күкрәк, килешле арт — барысы да мәхәббәт өчен өлгергән җимешләр. Озын нечкә муены аккошны хәтерләтә. Алтынсыман, тыңламас чәчләрен артка бәйләп куйган. Озын керфекләре ясалма тарттырган төсле өскә күтәрелеп тора.

Шулай да табигать-анабыз ифрат гакыллы шул. Бар шөһрәтен, мөмкинлеген бер затта күргәзмә кылырга ашыкмый. Барча балаларына

нигъмәтен тигезләп бүлеп бирергә тырыша. Татар белән яһүди каннары кушылуы җимеше Маринага рухи ягымлылык җитешми кебек. Артык нечкә иреннәре озынча түгәрәк йөзенә килешеп бетми. Күзләре сукыр кешеләрнекедәй бер урында катып калгандай. Кыскасы, кыз, Сакманов фикеренчә, әкияти матурлыгы белән әнә шул катып калган рәсемне хәтерләтә.

Сәет аны кечкенәдән белә, башыннан сыйпап үстерде диярлек. Ул аның акылына, таң калдыргыч матурлыгына сокланып, бәхет теләп яшәгәнен хәтерли. Әнисе Римма кызының талчыбыгыдай төз, ак каендай сылу булып үсүен бер дә хупламый иде. «Хатын-кыз артык матур булырга тиеш түгел. Чөнки андыйларны ир-ат хатынлыкка алырга, өенә алып кайтып, түренә утыртырга ашыкмый, тәти уенчык кебек кенә кабул итә: шаяра, хисләнә, вата, оныта... Тормыш алып барыр өченгә урта кул хатын-кыз кулайрак. Ул өй җиһазлары кебек иренең үзенеке генә була. Чибәрләрнең бәхетле шәхси тормыш белән яшәгәне сирәк. Маринам бәхетсез булачак. Матурлык белән бәхетле гаилә — сыеша алмыйлар, үзара дошманнар ук булмаса да, алар пәкенең ике ягы».

Римманың сүзләре аклана түгелме соң? Бала ата-ана тигез гаиләдә үсәргә тиеш. Марина бер дә җилбәзәк кыз — миләүшә чәчәге булырга охшамаган иде. Матур гөлне кырау тиз ала диләр шул. Ничек ул унбиш-уналты яшендә «тәп-ләп» әтрәк-әләмнәре кулына төшкән? Бәлки, куркыту, өркетү, янау алымнары нәтиҗәседер шул хәлгә калуы? Табигый дәрте, һәлакәтле хисси холкы шул юлга алып кергәнме Римма кызын? Бәлки, Сәет җенси мөнәсәбәтләргә искечәрәк карый торгандыр? Кызый матди яктан кыен яшәп, чарасызлыктан шул юлга тәгәрәгәнме?

Әнисе янып үлгәннән соң, Сакманов Марина турында еш уйланды. Нарасый ятимә каршында үзен күпмедер күләмдә гаепле сизде. Мәгәр адәм баласы — сәер зат. Намус, вөҗдан, бурыч кебек кулга тотып, капшап карап булмый торган нисби нәмәстәкәйләр күңелен кымтырыклый башласа, ул шунда ук үзен пакьләү, «чистарыну» юлларын эзли башлый. Әмәлен таба тәки: «Маринаның сау-исән әтисе бар. Нигә кеше өлешенә керәсең, кайгыртсын кызы турында ата кеше. Бу фани дөньяда син соңгы гуманист дәрәҗәсенә төшеп, Лев Толстойлар кебек кыланмакчы буласыңмы? Качып котылыр урын табарсыңмы соңыннан? Ә үз кызың турында ихластан кайгыртканың, акча күчереп торудан, институтка укырга керергә булышудан уза алганың бармы, абзыкай? Бәлки, ул да Уфа мафиясенең җенси азгынлыгын канәгатьләндерү корбанылыр? Булмас димә. Дөнья бу».

Кеше күңеле — мәңгелек табышмак. Ул язмышын тирән аң типкеле белән сизенеп, борчылып яши. Берәүне төшеңдә күрсәң, аның белән гамәлдә, басмада сөзешкән тәкәләр төсле, очрашып куюың ихтимал. Еш кына нәкъ шулай була да. Икенче бер затны очратасың килсә дә таба алмыйча интегәсең, аннары инде танымый да башлыйсың.

Кыскасы, бу көтелмәгән «күрешү» Сәеткә авыр, үкенечле тәэсир ясады. Хәзер Марина өчен сугышып, бәхәсләшеп яту җитди булмас иде. Шәхси насыйбына күнеккән, язмышына ризалашкан бугай кызый. Болай гына тәртәгә тибүе. Әтәчтән качкан, ирләргә тезен ачкан...

Сакманов кесәсеннән визит картасын алып, Маринага сузды.

— Кирәк тапсаң, шалтырат. Мин сиңа ят кеше түгел.

Күзе белән артларыннан озатып калды да:

— Стаканны тутырып салыгыз,— дигән әмер бирде.

Күңелендәге моңны, күзләрендә үтеп киткән яшьлек чаткыларын аракы да баса алмады...

Бу сынау соңгысы булмаган икән.

Шул көннәрдә үк урын алган дәхи бер вакыйгага, кара көннең кара күзе мәсле йөрәгендә калды. Сакманов ир-ат хурлыгының ачысын вә төчесен берьюлы татыды.

Зөлфиясен күмгәннән соң, ул шактый вакыт хатын-кыз затын җанына, тәненә якын җибәрмәде, аларны каршы як җенесе буларак кабул итмәде. Вакыт шәрифләре тән ярасын төзәтсә дә, җан үрсәләнүен җиңә алмый икән. Тынычландыру даруы эчкән, мәҗбүри хезмәттәге хәрби кеби, эленке-салынкы йөри бирде. Җегәре алыш-биреш, ширкәтнең абруен үстерү, дошманнары белән көрәшкә китте. Җитмәсә, көннәрдән бер көнне хатынының якын ахирие Әлфия, мәҗбүри булмаган сөйләшүе белән, ярасы саркып торган канына тоз сибеп алды. Эш бүлмәсенә көпә-көндез килеп керде. Килешле озын гәүдәсен, киң каеш белән тарттырмасаң да сылу нечкәлеге хәттин ашкан билен, кеше күзеннән ирләр чалбарында яшерү ихтыяҗы булмаган төз аякларын да үзеннән калдырмаган. Матурлык белән акыл идарә итә. Оста шахматчыныкы төсле, һәр адым алдан уйланылып, расланып куелган. Дипломны кесәсенә салып, училищега эшкә урнашканнан соң, Мисхәтне бәхетле итәргә була кызый. «Туй хакында киңәш-табыш итәргә кергәндер, егеткә дә дәрвишлек туйдыргандыр»,— дип, фараз кылды Сакманов.

— Зөлфия җитми миңа, Сәет Яруллович,— ди-ди сүзен башлады «староста», кара көн тышлы урындыкларның берсен бәхетле итеп, исәнлек турындагы гомуми сүзләрдән соң. Килешле итеп көрсенеп куйды. Бу дәкыйкадә аның ихласлыгын шиккә алырлык кеше табылмас иде олы җиһанда.

— Әлфия, миңа болай да кыен, син хет керә-керешкә бәгырьгә тимә инде,— диде бүлмә хуҗасы, бай көз кебек уйчан гына.— Җаным болай да парә-парә телгәләнгән.

Һәр ниятен, хәрәкәтен, хисен зиһенгә буйсындыру сәләтенә ия, фил сөягедәй тиреле Әлфияне ярты юлда туктатып була торган түгел иде. Утлы күмерне әрәм итмәс. Һич югында самоварын дөрләтер.

— Теләсә ни әйтегез, теләсә ни уйлагыз, куып чыгарыгыз, Сәет Яруллович, тик мин сезнең кырыгызда үзгә хатын-кызны күз алдыма китерә алмыйм.

Сакманов әүвәл килешкәндәй булып, башын селекте. Шуннан соң гына карышырга җөрьәт итте.

— Мине инде шундый карт дип саныйсыңмы? Бернәрсәгә дә сәләтсез...

— Юк ла, мине дөрес аңламадыгыз,— диде Әлфия, зур соры күзләрен пошиныкы төсле түгәрәкләп.

— Калган гомеремне адашкан ялгыз каз кебек, каңгырып уздырырга тиеш дип саныйсыңмы? Үлем түшәгендә кашык белән су салырлык кешең булмаса, бик ямандыр ул? Әлфия, бу кешелексезлек булыр иде миңа карата.

— Мин барысын да аңлыйм. Минутлык назыгыз булуы да ихтимал. Сезгә әле чын-чынлап гашыйк булулары да бик мөмкин. Тик сезнең белән башка кешене күз алдыма китерә алмыйм,— дип, үҗәтләнеп, үзсүзләнеп кабатланды Әлфиюшка.

— Күңелемне сискәндererлек, йөрәгемне иләс-миләс китерерлек хатын-кыз очраса, беренче сиңа күрсәтермен, Әлфия.

Кунакбикә үзенең тирәнгә кереп киткәнен аңлады. Аның ни хакы бар ир уртасы кешегә киңәш биреп, акыл-нәсихәт сатып утырырга. Килүенең максаты үзгә. Йомышыңны үтә дә, ычкын, үзе тәкъдим иткәнче... Йөзенә кызыллык типте. Сакманов Әлфиянең сүзләрен җитди кабул итте. Борылмалы-сыгылмалы биек кәнәфиеннән кискен күтәрелеп, шүрлектән бер китап алды.

— Зөлфия миңа бик күп шагыйрьләрне ачты. Шулар арасында Хәсән Туфан бар. Бер өзек укып күрсәтим әле үзеңә.

Әйткән идең:
«Әгәр сөя калсаң,
Миннән башка берәр бүтәнне,

Сөй... бары тик
Миннән яхшыракны,
Сөймә ләкин миннән түбәнне...»

Зеленодол кызы, табигый ки, бу шигырь белән таныш түгел иде. Мәгънәсен аңлады. Аның тәртибенә төрттерү дә бар иде кебек «Әйткән идең...» шигыренең дәвамында. Урысларда «чит монастырьга үз канун-нарың белән килмә», дигән акыллы мәкаль яши. Телне тыя белергә өйрәнәсе бар.

Бүлмәдә бермәлгә тынлык урнашты. Икесенә дә ничектер җайсыз булып китте. Сәет кунак кызының истәлек-хатирәләрдән башка, үзгә эше барын сизенә. Ике бөртек кайнар яшь агызу өчен бер-береңне борчып йөрү заманасы түгел.

Әлфия гозерен тәрәзәгә карап әйтте:

— Мин сезне, Сәет Яруллович, туйга чакырырга килгәнием.

Оялып куйгандай итте.

— Бик шәп, Әлфия. Кылны кырыкка ярыр чагым булса да, туегызда ахыргача утырырмын, чыгымнарын күтәрешермен. Мисхәт белән синнән дә якын кешеләрем күп түгел минем.

...Шул ук кичне Сәет гөнаһ шомлыгына каршы, аяк киемнәре кибетенә сугылды. Ап-ак чәчле, чем кара озын керфекле, шактый килешле гәүдәле ханым аны күптәнге танышыдай, елмаеп каршы алды, дөньясын онытып, туфли сайлашты. Аяк киемнәре җитәрлек булса да, итагатьле кибетче теләгенә буйсынып, малын сатып алды, ә үзен кафега дәште. Рәсми булмаган чакыру кабул ителде. Хәтта эш сәгате беткәнне дә көтеп-нитеп тормадылар.

Чәйханәдә озак утырмадылар. Аягүрә каһвә эчтеләр дә, урамга чык-тылар. Сәет уйланып, тәшвишләнеп калды: ханымны өенә чакыру уе юк иде, ташлап китеп тә булмый. Чибәрлеге, чаялыгы да бар шайтанның.

— Әйдәгез, киттек,— диде ханым, узып барышлый гына дигәндәй, сизелер-сизелмәс кенә, Сәетнең терсәгенә кагылып.

— Исемең матур икән,— диде «Игелек» хуҗасы, уенны кабул итеп. Күзе ак муенының чәч белән капланмаган өлешендә «кунып» алды.

— Миңа игътибарлы булуыгыз өчен рәхмәтләр. Сезгә... өегезгә бергә кайтырга ярамаса, миңа киттек, зыялы кешеләр болай гына аерылыш-мый дип ишеткән идем.

— Әйдәгез, минем фатирны күреп чыгыйк,— диде Сәет, икеләнү-шөбһәләнүләренә нокталы өтер куеп.

Гомере буенча шундый итагатьле мәрхәмәтлелекне көткәндәй, матур апа бик тиз ризалашты.

Өйдәге нигъмәтләрдән бергәләп өстәл әзерләп, шампан шәрабын ачып, кәеф-сихәтне күтәреп, арадагы читсенү сызыгын алгач, Сәет әрсез-ләнеп китеп, дөнья бизәген тезенә утыртты, муенын иреннәре белән кытыклады. Вакыйганың мондый борылыш алуына ханым каршылык күрсәтмәде, ирнең җилкенсенүен хәерлегә юрап, чишенә үк башлады. Бу гамәли шөгылен зур осталык белән, тиешле югарылыкта үтәвенә игъ-тибар итте хуҗа.

Ашыкмыйча, тәҗрибәсез яшьләр төсле каударланмыйча, үз кадерен белеп кенә, кырмызы йон күлмәген салып, урындык башына элде. Кы-рыйлары чиккән, кыска, эчке ефәк киеме тәненә сыланып, шактый алга чыгып торган күкрәген кысып, шәрехләп тора. Анысын тәненнән аерып алырга ашыкмады.

Шуннан соңра кунакбикә, реклам рәсемнәрдәге төсле озын нечкә тәпиләрен берәм-берәм тәбәнәк кәнәфи читенә куеп, өстән ачыла килгән аякларының бар рәвешен күрсәтә-күрсәтә, тыгыз кара оегын, түгәрәк төргәк ясап, аска шудыра башлады. Җитлеккән кабак кебек йомыры артын, уелып кергән билен, бөгелгәч, тагын да алгарак авышкан мул күкрәген, үзгә йомшак сыйфатларын буялган тыгыз иреннәре бизи. Кыр

кәҗәсенеке кебек гаҗәпсенгән күзләре ятакта, чишенмичә үзен күзәтеп яткан ир ягында. Тәне белән мактанырга хакы бар иде сатучы ханымның. Үзенә карату, ул гына да түгел, буйсындыру, кыздыру, җенси котырту алымнарын яхшы белүен яшерми.

Сирәк ир-ат баш тартыр иде мондый табигать бизәгеннән. Сәет белән шул мизгелдә әллә ни булды. Бөтен барлыгы, җаны, тәне илә бүген бу чибәр фахишә белән йоклый алмасын, үзен кочләргә кирәк түгеллекне аңлады. Әлфия белән булган сөйләшү дә кышның зәһәр җиледәй сөягендә утыра. Теләсә кайсы итәк астына чуму көненә калдыңмы, абзый? Туфан шигырен исеңә төшер!

Үзенә игътибарны алмыйча, мыштым гына чишенеп, юрган астына иркә песи баласыдай чума белгән Зөлфиясе сихерләдеме, әллә ханымның юха еландай боргалануларын, үтә профессионал кыланышларын кабул итә алмадымы, ул хәтлесен шайтан белсен, тик хуҗаның уяна башлаган дәрте җилгә тарган шәм кебек сүнде, сүрелде, шиңде.

— Хәзер киен,— диде Сәет кырыс кына, ятагыннан күтәрелә-күтәрелә.

Мондый борылышның сәбәбеннән, ирнең рухи-мәгънәви халәтеннән хәбәрдар булмаган ханым, бу сүзләрне үзенчә аңлады.

— Күлмәкне генә кисәм, җитәрме? Үзең чишендерергә яратасыңмы? Теге, анекдоттагы грузин кебек.

— Ниткән грузин ул тагын?

— Ханым үзе чишенгәч, грузин карап торган да, әйткән ди: «адивайся и супритивляйся».

Сәет мәзәк кабул итәрлек, шаярып утырырлык хәлдә түгел иде.

— Мин бернинди грузинны да белмим. Чагыштыруың өчен барыбер рәхмәт...

Үзен аңламаганга ачуы күкерттәй кабынса да, ир үзенең тупас, дорфа кыланырга хакы юклыгын бәяләрлек хәлдә иде. «Ханымның ни гаебе бар. Эссе мунча тактасыннан бүселеп чыккан нарат чәередәй үзең бәйләнгән, өеңә алып кайтып, шәраб эчердең. Ул үзе аңлаганча, алар мохитендә кабул ителгәнчә, сиңа ярарга тырыша».

Хуҗа аягына басты.

— Сеңелем, гафу ит, шулай килеп чыкты. Син миңа ошыйсың, һәммә җирең килгән. Тик мин бүген туарыла алмыйм. Хәзер генә исемә төште: нәкъ менә сәгать тугызга башка кешене чакырган идем. Хәзер килеп керергә тиеш. Склероз...

Сакмановның ялганы җылытылган кичәге аш кебек тәмсез килеп чыкса да, кара күлмәк өстенә яткан ак җеп булса да, ханым озын муенга утыртылган ак башын аңлагандай итеп какты. Тавыш, җәнҗал күтәрергә исәбе юк иде. Ир ягына борылып карамыйча, мышный-мышный киенде. Шундый гүзәл тәннән баш тарткан иргә ачуы килү табигый иде.

— Озата чыкмасам үпкәләмәссеңме?— диде ир, кирәкмәгән эш кылып тотылган, гаепле кешедәй.

— Миннән матуррак, яшьрәк хатынны көтәм дисең ич,— ди-ди, хатын көзге каршында кәттәләнә башлады. Юри озак матаашты. Иркенләп бизәнде. Хатын-кыз бурычлы калмас.

— Син бик чибәр, Люда,— дип, сүз катырга кирәк тапты хуҗа, киеренке тынлыкны кисеп.

— Минем әти-әни кушкан исемем Лида. Күптән түгел генә исememне мактап килгән идегез. Ярый инде, сезгә ошагач, шулай атагыз,— диде кунакбикә, олы көзге каршында гәүдәсен уйнатып.

Комодтан бер уч акча алып, санап карап та тормастан, Лидага сузды. Оят иде аңа барыбер.

— Алыгыз, юлга кирәк булыр. Чит ил акчасы янымда юк.

Ханым өр-яңа кәгазь тамгаларны учына йомарлады. Ул да хирыслык күрсәтеп, чутлап маташмады. Тир түгеп алган хезмәт хакы түгел.

— Мин валютный түгел, абзыкай. Монысы да бата.

Бик күпләр интеккән серле йозакларны үзе ачып, таш мәйданга аяк баскач, борылып, соңгы сүзен әйтте: «Врачка күренгәч, кирәк булсам, эзләп табарсыз. Кая эшләгәнне беләсез. Сезнең ярдәмчегез, мәрхүм Фердинанд, хатын-кызны болай гына ычкындырмый торган иде. Чао, Сәет Яруллович».

Ханымның әйткәннәреннән тораташ булып, телен йотып катып калган Сакмановның колагына тимер үкчә тавышы иңде: «Дың-дың, тык-тык...» Әйтерсең лә, тукран туң агачны томшыгы белән тишә. Тавышы бәгырьгә килеп кадала.

Йа хода, җир шары һаман-һаман бер үк кояш тирәсендә әйләнә. Адәм баласы да...

«Игелек» хуҗасы ширкәтенең исемен аклады. Әлфия белән Мисхәтнең шатлыкларын уртаклашып, туйда катнашты. Икесенә дә җылы туннар бүләк итте. Әлфия бүген ак күлмәктән, Голливуд артисткаларын бусагадан бәреп егарлык матур иде. Сакманов туйда иң кадерле мифман. Матди киләчәкләре кемнән торганын чамалый хәйләкәр кызый, Сәет янына йөгереп килергә дә вакытын таба.

— Пар сандугачлардай гөрләшеп, бөтен дөньяны көнләштереп, озын-озак яшәгез,— диде Сәет, теленә килгән купшы сүзләргә гаҗәпләнеп. Әлфиянең алсу яңагына иреннәрен тидерү рухын күтәреп җибәрде, бугай. Ни әйтсәң дә, самими, табигый гүзәллек каршында адәм баласы көчсез. Матурлык яшәгәндә кешелек юкка чыга алмый.

Бит очының икенче ягын үбәргә куйган Әлфия тәүфыйклы песи булып кыйлануны кирәк тапмады.

— Анысы миннән торачак, Сәет Яруллович.

Шул арада яннарына ак күлмәген муенына бизәкле ефәк тасма белән ныгытып куйган бәхетле Мисхәт килеп җитте.

— Әлфия, башка кунакларны да онытма!

— Көнләшәсеңме әллә, абзыкай?

Сәхнәгә кабат чакырылган артист мәсле, Мисхәт озын кулын күкрәгенә куйды.

— Сезнең өчен җаным җәл түгел, Сәет Яруллович.

— Ә Әлфия?

— Ул башка, ул җанымнан да кадерлерәк!

— Карунның да каруны инде үзең, Мисхәт,— дип егетнең кулын кысты.— Безнең заманда җанның поты бер тиен торганны беләсең дип уйлыйм. Кешенең дә... Син моны аңларсың! Соңрак...

## 6

Инсанлыкка яз, яшьлек, иртәнге сафлык хакында беренче хәбәрне иңдергән умырзая чәчәгенең гомере тарих өчен бер мизгел генә булса да, аның исемен йөртүче ресторандагы вакыйганың кайтавазы шактый озакка сузыла. Тишекле тәңкә җирдә ятмас. Җаваплы даирәләр хәлне куерталар, башка җинаятьләр белән бәйлиләр. Салих Гаяровның бу хактагы тәфсилле сөйләмен — лаф оруын Сакманов яхшы хәтерли. Барысы да күз алдында. Үзе катнашканнан да болайрак йөрәгендә калды. Полковникның болытларны ясалма куерта белүен кире чигергән очракта да өч дусның хәлләре шактый хөртиләнеп китәргә мөмкин иде. Салих дәдәләре булмаса... Ут нәгърәсен, Александр Матросовлар кебек, күкрәге белән ул каплап тормаса...

Икенче көнне үк Гаяровка ашыгыч эшләр бүлегеннән «Умырзая»дагы хәл-әхвәлләр турында белешмә кертәләр. Ул алдындагы кәгазьләрне ваемсыз гына караган була, хокукый хакы булса да, бу фәтва белән кызыксынган кеше икәнлеген сиздермәскә, чыраенда битарафлык саклаpга тырыша, өстәмә хәбәрләр таләп итәргә ашыкмый. Сакланганны үзем сакларрмын, дигән тәңребез. Шашкын күзле чибәр егет җан тәслим

кылган булып чыкты. Ифрат оста мәргән кулына эләккән, бичара. Ике кургашның берсе йөрәккә кергән, икенчесе корсакны сайлаган. Пуляларны тапканнар, нинди коралдан чыкканнарын ачыклаганнар. Сакмановка ыргытылган хәнҗәр юкка чыккан.

Сәет тәкъдим иткәнчә, җинаять кылынган, кеше каны аккан урынга, ягъни кунак-кунак уйнаган җиргә барып, таныклыгын күрсәтеп, үзе тикшерү-сорау алып йөрү юлыннан ул баш тартты. Җиде кат үлчәп, алдынартын уйлап эш итәргә булды. Ашыгу, кабалану борча тотканда гына бата. Бераз тынычланып, күңелен тупсага утырткач, иң әүвәл, үз бүлегенең турыдан-туры җитәкчесе — министр урынбасары янына кереп китте. Чыраена хәсрәтле-кайгыртулы төсмер чыгарып: «Әскәр Әлмиевич, кичә күңелсез хәл булды әле, «Умырзая» ресторанының хуҗасы Ленар Динмухаметовны атып үтергәннәр, кичке сәгать алтыларда»,— дигән белдерү ясады.

— Ул шәхси ресторанмени? — дип сораган булды урынбасар кәнәфиенә җайлабрак утырып. Бу җинаять турында ул инде хәбәрдар иде. Министрның хуҗалар яныннан кайтып җитүен генә көтеп утыра. Яңалыкны аның авызыннан ишетергә тиеш. Салих төлкенең атасы.

— Шундый икән шул! Мин дә бүген генә белдем әле.

— Анда ризыкны бик яхшы әзерлиләр, балык ашлары төрледән, диләр. Дөресме икән?

Гаяров канның чәнчи бармагыннан миенә, күзенә күтәрелүен тойды. «Безнең кичә шунда типтергәнне белә микәнни? Тикшереп каравы гынамы? Әллә дөресен сөйләп бирергәме» дигән, шайтани фикер дә узды башыннан. «Юктыр, эч пошканнан гына сөйләнүедер? Бәлки, коткы салуыдыр? Җебеп төшәргә ярамый. Юкса, бетте баш, калды муен тырпаеп. Синең башсыз муеның берәүгә дә, хәтта хатыныңа да кирәк булмас».

— Бер дә ишеткәнем юк,— дип мыгырданды да, тавышына саф йөрәгеннән чыккан күтәренке-рәсмилек рухы өстәп.— Бу эшне алып баруны үземә тапшырсагыз, кызыксынырмын. Бәлки, ашатып та чыгарырлар.

— Син анысын булдырырсың. Катыйлны эзлисе урынга, шунда ашап-эчеп ятырсың бер-ике атна. Син корсагыңның күңелен күргән арада үтерүче Гарәп Әмирлегенә барып җитәр.

Урынбасарның шаян төрттерү алымына күчүен Салих хуплады, яхшыга юрады. Җил-давыл читләтеп үтте дигән сүз иде бу. Димәк, ул артыгын белми.

Ирлек сыйфатлары гәүдәсенә, йөзенә чыгып торган, почмаклары текә иякле Гаяровны ярата иде Әлмиев. Абыйлары белән дус, әшнә яшәде, ярдәм итешеп үстеләр. Хәзер алар нәселен сәхнәдән кысрыклап чыгардылар дип кенә энеләренә мөнәсәбәтне үзгәртү кешелекле булмас иде. Дөнья күләсә, бер әйләнә, бер баса. Үзен лаеклы ялга озатсалар, кирәк булыр әле. Бик күпләр түрәлекләрен мәңгелеккә санап, киләчәкләре турында уйламыйча, харап булалар. Бакчасына ашлама, тирес илтергә машина сорарга түгел, зурлап күмәргә дә дус-ише калмаган кәкре сыйракларны күп белә. Бурыч алып, дуслыкны югалтма, бурыч биреп, дошманны арттырма. Бүлмәдәге тынлыкны Салих үз файдасына борырга булды.

— Министрга үзем кереп доложить итимме?

Урынбасар уй дәрьясыннан арынып, юан бармагын пистолет көпшәседәй ясап, өскә күтәрде.

— Урысларда: атаңнан алдан утка кермә, дигән әйтем бар.

Дөресен әйткәндә, Гаяровның министр алдында басып торырга теләге зурдан түгел иде. Болай гына әйтүе.

— Яңалыклар булса, миңа хәбәр ит. Кемнәр гаепле дип уйлыйсың?

Министр урынбасары озынча бүлмә буйлап йөренеп алды. Олы гәүдәнең авырлыгын өстенә алган паркет идән салкын кар төсле ыңгырашып куйды.

— Мафиянең бер-берсеннән үч алуы, байлык бүлешүе дип уйлыйм. Гадәти разборка.

— Син дә, Җәүдәт Габдуллович кебек, бар нәрсәне мафиягә сыларга торасың. Бу — иң җиңел юл. Очраклылык, ялгыш ату, көнчелек, бурыч түләмәү, хатын-кыз бүлешү кебек нәрсәләр бар бит әле. Мәсьәләгә киңрәк карарга, колачлырак уйларга өйрәнергә кирәк,— дип, идән такталарының җылавына игътибар итмичә, «яшь буынга» әхлак-әдәп кагыйдәләрен кызганмыйча өләшүен дәвам итте Әлмиев. Чынында исә, бу «юеш эш»тә заманында Җәүдәт Габдуллович кулга алырга рөхсәт сорап кергән әһелләрнең катнашы булуында бер грамм шиге дә юк иде.

Министр урынбасары яныннан чыккач, Гаяров үз бүлмәсенә күтәрелмәде, халык хәтеренә «черек күл» яманаты белән кереп калган бакчага төште. Үзе генә каласы килүе табигый, полковникка тынычлану, уйлану өчен вакыт кирәк иде.

«Рестораннан алдан чыгып китеп дөрес эшләнгән, прәметеки ак сакаллы карт булынган. Тегене Ваһаповның тән сакчысы чәпәгән булырга охшый. Хәнҗәрне дә үзе белән алырга өлгергән булса кирәк. Кухня работниклары алып яшергән булуы да ихтимал. Наганын шунда ташлап калдырган булса, ресторан хезмәткәрләренә сылап булыр иде. Юк, үтерү һөнәрен сайлаган адәм беркайчан да коралына хыянәт итмәс. Ул аңа, язучының яраткан каләмедәй, газиз була. Бит әле коралда бармак эзләре калу, аны номеры буенча эзләү ихтималы турында онытырга ярамый».

Гадәтенчә, үзен тайгак юлга сөйрәп керткән Ваһапов белән Сакмановны туйганчы, читтән торып «дөмбәсләгәннән» соң, полковник үз-үзенә тәнкыйть белән карау кимәленә күтәрелә. Йөрәгенә шик-шөбһә, шөлләү үтә. Убырның күзе күрмәсә дә, күңеле тоя.

Яшерен-батырын түгел, хаталанды. «Чит суда ят көймә белән йөзү яхшырак», дип, ул салмыш ханымнарның күңеленә үтеп кергәнен кочаклашып биергә чакыра. Тегесе разый була, ак кайнар кулын җилкәсенә, түшен күкрәгенә сала. Куллары йомшак, күкрәге мул, теле тутый кошныкыдай татлы. Гаяровның танцы сүзенең килеп чыгышы, нәсел-нәсәбе буенча татарныкы дип, Сәетнең башын катырганы бар иде. «Тансы — тансыктан алынган. Ягъни син кочаклашып биергә, парлап селкенергә үзеңә тансык кешене чакырасың». Гәүдәсе тулы булса да, җиңел хәрәкәтле иде ак чәчле, ак тәнле, ачык җилкәле «тансыгы».

Гаяров кебек каракучкыл тәнле, «җитди» яңаклы ирләр ак ханымнарга тартылучан була. Кавказ мәмләкәтләренең Рәсәй чабуына ябышып ятуының төбендә, базар, сату-алу мәнфәгатьләреннән тыш, менә шул төрле яссылыкларның үзара гамәли-җенси тартылуы да әһәмияткә иядер әле, тикшереп баксаң.

Кыскасы, хатын таза бәдәнле, үзен ышанычлы тотучы, аксыл-соры килешле кәстүмле ирнең чакыруын бик теләп кабул итте, бераздан, кулларын ялгышып кына җилкәдән муенга күчерде. Дәртле көй күңел тәсбихләрен урынына утырта, дөнья мәшәкатьләрен, иртәгә туачак кайгы-хәсрәтләрне онытыра, иплән кенә сөйләшергә, аңлашырга җай тудыра.

— Бик тәмләп, тормышның кадерен белеп гуляйт итәсез. Менә без, өч житлеккән буйдак, сезгә карап сокланып, арагызда утыра алмауга көнләшеп яшибез,— дип, ханымның үтә күренмәле ак колагына җим сала башлады мут ир.

Җәтмәләргә күп эләгеп тә, исән калган хәйләкәр балык булып чыга ханым. Җебетелгән борчакны йота, кармакны тәкерә.

— Кызык! Дүртегез дә өйләнмәгән яшь егетләрмени?

— Шулай килеп чыкты инде. Гомергә буйдаклар булып калырга карар чыгардык.

— Хатыны янында утырып, җиңеннән тартып тормаганда, ирләр гел ялгыз дүдәкләр булып чыга түгелме?

Салих сүзне җайсызрак башлап җибәрүенә үкенә, фикер җебен үзгәрәк юлга чыгарырга тырыша.

— Туган көнне билгеләп ятасызмы? Бик килештереп, шартын китереп утырасыз. Сезнеке түгелме?

Хатын Салихның әрсез күзләренә, эре тарттырган арыш онынннан пешерелгән коймактай тупасрак иреннәренә, яңакларына зәңгәр күзләренең яктысын сирпи дә, янә туры җаваптан кача.

— Сез әллә милициядә эшлисезме?

— Яхшы сорау. Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?

— Сорауларыгыз допроска тартым: каян, кая, ник, ни өчен?

— Адәм белән Хава да шулай танышканнар дип язалар. Аларны күргәннәр күптәннән үлеп беткән булса да, шул әкияткә ышанасы килә. Кешеләр, хайваннардан аермалы буларак, сөйләшеп таныша. Шуңар да үземне артык гөнаһлы санамыйм. Җавап бирәсегез килмәсә, көчләү юк, гафу итегез.

Ханым үпкәләргә җыенмаган, үзе дә ачыкламыш сәальләрне ярата икән.

— Үзегез нәрсә белән шөгыльләнәсез, дәүләт сере булмаса? Игътибар итегез, мин кая эшлисез дип сорамыйм.

— Азрак эшләп, күбрәк ләззәт алу турында хыялланып яшәүче бәхетсез бәндәләрнең берсе инде мин.

— Дусларыгыз да шундыйлармы?—дип, белешергә булды ханым, Салихның гәүдәсен үзенә тартуына катгый карышмыйча.

— Без гамәли шөгыль төрләрен туктаусыз үзгәртеп яшәргә тырышабыз.

— Аңлашыла. Сез беркая да эшләмәсәгез дә рәхәт яши беләсез,— дигән нәтиҗә ясады ак фәрештә.

— Тормыш ләззәтләреннән баш тартмасак та, без алай ук яши алмыйбыз шул. Йә вакыты җитми, йә башка ягы килеп чыга. Бүген дә әле сезнең биредә ял итүегез турындагы хәбәрне саескан китереп җиткергәч, кырык эшне ташлап кырык якка, бирегә йөгердек.

Ярый әле көе озын булды. Рәхәтләнеп сөйләшергә, аңлашырга мөмкинлек бирде.

— Сезгә төрттерүем түгел иде. Зинһар үпкәләмәгез! Холкым шундый инде.

— Ирләрнең күз явын алырлык чибәр кыз-хатынга барысы да гафу ителә.

Салихның тупас кочагында үзен өендәгечә яхшы хис итә башлаган ак тәнле, ак чәчле җан иясе чытлыкланырга булды.

— Мин үземне матур дип санамыйм. Карагыз әле безнең кызларга, нинди гүзәлләре бар араларында.

Ханым пумаладай чәчле башын мәҗлес гөрләгән якка борды, озынча муенының җилкәгә килеп тоташкан борылышы Салихның кытыршы иренenә якынлашты. Акыллы уйлап өлгергәнче, тиле эшен бетерер дигәндәй, полковник бәйдән ычкынган комсыз авызын ак тәнгә батырды. Кайнар сихәтлек бөтен тәненә йөгерде.

Ханым эреп, җебеп төшмәде. Кискен хәрәкәт белән муенын, иңбашын бәйләнчек ир тозагыннан азат итүне хәерлегә санады. Тынсыз калып, зәңгәр күзләрен Салихка текәде.

Бер мәлгә Салих үзе дә югалып калды. Хата үтергеч булмаса да күңелсезлек тудырырлык иде. Әмма дә ләкин каршы як хәзерлекле булып чыкты. Ханымның: «фу, какой нахал»,—дип әрләве, әрсез ирнең гамәлен хуплауга тиң иде. Полковникның эченә җылы керде, теленә җорлыгы кайтты. Мафиозник Сакманов бит аны Шаяров дип йөртә. Юкка түгелдер.

— Бер дә борчылмагыз, мин үпкән төшкә чуан чыкмый. Шифалы.

Эчендә шәраб кайнаган ханым җитдилек буразнасын ахыргача алып чыга алмады, авызын турсайтырга җыенган җиреннән, кычкырып көлеп

җибәрде. Гаяровның карасу йөзе хатынның күзләреннән иңгән зәңгәр нурлар көлтәсе эчендә калды.

— Без киләчәктә очрашырга тиеш.

— Язган булса,— диде ханым басылып, тыйнакланып китеп.

— Яздырабыз аны,— дип, вәгъдәдән калмады полковник.— Исемегезне дә ишетү бәхетенә ирешеп булмасмы икән?

— Сез күпне телисез, иптәш кем... Теге кыланышыгыз өчен гафу ит, исем-фамилияне чыгарып сал.

Музыка күптәннән туктап, биючеләр һаман кочаклашып басып торалар икән. Ханым аңына килеп, «Любовь Сергеевна булам мин»,— дип урынына ашыкты.

Мәҗлестәшләре аны кул чабып каршы алдылар. Олы орыштан җиңеп кайткан батырша диярсең.

## 7

...Сакмановның нык зиһене истәлек-хатирәләрне кайтара торды. Энесенә караганнары иң авырлары иде. Баскычта бер дә юкка тукмалганнан соң, беренче мәлне, кызулык белән, авыртуны артык сизмәсә дә алдагы көннәрдә Рафаэль үзен начар хис итә. Тәне кызыша, кабырга-янтаулары әрни, оча сөягенә чаклы сызлый. Гарьләнүдән җаны тетрәнә. Татарның баш каласында шулай каршы алсыннар әле үзеңне? Урамда очратсаң да котың алынырлык «гориллалар» тиктомалдан изеп ташласыннар инде. Ватаны каршында берәр гаебе булса рәнҗемәс тә иде. Дөреслек эзләп, ата-бабасының тарихи җиренә аяк басты кеше. Һәм шундый «дәрәҗәдә» кабул итү...

Сәет эштән кайтканда, энесе чалкан яткан килеш, мишәрең әйтмешли, паталокка багып, тынсыз-өнсез, авыр уйлар дәрьясында йөзә иде. Сакманов аның халәти рухиясен аңлады.

— Рафаэль, әллә чынлап та чирләп киттеңме? Кай җирең авырта?

— Үпкә күңелне кимерә, абый. Ата-баба туып-үскән, изге, газиз туфрагыма кайттым. Кунакчыллыкның югары үрнәгенә кабул ителдем. Патшалар авыз оештырдыгыз.

Сәет үзен бу очракта хаклы санаса да, магаданлының рәнҗеп-сызланып бимазалануын гафу итә. Аңа беркадәр оят.

— Вакыты шундый матавык, энекәш. Аннан килеп, туганнар берберсен танып белергә тиешләр. Аяз көнне яуган боз шикелле килеп төштең.

— Син, абый, укыган кеше. Әйт әле? Нәрсә ул ялган? Нәрсә ул чын? Минем өчен чеп-чи ялган, кем өчендер чын булырга мөмкин түгелме?

— Бу фәлсәфи сорау, аңа җавапны бик күп акыл ияләре эзләп тә, берсенең дә канәгатьләндерерлек аңлатма бирә алганы юк,— диде «Игелек» хуҗасы, мондый фикри борылыштан беркадәр сагаеп калып: «Башына катырак тондырмадылармы икән, теге мөртәтләр».

— Шундый гади сорауга да җавап тапма имеш? Адәм көлкесе. Минем йөрәгем буш. Мин берәүне дә яратмыйм. Кешелекне дә күрә алмыйм, абый.

«Егетнең башына катырак әләктергәннәр, бугай, шайтан тояклары. Ычкынмасын тагын. Миңа шул гына җитмәгән»,— дип янәдән уйлап алды Сәет.

— Каян килә сиңа шундый күңелсез уйлар. Син әле яшь. Гомерең алда. Ә менә табигатьнең таҗы — кешене күрә алмавыңны аңламыйм.

Рафаэль урынына торып утырды.

— Адәм баласы бик ямьсез бит. Эт, дуңгыз аңа караганда матуррак. Алар — дүрт аяклы. Эт — йорт саклый, дуңгыз — тәмле ит, ветчина, сало бирә. Ә кеше? Аңардан ни файда?

— Алай ук шаяртма инде, Рафаэль, мондый кофер сүзләреңне Алла ишетсә, үпкәләр.

— Үзем өчен мин үзем Алла. Дөресе, мин ялгызлык, серле дөнья Алласы. Олы галәмдә мин үземне барысы тарафыннан да ташланган, кирәксез бер җанлы йомычка кебек сизәм.

Сакманов дини кеше булып, ислам тәгълиматына сукырларча табынмаса да, тәңре белән бил алышуны, аңа тел-теш тидерүне хупламый иде. Инсан кемгәдер, нәрсәгәдер ышанырга тиеш. Халыкка, җәмгыятькә, хәтта гаиләләренә сукыр бер тиенлек файда китермәсәләр дә, үзләрен күкләргә чөеп, болытлар җилкәсенә утыртып куйган фәйләсуфлар, шагыйрьләр турында укыганы бар иде. Ә бу йөнтәс аяклы, ясалма тешле, олы миңле, кыскарак буе һәм яшьрәк булуы белән генә Сәеттән аерылып торган егеткә каян килгән мондый кизәнү, кәперәю, тайчыну... Бу фикерләре үз башында туганмы? Башка берәүне кабатлыймы? Каяндыр укып, шуларны үз фикере итеп уч төбенә утыртамы? Барыбер, сәер егет.

— Каян килгән сиңа шундый өметсезлек, рухи бушлык... Мондый халәт узып китә ул. Заманында мин дә үземне дөнья үзәгендә торам, һәрнәрсә миңа бәйле, дип уйлый идем. Ачы тормыш дәреслеге бу хыялымны чәлпәрәмә китерде. Төн караңгы... Аның артыннан таң килә. Син ишеткәнсеңдер, минем хатынымны үтерделәр. Балабыз туа алмыйча калды.

— Мин мәңге ялгыз, берүзем бу җаһил дөньяда. Тирә-якта караңгылык, бозлык. Кругом ялган, алдау, мин берәүгә дә ышанмыйм.

— Горькийның бер каһарманы: «Яхшы кешеләр, ялган акчалар кебек, сирәк очрыйлар»,— дигән. Димәк, алар аз булса да бар. Яхшылыкны күрә, аңлый, көндез чыра, төнлә шәм яндырып булса да, таба белергә кирәк, Рафаэль. Болай яшәп булмый.

Шактый озак сөйләшеп утырдылар ул кичне яңа табылган, рухы төшкән, өметсезләнгән, тәмам мәэюсләнгән энесе белән Казан мафиясы башлыкларының берсе. Һәр кеше укылмаган роман икән ләбаса.

Табигате белән көчешле, какшаучан, тотрыксыз, исәп-хисапсыз тәэсирләр, хисләр дөньясында яшәүче кеше икән Сакмаровларның Магаданда үрчегән нәсел-нәсәбе вәкиле. Андыйлар өчен дөнья ак белән кара төсләрдән, күк белән җирдән, ут белән судан гына тора. Хисси кешеләрнең күңеле әрнүчән, михнәт, җәфа чигүчән, тиз яраланучан була. Ул гомере буенча дөреслеккә юл эзли, әмма кичерешләре артыннан үрелеп баруы сәбәпле, баштан ук дәвамсыз тыкрыкка кереп китә, якыннарына, үзенә кайгы-хәсрәт китерүдән уза алмый.

Сөйләвенә караганда, Рафаэль урта мәктәпне тәмамлагач, элемтә техникумында укый. Булачак белгечлеген ошатмыйча, аны ташлый. Ике елга якын җирле югары уку йортының филология факультетында белем эсти. Хакыйкать эзли. Төпченүчән кешеләрне бер чорда да яратмадылар. Институттан куыла.

Ике тапкыр гаиләле булып та караган икән Сәетнең энекәше. Бу тарафтан абыйсын куып җитә язган. Беренче хатыны — казакъ кызы — Рафаэльне ике айдан, сәбәбен аңлатмыйча, ташлап киткән. Хуҗа-бәк утырып җылаудан ары китә алмаган.

Икенче хатыны, шул якта туып-үскән Татьяна иренең: «Кешенең җаны үлми», «җимерү — минем хыялым»,— кебек сөйләнүләренә игътибар бирмичә, Сакмаровлар нәселенә чем кара чәчле бер малай, сыек зәңгәр күзле, ап-ак чәчле бер кызый бүләк итеп, «философ» ирен өеннән куып чыгарган. Нәкъ Наполеонча тоткан үзен Рафаэльнең хәләл җефете. Ерак сәхрадагы гаскәренең җиңү хәбәрен алып килгән чапкынчыга нисбәтән ул мондый әмер биргән, диләр: «Мавр үз бурычын үтәде, мавр теге дөньяга китәргә хаклы».

Белемсез, фатирсыз, акчасыз Рафаэльнең күңел түрендә, чуар йөрәгендә Татарстан тарафларына юл тоту нияте туа. Ерак туганнарыннан ялкынлы чакыру алган сөйкемле сөяк мәсле, тиз генә җыена да, бердән-

бер байлыгы, өмете — алтын коелмасын кыстырып, олы юлга чыга. Әүвәл этисенең туган авылына кайтып төшә. «Пәйгамбәрнең иңүен» берәү дә көтмәгән булып чыга. Татарча бөтенләй диярлек сөйләшә алмаган, холкы-фигыле шактый сәер ир авыл җирендә озак яши алмый. Артык якын туганнары калмаган. Сәетнең адресын юллап, бик теләп, «күчтәнәчне» Казан каласына озаталар. Соңрак, авылдан килгән игенче туганы Рафаэльга үз мөһерен сукты: «Сәер бәндә. Таракан кебек яктыдан кача. Гел тыныч почмак эзли. Бер эшнең рәтен белми. Ашавы да әлләкем тегел. Салып бирсәң, эчә. Үзе эзләп йөрми. Бердәнбер яхшы гадәте шул. Туганнар җыелышып киңәштек тә, сиңа җибәрдек. Ачуланма. Шәһәр зур бит, сыяр әле шунда ул гына».

Шәһәр зурын зур анысы. Сүз дә юк. Мәгәр дөньяның иң олы каласында да һәркемнең яшәү урыны, ятагы булырга тиеш шул ходаның хикмәте.

Ничек кенә булмасын, Сәет аның турында кайгыртырга, тормышын сипләп җибәрергә бурычлы дип тапты үзен. Кызганды. Шул хәтлесенә дә игътибар итте Сәет: яшәеш, галәм, йолдызлар, дөреслек һәм гаделсезлек турында сөйләшергә, шәхси фикерен әйтергә яратса да, Рафаэль язмышын каһәрләми, зарланмый, хатыннары хакында да яман сүз ычкындырмый. Бу сыйфатын Сакманов хуплады. Ялгызлыкка омтылуын, гомеренең йомгак очын эзләвен ошатмады. Бозыклык, фәхишлек үзәге, әхлакый череклек оясы — зур шәһәр аның өчен түгел иде. Һәр адымда явызлык, һәлакәт саклап торгандай тоела Рафаэльга. Авылда яши алмаган.

Сәет килмешәкнең үзе генә белгән куркыныч һәм серле дөньяны тоеп яшәвен сизде. Берәр гасырга иртәрәк йә соңрак, җәмгыятьтә иплe тормыш, тәртип урнашкан, игелекле чорда туарга тиеш иде, нечкә хисле, яралы йөрәкле егет.

— Мин кешеләрне үтәли күрәм,— диде Рафаэль бер көнне.— Беренче хатынымның мине яратмаганын, бары тик кызганып кияүгә чыкканын яисә чират уздырасы килгәнен генә белдем. Шуңар да, яратсам да, үземне тәртипсез тоттым, кыландым, тавыш, җәнҗал чыгардым. Үзем күбрәк интектем. Йөрәгем утында, ялгызлыгым ялкынында үзем яндым. Икенче хатыным үзен хәйләкәр, акыллы санады. Кызымның үземнеке түгел икәнен беләм. Кайсы көнне чит-ят ирдән балага узган вакытын санап чыгардым. Үземнеке булмаса да, Ларисаны барсыннан да артык яратам. Тәне миннән түгел, ә җаны миңа якын... Мин хәсрәтне, михнәтне олылыйм. Шуның белән мин башкалардан өстен.

— Ни өчен татар кызына өйләнмәдең? — дигән сорау бирде Сәет аңа бер кичне.

— Безнең якта хатын-кызга кытлык зур. Чибәрләрен шампан шәрабы ванналарында коендырып, алтын-көмеш тагып, яшьли бозып, иртә картайтып бетерәләр. Кыскасы, аларның гомере, умырзая чәчәге белән кыргый суганныкы кебек, бик кыска. Тормыш өчен ярамый алары.

Магадан ягында туып-үскән, ата-анасы ягыннан татар кызы үзенең милләтен белми, танымый. Минемчә, хатын-кызның милләте юк, була да алмый. Табигать аны башка максат белән — кеше нәселен үрчетү өчен яраткан.

— Һәр халыкның алдынгы, изге хисле, азатлык өчен көрәшче хатын-кызлары бар. Киресенчә, алар милләтнең җаны, көче, киләчәге...— дип, Сәет бирешмәде, карышты.

Рафаэль кулын гына селтәде: «Син әйткәннәре инде хатын-кыз түгел».

Әйе, дөньяны аңлавы, фикерләү рәвеше яссылыгыннан бәяләгәндә дә, Сәетнең энекәше сәер, гадәти түгәрәктән төшеп торган кеше иде.

Шул ук вакытта аңарда ниндидер эчке көч, ышаныч-таяныч та бар кебек. Андый кешеләрнең чынбарлыкны, яшәешне үзаңлавы, үз тануы була. Килешмәүчән, алдашуга бармаучан холыклары болгавыр заманга авыр җайлашса да, алар беркайчан дусларын сатмый. Үз

фаҗигасенә бикләнә. Үзен каһәрләп өермәләнә. Мәгәр күңеле изге булса да, якыннарына яхшылык эшли алмый, иң раушан нияте дә ахыр йә көлке кабул ителә, йә һәлакәт юлына алып чыга.

## 8

Гаяровның ыргылып алга барган тулпарын туктата алырлык көч юк иде кебек дөньяда. Барча хыяллары диярлек гамәлгә ашып бара. «Күлмәктә туган», диләр андыйлар турында. Полковник дәрәҗәсен алу белән бүлек мөдире итеп расланды. Тавык кебек, бөртек чүпләп, вакланып аптыраткан Җәүдидән дә котылды. Пенсиягә озаттылар бахырны. Салих элеккеге шефы Насыров белән эре генә саубуллашты.

— Ары-бире кирәк булсам, шалтырат, ярдәм итәрбез,— дип, кулын көймә рәвешле ясап сузды да, алдында яткан кәгазьләргә кадалды. Янәсе, аягүрә басып торучы кешене хөрмәт итсә дә, аның өчен эштән дә мөһим нәрсә юк. Җәүдәт Габдуллович астан, кайнап күтәрелгән сарутын, чүпрәле кабартмадай ачуын төкереге белән йотты да бүлмәдән чыгып китте. Артык аның белән кызыксынучы кеше булмады.

Яңа хезмәтенең башында ук үзен ныгытып кую нияте белән, Гаяров бер олы җыелыш уздырып алырга булды. Гамәли-нәзари әзерлекле нотыгы белән «текәләрне» бераз өркетеп алып, бүлектә селкенеп йөрүче кибәк, әрбә, очыкларга үзенең кем икәнен күрсәтеп, ду килеп алу иде якты хыялы. Тик «Умырзая» да аяк астыннан чыккан хәл-әхвәлнең бер кисмәк балга төшкән сыңар кашык дегет булып чыгуы бар иде. Югары менгән саен егылып төшү куркынычы да арта бара икән, шайтан алгыры.

«Җинаятьчелеккә каршы көрәшнең чираттагы бурычлары», дип исемләнгән берәгәйле теманы тикшерүгә кул астындагы хезмәткәрләреннән тыш, район милиция бүлекчәләреннән, прокуратура һәм КГБ кебек җаваплы оешмалардан шактый кеше чакыртты. Күбесенә үзе шалтыратып чыкты. Күрсеннәр, тыңласыннар, өйрәнсеннәр, нәтиҗә ясасыннар.

Зиһенендә шыткан уйларын ишеткәннәре белән баетып, яшьрәк чакта укыганнары илә тулыландырып, киңәшмәне гомумирәк рухтагы кәлимә белән башлап җибәрде.

— Чыгышымны министрыбызның армый-талмый кабатлый торган нигез сүзләреннән башлап җибәрәсем килә: «Без хөкем оешмасы булудан бигрәк, тәрбия һәм ышаныч оешмасы. Халык безгә тулысы белән язмышын тапшыра икән, без бу өметне аклый белергә тиешбез».

Бу гыйбарәне бүлмәдә утыручы сөмсез җаннардан өстенлеген күрсәтү өчен, тантаналы, рәсми дулкында кабатлады. Иңендәге яңа йолызлары көч өстәп тора үзенә.

— Тормышыбыз ипләнеп бара. Яшәешебез мәгънәле, республикабыз мөстәкыйльлек юлыннан эре адымнар белән алга атлый.

Әмма тирә-ягыбызда һаман да җинаятьчелек яши, һаваны агулый, сугыш, ызгыш, үтерешләре була тора. Мәгълүм булганча, сәламәт яшәеш үзеннән-үзе генә килми, организм аның өчен көрәшергә тиеш. Мин туктаусыз бер нәрсә хакында уйланам: кешегә бу чаклы явызлык каян килә? Тумыштанмы, мохиттәнме, әллә тәрбияви алымнарыбыз дөрес түгелме?

Шул рухтагы фикерләре белән полковник шактый озак итеп, иренмичә уртаклашты җыелыш әгъзалары белән. Барысы да, шөшле биреп балта алган кешеләрдәй, аны йотлыгып тыңладылар. Тик аңа буйсынмаган прокуратура вәкиленең генә болай да чалыш аскы ирене тагы да аскарак салынды. Аның көлемсерәвен Салих үзенчә юрады: «җинаятьчелек юкка чыкса, синең ни пычагыма кирәгең бар»,—диюе иде әтрафсызның.

Төп чыгышны өч урынбасарының берсенә — Алексей Тимофеевка йөкләгән иде. Артык җаваплы бурычны аңа кушканына соңыннан үкенде.

Кардәш милләт вәкиленә үҗәтлек, үзсүзлелек хас икәнне белә иде. Терсәкне тешләп булмый. Әле генә майор дәрәҗәсенә күтәрелгән кеше, йомышына артык җаваплы килеп, тырышып, төпченеп әзерләнгән, житди җыелышта яңгыравы мәҗбүри булмаган хәл-әхвәлләргә дә тукталган. Карьерага юлны һәркем үзенчә яра.

— Җинаятьчел төркемнәр арасында өстенлек, байлык өчен сугыш дәвам итә. Үткән атнада гына «Умырзая» ресторанында, аның хуҗасын атып үтерделәр. Үтерүче әлегә тотылмаган, тикшерү алып барыла, шаһитлар житәрлек. Аерым алганда, шул ук көнне, Йошкар-Оладан махсус автобус белән килгән егерме биш хатын-кыз берсенең юбилеен бәйрәм иткәннәр. Берничә сәгатьтән соң, өч, дөресе, дүрт ир почмактагы өстәлне биләгәннәр. Дүртенчесе, күрәсең, йә сакчылары, йә шоферлары булгандыр, ашау-эчүдә катнашмаган. Әлеге кешеләрнең берсе тышкы ишектән чыкканда, тәннән алынган патроннарыннан күренгәнчә, тавышы кысылган чит ил пистолетыннан, әйткәнемчә, ресторан хуҗасы Ленар Динмухаметовка аткан. Оператив группа, ашыгыч ярдәм килгәндә, ул үлгән була. Сәбәбе билгесез. Үтерелгән кешенең шәхесе ачыкланды: ике ел элек, үз фатирыннан чыкканда, милиционер киемендәге кеше тарафыннан атып үтерелгән Мансур Маулетовның якын туганы булып чыкты. Үтерүчене тапкан, кулга алган идек. Тикшерүне ахырына житкерә алмадык. Камерасында асылынды. Бәлки, асып үтергәннәрдер.

— Читкә китәсез,— дип, шактый кырыс тавыш белән бүлдерде аны полковник.— Көне буе утырырга туры килер.

— Мансур Маулетов вафатына бер атна калгач, әлеге ашханәне, киләчәген сизенгәндәй, энесенә яздырган. Дөресе, бик арзан бәягә сатып җибәргән. Динмухаметовны шунда тукланган дүрт ир-атның берсе атып үтергән дигән фикер-версия бар. Вакытын төп-төгәл әйтә алам. Пешекче ханым (Алексей Тимофеев алдында яткан кәгазьгә күз ташлап алды), әйе, Альмира Ситдикова милициягә алты туларга ун минут калгач шалтырата. Җиденче ун минутта безнең егетләр тикшерүне башлап җибәрәләр...

Бу чаклы ваклап сөйләүнең Гаяров күңеленә хуш килмәве аңлашыла булыр. Ул күн тышлы, биек артлы кәнәфиендә зыр итеп әйләнеп алды. Канәгать түгел. Сакманов аңардан: «Тикшерүне сразы үз кулыңа ал, башка берәүне дә якын китермә, дип үтенгән иде. Ә ул замминистр янында коерык болгап чыкты да, тынычланды. Монысы да артык тәфсилли. Татарстанда үзгә хәлләр, башка үтереш, талаш, суешлар булмаганмыни? Бу җирән тумранга ирек бирсәң, әллә нәрсәләрне, әллә кемнәрне тартып-йолкып чыгарыр? Фикерләү киңлеге житешми? Тырнак астыннан кер эзләү, олы вакыйгалардан читләштерә. Глобаль фикерләү һәркемгә дә бирелми шул. Шул сыйфаты — ваклыгы өчен Җәүдәт Насыров ярата иде үзен. Аның кешесе бит әле ул. Кысарга кирәк булыр.

— Альмира Ситдиковадан ике көн буена үзем төпченеп, җентекләп сорау алдым,— дип, төссез, соры тавыш белән дәвам итә Алексей Тимофеев, үзен ниләр көтәсен белмичә.— Безнең ышып килүче кануннар рөхсәт иткән, мөмкин булган, барлык алымнарны кулландым.

Бераз икеләнеп торганнан соң өстәп куйды: «Йөзе көл төсенә кергәнче селектем. Дөресен әйтеп бетерми хуҗасы турында, хәйләкәр. Кыскасы, торгашка. «Бездә тукланган ирләрне шул ук киемнәреннән күрсәм, бәлки, таныр идем, йөзләренә күтәрелеп карамадым. Берсе — иң өлкәне — кирәгеннән артык тулы гәүдәле, икесе, бик нечкә булмасалар да, рестораннарда ашап йөрүчеләр өчен шактый төз гәүдәле иделәр. Шул чаклысы хәтердә калган».

«Артыгын сөйләмәгән, бугай. Акылсыз хатынга охшамый. Үлгән артыннан китәсе килми. Ашау-эчүдә катнашмаган яугир турында ләммим сүз әйтмәве сәер».

Үзләрен ашаткан хатынга уңай карашы белән бүлек мөдире ашыгыбрак ташлады. Чәчәкләре артыннан җиләкләре өлгергән икән әле.

Тимофеев аксыл-саргылт йөзенә канәгать, төче елмаю чыгарып, полковник Гаяровның киң өстәленә япон диктофонын китереп куйды.

— Ситдикованы язып алдым. Анда әле мин әйтеп бетермәгән өстәмә хәбәр-белешмәләр бар. Мәсәлән ул: «Шул тирәдә, залда булсам да, кем атканын шәйләми калдым. Болар чыгып киткәч, кемдер урамнан йөгереп кереп атып чыкмадымы икән, дигән шигем дә бар»,— ди. Хәзер тыңларга уйласагыз, иптәш полковник, менә шул сырлы төймәгә басыгыз.

Кызыклы борылышларга, фаш итүләргә мөкиббән прокуратура вәкиле (милиция бездән күп нәрсәне яшерә дигән фараздан чыгып): «Тыңлап карасак, мәгълүматыбыз тулырак булыр, катмарлы эш күренә, безнең күбебезгә бу үтерү белән шөгыльләнергә туры килмәгәе?» — дип, үҗәтләнде, тыңларга әзерләнде.

Тасманы күмәкләшеп тыңлау һич кенә дә Гаяровның ниятенә, теләгенә туры килми иде. Ул аның эчтәлеге белән әүвәл үзе танышырга тиеш. «Әгәренки ханым, кабымлыкка өстәмә рәвештә кара уылдык китерткәненең өстендә фәлән-фәлән төсле кәстүм иде, миңа фәлән-фәлән сүзләр кыстырып утырды»,— дип тә өстәгән булса? Хәлнең хөртиләнеп китүе мөмкин...

Салих дулкынлануын басарга тырышып, үзе дә сизмәстән, бармакларын ак шома өстәл кырыена батырды. Бераз хәл тарткач, уң кулын өскәрәк күтәреп, киеренке һаваны кисеп төшергәндәй итте. Йөзе кырысланды, күзенә кан менде.

— Хәзер бүленеп тормыйбыз. Алдан докладны тыңлап бетерик, аннан соң, күз күрер. Дәвам итегез, Алексей Фирсович,— диде, соңгы сүзләренә йомшак, дустанә аһәң бирергә тырышып.

Хакимият оешмаларында язылмаган канун шундый: кем өлкән — шул хаклы, кем өлкән — шул акыллы.

— Так вот! Шартлау тавышы залда паника уята. Чыр-чу, шау-шу куба, чинаш китә, хатыннар дәррәү урыннарыннан күтәрелеп, урамга йөгереп чыгалар, күп уйлап тормастан, көтеп торган автобусларына төялеп, кайтып та китәләр. Исәп-хисап ясап тормыйлар. Берәү үлми, икенче көн күрми дигәндәй, директорны күз алларында ату, 3 миллионны кесәдә калдырырга мөмкинлек бирә. Беркатлылар заманасы узды... Тик без компаниенең эзенә төштек. Алдарак әйткәнемчә, Йошкар-Оладан килгән «десант» булып чыкты.

— Каян белдегез аларның Йошкар-Оладан икәннәрен?

— Менюның бер читенә карандаш белән язылган булып чыкты: «Фәлән шәһәрдән сәгать бергә 25 кешегә өстәл. Туган көн». Заказ ясаган хатынның телефоны да бар. Шунда ук язылган. Аны эзләп таптым. Үзе күргәнне төкми-чәчми сөйләп бирде, анда утырган дүрт ир турында яңарак мәгълүматлар өстәде: «Төсләрен, битләрен төп-төгәл хәтерләмим. Бердән, алар багана артында утырдылар, миннән ерак иделәр. Икенчедән, үземнең туган көнем булгач, кешеләрне шулай еракка алып килгәч, игътибарны кунакларыма бирергә тырыштым. Ә менә безнең Любовь Сергеевна исемле чибәр хатыныбызны ирләрнең берсе биюгә чакырды. Озын буйлы, коңгырт чәчле, светлыйрак кәстүмлесе подругабызны күкрәгенә кысып, битен яңагына куеп, шактый озак биеде...»

Полковник Гаяров, әлбәттә, инде үз «галиҗәнабләрен» таныды. Тәне эсселе-суыклы булып китте, маңгаена, аркасына тир бәреп чыкты. Күпне күргән, чуар йөрәге тартышып куйды. Әйтерсең лә, ул Сират күперен кичеп ята, тәмуг учагының кызыл телләре тәнен ялап-ялап ала. Тормышында иң хәтәр мизгелләрне кичерүе булгандыр аның. Табигый сизем-ләве, тумыштан килгән саклану йөгәнеше, тәҗрибәсе дилбегәне үз кулына алырга боерды. Җиде биреп алты ала торган вакыты түгел иде. Ситдиковасы да әләкче хатын булып чыккан. Үзен эләктерәсе булыр.

— Кызыклы хәл. Ул ханымны эзләп табуыгыз яхшы булган. Ә тегесен?

Тавышы киселеп, сизелер-сизелмәс кенә калтыранып чыкты. Тимофеев хуҗасының дулкынлануын яхшыга, үз файдасына юрады.

— Любовь Сергеевна дигәненең эш, өй адресларын таптым. Тик ул әниләренә, авылга, берничә көнгә утырмага киткән булып чыкты. Бүген, иртәгә кайтырга тиеш. Үзем барырга җыенам. Кыскасы, без үтерүченең янсә үтерүчеләрнең коерыгына басып киләбез. Бәлки, шулар аша башка ачылмый калган җинаятьләрнең дә эзенә төшәрбез.

Адәм баласына кыенлык килгәндә, бигрәк тә хәвеф-хәтәр янаганда, аның өстәмә мөмкинлекләре, баш миенең әлегәчә йокымсырап яткан күзәнәкләре уянып, хуҗаларына ярдәмгә килә, диләр. Хак сүз икән.

Майор Тимофеев уңышлы гына алып барган тикшерүгә Салих Гаяров икенче, көтелмәгән яктан килеп чыкты.

— Миндә бер житди сорау бар, майор. Сез Йошкар-Олада төпчү эшләрен алып баруга хакимият оешмаларыннан рөхсәт алдыгызмы? Әллә партизанщина белән шөгыльләнәсезме?

— Без бит бераүне дә кулга алмадык. Шау-шу чыгармыйча, тавыш күтәрмичә генә башлап җибәрдек тикшерүне. Рөхсәт алырга кирәктер дип, уйламадык та,— диде мондый сорауның бирелүенә үк гаҗәпләнеп, сәясәттә бик көчле булмавы, интригалар мәктәбен тулысы белән үтеп җитмәве сәбәпле шөбһәләнеп калган Тимофеев. Мондый борылышка ул әзер түгел иде.

— Сез, яшьләр, уйлап җиткермисез шул, безне — җитәкчеләрне кыен хәлгә куясыз,— дип, теләктәшләр эзләп, кабинетта утыручыларга күз ташлады Гаяров.

— Дөрес сорау. Мари-эль, Татарстан шикелле үк, мөстәкыйль республика. Ник әле без, үзара исәп-хисап ясап, атышып, чәнчешеп йөрүче шакаллар, җинаятьчеләр өчен ике дәүләт арасындагы мөнәсәбәтләрне бозарга, катлауландырырга тиешбез. Дөрес юл түгел бу,— дип, бернәрсәгә дә исе китмәсә дә, җае чыкканда үзен милләтче итеп күрсәтергә яраткан Казан прокуратурасы вәкиле Әхмәт Мурзин.

Бүлек мөдиренең фикер сөрешен һәм ниятен дөрес сиземләп алган, Гаяровның икенче ярдәмчесе Рәхимҗанов: «Алексей Фирсович, син бу моментны уйлап җиткермәгәнсең! Иртәгә Йошкар-Оладан, Сыктывкардан, Чебоксардан милиция әһелләре килеп төшеп, безнең гражданнарның өнен ала башласа? Без бит җәза оешмалары гына түгел, бу хакта чыгышының башында министрыбызның сүзләрен дөрес искә төшерде иптәш полковник,— дип, нотыкчыга шелтә белдерүне мәслихәт тапты.

Полковник Гаяров үз табышын хуплады, бераз тынычланды, бәйдән ычкына башлаган нервларын тупсага утыртты.

— Миңа ике җөмһүрият арасындагы мөнәсәбәтләрне җайлауны үз өстәмә алырга туры килер. Ярый әле министрны да, аның замнарын да яхшы беләм. Теге хатыннарның адресларын миңа бирерсез! Әүвәл, хуҗаларыннан рөхсәт алырмын да, үзләреннән вәкилләр ияртеп, тикшерү эшен дәвам иттерермен.

Хакимият оешмаларында бәхәскә йолдызның эресе нокта куя. Үзен күрсәтеп алу өчен яхшы мөмкинлекнең кулдан ычкына баруын сизенде майор Тимофеев. Җитмәсә, кисәтү алды. Табигый ки, аның кәефе кырылды, күтәренке рухы төште, сөмсере коелды.

— Сез каршы килмәсәгез,— дип, табигый халәтенә кайткан Гаяров, корыч тавыш белән сүзен ялгап китте,— бу пычрак эшне үз өстәмә алырмын. Чөнки операция бик катлаулы, четерекле булырга охшый, аның, бирегә дөрес әйтелгәнчә, башка җинаятьләр белән бәйле булуы мөмкин. Ачылмыйча калган яллаулы үтерүләр бар. Җәмәгатьчелек безнең артык акрын кыймылдаудан канәгать түгел,— дип, бүлмәдә утыручыларның барысына да уртак кисәтү ясады да, Тимофеевка баш кагу, каш сикертү белән, фикерен дәвам итәргә рөхсәт бирде.

Башка бүлектән чакырылган Александр Атнагулов беренче мәсьәләне болай тиз генә ябу белән килешмәде. Дөрес, сүзне ул да Гаяров ягына ялагай ымнан, салпы якка кыстырудан башлады.

— Полковникның бу эшкә үзе алынуын хуплыйм. Кулыгыз каты, күзегез үткен! Тик минем майорга бер соравым бар, рөхсәт итсәгез? «Умырзая»дан фаҗига турында хәбәр алынганнан соң, урынга чыккан оператив группаның җитәкчесе кем иде? Ул анда нәрсәләр тапкан? Җаваплының үзен тыңларга иде!

Салих чыраен сытты. «Мәсьәлә хәл ителгәч, ни пычагыма куертып маташа инде бу мөртәт, сәнәктән көрәк булган нәрсә. Авызына чүпрәк тыгып булмый шул. Үзен хәйләкәр дип саный, мине мактаган була. Синең мәдхияңнең бәясе безгә мәгълүм. Бозлыктагы бозау кебек таеп егылганны көтеп кенә йөрисең».

— Тәкъдимне яклыйм. Киләсе киңәшмәгә чакырырбыз,— дип вәгъдә бирде Гаяров.— Әйдәле, майор, дәвам ит.

— Икенче үлем шулай ук алдан оештырылган. Мафия эше. Олы бизнесмен Сәет Яруллович Сакмановның энесен җәзалап үтергәннәр.

Кайсыдыр сорау тондырды: «Сәет Сакмановның туган энесеме?»

— Юк, туганнан туганы. Күптән түгел Магаданнан килгән булган. Казанда рәтле-юньле бер җирдә дә төпләнеп эшләмәгән. Аның үле гәүдәсен Коры Елга урманында таптык. Чишендереп, кулларыннан агачка элек куйганнар да, вак калибрлы мылтыктан атыш ярышы оештырганнар. Шактый пуля алынды тәненнән. Автобускамы, чит ил маркалы җиңел машинагамы утыртып алып киткәннәр. Байтак кеше күргән, тик берсе дә тәгаенли алмый.

— Беркая да эшләмәгән кеше — «бич» кемгә кирәк булды икән?

— Сакмановның «дуслары» тончыктырган аны. Абыйсына үч итеп.

Тимофеев сорау-аңлатмаларга игътибар бирмичә, төссез, тигез тавыш белән докладын дәвам итте. Бу юлы аны бүлдермичә тыңлап бетерделәр.

Гаяров эшлекле кыяфәт белән, кара-кучкыл йөзенә ифрат борчулы төсмер чыгарып, майорны тулыландырды, яклады.

— Элек без штатлар җитми, машиналарыбыз иске, коралларыбыз тутыккан дип зарлана идек. Хәзер хөкүмәт безнең бу «бүкәнне» бәреп екты. Шикаять өчен нигез юк. Ә оештырылган җинаятьчелек котыра. Безнең борын төбендә әллә ниләр кыла.

— Хокукларыбыз аз. Кулларыбыз бәйле. Кулга алабыз, җитди гаеп куябыз, өч көннән чыгарып җибәрергә мәҗбүр ителәбез,— дигән булды прокуратура вәкиле, фикер алышуда катнашмады дип әйтмәсеннәр өчен генә.

— Без дә зарлансак инде. Теләсә нинди машинаны туктатып тенти алабыз. Шикле күренгән кешене судсыз-нисз ябып куя алабыз,— дип, Гаяров мәсьәләгә ачыклык кертергә булды.

— Бәлки җинаятьчел төркемнәр үзара сугышып, берсен-берсе кырып ятканда, безгә мыек борып, читтән карап, җыелышлар уздыру хәерлерәктер,— дип, пыскып янган учакка чыбык-чабык ташлауны кирәк тапты шул ук Александр Атнагулов.

Бу ярым шаян сүзләрне үзенә төрттерү дип кабул иткән Гаяров кисәтү ясауны кирәк тапты. Бер тапкыр йомшаклык күрсәтсәң, муеныңа менеп утырачаклар.

— Мин, иптәш подполковник, сездән мондый бәяне көтмәгән идем. Без бирегә вакытны заяга уздырып утырабызмыни? Ничаклы файдалы фикер ишеттек, күп нәрсәгә ачыклык керттек.

Турыдан-туры Гаяровка буйсынмаган Атнагуловның үз этлеге үзенә җиткән.

— Мин каршы түгел. Бирегә җылы, тәрәзәдән күренеш матур.

— Һәр кинаянең чиге була,— диде Салих, үзе тегеңә күз кыскан булды.— Нәтиҗә ясыйк. Ачылмаган җинаять эшләрен бүлешеп алабыз. Бер атнадан һәркемнең докладной запискасы әзер булсын.

Үз өстемә «Умырзая»дагы җинаятьне ачуны алам. Барыгызга да рәхмәт.

Бүлмәдә берүзе калып, Салих Гаяров бик озак уйланып утырды. Җыелышка, башыннан узган өермәле вакыйга-хәлләргә бәя бирде. Иң әүвәл күңеле тырналды. «Кемсәләр рәхәт күргән өчен ул госел коенырга тиешме? Кемдер аш ашый, кемдер баш кашый түгелме соң? Биредә, абзыкай, үзең гаепле, сазлыкка аңлы рәвештә кереп баттың, монысыннан исән-имин котылсам, дистанцияне тота белер идем.

Нишләп үземне шулай битәрлим соң әле! Дуслары, юк, танышлары, аны төшке ашка чакырган, ди. Хәзерге демократия заманында, хәтта безгә дә, гомердә бер мәртәбә булса да, иҗтимагый урында тукланырга мөмкиндер бит? Аннан килеп, шәхси рестораннарның ни мәтәштереп ятуларын, кайсы тарафларга хәрәкәт итүләрен мин белергә тиешме? В курсе булырга тиешме? Әлбәттә.

Шәһәр абруйлары, мафия әһелләре белән көпә-көндез ресторанда кунак-кунак булып йөргәнсең, полковник башың белән дисәләр? Алар белән, тиле тәкәләр кебек, гел сугышып яшәргә дигәнмени? Мин алар белән аралашып, эч серләренә үтеп керәм, хәбәрдә торам, бик күп канлы бәрелеш, үтерешләрне искәртәм».

Барыбер тынычлык килмәде полковникка. Әшәке, сасы, шакшы курку хисе җанына үтеп керде, күңелсезлек салкыны тәнен, йөрәген бимазалады. «Әгәренки бу хәлләр ачыла калса, мин алдан чыгып киткән идем, берни күрмәдем,— дип кенә котылып булмаячак. Сакмановның белгәндә кан эзен күрүгә, тикшерүне ачып җибәрергә, кире әйләнеп кайтырга тиеш идең»,— диярләр «акыллы» башлар.

«Эш өчен тырышып, кыен хәлдә калуың бар», дигән катгый нәтиҗәгә килеп, «Умырзая» операциясе кебек, тәҗрибә вә акыл сорый торган катлаулы һәм четерекле шөгыльне, бала-чагага ышанып тапшырмыйча, үз кулына алырга карар кылды полковник Гаяров. Шуннан да кулайрак чараны күрми иде ул төн юлының аргы башында.

Аның өчен әлегә иң аянычы шунда иде: үзенә ифрат килешеп, гәүдәсен кысмыйча, сыланып торган, шул ук Сакманов бүләк иткән, яраткан кәстүмен тиз кия алмаячак. Танып алулары ихтимал.

Берәүгә дә аңлы рәвештә начарлык кылмаган, нарасый җан, матурлыкка сизгер Рафаэль Сакмаровның ничек, ни рәвешле үлеме турында оста шымчы Гаяров та, абыйсы Сәет тә белми калдылар. Көтелмәгәнчәрәк булды бу фаҗига...

*Дәвамы бар*

КАЗАН УТЛАРЫ

## ХӘТЕР

**Ел арты еллар үтә тора. Журналыбыз сәхифәләрендә ул елларның һәркайсысы, әлбәттә, үз эзен калдыра бара. Без шул сәхифәләр аша ил-халык тормышын, тарихыбызны күзаллый алабыз.**

**Ел арты еллар белән бергә юбилейлар да чиратлашып үтә торалар. Әгәр дә чирек гасырлар белән исәпләсәк, журналыбызның беренче егерме биш еллык бәйрәме 1947 елга туры килгән. Сугыштан соңгы ач-ялангач ил... Әле Иосиф Сталин исән... Кая ди инде анда журнал юбилейлары уздырып тору! Бүгенге әдипләребезнең дә әле күбесе тумаган да...**

**Ә инде «Казан утлары»ның ярты гасырлык гомере (1972) — безнең күз алдында. Журналның илле еллыгына багышланган санында (№ 5, 1972) бер төркем язучыларның «Безнең анкета»га җаваплары урнаштырылган. Янә егерме биш ел үткән: хәзер ул язучыларның да өчтән икесе арабызда юк...**

**Әйдәгез, укып карыйк әле: үз журналлары «Казан утлары» турында мөхтәрәм әдипләребез (хәзер инде күбесе вафат) ул вакытта нинди фикерләр әйтеп калдырдылар икән? Сезнең игътибарга берничә өзек китерәбез.**

## Афзал Шамов

### Журналның бер нөсхәсе

...Бөек Ватан сугышы елларында без, фронттагы язучылар, «Совет әдәбияты» журналының һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Безнең өчен бик кадерле кунак иде ул. Аның яңа саны килгән саен көннәр күңелле бер бәйрәмгә әверелә иде дисәм дә, арттыру булмас.

Кызганычка каршы, журналны тәртипле рәвештә ала алмый идек. Хәрәкәттәге армиягә подписка юк иде. Бары бандероль белән генә килә иде ул безгә.

...1943 елны журналны алдыруда шактый зур өзеклек булды. Тылга, каләмдәш иптәшләребезгә хатлар язып, ялынып-ялварып та алдыра алмаган чакларыбыз булгалады. Андый вакытларда журналның яңа санын гына түгел, хәтта күптәнге саннарын күрү өчен дә әллә ни бирергә әзер идек без.

Журналның чираттагы саннарын күрергә сусап йөргән шундый айларның берендә, ... каты сугышлар барган көннәрдә, алгы сызыкта бер лейтенант миңа, сүз ара сүз чыгып:

— Безгә моннан бер ай чамасы элек «Совет әдәбияты» журналы килде,— диде.

— Ул журнал кайда соң? Миңа биреп тора алмыйсыңмы?



*Язучылар Фатих Хосни (уңда) һәм Афзал Шамов. 1976 ел.*

Кызганычка каршы, биреп тора алмый икән. Оборонада торганда журнал батальондагы татар сугышчылары арасында кулдан-кулга күчеп йөргән, аны аерым-аерым да, җыйнаулашып та укыганнар. Ә хәзер ул күрше батальондагы татар сугышчыларында икән. ...Сугышчылар аны тылдан, туганнарыннан, әти-әниләреннән килгән хат кебек итеп укыганнар.

...Шулай да мин әлеге журналны табу бәхетенә ирештем. 1943 елда чыккан 5 нче санның бер нөсхәсе иде ул.

Гадәттәге нөсхә. Сугыш елларындагы начар сыйфатлы саргылтсу кәгазьгә басылган. Буявы шактый тонык. Хәреф хаталары да җитәрлек. Шулай да аның тышкы күренеше, торышы һәм язмышы кызык иде.

Тышлыгын ертып алганнар. Әлеге лейтенантның әйтүенә караганда, аның эчке ягы буш булган, ягъни анда бернәрсә дә басылмаган. Кәгазь юклыктан йөдәгән сугышчылар моңа бик шатланганнар, шунда ук аны ертып алып, тылга, әти-әниләренә, туганнарына хат язганнар. Ике хатка җиткән, ике кешене бәхетле иткән.

Журналның текстлы өлеше беренче битеннән алып соңгы битенә кадәр тулысынча сакланган. Әмма ул, укыла-укыла, кулдан-кулга йөри-йөри, шул кадәр тузган, таушалган, күпереп, калынаеп киткән, аерым юллары хәтта танымаслык хәлгә җиткән иде — кыскасы, иң бәхетле, иң укылган китап язмышын башыннан кичергән иде ул.

...Бу кызыклы вакыйгадан соң инде бик күп еллар үтте, бик күп сулар акты. Шулай да журналыбызның әлеге укыла-укыла тузып, керләнеп, каралып беткән нөсхәсе, аның язмышы әле һаман күңелемдә, күз алдымда.

*

## Мирсәй Әмир

### Зур байлыгыбыз

...«Казан утлары»... һәрвакыт әдәби хәрәкәтебезнең иң тулы күрсәткече булу белән бергә, язучы белән укучы арасында иң эшлекле арадашлык хезмәтен дә үтәп килде һәм килә. Без моңа шул кадәр ияләшкәнбез, көндәлек тормышыбызда һавага, суга һәрвакыт игътибар итеп тормаган кебек, шундый журналыбыз барлыгын да бик табигый һәм гади хәлгә санап йөрибез.

Юбилей уңае белән аның турында бер-ике авыз сүз әйтү өчен кулга каләм алып уйлана башлагач тоясың: никадәр зур байлыгыбыз бит ул безнең «Казан утлары»! Безнең өчен, язучылар өчен һава белән су дәрәҗәсендә кирәкле зат бит ул! Аны алдырып өйрәнгән укучы өчен дә ансыз тору кыен. Юбилей көннәренә хас гадәт буенча гына түгел, чын-ихлас күңелдән янып әйтәсе килә: яшә, озак еллар буена еракларга балкы, «Казан утлары»! Редакциянең портфельләре берсеннән-берсе әйбәтрәк әдәби әсәрләр белән һәрвакыт тулып торсын! Укучыларың саны елдан-елга арта барсын!

*

## Фатих Хөсни

### Анның яктысында...

Кайчандыр Галимҗан Ибраһимов, Гомәр Гали кебек мөхтәрәм әдипләребез редакциясендә «Безнең юл» исеме белән чыгарыла башлаган бу журнал соңыннан берничә мәртәбә исемен алыштырды, редакторлары алышынды — берәүләре китте, икенчеләре килде, ләкин журнал үзе китмәде, дөресрәге, без аңардан китмәдек, ул безнең өчен — татар язучылары өчен гел шулай безнең юл булып калуында дәвам итте. Әле дә шулай! Рус классикларыннан берсе, ялгышмасам, Тургенев бугай, әйтә: «Без барыбыз да Гогольнең «Шинел»еннән чыккан кешеләр»,— ди. Шуңарга охшатып бүген без — әлегә исән булган татар язучылары бер авыздан диярлек әйтә алабыз: әйе, без шул бер юлдан — «безнең юл»дан килдек һәм шул юлдан килеп ялгышмадык шикелле...



*1972 елгы редколлегия әгъзалары. 1 рәт: Утырганнар. Сулдан-уңга: Ш. Маннур, М. Әмир, Г. Ахунов, Л. Ихсанова, Ә. Еники; 2 рәт: Сулдан-уңга: Р. Нәфиков, А. Расих, Ш. Галиев, Р. Мостафин, Г. Халит.*

...төп әсәрләрем — «Йөзек кашы», «Гыйльмениса», «Минем тәрәзәләрем», «Язмыш шуклыгы» кебек үзем бик яратып язган повестьларым, «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» кебек романнарым һәм күп санлы хикәяләрем бөтенесе шушы журнал битләрендә беренче укучыларын таптылар...

Ничек кенә димик, кай яктан гына килмик, без — татар язучылары гел шул үзебезнең ияләшенгән «Казан утлары» яктылыгына килеп чыгабыз...

*

## Әмирхан Еники

### «Безнең юл» — «Казан утлары»

Уйлап утырам... Беренче әйберем («Озын көй тынлаганда» дигән нәсер иде ул) «Безнең юл»да басылып чыкканда миңа унҗиде яшь булган икән. Ә хәзер... Хәзергесен әйтеп тормаганда да була. Кыскасы,

шул заманнан бирле кырык алты ел узып та киткән. Журналга исә менә илле яшь тулды. Димәк, без бергә картайганбыз! Хәер, журнал картаямыни ул?.. Журнал яши дә яши, буыннардан-буыннарга күчә-күчә яши, тик без генә олаябыз, китәбез, алышынып торабыз... Һәм шулай булырга тиеш тә ул!

...Соңгы егерме биш ел дәвамында инде мин журналның даими авторларыннан берсе булып таныldым дип әйтсәм, бу, шәт, мактанудан саналмас. Һәрхәлдә, барлык повестьларым һәм хикәяләремнең күп өлеше, шулай ук очерк-мәкаләләрем аның битләрендә басылып чыктылар. Билгеле, мин аңа бик үк ияләштем, төп иҗат йортым итеп карарга өйрәндем.

...Мин үзем җитлеккән әдәбият һәр җәһәттән дә бик төрле булырга тиеш дигән карашта торам. Һәр язучы, һәр шагыйрьнең үз дөньясы, үз йөзе булса гына талантлы һәм кызыклы әсәрләр туарга мөмкин. Менә безнең хөрмәтле «Казан утлары»быз, бай традицияле җитди журнал буларак, әнә шул төрлелекне... куәтли һәм чагылдыра алса, ул киләчәктә дә әдәбиятыбызның чын көзгесе булып калыр дип ышанасы килә... Бик озын гомер телим мин аңа!

*

## Риза Ишморат

### Ярату хисләре белән

«Казан утлары»... Казанның гына түгел, бөтен республикабызның, әдипләребезнең генә дә түгел, бөтен халкыбызның да уй һәм хисләре, гүзәл эшләре ялкын булып чагыла кебек бу журналда. Ана телебездә әсәр дөньяга килү белән аларны иң беренче булып бастырып чыгара торган әдәби журналыбыз, халкыбызның тормышы, культурасы елдан-ел үсә барган кебек, ул да үсә, эчтәлеге белән дә, сыйфаты белән дә байый һәм яхшыра барды.

Мин журналны беренче еллардагы саннарыннан башлап, димәк, илле елга якын, өзлексез диярлек укып килүчеләрнең берсе. Шикләнмичә әйтә алам, тормыш һәм әдәбият белән танышуда, эстетик зәвык тәрбияләүдә, шулай ук язучы буларак үсә баруымда зур ярдәм итте ул миңа. Күп санлы әдипләребез белән якыннан танышу, аралашу, дуслашуыма да сәбәп булды.

«Казан утлары»ның киләчәктә тагын да көчлерәк балкуын, аның битләрендә әдипләребезнең тагын да гүзәлрәк әсәрләре барлыкка килүен телим.

*

## Гамил Афзал

### Журнал миңа нәрсә бирде?

...Унтугыз ел тырышканнан соң гына мин әдәбиятка килдем. Башкортстанның Шәрип авылында каты авырып, «миннән булмас ахрысы, инде үлсәң дә ярый» диебрәк шигыләнә башлаганда, 1955 елның ноябрь аенда «Совет әдәбияты» берьюлы тугыз шигыремне бастырып чыгарды. Шуннан мин терелдем, аякка бастым, урамга чыктым. Журнал миңа киң юл бирде, нык канатлар бирде, биек трибуна бирде, тырышкан ташны яра икән дигән ышаныч бирде.

Мин биек трибунадан халык белән сөйләшә башладым, адымым ныгыды, тавышым көрәйде, җиргә каты басып йөреп була, колач салып йөзеп була, кадерен белеп эшлә дә эшлә генә.

«Казан утлары»н кайнар котлыйм, аңа зур тиражлар, талантлы авторлар телим! Укып исләрең китәрдәй романнар, пьесалар, хикәяләр (кибәк түгел), ялкынлы поэмалар, энҗеләрдәй шигырьләр елга булып агып килүен телим. Берсеннән-берсе гүзәл шедеврларның кайсын алданрак басарга белми редакторлар аптырасыннар! Амин.

## Илдар Юзеев,

Татарстанның халык шагыйре

* * *

Аңа хәзер берни кирәк түгел,
«Саумы?» диеп бер сүз дәш аңа...
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь тама.
Өмет өзәргә дә күптән вакыт,
Ярың — янда, үзең — яшь ана.
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь тама.
Очрашулар башка насыйп булмас,
«Бәхил бул...» дип, бер сүз дәш аңа...
Синең күзләреңнән яшьлек ага,
Аның күзләреннән яшь тама.

*

## Нажар Нәҗми,

Башкорстанның халык шагыйре.

### Хәтерләү

*Гамир Насрый истәлегенә*

Кайда барма — үткән искә төшә,
Ә үткәннәр ерак калалар.
Шулай инде — гомер узган саен
Хәтерләүләр арта баралар.

Артсын әйдә... Ләкин алда хыял,
Күпме өмет барыр юл сала.
Алда — хыял... Артта — хәтерләүләр...
Кеше яши шушы уртада.

Ирексездән сине хәтерләем,—
Караш салам диңгез иңенә.
Ул кемнәрне генә кочмаган соң,
Тик оныткан сине, мине дә.

Без утырган ташка дулкын кага,
Таш бирешми дулкын какса да,
Ташлар озак яши: йә шомарып,
Йә мүкләнеп-нитеп булса да.

Мәңгелеккә килмәгәнмен мин дә,
Вакыт үтә — булмый баш булып;
Ташлар озак яши... Ярый әле
Яратылмаганбыз таш булып.

*

## Шәүкәт Галиев,

Татарстанның халык шагыйре

### Кол Галигә

Сигез гасыр элек җырларыңны
Яраткан да халык, ятлаган.
Шуннан бирле аны онытмаган,
Күңелендә көйләп саклаган.

Каерылган күпме канатларның
Кауырыннан каләм очладың?
Көнләгәнсең әле: шул кошлардай
Ник иректә бераз очмадым?..

Кушаматың нигә «Кол» икән дә,
Кемнәр сиңа богау кидерде?
Мәхәббәтең — җырның канатлары
Сине азат көнгә китерде.

Күңел белән күрәм мин барыбер
Колларыңны бәйсез кул итеп.
Галине дә мөмкин кол итәргә,
Чын шагыйрьне булмый кол итеп!

*

## Равил Фәйзуллин

### Туганнарга

*Бергә чакта ускән идек*
*тал тамырлары кебек!*
Халык җыры

Безне бергә кайчак кайгы гына
җыя хәзер Туган нигезгә...

Без төрлебез төрле тарафларда
мәшәкатьле Тормыш-диңгездә.

Шатлыкларның, хәтта бәйрәмнәрнең
көче житми очраштырырга.
...Ә бит беркөн беребез ким булып,
туры килер басып торырга!..

*

## Рәшит Гәрәй

### Мендәр

Без бит инде өйдән читтә яшәп,
Төрле жирдә йоклап өйрәнгән.
Баш астына каты булмасын дип,
Әнкәй миңа мендәр жибәргән.

Мамыклары аның шундый йомшак,
Әнкәемнең кулы шикелле.
Сүрүенә төшкән бизәкләре
Киек казлар юлы шикелле.

Шул юллардан гүя кире кайтам
Малай чагым калган көннәргә.
Бәбкәләрем үсеп житкәннәр дә
Йон биргәннәр минем мендәргә.

Нәрсә житә үзең туып-үскән
Чирәмнәрнең тәмле исенә!
Кыйгак-кыйгак диеп каңгылдашып,
Йорт казлары керә төшемә.

*

## Ренат Харис

### Ясак

Кайчагында кылын чиртәм гитараның...
Чың чыгармы, көй чыгармы — битараф мин.

Чиртәм, чиртәм... Читкә куям уйнамыйча,
инде миңа моң кергәнен уйламыйча.

Һәм шул төндә миндә бер көй яңгырый башлый...
Ул матур Көй ап-ак йөзле, кыйгач кашлы.

Күкрәгемә куя да Көй җылы кулын,
ала туңган йөрәгемнең авыртуын.

Шундый итеп Көй иркәли мине, назлый —
уяныргa, күз ачарга хәтта базмыйм!

Уянамын... Күзем ачам теләмичә...
Гитараны кая куйдым соң мин кичә?..

Аны табам... Ә төш кайтмый... Инде беләм —
төше өчен түли кеше өне белән...

*

## Марс Шабаев

* * *

Әллә инде илаһилык иңә?
Әллә кайдан,
Мәңгелектән гүя
Өнме, моңмы —
Сүзсез бер җыр килә...
Адымымны көйләп шул җырга,
Кушылмакчы булам...
Чыкмый барып!
Таш диварлар көлә кубарылып,
Чыңлый гүя еллар-зынҗырлар!
Кара инде: бу нинди тамаша?! —
Әллә мең ел, әллә йөз ел аша
Ташлар җырлый икән, ташлар ласа —
Телен бел дә тыңлый бел генә.
Тыгыз итеп тезәп иңне иңгә,
Тигез сафта таш урамнар килә,
Җырлап килә гүя Ил белән!
Ул моң-җырда — Сөембикә сылу,
Ул моң-җырда — Кабан-Болак суы,
Ул моң-җырда — халык үч-ярсуы,
Ерак калган чорлар авазы.
Иван Явызларның өне анда...
Яна һаман, яна алсу таңда —
Кандай кызыл Казан һавасы.
Атлар чаба, чак-чок чакма чага:
Тояк асларыннан чаткы чыга!
Казан шулай чаба...
Килер чорга
Ашкыналар урам ташлары.
Даһиларың һәйкәлләрдән карый,
Һәрбер ташың, Казан, моңлы тарих, —
Тыңласыннар заман яшьләре.
Мин һәйкәлләр өмет итмим, шәһәр!
Дан-шөһрәт тә көтмим һич ул кадәр...
Сәгать суккач, мөмкин булса әгәр,

Тик бер ташың булыр идем, дим.
Төннәрендә ташлар җырлаганда,
Урыным белеп кенә, мин һаман да
Өн-моң булып торыр идем, дим...

*

## Рәдиф Гаташ

* * *

Биек күтәргәннәр — егар төсләләр:
Сурәтләреңдә кемнәр ул — көчлеләр?

Нык куллардан төшерми үстергәнме
Милләт кызын — ил агасы ишеләр?

Яшь хыялны күкләргә караткандыр
Юл башында әнә шундый кешеләр!

Ник аларны куенына алган соң җир? —
Язмышларның көчледә ни үче бар?

Ә шагыйрьне Тәкъдир үзе саклыйдыр! —
Мәңгелекнең без белмәгән көче бар...

Тусак та монда, җаныбыз — Күктәндер:
Тик хыялга — үз, Җиргә без — үксезләр!

Рухны шуңа биектә йөртүче без —
Язмышларны Җыр итүче «көчсезләр»!

*

## Зөлфәт

* * *

Һичберкем дә түгел, үзем бу,
Яшь чагымда әйткән сүзем бу:

«Күз нурларым күкне уяр күк,
Күкрәгемә дөнья сыяр күк —
Үз-үземне кайчак аңламыйм,
Әллә кеше, әллә Алла мин!»

Еллар узды... Инде уйлыйм мин —
Чын дөресен әйтәм, алдамыйм:

Алла чакта — кеше түгел мин,
Кеше чакта — бераз Алла мин...

*

## Мөдәррис Әгъләм

### Аздан тора

Яздан тора дәвам,
Яздан тора,
Илгә кайтып безнең табигатьтә
Яши алыр киек каздан тора —
Дәвам яздан тора.

Көчтән тора дәвам,
Көчтән тора,
Үткән белән бүген җитәкләшеп
Бара торган үзгәрештән тора —
Дәвам эштән тора.

Сүздән тора дәвам,
Сүздән тора,
Кеше заты синең сүзең белән
Китеп бәхет тапкан эздән тора —
Дәвам бездән тора.

Хистән тора дәвам,
Хистән тора —
Туган телең дигән Ана йортка
Җыелып килә алыр көчтән тора.

...Ә чын язмыш
Үзең язган гына...
Аздан тора дәвам,
Аздан гына...

*

## Роберт Миңнуллин

### Халык шагыйрьләре

*Сибгат ага Хәким истәлегенә*

Халык шагыйрьләре берәү, икәү...
Күпме алар безнең халыкта?
Халыкныкы булалмаганнар бар,
Тарихларда аты калып та.

Әй, татарның Алып шагыйрьләре!..
Һәркем сыймый андый калыпка.
Халыкныкы алар! Шагыйрьләрнең
Калганнары керә халыкка.

Халык шагыйрьләре үзләре дә
Халык арасыннан калыккан.
Әллә шуңа, читтән караганда,
Аерып та булмый халыктан.

Сибгат Хәким буйлы гына алар,
Хәсән Туфан төсле чал, чандыр.
Тукай гына чалармаган килеш,
Япь-яшь килеш киткән кайчандыр.

Кайгы килсә, алар үз халкының
Күз яшьләре белән язгандыр.
Кан белән дә, яшь белән дә язу
Алар язмышына язгандыр.

Күз яшьләре сүз яшьләре булып
Җырга тамган андый елларда.
Ул яшьләрне кемнәр сөртте икән,
Ярамаганда да еларга?

Ә аларны исән чакларында
Кадерләрлек юкса, санларлык.
Болай да бит алар өчәү, дүртәү...
Бармак белән генә санарлык.

Халык шагыйрьләре китә тора —
Кемнәр килер, кемнәр таныйлыр?!
Исән булсын халкым! Халкы булса,
Шагыйрьләре аның табылыр!

*

## Харрас Әюп

* * *

*Айрат Арслановка*

Юкка гына ук атылганмыни? —
Тигәндер шул,
Илгә тигәндер...
Ил ярасы — ирләр йөрәгендә,
Аваз ала икән синнән бер:

Кычкырасың,—
Йә ул шигырь була,
Йә күкләргә ашкан җыр була.

Гомерлек бер моңга әйләнергә
Яратыла икән ир бала.

Үзәк өзеп күтәрелә бит ул
Күкрәктән, йөрәк түреннән,—
Бәлки күкләр газиз бәндәсенә
Эндәшәдер шулай, кем белгән?!

Савыгадыр аны тыңлаганнар,
Сабырлыклар җанга иңәдер.
...Заманнарның иң кирәкле сүзе
Ирләр йөрәгендә нигәдер...

*

## Лена Шагыйрьҗан

### Хакыйкать

Сулар ага, еллар ага, гомер ага...
Җир үзе дә бер искерә, бер яңара.
Үзгәрәләр кешеләр дә, нигезләр дә.—
Бертөрлелек сыя алмый бу дөньяга...
Һәммә җисем сайланышта, үзгәрештә.
Тик бер нәрсә кала мәңге бер рәвештә:
Ул — хакыйкать! — Бүгенгеме,
кичәгеме —
Аерма юк!
Без табынган бу изгелек ни зурлыкта?
Без соң аның бөтенеме, кисәгеме?..
Тик хакыйкать бүленмәгән өлешләргә —
Ваклап булмый аны алтын-көмешләргә!

*

## Гәрәй Рәхим

### Төркиядә татар китабы

*1996 елның мартында Төркиянең Истанбул каласында татар китабы күргәзмәсе эшләде. Аны оештыру һәм тантаналы ачу эше миңа тапшырылган иде. Бу шигыремне күргәзмә эшенә олы ярдәм күрсәтүчеләр — «Төрк доньясын өйрәнү» вакыфы президенты Туран Язганга һәм «Татурос» ширкәте президенты Рево Һидиятуллинга багышлыйм.*

Автор

Иртән Казан... Көндез Истанбулда...
Заман белән бергә очабыз...

Казанда кар... Ә без Истанбулда
Төрек чәчәкләрен кочабыз.

Төркиягә китап илтәбез без,
Үзебезнең татар китабын...
Китап таратучы мөсафирлар —
Без тик китап белән отабыз.

Безнең белән бер очкычта бара
Чын Мөхәммәт[1]... Мисле пәйгамбәр.
Акыл җыйган бу аксакал әйтә:
— Китап булган җирдә бәйрәм бар.

Китап булган җирдә — дуслык, әхлак
һәм тормышның яхшы дәвамы.
Күр, табигать безгә көйләп куйган
Пәйгамбәрләрчә шәп һаваны!

Пәйгамбәрнең адашы да үзе...
Уртлап татлы суны йотабыз...
...Без берьюлы ике Мөхәммәтнең
Әйткән васыятен тотабыз:

Төркиягә татар күңеленең
Иң кыйммәтле уен илтәбез.
Татар бит без, бөтен дөнья буйлап
Тик матурлык, тик җыр йөртәбез.

Мөхәммәтләр фатихасын бирде.
Васыятьне тәгәл тотабыз —
Чыңла, татар моңы, Төркиядә,
Бар төреккә, татар китабы!

*

## Рашат Низамиев

### Кайта җавап...

Җәйге чиллә...
Тир агызып күкрәгемнән
Ургый-ургый печән чабам карурманда.
Чү! Зәңгәр күк дер селкенде — үткен чалгым
Килеп тиде йөз яшәгән тамырларга.

Куркытылган кошлар очты пырхылдашып,
Күркә яуды ике нарат арасына.
Нигә әле моңсуланып калды урман:
Кагылдыммы берәрсенең ярасына?

[1] Төркиядә татар китабы күргәзмәсе оештыручылар белән бер самолетта татар халкының күренекле дәүләт һәм җәмагать эшлеклесе Мөхәммәт Сабиров та очты.

Әллә вакыт, әллә хәтер — тиен сыман
Сикереп уза агачларның башларыннан.
Бабам яккан учакларның төсе булып
Кайта җавап, кайта туфрак асларыннан.

Бу дөньяда кемнәрнеңдер күккә карап
Булды микән нәкъ минемчә уйланганы?
Учлам-учлам йолдызларга, яфракларга —
Һәммәсенә йогып калган кеше җаны!

Тоташтырып сагышларны, әйтерсең лә,
Басып торам ике заман арасында.
Нигә әле моңсулыкка чумды җиһан:
Кагылдыммы мәңгелекнең ярасына?..

*

## Марсель Галиев

### Бәгырь өзгәләнгәндә

*Без бар идек, без юк инде.*
Латин әйтеме

Алланың канат астында
күпме урын дауладык.
Учакларга кырау тиде —
дөрләп китә алмадык.

Каргалган туфрак ташларын
кочаклады тамырлар.
Ил җуйганны, гидай кавем,
бары таштан танырлар.

Кыямәт көне килгәндә
күктән әмер бирелер.
Идел тулып аккан каннар
шаһитка әверелер.

Таркалган җаннарга карап
ни әйтер соң хөкемдар?
Хәрабәләр кайтавазы
бары сыктап сулкылдар.

Бирелгән иде югыйсә
Тәңренең коч-фәрманы:
Кылдай кылыч йөзләрендә
биетергә дөньяны!
Булмады...

Төшеп утыр инде хәзер
тамырың төпкеленә.

Җиңелгән арыслан риза шул
ишәкнең типкәненә.

Шундый уйлар кайнап алды
сыгылган күңелемдә.
Күз яшендә олыгаеп
кояш баеган мәлдә.

*

## Камил Сәгадәт

### Андый чакта...

Аеры үскән
Мәгърур агачларның
Җилләр күбрәк башын идерә.
Давыл-афәт ешрак ябырыла,
Яфракларын яшен көйдерә...

Әгәр мин дә
Бер көн ялгыз калсам
Кем янәшә басар яныма?
Киләчәккә өмет өзелгәндә
Кем көч бирер горур җаныма?

Кайчак шундый уйлар килә башка.
Андый чакта
Сиңа эндәшәм:
Ә үзем соң
Бер ялгызың калсаң,
Баса алырмынмы янәшә?
Баса алырмынмы янәшә?



# ТАТАР ПЕН-ҮЗӘГЕ КОЛАЧ ҖӘЯ

**Журналыбызга 75 яшь тулган көннәрдә безнең хәбәрчебез Татар ПЕН-үзәге президенты Туфан МИҢНУЛЛИН белән очрашты һәм аңа берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.**

*— Туфан әфәнде, язучыларыбызның яңа оешмасы барлыкка килүгә дә берничә ел узды бугай инде?*



— Әйе. Төгәлрәк әйтсәк, быелның 19 апрелендә безгә дә ике яшь тулды. Әнә шул комшлы яз көнендә Татар ПЕН-үзәгенең оештыру җыелышы булган иде. Инициатив төркем 1994 елның көзендә эшли башлады үзе. Шул ук елда язучылар, журналистлар, галимнәр, рәссамнар, артистлар — татарның иҗади эшлекләре бергә тупланып, «Татарстанга үз ПЕН-үзәге кирәкме?» дигән мәсьәләне тикшерделәр. Шунда: «Әйе. Республикабызны, халкыбызны, әдәбиятыбызны һәм тулаем мәдәниятебезне халыкара мәйданда танытыр өчен чын-чыннан демократик иҗади оешмабыз кирәк»,— дигән фикергә киленде.

Без менә шулай 1995 елның язында җәмәгатьчелеккә үз авазыбызны ишеттердек һәм шул ук елның ахырында Республикабызның юстиция министрлыгында хокукый берләшмә булып теркәлдек. Милли ПЕН-үзәкләр Бөтендөнья язучылар ширкәтенең — Халыкара ПЕН-клубның бер өлешен тәшкил иткәнлектән, без әле шунда кабул ителмичә, тәмам туып җитә алмый идек. Былтырның ноябрендә безнең дүрт вәкилебез — Разил Вәлиев, Рафаэль Мостафин, Әхәт Мушинский, Вахит Юныслар Татар ПЕН-үзәген Халыкара ПЕН-клубта теркәтү максатында Мексиканың Гвадалахара шәһәрендә узган язучыларның Бөтендөнья Корылтаенда катнаштылар, 124 илнең вәкилләре килгән шушы Корылтайда алар тарафыннан инглиз телендә татар һәм аның әдәбияты хакында доклад сөйләнде (Вахит Юныс). Конгресс делегатларына республикабызны таныту эшен башкардылар. Шуннан соң безне Халыкара ПЕН-клубка бертавыштан кабул иттеләр. Әйтергә кирәк, бу — безнең өчен куанычлы хәл булды, чөнки анда кайбер бәйсез илләрнең дә язучылары оешмасы кабул ителмәве сер түгел.

*— Туфан әфәнде, бәлки Сез шушы уңайдан, ПЕН-клуб турында бераз аңлатма да биреп китәрсез?*

— Халыкара ПЕН-клуб 1921 елда барлыкка килгән, аны оештыруда К. Э. Даусон-Скотт һәм Дж. Голсуорси кебек атаклы шәхесләр башлап йөргән. ПЕН-клуб иҗат ирекен тәэмин итү, җәбер-золымга каршы көрәшү, дөнья ха-

лыклары арасында мәдәни кыйммәтләрне алмашу максатын күздә тота. Хәзер ул милли үзәкләр аша бөтен дөньяны колачлаган куәтле оешма булып тора.

— *Татар ПЕН-үзәгенең шундый оешмада тулы хокуклы әгъзага әйләнүе күңелле. Киләчәктәниләр майтарырга җыенасыз?*

— Без татар телендә язучыларны табигый, тулы канлы иҗади тормышта яшәтер өчен тышкы дөньяга ишекләр ачтык. Хәзер безгә төрле илләрдән һәм кыйтгалардан, бигрәк тә ПЕН-клубның штабы урнашкан Лондон шәһәреннән әдәбият, хатлар, факс язмалары, хәбәрләре килә. Кайчандыр «тимер пәрдә» артында яткан дөньяга тәрәз ачу һәм йөзгә-йөз, турыдан-туры аралаша алу зур ганимәт. Хәзер без татар шигърияте җыентыгын инглиз телендә бастырып чыгарырга әзерлибез. «Бүгенге татар әдәбияты» еллыгын инглиз телендә чыгара башларга һәм бөтен дөньяда таратырга ниятләп торабыз. Планнар күп, тик без әле хәзергә аякка басу дәверендә генә. Барлык мәсьәләләрне тиз генә хәл итү мөмкин түгел, без дәвамлы һәм мәшәкатьле эшкә керешүебезне яхшы аңлыйбыз.

— *Пен-клуб Татар ПЕН-үзәген нинди эшләргә җәлеп итә?*

— Милли ПЕН-үзәкләрнең бер вазифасы — Халыкара ПЕН-клуб корылтайларында катнашу. Бөтендөнья язучыларының нәүбәттәге җыйналышы Англиянең Эдинбург шәһәрендә узачак. Быелның 5—11 августында безнең вәкилләр дә шунда юл тотачак.

— *Кемнәр?*

— Әлегә Әмирхан Еники, Равил Фәйзуллин, Вахит Юныс исемнәрен генә атый алам. Бүтәннәре якын арада сайланачак. Шуңа аеруча игътибар итегез: алга таба Бөтендөнья Корылтайларында без Татар ПЕН-үзәге әгъзаларының һәммәсе катнашуын күздә тотабыз. Нәүбәтләшеп.

— *Татар ПЕН-үзәге президенты бу корылтайда да катнашмаячакмы?*

— Чит илләргә җитәкчеләрнең генә барып йөрүен мин әдәп-демократия кысасына сыймый, дип уйлыйм. Шундый гадәттән баш тартуны яңа оешмабызның хөрриятккә тугрылыгын раслый торган билге итеп саныйм. Каләмдәшләрем дөнья күрсен әле, киләчәктә мина да форсаты чыгар. Иң мөһиме — туган әдәбиятыбызны дөньяга лаеклы итеп таныту, шуны кайгыртыйк без!



**Зөлфәт Хәким**

# ГӨНАҺ

РОМАН

## 2

Карлы-яңгырлы кыш җитте. Учебка тормышына ел фасылының үзгәрүе зур үзгәреш кертмәде. Яңа елны Фәиз төнге патрульдә нарядта каршылады.

Аны көнаралаш нарядка куйдылар. Кулиш аның тетмәсен тетте. Фәиз кырмыска шикелле үрмәләде, тырышты.

Соңгы вакытта аны һаман бер үк уйлар бимазалады. Кулиш белән булган әңгәмә бәгырьгә яңа җәрәхәт ясады. Эчең черек синең дигәне, никтер, нык тәэсир итте. Шулай бугай шул. Шуңа күрә дусларым да юктыр. Кулиш нидер сизенде, нәрсәдер миндә күреп алды. Башкалар күрмәгәнне абайлады.

Кимчелекләр комплексы Фәиздә артты, ишәйде. Шул ук вакытта буйсынмаска тырышып та карады Фәиз. Каршы әйтте, хәтта взвод командирына да киреләнеп каршы әйтә башлады ул. Нарядларны өстәп кенә тордылар үзенә. Анда бер караганда, рәхәтрәк, ничектер тынычрак, чөнки — ялгызың. Нарядта конкрет эш бар, шуны эшләп бетергәч, утырып тәмәке тартасың.

Буйсынмаска тырышуы, асылда, үзендә җәзага ихтыяҗ тоюдан иде аның. Әмма ул үзе моны аңламый иде. Буйсыну ул — җәза дип, Фәизнең баш иясе килми, ә буйсынмаган өчен исә катырак җәза ала. Ничектер, җәзага сусау бар иде аңарда. Нечкә күңеллелек тә үзен ныграк сиздерә башлады. Җитешсезлекләр комплексы көчәя барды. Кайчан бетәр бу интегүләр. Аңа инде бөтен взвод ниндидер бер пычрак эш башкаручы ишәккә караган шикелле карый иде. Ул моны сизеп, көннән-көн үзенә ныграк бикләнә башлады. Үз дөньясына бикләнеп, газаплы уйларга чумса да, режим, хәрәкәт аның кан йөрешен тигезләштереп торды. Солдат тормышы яшь организмны әлегә депрессиядән саклап кала килде.

Хәле җиңел булмады, әмма шул ук вакытта ул үзендә моңарчы сизелмәгән горурлык хисе барлыкка килүен тойды. Гүя, ул кайдандыр эчтән үсенте сыман шытып чыкты. Җан газаплары кичерүен ул кайвакыт үзенең башкалардан өстенлеге итеп кабул итә башлады. Кайчан туды соң әле мондый хис-кичереш — анысын анык кына әйтеп булмый. Әллә эшелон белән монда килгән чакта, ТЕГЕ ВАКЫЙГАНЫ уйлаудан

---

Дәвамы. Башы 3, 4 саннарда.

туктап, аң беркавым ял иткән чордамы? Бәлки шул вакыттадыр. Ялгызы калырга насыйп булган минутларда, бигрәк тә йоклар алдыннан, тузан эчеп авыраеп беткән одеялга төренеп уйлаганда, үзендә, хәтерендә, күңелендә аңа гына хас һәм башка беркемдә дә кабатланмас «байлык» бардыр шикелле тоела иде. Җан газабы аңа башкалардан ниндидер өстенлек бирәдер шикелле — моны ул акылы белән түгел, вөҗүденең кайсыдыр аң топалмаган урыны белән тоя иде. Хәрби тормышның коточкыч һәм җан биздергеч муштрасы, идиотизм дәрәҗәсендәге үзара мөнәсәбәтләр тәэсирендә ул ГАЗАП каядыр тирәнгәрәк кереп яшеренгән иде. Ләкин ул бар, ул качмады, бетмәде. Аңа бары тик уңай шартлар гына кирәк, ул яңа галәмәт зур көч белән күтәрелеп бимазалаячак, җаныңны суырачак. Аның турында кемгә булса да сөйлисе иде. Чөнки ул ГАЗАПНЫ югалтасы килми, аны гел барлап, капшап, котыртып торасы килде. Ул кирәк, ул булырга тиеш. Чөнки *теге вакыйга* булды. *Теге вакыйга* нәтиҗәсендә туды ул газап. Ә теге вакыйга аның дусты Зәбир белән бәйле. Ә Зәбир белән детдомда шау-гөр килеп узган балачак еллары бәйле. Юк, кирәк ул газап, ул җәза кирәк. Ә бу газап кына аз түгелме соң? Дустын үтергәне өчен?! Шушы сорауга җиткәч, үзен изүче чынбарлыкка ул табигый хәл дип карарга тырышты. Кичеп чыккысыз кайгы хисе аны бер яктан сытарга тырышса, икенче яктан ул газап башкалардан гамәлгә ашмаган ниндидер өстенлек дәгъвалады. Сәер горурлык бар иде үзәктә. Үзе өчен генә, фәкать эчтә. Тышка чыгып, тирә-юньдәгеләрнең күзенә ташланырдай горурлык түгел иде ул. Гәрчә Фәиз үзендә ошбу горурлыкны вакыт-вакыт сиземләсә дә, бу халәтнең хәтта янәшәдә басып торган кешегә дә мәгълүм түгеллеген белмәде.

Эчтә, күңелдә ниндидер хөкем бара дип горурлану хисе иде ул. Кулиштан, офицерлардан наряд-җәза алу бик читен һәм мыскыллы булса да, бу күренештә аңа гына хас ниндидер нәрсә бар иде. Кулишка каршы әйтеп, аның белән әрләшеп, хәтта взвод командиры каршында да киреләнеп куюы мескен булмыйм дип протест ясавы иде. Ә бит алай тәртипсезләнүе, буйсынмаска тырышуы өчен аңа җәзаны арттыра гына бардылар. Эшнең дә пычраграгын, нарядларның да авырракларын бирә башладылар, өс киеменә, кыяфәтенә дә таләпләрне арттырдылар. Мыскыл булмыйм дип тагын да мыскыллырак хәлдә кала иде ул. Димәк, аңарда бу хәлгә мохтаҗлык булган. Һәм дә шундук бу халәте белән горурлану хисе уянып куя — мин буйсынмыйм! Шуңа күрә михнәт чигәм. Протест белдерәм! Һәм минем протестыма күз йоммыйлар, мине инкарь итмиләр. Алар минем киреләнүемә җавап бирәләр. Наряд бирсеннәр. Димәк, алар мине күрәләр, мине инкарь итмиләр. Мин — бар! Менә ул — мин! Мин беткән кеше түгел! Мин бөтенләй яраксыз, бөҗәк булсам, минем белән сөйләшеп тә тормаслар иде, мөгаен. Юу-у-ук, әнә бит Кулиш ничек каныга миңа. Взвод командиры да күралмый башлады бугай инде. Димәк, Фәиз кемнәрнеңдер нәфрәтен уята ала. Әгәр җәза бирмәсәләр, бәлки, киресенчә, авыррак булыр иде әле.

Ха-ха, беркөнне Кулиш кычкыра:

— Курсант Сибгатуллин! Взвод кинодан кайтуга расположениедәге идәнне юып куй!

Фәиз кычкырып җавап бирде:

— Юмыйм!

Бөтен взвод таң калды.

Тагын төне буе Кулиш аңа нотык укыды, тагын янады. Һәм, сүзендә торып, барыбер Фәизне эшләргә мәҗбүр итте.

Бу халәттә каршы тору — үзенә каршы тору икәнне Фәиз аңлый алмады.

Үзгәреш кирәк иде тагын. Бер үк казарма, һаман шул ук чырайларның бертөрлелеге белән үзәккә үткән режим, Кулиш, битараф кыяфәтле офицерлар — барысы да тәмам җанны биздерде. Тизрәк китәргә иде

боевой частька. Анда «бабайлар» бар ди, хезмәт авыр ди. Мондагыдан да читенрәк микәнни?!

Февраль уртасында, батареяны тезеп куеп, дивизионның замполиты чыгыш ясады. Коммунизм идеяләреннән читкә тайпылган Кытай социалистик Вьетнамга каршы сугыш башлаган. Бу хәбәр учебканы бераз пошаманга калдырды, чөнки Совет Армиясенең дә катнашуы ихтимал. Әлбәттә, яшь йөрәкләрнең күбесе дәртләнде — сугышларны кинолардан гына күреп үскән малайлар арасында сугышка омтылучылар да байтак иде.

Гәрчә сугыш моннан би-ик еракта барса да, бу хәбәр Фәизгә ниндидер аңлатып булмаган өмет, ышаныч бирде. Сугыш! Совет Армиясе бу сугышта Вьетнамны яклап катнашачак дигән имеш-мимешләр күңелне күтәреп җилкендерде. Бөтен нәрсә үзгәрер сыман иде. Сугыш булгач, бөтен нәрсә буталып бетәчәк ләбаса. Кайбер кылган эшләр пүчтәк булып кала, күп нәрсә онытыла, күп нәрсә гафу ителә, күп нәрсәгә башкача карыйсың. Дөньяга карашлар үзгәрәдер. Ниһаять, сугышта ничек тә акланып буладыр — кем алдындадыр, нәрсә алдындадыр. Китәргә иде шул сугышка.

Бу аның җәза эзләве, чистарынуга булган ихтыяҗ галәмәте иде. Әлбәттә, моны аңы белән аңламый иде ул. Кытай белән Вьетнам чигенә барып окопка ятып, бөтен дөньяны тетрәндергән сугышта үзенә урын табасы килде.

Әмма ләкин анда сугыш дәвам итте, монда, учебкада исә, тормыш гадәттәгечә барды. Политзанятиеләр генә ешайды — курсантларга социализм белән капитализм арасындагы аерманы, Көнбатышның кабахәтләр оясы икәнен, Американың атом-төш коралы белән дөньяны көлгә әйләндерергә хыялланууын — барысын да политработниклар кәбестә шулпасы белән туенып шыр сөяккә калган курсантларга чәйни-чәйни аңлаттылар.

Майор, авыз кырыйларын күбекләндереп, сөйли дә сөйли, курсантлар кайсы йокымсырап, кайсы туган йортын сагынып, һәркем үз хыялы белән саташып утыра.

Фәиз дә үзенең уйларына чумган.

Их, Зәбир дә монда булса иде. Аның белән болай авыр тоелмас иде. Ул янәшәсендә утыручы украин егете Багинскийга карап куйды. Багинский борынын казып утыра иде. Аңа нәрсә, тиздән сержант звaниесе алачак ул. Кайчан өйдән посылка килер икән дип хыялланып утыра. Посылкада: эре-эре тоз сибелгән ап-ак дуңгыз салосы, сарымсак, прәннекләр... Багинский аңа никтер бәхетсез булып тоелды. Ничек инде бер кайгысыз, уйсыз, борын казып ваемсыз утырмак кирәк!

Зәбир монда булса, Багинскийга төрттереп берәр нәрсә әйтеп куяр иде инде! Ну пычак телле иде Зәбир. Багинскийны күралмас иде ул. Тук чырайлыларга аның гел нәфрәте куба торган иде. Нәрсә белә, ни аңлый бу дөньяда Багинский? Әйтерсең лә, Багинскийның гаебе бар. Ә ул исә, берни белмичә, озак итеп, рәхәтләнеп борынын казып утырды.

Зәбир белән детдом бакчасында качып тәмәке тартырга өйрәнгәннәре искә төште. Әүвәле Зәбир олырак малайлардан бу һөнәрне отып алды, аннары инде дусты Фәизгә өйрәтүне үзенең бурычы дип санады. Тәмәке тартканнан соң күңелләре болганып, косасылары килеп интегә иде Фәиз. Ә Зәбир, күрәсең, һәр яктан нык булгандыр — ул үзен бик әйбәт хис итә иде. Барыбер өйрәнде тәмәке тартырга. Ташлап кына булырмы аны алга таба, юкмы?

Кинәт *теге вакыйга* кылт итеп исенә төште. *Теге урын* күз алдына аермачык килде. Онытккан лабаса. Тыныч кына исенә төшереп утыра. Дустын коткармады да...

Вакыт-вакыт, Зәбир исәндер, кайчандыр, кайдадыр бер очрашырлар, дигән хыял да уянып куя иде күңелендә. Ләкин бик кыска гомерле хыял

була иде ул. *Теге вакыйга* күз алдында бит! Һәр мизгеле хәтернең кул җитәрдәй урынында гына саклана. Бәлки ул төштә булгандыр дип үзен алдамакчы да кайчак, әмма алдау мөмкин түгел. Юк, төш түгел иде ул!

Дустының, соңгы тапкыр кулларын сузып, күзләрен акайтып күккә каравын хәтерендә калкыткач, Фәиз, үзен урамга алып чыгып атып үтерсәләр дә, каршы килмәс хәлгә җитә иде. Шул ук вакытта тирәяктагыларга нәфрәт арта иде. Үзендә коточкыч гаеп сизеп, иң куркыныч җәзаларга әзер булган минутларда да аңарда чынбарлыкка каршы торырдай горурлык бар шикелле. Болар, янәшәдәгеләр, хөкем итәргә тиеш түгел аны, аларның хөкем итәргә хаклары юк. Ул үзен-үзе хөкем итә иде. Менә шул үзең алдындагы җаваплылыкны, үз хөкемеңнең коточкычлыгын бу батареяда аңлаучы бармы соң?! Казарманың тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп акыручы чуваш Кулиш моны аңларлыкмы? Взвод каршында икенде күләгәсе хәтле гәүдәсен бөкрәйтеп торучы лейтенант Тереховкамы соң курсант Сибгатуллин күңелендә ниләр кайнаганны аңларга! Бу солдатларга аңлатып буламы соң синең нинди бәлагә дучар булып, нинди җәзага хөкем ителгәнеңне?! Моны бит хәтта Фәиз үзе дә аңламый!

Яз җитте. Карпат якларыннан кар сулары агып төшеп бөтен тирәякны су басты. Агып китәргә иде язгы ташулар белән. Һәм гомер буе агырга да агырга иде. Бөтенләй югаласы килми — үлем куркыта. Әле яшисе килә. Яшәрлек көчләр бар бугай әле. Ә бәлки газапны ахырына кадәр күтәреп алып барырга кирәктер?!

## 3

Якташы булса да, Ренат Фәиз белән аралашмаска тырышты. Ренат хәлле егет, үзен кыерсыттырмый, көче бар, взводта абруйлы. Нигә аңа мондый якташ?!

Кулиш Ренатны да күралмады. Тик монда сәбәп башкарак иде. Ренат тиктормас һәм тәртип бозучан иде. Юк кына сәбәптән сугышып китә. Бигрәк тә украин малайлары белән уртак тел табалмады, тынышмады. Бервакыт дүртенче взводтагы үзе шикелле бер таза хохол егете белән сугышып чак кына трибуналга китмәде. Көч-хәл белән алып калдылар үзен, гауптвахтада ун тәүлек утырып котылды. Шулай итеп, Ренатның да хәлләре учебка батареясендә бигүк яхшылардан түгел иде.

Кулиш күп тапкырлар строй алдында тузынганда кабатлады:

— Арагызда берничә кеше бар — сержант исемен алырга лаек түгелләр.

Һәм фамилияләрне дә тезеп китә иде. Арада һичшиксез Мирзин һәм Сибгатуллин булмый калмый иде.

...Беркөнне аларның икесен бергә стрельбищены сакларга патрульгә куйдылар. Дөм караңгы булса да, язгы урманда гаҗәп рәхәт иде. Алар саф һавада рәхәтләнеп йөрделәр. Буш стрельбищеда шайтан да йөрми, бигрәк тә төнлә.

Алар Кулиштан зарланып, Совет Армиясен сүгеп, аулакта эчләрен бушатып, дот өстендә утырдылар. Бераз зарлангач кәефләр күтәрелеп, җиңелрәк булып китте. Ренат Фәизне өнәп бетермәсә дә, рәхәтләнеп сөйләште — ни дисәң дә, якташ бит, бер шәһәрдән!

— Детдомга кадәр кайсы урамда тордың? — дип сорады Ренат, туып үскән шәһәре турында сөйләшәсе килеп.

— «Солнечная» урамында,— диде Фәиз.

— Мин детдом малайларын белә идем. Танцыларга безнең янга йөриләр иде.

Ул берничә исем атады, арада Фәизгә танышлары булмады.

— Без дә Студенческаяга йөри идек танцыга,— диде Фәиз.— Зәбир белән. Зәбирне белмисеңме?
— Юк.
— Минем ахири дустым иде ул.
Фәизнең кинәт аңа барысын да сөйлисе килде, тик нәрсәдер эчтә барыбер комачаулап торды. Юк, юк, Ренат бит шул шәһәрдән, аңа сөйләргә ярамый. Шулай да сүз гел шул шәһәргә, детдом янына, Зәбиргә таба тартты.
— Бик якын дуслар идек без аның белән,— дип кабатлады Фәиз.— Безне бер үк көнне алып килделәр детдомга. Кабул итү бүлмәсендә икебезне бергә оформлять иттеләр. Ничектер, бик нык дуслашып киттек.
— Аны армиягә алдылармы соң?
— Юк.
— Т.да калдымыни?
— Белмим.
Ренат авыр сулап куйды.
— Әйдә, бер тартып алыйк.
Алар тәмәке кабызып рәхәтләнеп тарттылар.
Фәизгә Зәбир турында сөйләшү кызык тоелды һәм аның дәвам итәсе килде:
— Зәбир синең шикелле көчле, кыю малай иде. Минем кебек җебек түгел.
Ренатка исә ниндидер Зәбир турында мәгълүматлар бөтенләй кирәк түгел иде.
— И-и-их, Т.га кайтырга иде тизрәк,— диде ул, киерелеп.— Ирекле жизнь, девочки... Аракы эчмәгәнгә дә ярты ел була бит инде. Тагын ел ярымнан артыграк служить итәсе бар шул әле!— Ул әшәке итеп сүгенеп куйды.
Фәизнең әңгәмәне тагын Т. каласына юнәлтәсе килде.
— Син ишеткән идең микән, Т.да ювелирный кибетне басканнар иде бит.
Фәизгә әңгәмәдәшенең бу вакыйгага мөнәсәбәте, алтын урлаучылар турында нинди фикердә булуы кыйммәт иде.
— А-а,— дип сузды Ренат, әйтерсең лә, ниндидер бер пүчтәк вакыйга хакында сүз чыккандай.— Теге «Культтовары»дагымы?
— Әйе,— диде Фәиз һәм тып-тын калып көтте.
— Х... безмозглая!— диде Ренат һәм караңгылыкка лачт итеп төкереп куйды.— Дурдом!
— Кемне сүгәсең?..
— Кибет җитәкчеләрен дә, каракларны да. Кем инде алтын әйберләрне сейфка бикләмичә пыяла витрина астында калдыра? Ул көнне сейфка япмаганнар бит...
— Кайдан беләсең?
— Ишеттем.
— Анда каравылчы бар иде.— Фәиз телен тешләде.— Каравылчы булган бит анда.
— Нинди каравылчы! Каравылчы эчеп унбиш суткага эләккән булган, ул көнне каравылчы да сакламаган.
— Ничек инде булмасын! Ни сөйлисең син?!
— Син нәрсә, белгән кеше шикелле сөйләшәсең...
— Миңа да сөйләделәр. Анда бит бер ир кеше булган каравылда.
— Юк сүз сөйләмә! Бернинди каравылчы булмаган ул көнне.
— Кем булган икән соң ул?— диде Фәиз үзе өчен генә.
— Каракларын да әйтер идем.
— Ә нәрсә караклар?
— Тоже җүләрләр.
— Җүләрләрме, юкмы, аларны тота алмадылар бит.
— Кем әйтте моны?

— Беләм.
— Беләсең, әбиеңнең келәсен! Алар инде күптән төрмәдә.
Фәиз шашынып көлеп җибәрде. Бу әңгәмә аңа күпмедер дәрәҗәдә ләззәт бирде, әмма бу күңел күтәренкелеге нормаль хәл түгел, ниндидер авыру, сәламәт кешегә хас булмаган кәефлелек иде.
— Ничек инде төрмәдә?
— Шулай.
— Ә берәр кеше үлмәгәнме ул көнне кибеттә?
— Юк, анда үлүче булмаган. Директорын снимать иттеләр эшеннән.
Фәизнең бу дуамал егет сөйләгәннәргә ышанасы килмәде, шулай да күңелендә зур кызыксыну уянды. Әңгәмә ШУЛ ВАКЫЙГА тирәсендә баруы белән мавыктыргыч иде.
— Кемнәр булган соң ул караклар?
— Әллә тагы. Кавказ кешеләре диделәр бугай.
— Син белеп сөйләшәсеңме, юкмы?
Ренатның ачуы кабара башлады.
— Между прочим, сине менә шушындый сарык булганың өчен ярат-мыйлар... Мондый сәер кешене бер коллективта да уважать итмиләр! Син нәрсә, мин монда туфта сөйләп утырам что ли!
— Ярар, кызма инде,— диде Фәиз, аның нервылануына чын күңелдән борчылып.— Ә алтын?
— Нәрсә алтын?
— Урланган алтыннарны кайтарганнармы соң?
— А куда денутся?! Аларны бит шул урланган алтыннары белән тотканнар да.
Фәиз төпченергә җөрьәт итмәде, гәрчә кат-кат сорап, энәсеннән җебенә кадәр белешәсе килсә дә.
Фәизгә бу әңгәмә бик ошады. Зольмәт уртасында ниндидер яктылык күренде шикелле. Белоруссиянең нарат урманы уртасындагы караңгылык нибары бер ышык урын булып кына калды. Теге вакыйга өндә булды ләбаса. Күрәсең, алтынны кемнәрдер тапканнар да, аларны гаепләп, төрмәгә утыртып та куйганнар. Сөенергәме, тагын көенергәме?.. Ә бит Зәбир барыбер исән түгел!
Фәизгә болай да җирәнеп караучы Ренат һаман әле тынычланып җитмәгән иде:
— Син нәрсә мине, берәр х... малайга саныйсың, что ли!
— Юк ла инде, гафу ит.
— Сине физически көчсез булганың өчен түгел, менә шундый сәер булганың өчен, үзеңә бикләнеп бич шикелле почмакта утырганың өчен яратмыйлар.
Фәиздә инде Ренатка эчендәге серләрен ачу теләге югалды. Ярый әле хәсрәтемне сөйләмәдем бу холыксыз бәндәгә, дип күңеленнән генә куанып куйды ул.
Алар тып-тын гына тагын берәр папирос тарттылар. Стрельбище тирәли ике тапкыр абына-сөртенә әйләнеп чыктылар.
Ренат тынычланды. Ял итәргә туктагач:
— Минем батя эшли торган урман да менә шулай густой,— диде ул.
— Нинди лесхозда соң ул?
— Красно-Ключинский. Ишеткәнең бармы?
— Әллә тагы...
— С... поселогын ишеткәнең бармы?
— С...?..
— Районный центр ул.
Фәиздә тагын ялкын кабынды:
— Исемә төште! С...ны белмәскә! Минем анда больницада ятканым бар,— дип ычкындырганын сизми дә калды.
Юкка-барга исе китми торган Ренат аның больницада ятуы белән аз гына да кызыксынмады.

— Менә шул поселоктан өч чакрым баргач урман башлана. Красно-Ключинский лесхозыныкы ул. Минем әти шунда директор.
— Карале, анда сазлыклар да бар бит.
— О-о-о, анда үтеп булмаслык урыннар бар.
— Анда батып үлүчеләр дә бардыр?
— Нишләп булмасын.
Фәизнең сөйләшерлек хәле калмады. Ренат кына әтисе эшли торган сазлыклы урман турында, шул урманга кызлар белән күңел ачарга баруларын, озак итеп, сүгенә-сүгенә сөйләп йөрде.
Ренатның кибеткә бәйле мәгълүматларына тәгаен ышанып җитмәсә дә, алтынны тапкан кешеләрне төрмәгә утыртулары, чыннан да, ихтимал иде. Монысына ышанып була — кемдер рюкзакны тапкан да, аны тотып утырткannар.
Әмма *теге вакыйга* Фәизнеке. Аның гаебен бернинди яңа хәбәр җиңеләйтмәс.
Ренатның сөйләүдән арып туктаган мәлен чамалап, Фәиз кинәт сорап куйды:
— Карале, Ренат, сазлыкта батып үлгән кешене эзләп табып буламы?
— Ю-у-ук, син нәрсә...— Ул беркавым уйланып торды.— А черт его знает. Бәлки специальный приспособлениеләр белән буладыр...
«Ренатка сөйләсәм, сатмас микән? Андый егеткә охшамаган. Мондыйлар әләкче булмыйлар. Әмма шул ук вакытта мине яратмый бит ул. Әгәр сөйләп, ярдәм сорасам? Юк, ярдәм итмәячәк... Ничек ярдәм итсен инде ул. Әнә, спецприспособлениеләр кирәк ди бит... Әй, юк, моңа сөйләргә ярамый.
Армиядән кайткач күз күрер».
— Ә сазлыкта мәет чериме? — дип бәйләнде ул якташына.
— Ну син таптың тема сөйләшергә! Кругом кап-караңгы урман... Ә син — мәет, сазлык...
Әмма Фәизгә *ул вакыйга* белән бәйле булган бер нәрсә дә куркыныч түгел иде. Ул Зәбирнең акайган күзләреннән дә, калтырап сузылган кулларыннан да ул вакыйгадан бәйсез рәвештә курка иде, ул курку аның үзендә иде. Моның өчен инде сазлыклар, урманнар кирәкми, бу турыда кабергә төшеп сөйләшсән дә — *ул вакыйга* аерым бер дөнья булып вөҗүдтә яшәде.
Ренатның каты бәрелүенә Фәизнең исе китмәде. Бу каты бәгырьле кешедән әллә нәрсәләр көтәргә була. Әле күптән түгел туалетта, курилкада Кравчук фамилияле бер малай белән сугышты. Кравчукны үтерә икән дип торырсың. Бик каты кыйнады. Күн итеге белән эченә китерә дә тибә, китерә дә тибә. Аның вәхшилегенә Фәиз кат-кат таң калды.
Бу вакыйганы исенә төшергәч, Ренатка карата кинәт нәфрәте уянды. Аңа башта эчендәге серләрен ачарга теләп, шулай да җөрьәт итмәү — күңелдә канәгатьсезлек калдырды, теләк үтәлмәде. Зур ихтыяҗ гамәлгә ашмады. Бушану насыйп булмады. Кинәт нәфрәтләнүнең сәбәбе бәлки шул булгандыр?
— Син Кравчукны теге көнне чак кына үтермәдең бит...— диде ул көтмәгәндә.
Ренат аның бу кыюлыгына гаҗәпләнде һәм тыныч булырга тырышып:
— Үзе гаепле,— диде.
— Син аның эченә типкәндә...— Фәиз калтырый башлады.— Син аны ничек кызганмыйсың... Авыртадыр дип уйламыйсыңмыни?!
— Син нәрсә, мин кыйнамасам, ул мине кыйнар иде. Син бүген генә дөньяга туган кеше шикелле сөйләшәсең!
— Юк, алай түгел! Әгәр үтергән булсаң?
— Юу-у-ук, кеше эчкә типкәннән генә үлми.
— Кеше абынып егылып та үлә. Батып үлә.

— Ирек бирсәң, көчсезлегеңне күрсәтсәң, үзеңне шундук таптап китәләр.
— Кешенең тәне авырта, җаны сызлый дип уйламыйсыңмыни син?
Ренат ни әйтергә белми аптырап торды. Аннары караңгыда Фәизнең битен чамаларга тырышып кычкырды:
— Син миңа нотык укыма, яме! Үзең хәлсез булгач, рәхәтме соң? Бөтенесе таптап өстеңнән йөриләр. Санга сугучы да юк! Үзеңне яклап бернишли алмыйсың! Шуңа күрә мораль укып утырган буласың бит син!
— Алай түгел. Аңламадың син мине.
— Аңлыйм. Көчсез кеше гел мораль укый башлый ул. Запомни, һәркемнең үз морале бар, һәркем үз көченә карап мораль сайлый.
— Бәлки шулайдыр,— диде Фәиз ишетелер-ишетелмәс.— Чыннан да, шулай бугай шул. Тик син миңа кычкырма инде. Миңа болай да бик авыр. Көчсез булсам да, бик авыр йөк күтәреп йөрим мин.
— Ул Кравчукның авызын җимерәм әле мин! — диде Ренат тешләрен шыгырдатып.
— Каты кеше син. Миһербансыз. Шуңа күрә мин синнән бераз көнләшәм дә. Синең шикелле каты бәгырьле, хиссез буласы килә кайвакыт.
Ренат көлеп аның иңеннән каккалады:
— Нindидер шизанутый син, брат. Сәер син, сәер. Армиядә делать нечего сиңа!
— Бәлки миңа дөньясында делать нечегодыр,— диде Фәиз төннең чиксезлегеннән калтыранып.
— Ансы синең эш, земляк. Ха-ха-ха. Әйдә, тартыйк тагын берәрне.
Сөйләшергә сүз дә бетте.
Фәиз тагын үзенең күңелендә казынды. Чыннан да, мин соңгы вакытта мораль укый башладым, гаделлек таләп итәргә тотындым түгелме? Мин үземнең кем икәнемне, нинди җинаять кылганымны онытып, миһербанлык эзлим түгелме. Хакым бармы соң? Кем соң мин? Бәлки шундый кайгым барлыгы миңа хокук бирәдер, бәлки мин башкалар аңламый торган нәрсәләрне аңлыймдыр. Дөресрәге, тоямдыр. Ай, артык акыллыланып киттем әле мин. Нишләп үземне «кыйнарга» омтылам соң һәрвакыт? Мин бит әле белмим, алданиләр көтәдер, киләчәктә нинди сынау-җәзалар насыйп булыр. Тәкъдир ниләр кушкан икән алда? Шуңа күрә, бәлки үземне кыйнарга да, мактарга да ашыгырга кирәк түгелдер.
Аның фикер йөртүе гражданкадагы шикелле түгел иде инде. Ярты ел вакыт эчендә олыгайды, балалыктан тәмам чыкты. Яктылык күренмәсә дә, җанында үзгәреш булды. Үзгәреш гел булып тора ул. Газап үзгәрдеме? Үзгәрде кебек. Юк, үзгәрмәде. Вакытлыча тынып торды бугай. Чөнки хәрби муштра аңа иркенлек бирми торды һәм ... ТЕГЕ УРЫН моннан ерак иде. Арада пространство булу УЛ ВАКЫЙГАГА мөнәсәбәтне үзгәртте. Вакытлыча. Әмма ул вакыйгага бәйле газаплар үзгәрде дигән сүз түгел бу.
Фәиз элегрәк тә кыерсытылган кешеләрне кызганып, кыйналган кешене җәлләп кайгыручан иде. Соңгы вакытта аның бу сыйфаты көчәйде, нечкәрде. Гомумән ТЕГЕ ВАКЫЙГАДАН соң сизгерләнде аның бу сыйфатлары — күңелне әрнетә, елата торганнары. Газап, төрле сыйфатларга әверелеп, үзенең барлыгын белгертеп торды.
Казармага җитәрәк, Фәиз, үзе дә сизмәстән, нindидер көй шыңшып баручы Ренатка әйтеп куйды:
— Син Кравчукны кыйнама бүтән, яме.
Ренат, таң калып, карап барды.
— Ә кыйнасам?..— диде ул, авызын кыйшайтып.
Фәиз каешында эленеп торган штык-пычагының сабын кысып тотты:
— Әгәр дә тагын бер тапкыр аңа суксаң, мин сине төнлә, йоклаганда, суям.
Әйтеп бетергәндә аның авызы корыды, күкрәге кысылды, битенең тиресе тартылганны тойды.

— Син нәрсә, зема! — Ренат аны беләгеннән тотып туктатты.— Син кемгә угрожать итәсең?! Сука! Мин синең үзеңне менә шушында хәзер ботарлап ташлыйм бит!
Ул Фәизне шинель изүеннән эләктереп җилтерәтеп алды.
— Җибәр,— диде Фәиз тыныч кына.
— Сиңа кем соң ул Кравчук? Ул хохол үзе миңа бәйләнде башта. Мин аңламыйм, сиңа нәрсә, проблемалар җитми что ли! Син на свою жопу приключение эзлисең? Мин бит хәзер синең чыраеңа берне тартсам, син үләсең, урод!
Фәиз дәшмәде. Әллә нинди Кравчукны ник яклаганын үзе дә аңламады ул. Шул ук вакытта ярсып шашкан Ренаттан да курыкмады. Аның бу матавыкны тизрәк туктатасы килде. Ренат аның битенә төкрекләрен чәчүдән туктасын гына берүк. Бик авыр менә болай ызгышып торуы — ни башы юк, ни ахыры.
— Гафу ит, җибәр мине,— диде Фәиз.
Аның кинәт гафу үтенүе Ренатка тәэсир итте, ул аны җибәрде. Нәрсә булса да аңларга тырышып, ул Фәизнең шәүлә кебек гәүдәсенә карап торды. Атып килгән таң яктысында Фәиз өрәк сыман басып тора иде.
Ренат берни аңламады һәм:
— Ублюдок! — дип төкерде дә казарма бинасына кереп китте.
Фәиз баскан урынында катып калды. Минме соң ул Ренатны акылга утыртырдай кеше?! Мин аны сую түгел, кул күтәрә дә алмыйм лабаса. Минем аңа сугарга көчем, рухым җитәме соң?! Әгәренки кодрәтем җитсә... Хәлемнән килгән сурәттә дә — хаклымы соң мин аңа кул күтәрергә? Бигрәк тә мин! Әле күптән түгел генә мәңге юылмаслык кара эш кылган кеше?! Әле *теге вакыйга* өчен дә җавап бирмәдем бит. Әгәр мин кычкырып: «Суям!» — дигәнмен икән, димәк эчтә шундый теләк бар?! Сую түгел, гомумән хөкем итәргә, Ренатны гаепләргә минем ни хакым бар соң?! Ренатның үзенә хилафлык кылмасын өчен кайгыруымы бу? Әллә Кравчукны кызгануданмы?
Ул үзен кеше хәленә куеп карый иде. Үзен Ренат урынына куя да, кыйнаган өчен хөкем ителеп, җәзага дучар булудан курка. Ренатның җәза алу ихтималын үзенә проекцияли. Үзен Кравчук урынына куя да, тагын күңеле сыкрап елый. Ренатның сугуларын үзендә тоя, чөнки Кравчукның тиресенә керү аңа җиңелрәк, көчсезлеге белән ул аңа тартым. Шулай итеп, Кравчук-Ренат мөнәсәбәтләрен күрү аңа ике яктан да авыр иде. Әлбәттә, ул үзендәге хис-кичерешләрнең төп сәбәбен, табигатен анык аңламады. Бары тик күңелендә ярсу, сыкрау һәм кайгыру тойды. Шундый ямьсез күренешләрнең һәрберсе аның күңел җәрәхәтен кузгата, күңел авыруы исә аның үзен шул күренешләрдә, вакыйгаларда «катнашырга» этәрә. Нәтиҗәдә, ул кыйнаучының да, корбанның да роленә кереп карый, һәммәсенең халәтен үзендә кичереп карамакчы була. Шуннан соң аңарда гаепләне хөкем итү теләге барлыкка килә. Ә бу теләктән соң күңелдә яңа конфликт башлана — минем хакым бармы хөкем итәргә?! Шулчакны инде, әлбәттә, үзен гаепләү процессы кузгала.
Фәизнең казармага керәсе килмәде. Әмма барыбер керергә кирәк иде.

## 4

Белоруссиягә Карпат тарафларыннан язгы сулар агып төшкән вакытта башка дивизионнардан боевой частьларга курсантларны алып китә башладылар. Алтынчы батареягә әле иртәрәк диделәр, имеш солдатлар батареяләрен генә әле алып китәләр, ә алтынчы батарея исә тулысынча булачак сержантлар подразделениесе иде.
Шулай да беркөнне уникe кешегә запрос килде. Сержант итеп түгел, рядовойлар булып, уникe специалистны әзерләп куярга. Иртәгә китәләр.

Татарларны ни сәбәптәндер кураалмаучы Кулиш алтынчы взводтан Сибгатуллин белән Мирзинне җибәрергә взвод командирын күндерде.
Якташларның икесенә дә авыр булды бу хәбәрне кабул итү. Сержант званиесе кирәк түгел дип кыланып, батыраеп йөрсә дә, Ренат взводтагы иптәшләре алдында хурлыгыннан үзен кая куярга белмәде. Кравчук әләкләгәндер дип, сүгенеп, аның эченә тагын берәр тапкыр тибәргә хыялланып йөрде.
Фәизгә исә сержант званиесе алмыйча башкалардан алда сугышчан частька китү үзгә тәэсир ясады. Аның өчен дә зур удар иде бу. Үзенең башкалардан ким-хур икәнен ассызыклый торган бер мисал буларак кабул итте ул моны. Учебкадан, бигрәк тә рәхимсез Кулиштан җаны бизсә дә, звание алмыйча, куып җибәрелгәндәй китеп бару аның болай да тотрыксызланган психикасына начар тәэсир итте. Ул тагын коелып инде. Ренат белән бергә китү аның бу халәтен бермә-бер көчәйтте. Ренатның ясалма батырлык белән:
— Күтәр башыңны. На х... сиңа ул звание, хохол таксын погонга лычкасын! — дип Фәизне юатырга тырышуы, киресенчә, болай да ярсыган күңелдә ачуны тагын да ныграк кабартты.
— Забайкальега алып китәләр, — диде батареяның старшинасы. — Хәерле юл.
...Җәмгысы алтмыш рядовойны узып баручы поездның гомуми вагоннарына бүлеп-бүлеп урнаштырдылар. Егетләрне алырга дүрт офицер, алты сержант килгән иде. Алар озаклап, исемлек буенча кат-кат тикшереп, общий вагоннардагы халык арасында таралып беткән солдатларны барлап-барлап йөрделәр.
Фәиз белән Ренат ниндидер бер зур гаилә урнашкан вагонга кысылганнар иде. Ярымкараңгы вагонда ул гаиләнең кайсы ата, кайсы бала, кайсы әби икәнен аңларлык түгел, аларның шау-гөр килеп сөйләшүләреннән генә бер гаилә икәннәрен абайларлык иде. Фәиз белән Ренат өстәге полкаларга менеп кунакладылар.
Вагонның аскы өлешеннән пешкән тавык, тозлы кыяр исләре менеп, борыннарга бәреп керде, ике яшь һәм ач организмда әллә нинди тойгылар барлыкка килде, авыздагы селәгәйне йотып житешерлек түгел иде.
— Безне бүген ашатмаслармы икәнни? — диде Ренат, аска күз ташлап.
— Юктыр инде, төн бит.
Ренат әшәке итеп сүгенде дә борылып ятты, күп тә үтми аның гырлаганы ишетелде.
Ямьсез кеше бу Ренат... Якташ булса да. Кансыз.
Дөрес эшләделәр сержант званиесен бирмичә... Шул кирәк! Күпме кешене кыйнады бит ул взводта. Кравчукны чак кына үтермәде. Фашист. Ә мин шушы кабахәт белән беррәттән, бер вагонда, бер купеда барам. Безнең бит аз гына да охшашлыгыбыз юк!
Дөньясына төкереп карый торган кеше белән янәшә каядыр алып баралар. Мине — юк кына нәрсәдән дә коелып иңүче, борыны канаган малайны да еларга житеп жәлләүче кешене шушы Ренат белән — теләсә кемнең эченә күн итеге белән тибә алучы бәндә белән бер командада йөртәләр.
Ә мин үзем әйбәт кешеме? Аны яманлаган булып...
Астагылар җырлап җибәрделәр — олысы да, кечесе дә.

«Снова птицы в стаи собираются,
Ждет их за моря дорога дальняя»...

Бу җыр бик танылган, аны Алла Пугачева җырлый.
Фәизгә кинәт рәхәт булып китте. Ниндидер бәйрәм хисе уянды, чөнки астан тәмле ризык исе, тигез һәм матур итеп җырланган җыр күтәрелеп кочып алды. Арадан бер ир кеше аның карап ятуын абайлады да киң күңелләнеп кычкырып җибәрде:

— Солдат, монда төш әйдә, йокы симертергә иртә әле!
Фәиз ялындырып тормады, сикереп төште. Шау-шулы компания белән сөйләшергә уртак тема тапмаса да, аларның сорауларына аннан-моннан йолкып җавап бирде. Булган ризыкны рәхәтләнеп ашады. Аракы эчәргә генә курыкты. Офицерлар белсәләр, бәреп үтерәләр дигәч, аны эчәргә кыстамадылар. Бераздан Ренатны да уятып, йолкып төшерделәр.
Берничә тапкыр чыгып тамбурда тәмәке тарткач, тәрәзәдән кырларны, урманнарны байтак күзәтеп баргач, урыннарына менеп яттылар. Әле генә дөньяны куптарып бәйрәм иткән компания, бер-берсенә елышып, утырган килеш йоклап бара иде инде.
Икенче көнне өлкән лейтенант белән сержант аларны җилтерәтеп уятканда, кичәге шаулы компания урынына, кайсыдыр станциядә кереп урнашкан карт белән карчык кына утыра иде.
Солдатларны вагон-ресторанга егермешәр-егермешәр кеше алып кереп ашаттылар. Рестораннарга хас саранлык белән әзерләнгән ризыклар официантны тотып ашардай егетләрнең ач корсакларын бары тик кытыклап кына куйды. Акчасы булганнары, җаен туры китереп, поезд туктаганны чамалап, станцияләрдә пирожки, колбаса алып туендылар.

...Поезд Көнчыгышка таба баруын дәвам итте.
Берзаман:
— Мәскәү, Мәскәү,— дигән тавышлар ишетелде.
— Мәскәүгә килеп җиттек!
— Мәскәү инде бу!
— Ниһаять!
Азык-төлек, әфлисун, лимон, затлы кәнфит сыман нәрсә, колбаса ише ризык һәм дефицит товар юнәтергә баручылар өчен, әлбәттә, «Мәскәү» — татлы сүз. Йөрәк турысындагы кесәгә партбилет тыгып берәр съездга яисә конференциягә баручы коммунист өчен, һичшиксез, «Мәскәү» — бөек исем. Наданлыгы, томаналыгы аркасында үзе туып-үскән төбәгеннән ары дөнья күрмәгәннәр өчен дә, табигый ки, «Мәскәү» — бөек һәм данлы аваз.
Көнбатыштан Көнчыгышка юл тоткан солдатлар өчен башкалага якынаю алай бигүк илһам өстәмәде. Мәскәүгә якынаю демобилизация приказының көнен һич кенә дә якынайтмады.
Шушы микәнни илнең генә түгел, бөтен дөньяның башкаласы булырга омтылучы серле кала?! Бер дә Мәскәүгә охшамаган ла бу. Кая соң рәсемнәрдә, киноларда күренгән Мәскәү? Аның йолдызлы Кремле күренмәсә Мәскәү икәнен болай гына чамалап та булмый икән. Кызыл мәйданнарын, Ленин мавзолеен күрмәсәң, бу шыксыз, ыгы-зыгылы, соры шәһәрне Мәскәү дип авыз тутырып атап та булмас, мөгаен.
Ни дисәң дә, Мәскәү иде бу, башкаланың Ярославль вокзалы.
Аларны иң элек тезеп санадылар, шуннан соң умарта күчедәй гөжләп торган вокзал бинасы эченә алып кереп утыргычларга урнаштырдылар. Һәм кымшанмыйча да сабыр гына команда көтеп утырырга куштылар.
Мәскәүнең Ярославль вокзалына килеп кергәч, акылы аек һәм бераз уйлый белә торган кеше коммунизмның мәңге гамәлгә ашмаячагын аңлар иде. Башкаланың үзендә бу кадәре шапшаклык, бу кадәре җайсызлык булгач, ил күләмендә ничекләр тәртип урнаштырмак кирәк? Фәизнең моңарчы бер урында бу кадәре күп алкоголикларның җыелганын күргәне юк иде. Куркыныч төшләрдә генә күренә торган чырайлар, кыяфәтләр, әдикалун эчеп яшелләнгән кешеләр монда ялгыш кына килеп эләккәннәрдер дә, махсус поезд менә-менә килеп җитәр дә, алар барысы да төялеп кайсыдыр тарафка китеп барырлар сыман иде. Алар үзләре, үз теләкләре белән, коммунизм төзүгә комачауламас өчен гаип булырлар шикелле иде.
Беркавым киңәшләшеп торганнан соң офицерлар вокзалдан каядыр чыгып киттеләр, сержантлар исә, билгесезлектән боегып, шәлберәеп

калган һәм вокзал эчендә йөрүче чибәр кызларны күз кырыйлары белән генә күзәтеп бимазаланып утырган солдатларны саклап калдылар.

Алты сержант та бер-берсенә ничектер охшаганнар: формалары ятышкилешеп тора үзләренә, барысы да тәкәбберләр, хәрби хезмәтне шактый татыган, дембельгә бер генә адым ясыйсылары калган, олыгайган егетләр иде. Кукыраеп утыручы солдатлар аларга көнләшеп карадылар — шулар урынында булырга иде.

Берәм-берәмләп туалетка барып килергә рөхсәт иттеләр.

Ренат бәдрәфтән килгәч, Фәиз янына килеп утырды.

— Синең күпме акчаң бар?

— Шул, китәр алдыннан бирелгән акча инде — өч сум сиксән тиен.

Ренат пышылдауга күчте:

— Әйдә бераз аракы эчәбез.

— Ничек инде?! Офицерлар белсә бәреп үтерәчәкләр.

— Күп эчмәбез. Алар бит синең авызыңны килеп иснәмәячәкләр.

Бик кызыктыргыч тәкъдим иде бу. Кәефләр бераз күтәрелмәсме. Аракы эчмәгәнгә ярты ел бит инде. Аны эчкәч хәлләр яхшырып китә ләбаса, рәхәт була.

— Ничек итеп, каян алып була соң аны?

Ренат як-ягына карап куйды.

— Мин инде бер сержант белән сөйләштем. Аңа да өлеш чыгарачакбыз. Аның да эчәсе килә. Әнә ул.

Фәиз ул ымлаган якка карады. Өлкән сержант Кавказ егете иде, ахрысы. Кулларын артка куеп ул башка сержантлардан читтәрәк йөрде.

Фәиз шикләнеп Ренатка карады:

— Ә бәлки юри ризалык белдергәндер.

— Син нәрсә, мине җүләргә саныйсыңмы әллә? Бир өч сумыңны. Мин дә өч сум бирәм.

— Кем бара соң аракыга? Кемгә бирәбез акчаны?

— Бир тизрәк. Сержант үзе алып киләчәк. Тизрәк инде.

Фәизнең өч сумын алып, Ренат утыргычлар арасыннан әлеге дә баягы сержантка таба юнәлде. Алар вокзалдан чыгып киттеләр. Берничә минут үткәндерме, Ренат вокзалда янә пәйда булды һәм елмаеп якташы янына килеп утырды.

— Тәртип.

— Алып киләме? — диде Фәиз, әле һаман ышанып җитмичә.

— Нишләп алып килмәсен! Тик менә поезд килгәнче җитешергә иде. Кайчан китәбез икән?

— Белмим.

— Нәрсә, тагын задумался?!

— Ул ничек, сержант башы белән... риза булды... Үз куллары белән солдатларга аракы китереп бирергә.

Ренат көлемсерәде:

— Сержант та кеше бит. Аның да эчәсе килә, тем более бушка. Аннары, ни, мине ышанычлы кеше дип тапкан, димәк.

— Син ничек, бардың да тәкъдим иттеңме?

Ренатның ачуы килә башлады:

— Төпченмә инде! Тик кенә утыр. Хәзер вокзалның артына посабыз да эчәбез. Калганы синең проблема түгел!

Вокзал артындагы автобуслар арасында тиз генә өчесенә алты шешә кызыл аракыны бушаткач алар, берни булмагандай, шешәдәш сержант озатуында үз урыннарына кереп утырдылар.

Кызыл вино тәэсиреннән рәхәт булып китте. Ренатның кыяфәтенә карап исерек икәнен чамаларлык түгел, ә менә Фәизнең башына нык бәрде — ул шундук каты исерде.

— Нык тот үзеңне. Синең кыяфәткә чыкты, — диде Ринат.

— Ярар, — диде Фәиз чайкалып торган вокзалга күз йөгертеп.

Поезд килгәч, аларны тагын тезеп санадылар. Исерекләр барлыгын сизүче булмады. Фәиз янында торучы симез солдат кына аракы исен тоеп, гаҗәпләнеп як-ягына карап куйды.

Тагын гомуми вагон, тагын гражданскийлар белән барырга туры килде. Фәиз нык исерде, шул сәбәпле Ренат аның яныннан ераграк булырга тырышты һәм башка купега элэгү ягын карады.

Ни гаҗәп: Фәизнең халәтенә офицерлар игътибар итмәде, сержантлар да әллә күрмәделәр, әллә үзләре дә салганлыктан, күреп тә игътибар итмәделәр.

Бермәлне Фәиз купеның икенче киштәсендә чайкалып ятуын аңлады. Аста кемнәрдер сөйләште, әмма аның башын калкытып карарлык та хәле юк иде. Кызыл аракы аны киштәгә ябыштырып куйды һәм ул йокыга талды.

Күпме вакыт үткәндер, Фәиз бик читен халәттә уянып китте: бөтен җире юеш, башы әйләнә, кемнәрдер аңа шап та шоп сугалар.

Ул башын калкытты. Киштә юешләнгән — коскан! Астагы гражданскийларга бу пычрак сыекча агып төшкән дә, алар шау-шу куптарганнар.

— Әй, командирлар, бер солдатыгыз монда косып ята! — дип чәрелдәде бер хатын-кыз.

Ир кеше исә, ачы итеп сүгенеп, нишләргә белми һаман кырын ятучы Фәизнең касыгына сугып алды. Теге хатынның тавышы тагын берничә тапкыр ишетелгәч, купе янында дүрт офицерның берсе — өлкән лейтенант пәйда булды.

Фәизнең хәле яман иде — башы чатный, авызда әйтеп бетергесез тәмсез. Поезд туктаган булган икән, һәммәсен чайкалдырып кузгалып китте, Фәиз чак кына киштәдән егылып төшмәде. Караңгыда офицерның йөзен күрерлек түгел иде, аның карауы тавышы шулхәтле каты яңгырады, шуннан соң чыраен күреп торуның да кирәге калмады:

— Иптәш солдат! Минем янга!

Фәиз әле айнып җитмәгән иде, уңайсыз сикереп төшеп кемнеңдер өстенә ауды, ул теге ир кеше булып чыкты, ахрысы, аны икенче якка төртеп җибәрделәр. Берничә тапкыр шулай эткәләп алганнан соң, ниһаять, ул офицер каршына килеп басты. Көтелмәгәнлектән ул хәтта куркырга да өлгерми калды.

Эре гәүдәле, сукса тимер өзәрдәй өлкән лейтенант ниндидер бер урам алкашына караган сыман аңа җирәнеп карап торды да, никтер, тыныч кына:

— Фамилия? — диде.

— Сибгатуллин.

Офицер янында ике сержант хасил булдылар. Тегесе, Фәизләр белән эчкәне, күренмәде.

— Тиз генә кондуктордан чүпрәк ал да пычрагыңны сөрт! — дип боерды өлкән лейтенант. — Аннары минем янга тамбурга чыгарсың!

Фәиз каушаудан «Есть!» — дип әйтергә дә онытып, вагон башына ыргылды.

— Ул якка түгел, чмо! — дип кычкырды бер сержант. — Кондуктор әнә теге якта утыра.

Фәиз, абына-сөртенә, икенче якка китте.

Бер частьтан икенчесенә баручы солдат исереп косып ята дигән хәбәр минуты белән вагонга таралды. Әле тегеннән, әле моннан тәртипсез солдатны сүккән тавышлар ишетелде.

Бу коточкыч ударны Фәиз әле ахырынача аңлап бетермәде. Үзе пычраткан купены чистартканнан соң бер сержант килеп бөтен вагонның идәнен юып чыгарга боерды.

— Бик дөрес! — диде янәшә утыручы олы яшьтәге агай.

Тагын төрле тавышлар ишетелде:

— Маңка!

— Солдат шундый була димени?!

— Салага!
— Утыртып куярга кирәк аны!
— Солдат имеш!..
Бөтен дөнья Фәизгә каршы сыман тоелды. Тизрәк вагонны юып чыгарырга да. Ә кая качасың ди аннары? Танып калмасалар ярар иде. Иртәгә, яктыда ничек вагондагы кешеләрнең күзләренә карарсың.
Идән юганда һәр купедан кем дә булса бер тозлы сүз әйтми калмады.
— Илнең сакчысы, имеш!
— Оят түгелме?
«Оятка калдым. Хурлык! Эчкән булып... Нигә кирәк булды!»
Вагон идәнен аннан-моннан юып чыккач, тамбурга таба китте. Ул инде айнып беткән иде, тик менә төтен эченә күмелеп тәмәке тартып торучы өлкән лейтенант һәм аның янындагы сержант нишләтерләр икән аны хәзер. Хәзер, бернишләтмәсәләр дә, частька барып житкәч командирларына сөйләрләр инде. Ә бәлки шушы өлкән лейтенанттыр әле яңа командиры. Алай булса да эш харап — срок беткәнче җелекне суырачак.
Тамбурга чыккач, ул дер селкенеп барган поезд чайкалуына бирешмәскә тырышып басты:
— Рядовой Сибгатуллин по вашему приказанию прибыл!
— Төшер кулыңны, мудак! — диде өлкән лейтенант кыжрап.— Нишләтергә сине, п.., ә?
— Мин гаепле, иптәш өлкән лейтенант.
Офицер сержантка эндәште:
— Бар купеңа!
Сержант тәмәкесен таптады да тиз генә үз купесына юнәлде.
— Иптәш өлкән лейтенант...— дип Фәиз гафу үтенмәкче иде, ләкин житешә алмады.
— Нишләтергә сине! — дип акырды өлкән лейтенант аның битенә төкереген чәчеп һәм чатнатып яңагына чабып җибәрде.
Фәизнең күзләреннән утлар чәчрәп чыкты. Тамбур кысан булганлыктан, ул егылмады, стенага килеп бәрелде.
— Кайда эчтең?
Әйтерсең лә аның кайда эчкәнлеге нинди дә булса әһәмияткә ия. Хәер, бу сорауны ул җавап алыр өчен түгел, нәрсә дә булса кычкырыр өчен генә бирде. Яңагына гына сугу аз тоелгандыр, күрәсең, бер-ике тапкыр иягенә дә тондырды. Фәиз егылды һәм, үзендә зур гаеп тойганлыктан, тизрәк торырга ашыкты. Өлкән лейтенант эченә китереп оргач, ул озаграк ятты, чөнки бик каты суккан булып чыкты.
Офицер бераз шүрләп калды һәм тавыш-тынсыз ятучы солдатны селкетеп карады. Фәиз аның куркып калганын сизенде һәм әкрен генә торып басты.
— Гафу итегез, иптәш өлкән лейтенант,— диде ул, күпергән иреннәннән канны кулы белән сыпырып.
— Кульяулыгың бармы?
— Юк.
Өлкән лейтенант кесәсеннән кульяулык чыгарып сузды:
— Мә, сөрт. Бар туалетка, ю битеңне.

Аның туалеттан чыкканын офицер көтеп торды, чөнки кызып китеп ныграк кыйнап ташлавына үкенде булса кирәк.
— Рядовой Сибгатуллин. Син армиядә икәнеңне оныттыңмы әллә? — диде ул тыныч кына. Үзе солдатның битендә зур синяклар калмады микән дип җентекләп күзәтте. Чөнки җавап бирергә туры килүе ихтимал. Әләкләсә?! Болай шаһитлар булмады бугай.
Фәиз исә әләкләү түгел, киресенчә, үзен бәреп үтерсәләр дә риза иде бу минутта. Чөнки гаепле иде ул, гаепле!
— Гафу итегез, иптәш өлкән лейтенант, аз гына эчкән идем... качып... Мәскәү вокзалында гражданскийлар салып биргәннәр иде.

— Бар купеңа, йокла!
— Есть!
Ярый әле барысы да йоклыйлар иде. Фәиз мыштым гына киштәсенә менеп ятты.
Өлкән лейтенант үзенең кызып китүенә гаҗәпләнеп, бәләкәй генә гәүдәле солдатны кыйнавына үкенеп тамбурда басып калды.
— «Ә үтергән булсам?—диде ул үзенә үзе.—Берәр җирен сугып сындырган булсам? Болай начар егеткә охшамаган үзе».
Ул һич кенә дә тынычлана алмады. Тарта башлаган папиросын ташлап, вагон эченә ашыкты. Сержантлар купесына килеп берсен уятты:
— Кикнадзе, Смирнов, чиратлашып бу Сибгатуллинны каравыллагыз. Кача күрмәсен.
— Ә ник качсын ул?
Өлкән лейтенант аны кыйнаганын әйтергә җөрьәт итмәде.
— Күп сөйләшмә! Каравыллагыз дигәч, каравыллагыз!
Сержантларның берсе, авыр сулап, торып утырды:
— Есть.
Фәизнең чыннан да качасы килә иде. Ләкин өлкән лейтенантның кыйнавыннан түгел, бәлки үзенең җебеклегеннән, хурлыктан.
Үзен нәрсәдәдер гаепле сизсә, һәрвакыт *теге вакыйга* гаебенә барып тоташа, кушыла торган булды. Күңелдә йөргән гаеп терекөмешенә башка вак-вак гаепнең бөртекләре тоташып бара түгелме?
«Адәм актыгы мин, адәм актыгы! Бу хурлыклар тикмәгә түгел миңа. Әллә сикерергәме поездддан?! Юк! Нәрсә, әллә яшисем киләме? Яшисе килмидер бәлки хәзерге минутларда? Ләкин яшәргә кирәк бит! Чөнки бик зур бер мәсьәләне чишәсе бар!»
Хәл авырайды, нык авырайды. Газаплы уйлар чолгап алып тагын әсир иттеләр.
Икенче көнне вагонда аңа беркем дә игътибар итмәде. Әллә инде кичәге пассажирлар барысы да төшеп, икенчеләре кереп утырган, әллә караңгыда аны танып калмаганнар. Сержантлар да берничә тапкыр үтеп киттеләр, хәтта борылып та карамадылар. Җанга бераз тынгылык керде, чөнки хөкемле күз карашлары күтәп уянган иде ул иртә белән. Ашарга чакырганчы барып тәмәке тартырга булды. Тамбурда берничә кеше бар иде инде, ул шулар арасына кереп тәмәке кабызды.
Тоныкк кына булып аның фамилиясе ишетелде:
— Сибгатуллин!
Һәм тамбурда кичәге өлкән лейтенантның курыккан чырае күренде.
— Мин,—диде Фәиз, каушап.
— Ә, син мондамыни,—диде өлкән лейтенант һәм җиңел сулап куйды.—Тарт, тарт тәмәкеңне. Мин сине югалттым. Шуңа эндәштем.
Шуннан соң өлкән лейтенант китеп барды. Фәиз аңлады: иртә белән офицер аның исән-иминлеген тикшерергә булган. Аны купеда тапмагач, курыккан, күрәсең, төнлә качмады микән дип. Зур гәүдәле, каты йодрыклы һәм шул ук вакытта олы җанлы, кешелекле өлкән лейтенант каршында Фәиз үзен тагын да ныграк гаепле итеп сизде.
Ренат икенче көнне дә якташыннан читтәрәк булырга тырышты. Тамбурда Ренат белән дә очраштылар. Ренат авызын кыйшайтып кызыксынды:
— Хәл ничек соң?
— Начар,—диде Фәиз тәрәзәдән йөгереп артта калган агачларга карап.
— Эчәргә ярамагач эчмәскә идең.
— Болай да сару кайный, аптыратма. Оят. Эчәсе килмәгән көе эчтем бит мин.
— Нык кыйнадылармы?
— Мине беркем дә кыйнамады. Битемне егылып сыдырдым.

— Син нәрсә, миңа үпкәләгән сыман сөйләшәсең! Мине гаепләмәкче буласыңмы әллә?!

— Юк, нишләп мин сине гаеплим. Карале, Ренат, шушы офицер безнең командир булыр микән?

— Юктыр. Болар бит безне алып баручылар гына.

— Син ничек уйлыйсың, частька барып җиткәч командованиегә докладовать итәрме икән өлкән лейтенант бу хәлне?

— Мин сиңа бер киңәш бирә алам. Син өлкән лейтенантка болай дип әйт: «Әгәр дә эчкәнемне частьта докладовать итсәң, кыйнаганыңны әләкләячәкмен»,— диген. Шаһитлар бар дип тә өстәп куй. Шулай дип шарт куйсаң, ләм-мим бер сүз катмаячак бу турыда.

— Юк инде, мин алай шартлар куя алмыйм, хакым юк.

Ренат авызын кыйшайтты:

— Моралист хренов! Алайса нәрсә сораулар биргән буласың. Бигрәк порядочный! Үзе лях исереп купены косып тутырган. Хак турында чәйнәнеп тора ичмасам! Әйдә, обед вакыты җитә, тиздән команда булачак.

Фәиз тамбурда калды. Аның үзенең дә Ренаттан ераграк буласы килде. Ә бит Ренат хаклы. Әле генә дөрес сүзләр әйтте бит ул.

— Сибгатуллин!

Фәиз сискәнеп борылды.

— Мин!

Өлкән лейтенант иде бу.

— Обедка! Мин сезне берәм-берәм җыеп йөрмәм, әйдә тизрәк,— диде ул ачусыз гына. Аның тавышында инде бераз ягымлылык та бар иде шикелле.

Кичәге инцидентның дәвамы булмаганга һәм аның тәмамлануына офицер да, Фәиз дә шат иде.

## 5

Поезд көн-төн барды.

Юлның як-ягында таулар, урманнар, үзәннәр, яшькелт чирәмнәр, әле һаман калын кар катламы яткан тау итәкләре берсен-берсе алыштырып кына торды. Узып киткән шәһәрләрне, поселокларны, авылларны санап бетерерлек түгел.

Аракы эчү аркасында килеп чыккан күңелсез матавык Фәизне озак эзәрлекләсә дә, әйләнә-тирәдәге киңлек, ерак ара үтү барыбер психиканы тынычландырды. «Өлкән лейтенант кыйнады, шул кирәк миңа!» — дип уйлады ул.

Поезд чаба да чаба. Гүя кемнәндер, нәрсәдәндер кача. Кая качмак була, тиле, Җир түгәрәк ләбаса! Мәңге чабып, тоттырмыйм дип качып йөрү мөмкин түгел бит!

Шулай да хәрәкәт — бөек нәрсә. «Хәрәкәттә — бәрәкәт»,— дип тикмәгә әйтмиләрдер. Бару ул — яшәү. Кая барсаң да барыбер — яшәү.

Иң мөһиме — т е г е в а к ы й г а д а н, теге урыннан ерагаю факты бар. Ул, әлбәттә, яңадан кайтачак анда, чөнки кайту — аның бурычы. Бераз тынычлану аның өчен хәл алу гына булыр. Ике ел буена командирларга буйсынып яшәгәндә, хәрби хезмәттә барыбер җандагы төенне чишү мөмкин булмаячак. Шуңа күрә ераккарак китү — яхшырак. Әлбәттә, дусты аның белән һәрвакыт бергә, Зәбирнең соңгы минутларда ялварып күккә каравыннан да ул беркайчан котыла алмаячак.

Шулай да поездның чит тарафларга баруында ниндидер өмет бар: ерактарак, тыныч кына анализлап булмасмы ул фаҗигане.

Бәлки ул армиядән аңлап кайтыр — ник алай килеп чыкты? Нишләп *ул вакыйга* булды?! Вагон тәрәзәсенең салкын пыяласы маңгайны рәхәтләндереп җибәрде. Нишләп *ул вакыйга* булды? Сәер сорау. Ә нишләп соң әле бернichә көн элек кенә исерде, косты, өлкән лейтенант тотып кыйнады үзен? Вакыйгалар «нишләп» була димени?!.

Мин кайтканчы Зәбир инде исән булмас! Барыбер сазлыкка барырга кирәк. Ичмасам киемнәрен табарга иде.

Аның инде ничәнче тапкыр поездан сикерәсе килде. Тик нәрсәдер һаман тота иде. Куркумы? Курку булса, димәк, үлем куркыта. Ә үлем ник куркыта соң? Гәрчә бу дөньяда яшәү газаплы булса да...

Әллә җавап тоту куркытамы?.. Ә бит җавап бирергә кирәк булачак. Юу-у-у-к, иң элек бу дөньяда җавап бирергә кирәктер. Иң әүвәле — үзең өчен!

Моны аңламыйча! — үлеп булмый. Дөресрәге — моны аңламый торып үләргә ярамый!

Соңгы бер-ике айда Зәбир сирәк искә төште, *ул вакыйга* да хәтердә бигүк еш калыкмады. Әле генә булган күңелсезлек газаплы уйлар өерен яңадан кузгатты менә. Гүя пыскып кына яткан учакка коры утын өстәделәр. Ләкин поезд Көнчыгышка барган саен газаплы уйларның тәэсире дә үзгәрә торды. Элеккечә бугаздан буып, сулышларны кысу булмады. Күрәсең, хәрәкәт, яшәешнең тирә-якта поезд артында калуы үзенең серле бер тәэсиренә ия иде.

Вакыт бар әле. Тик менә бүгенгесе авыр, бик авыр. Ләкин бит хәрби хезмәт үтеп китәр, аннары иркенләп үз тормышымны *шул вакыйгага* багышлармын. Яшәү һәм Үлем — капма-каршы төшенчәләр, аның кайсысы начар, кайсысы яхшы соң? Шуны белми торып, нишләп газапланам соң әле? Зәбир белән минем туганнарча дуслыкны *ул вакыйга* юк италмый ләбаса. Әгәр дә якын дустыңның, абынып егылып, сазлыкта батып үлүе ихтимал икән, нигә кирәк бу яшәү! Ә-ә-ә-ә, юк шул, мин бит коткарырга тиеш идем аны. Коткармадым бит. Менә бит эш нәрсәдә! Әллә кайларга кереп уйларым белән адашып йөрим. Югыйсә бик гади җөмлә: коткарырга тиеш идем...

Коткармадым!

Әйдә, барсын поезд, барсын. Кызурак, ераккарак барсын. Бер могҗиза булып, адашсын иде бу поезд. И тиле, адашып та качып булмый шул!

Әнә биек наратлар поездга карап калалар. Аларга бит шушы поездда баручы кечкенә бер кешенең күңелендә ниләр булуы мәгълүм түгел. Ә бәлки мәгълүмдер?! Әллә нинди тузга язмаган фикерләр йөри башта. Югыйсә инде теге каһәр суккан кызыл аракыдан соң тәмам айнуы җитте. Аек чакта уйлар караңгырак әле алар!

«Кулиш дөрес интектергәндер мине. Тикмәгә түгелдер. Әнә бит, эчеп-косып... Фу! Беркем исерек түгел, беркем космады. Ә мин тоттым да башкалардан аерылдым. Пычрак бер үзенчәлек белән. Димәк, Кулиш күргәндер миндәге пычракны? Шулай түгел микән? Бәлки ул минем җай чыкса пычрак юлга басарга сәләтле булуымны күргәндер, аңлагандыр.

Ярар, Кулиш инде ерактa калды. Ул да, дөресен генә әйткәндә, шәп кеше түгел. Аны взводта да беркем яратмый иде. Ә мине яраталар идеме соң?

Поезд тукталды. Ниндидер кечкенә генә станция. Берән-сәрән кешеләр күренгәли. Гадәттә, мондый станцияләрдә кешеләр ашыгып йөрмиләр. Әйтерсең лә алар соңга калудан, кая да булса житешмәүдән курыкмыйлар. Зур-зур йөкләр күтәреп йөрүчеләр дә юк. Күрәсең, мондагылар бигүк бай түгелләр. Бәлки шул бай булмаганга тыныч кына йөриләрдер. Ә бәлки, киресенчә, ашыкмыйча йөргәнгә бай түгелләрдер.

Поезд тагын кузгалды. Станция үзе дә, утлары да кинәт күздән югалды. Тирә-якта ачык кыр башланды, ахрысы. Дөм караңгы иде. Ерактан гына җемелдәп утлар күренде. Өмет сыман ерак, барып житкесез, әмма якты.

Күңелдә дә өмет бар бит. Нәрсәгәдер өмет бар! Үзгәртеп буладыр шикелле — үземнеме, дөньянымы... Әле яңа гына кызыл аракы аркасында күңелсезлек килеп чыгуга карамастан, зур тизлектә каядыр бару,

ерактагы утларны күзәтү, ялгыз гына тәрәзәдән карап уйланырга мөмкинлек булу — барысы бергә күңелдә тонык кына яктылык сирпеп торган бер хисне кымшатты. Өмет бар — нәрсәгәдер, кемгәдер. Болай гына бетәргә тиеш түгел. Болай котылгысыз җимерелергә тиеш түгел тормыш, әнә бит инде ничәмә еллар дәвам итә. Яшәү дәвам итә! Әгәр хатаны төзәтеп, үкенеп, офтанып, ярлыкауны сорап, чистарынып булмый икән, яшәүләрнең мәгънәсе калмый түгелме соң?!

Юк, юк, өмет бар! Әнә бит утлар ничек якты җемелди. Әнә бит поезд ничек нык чаба. Ул бит шул утларга таба бара. Бормаланып, чуаланып, киселешеп беткән юллар барыбер, урап-урап булса да, утлар янган төбәкләргә алып бара түгелме? Гомер поезды төпсез караңгылыкка илтеп атмыйдыр кешене. Барыбер бер якты, җылы учакка китереп җиткерәдер.

Әнә теге тонык кына балкыган нокталарга урап-урап булса да поезд килеп чыгачак. Төнләме, таң аткачмы, көннәр алышынгачмы, еллар узгачмы...

Поезд барыбер яктылыкка юл тотачак.

Күңел күтәрелеп китте. Ул инде тынчу вагоннан чыгып очып каядыр Себер киңлекләрен гизә иде. Ерактагы утларга таба очамы ул? Еракта җемелдәгән утның кайда янып, нәрсәне яктыртып, кемне җылытканын читтән карап белеп булмый шул. Бәлки төрмә бинасыдыр ул. Анда да электр лампалары яна бит. Бәлки хастаханәдер һәм анда кем дә булса үләргә ятадыр. Бәлки гап-гади бер йорттыр һәм анда кичеп чыккысыз кайгы яшидер.

Фу, тагын уйлар караңгылыкка алып кереп киттеләр. Дөм караңгылыкка караганда ут яктысы барыбер яхшырак. Ерактагы утны да начарлыкка юрамаска инде.

Хәрәкәт барыбер җиңде. Поездның төнне ертып баруы йөрәкне тагын җилкендерде. Кешеләр поездны уйлап чыгарганнар икән, димәк, ул каядыр җылы урынга, яктылыкка алып барырга тиештер ләбаса. Алай дисәң, концлагерьларга да поездлар белән алып баралар кешене. Тфү! тагын нинди уйлар!

Юк, юк, барыбер рәхәт поездда бару! Әле соңгы вакытта мондый күтәренкелекнең булганы юк иде. Шул каһәр суккан кызыл аракыны эчеп кенә хаталандым. Югыйсә хәзер күңел тагын да тынычрак, кәефлерәк булыр иде мөгаен.

Офыктагы утлар югалды. Дөм караңгы. Нинди булса да, утлар кирәк икән! Кирәк, кирәк, барыбер кирәк. Өмет кирәк. Өметсез ярамый. Минме, әллә миндәге өметме — еракларга карап киләчәкне эзли?.. Үзеңнән качар өчен күңел офыкка омтыламы, әллә анда утлар булгангамы?

## 6

Байкал арты хәрби округы — Кытай чиге янындагы иң көчле гаскәрләрнең бер өлеше. Байкал күленнән соң Көнчыгышка һәм Көньякка таба хәрбиләрнең нindиләре генә очрамый да, нинди генә хәрби техника күзгә чалынмый! Кызыл погонлылар, кара погонлылар, яшелләр, зәңгәрлеләр. Күктә кошлар да сирәк күренә, чөнки көне-төне истребительләр эскадрильясе рейд ясый. Кытай белән аралар нык бозылышкан — шуңа күрә психологик тәэсир өчен чик буйларын котсыз калдырып имәнгеч тавышлы тимер кошлар күкне берөзлексез айкыйлар. Читаның үзендә гади кешеләрдән хәрбиләр күбрәк, һәрхәлдә урамнарда күбрәк күренә. Хәрби частьта үзенең лампаслары, папахасы белән солдатның йөрәген яра торган генераллар Чита урамнарында гап-гади күренеш санала. Монда Чита армиясенең штабы, командованиесе. Читадан көньякка таба, тыгыз сафлар булып, хәрби фән-техника казанышлары илнең тынычлыгын саклый. Монда кырмыска сыман пехота кай-

нашып тора, танклар армадасы торымнан-торымга тузан бураны куптара, күктә кошларга да урын калдырмыйча истребительләр очып тора. Монда десантчылар күктән җиргә иңеп сопкаларны яулап алалар. «Град»тан атып тауларны, урманнарны яндырып торалар. Җир өсте ракеталары бер тарафтан икенчесенә бал эзләүче кортлар сыман күчеп-күчеп куялар. Шартлау тавышларыннан соң куе кара төтен күтәрелгәч, автомат тавышларына күмелеп, полклар сопкадан-сопкага йөгереп йөргәч, күңелгә шом кереп урнаша. Өйрәнүләр бара дисәләр дә, күнекмәгән кешегә бик куркыныч.

Бөтен дөньяны куркытып торган континентара ракеталар исә җир астында, шахталарда яшеренгән. Алар бит, Җир шарын бер тапкыр әйләнеп чыгып, шуннан соң кирәкле ноктага килеп төшә алалар. Иң куркыныч корал әлегә шул! Әнә шул, җир астыннан калкып чыгып, күккә күтәрелә торган ракеталардан кытайлар тәмугтан курыккандай курка. Кытайлар гына түгел, бөтен дөнья курка алардан. Бер полкның ракеталары белән генә дә кечерәк илне көлгә әйләндереп була лабаса.

Фәиз шартлы рәвештә «Ясная» дип исемләнгән төбәктәге ракеталар соединениесенең тугызынчы полкына эләкте. Ренатны исә сигезенче полкка билгеләделәр. Бу полклар бер бинада: сигезенче полк — беренче катта, тугызынчы полк — икенче катта урнашкан иде.

Коточкыч куәткә ия булса да, ракеталар полкының шәхси составы нибары ике йөзгә якын кеше. Аның алтмышы төрле дәрәҗәдәге офицерлар һәм прапорщиклар, калганнары бер озын һәм киң казармада яшәүче солдатлар, сержантлар.

Йөз кырык солдат йоклап яткан тынчу казармага Фәизне таң атканда алып керделәр дә подъемнан соң офицерлар килгәнен көтәргә куштылар.

«Бытовая комната» дип язылган бүлмәдә, дүрт урындыкны бер-берсенә терәп куеп, сәгать ярым чамасы йокымсырады микән, «Подъем!» — дигән үзәкөзгеч тавыш казарманы какшатты. Моннан да ямьсез сүзнең булуы мөмкин микән? Подъем! Сиңа боералар! Торасың килмәсә дә, син торырга мәҗбүр! Әйтерсең лә син кеше түгел. Фәкать бер хайван. Подъем! Тормасаң, тибеп торгызалар. Подъем!

Аны өченче ротаның техник расчетына билгеләделәр. Техник расчет — берничә кешедән торган отделение — җир астында урнашкан КПның аппаратурасын күзәтеп торучы һәм кирәк вакытта бер-берсеннән шактый ерак арада урнашкан шахталардагы ракеталарны электр энергиясе белән тәэмин итүче подразделение. Техник расчет хезмәт итә торган җирдә ике бина: берсендә ракеталарның кнопкаларына бармакларын куеп Мәскәүдән команда көтүче офицерлар утыра, икенчесендә техник расчет үз вазифаларын башкара. Өч рота, чиратлашып, дивизия расположениесеннән йөз чакрым чамасы ераклыкта урнашкан ракета шахталарында дежур тора.

Әле дежурствога барганчы Фәизгә полкта яшәргә туры килде.

Аларның дивизиясе шактый зур мәйдан биләп тора. Иң беренче нәүбәттә күзгә ташланган нәрсә, мөгаен, алагаем зур плакатлардыр. Кая гына карама, биналар өстендә дисеңме, диварларда дисеңме, плацның як-якларында дисеңме — һәркайда, кысык күзле дошман тешләрен ыржайтып сиңа штык төбәп тора. Бу — кытай солдаты. Һәм әлбәттә эре-эре хәрефләр белән аста яки өстә язу бар: «Ракетачы сугышчы, исеңдә тот, кытайлар сине беренче номерлы дошман саный!» Куркыта бераз, шайтан алгыры. Тәэсир итә, шүрләтә...

Бу инде учебка түгел, сугышчан часть! Яшь солдатлар, офицерлардан тыш, «карт»ларга буйсына. Бер елдан соң гына монда «картая» башлыйлар. Бер ел хезмәт иткәч, «фазан» буласың, ел ярымнан соң — «бабай». Яңа килгән солдат — «щегол», ярты ел хезмәт иткәне — «чижик». «Чижик»лар һәм «щегол»лар хәрби хезмәтнең иң авыр һәм пычрак өлешен

үзләренең иңнәрендә күтәреп баралар. Гомумән алар фазаннарның, дедларның һәм дембельләрнең вазифаларын үтиләр, кыскасы, аларга хезмәт итәләр.

Фәизне иң шаккатырганы «картлар» һәм яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләр иде. Күп еллар буена калыплашкан кешенең шәхесен изү, таптау, юк итү системасына командование инде тәмам күнеккән, алай гына да түгел, офицерлар өчен «стариковщина» кирәк, чөнки Совет Армиясендәге тәртип бары тик шул вәхши система аркасында гына азмы-күпме саклана. Хәер, аны тәртип дип атап була микән? Командирлар күз буяу өчен генә бу яман күренеш белән көрәшкән булып кылансалар да, күңелдән аны хуплыйлар. Бик сирәк очракта гына, авыр җинаятьләргә китергән вакытларда теге яки бу частьта «стариковщина» өчен хөкем итәләр һәм җәза бирәләр иде.

Фәиз монда «стариковщина»ның чәчәк аткан чорына туры килде. Ул башта күнегә алмый интекте — монда барысы да башкача, учебкадагы сыман түгел иде. Аңа хәтта бу полк Совет Армиясенеке түгел, ниндидер башка илнең ниндидер бер төрмәсе яисә башка төрле зинданы булып тоелды. Ул, «чижик» буларак, үзе кебек үк яшь солдатлар белән беррәттән идәннәр юды, бәдрәфләр чистартты, «картлар»ның вак-төяк йомышларын башкарды. Әмма ләкин мораль яктан кимсетүгә, хурлауга һич кенә дә аның исе китмәде. «Картлар» кайвакыт яшьләрне мыскыл итәләр: мунчада шәрә килеш биергә мәҗбүр итәләр, казармада чиләк белән чебен куып тотарга кушалар һәм тагын башка төрле ысуллар белән мыскыл итеп, көлеп тамаша кылалар иде. Фәизнең дә берничә тапкыр төрле кимсетелүләргә юлыкканы булды. Түзәргә кирәк, түзәргә. Тагын ярты елдан ул үзе дә «фазан» булачак. Ләкин ул беркемне дә кыерсытмаячак. Әлбәттә, үзе кара эшләргә йөрмәячәк, тик беркемне мыскыл итмәячәк. Полк казармасында көннәр авыр уза, дежурда рәхәтрәк. Бигрәк тә баруы күңелле. «Урал» машиналарына төялеп, ракета урнашкан урыннарга йөз чакрым буе барганда як-яктагы биек сопкаларга карап, бурят авылларының ыгы-зыгысын тамаша кылып, күңел дә, баш та бераз ял итеп ала. Дежурда «стариковщина» шулай ук бар-барын, әмма полк казармасындагы кебек түгел. Расчет башлыгы — ике метр буйлы, таза, сап-сары чәчле урыс егете Павлов тын да алдырмый — аппаратураны чистарттыра, идәннәрне гел юдыртып тора, ләкин мыскыл итүләр, көлүләр юк. Аннан башка тагын бер «Карт» бар иде — Зимин. Ул да рядовой, ләкин ул инде дед һәм начальник белән бертигез хокукта иде. Расчетта Фәиздән кала тагын ике яшь солдат бар иде — Башкортстаннан татар телен белми торган татар егете — Абдуллин Алмаз һәм Чиләбедән — Чернов. Алар икесе дә «чижик»лар иде. Аларны учебкада түгел, шушы тирәдәге ниндидер мәктәп сыман урында укытканнар иде.

Шулай да тора-бара башкалардан нык аерылып торучы уйчан «татарин»га Павловның мөнәсәбәте начарлана башлады. Фәиз тиз арада үзенең һөнәрен үзләштерде, бөтен аппаратура буенча полк комиссиясенә бишле билгесенә имтихан тапшырды. Һәр кушылган эшне җиренә җиткерергә тырышып, хәленнән килгәнчә эшләде. Шуңа да карамастан, Павлов аңа көннән-көн ныграк бәйләнә башлады. Теге Кулиш сыман булырмы икәнни монсы да? Фәизнең хәтере яхшы, башкаларга караганда ул башлырак һәм үзенең вазифаларын тиз отып калды. Сөйләшкәндә дә үзенең эрудициясе белән расчеттагы иптәшләреннән аерылып торды. Бәлки, сәләтле, акыллы булган өчен күралмый башлагандыр Павлов аны? Кулиш ни өчен күралмады соң? Әллә тагы... Кыскасы, никтер беркем дә ошатмый Фәизне... Коллектив кешесе булмагач, нишләтсен инде. Кызык түгел аңа коллектив белән аралашуы.

Бер вакыйгадан соң Павлов аңа катырак бәйләнә башлады.

ОЗК өйрәнүләре үткәргәндә Павлов, бәжекләнеп, Фәизне эзәрлекләде. Кат-кат салдырып, яңадан кигертеп йөдәтте. Гәрчә башкалардан калыш-

маса да. Инде җиде кат тирләре чыгып, тәмам хәлдән тайгач, ул расчет башлыгының соңгы командасына буйсынмады.

— Арыдым,— диде ул һәм хәле бетеп плац асфальтына утырды.

Аның берүзен генә ОЗК киярге мәҗбүр итүләрен башка солдатларның тамаша кылып торулары Фәизне күбрәк рәнҗетте.

Павлов зәңгәр күзләрен акайтып аңа якынлашты:

— Аңламадым???

Фәиз торып басты:

— Иптәш сержант, Мин ОЗКны вакытында тиешле рәвештә кия алам, сез моны беләсез, әмма минем берүземне генә болай дрессировать итүегез нигә кирәк?

— Син нишләп командама буйсынмыйсың?—дип акырды Павлов һәм Фәизнең эченә китереп сукты. Әзмәвердәй сержантның йодрыгы да зур һәм каты иде. Фәиз эчен тотып бөгелеп төште. Плацта якын-тирәдә офицерлар күренмәде, шул сәбәпле аны тиз генә култыклап торгыздылар һәм шаһитлар күргәләгәнче казармага алып киттеләр.

Казармага җитәрәк бер капитан:

— Нәрсә булды бу солдатка?—дип кызыксынды.

Аны култыклап баручы Чернов:

— Башына кызу капты,—дип җавап бирде.

Казармага кергәнче үк Фәизнең хәле яхшырды. Алар курилкага барып утырдылар.

— Ни өчен суга ул миңа?—диде Фәиз ашказаны тирәсендә әле һаман да авырту тоеп.

— Аның үзен дә яшь чакта кыйнаганнар инде. Монда бит сержант булсаң да, әллә нинди должностьта булсаң да — яшь чакта эшләтәләр дә, кыйныйлар да.

— Бу бит төрмә түгел.

— Син әле яңа гына күктән төшкән сыман сөйләшәсең. Тәртип кирәк бит.

— Карале, Чернов, ни өчен мине генә куалый соң ул Павлов?

— Беләсеңме нәрсә,—диде Чернов бик күп белгән кыяфәт белән.— Сезне, ягъни учебкадан килгәннәрне, монда яратмыйлар, чөнки сез анда алты ай буена чын солдат хезмәте белән яшәмәгән дип саныйлар. Шуңа күрә бераз сине куаларга маташа ул.

— Ник суга соң ул миңа?—диде Фәиз аптырап.

— Һи, мине кыйнаганнарын күрсәң син. Противогазны җиде секундта кия алмаганым өчен бөтен эчке органнарымны какшатып бетерделәр минем. Түзәргә кирәк, түзәргә. Тагын ярты елдан без дә шулай яшьләрне куачакбыз.

Фәиз аңа аптырап карап торды:

— Ничек инде... Сине кыйныйлар, кара эш эшләтәләр, «карт»ларның ПШсын юдырталар, бу сиңа сабак түгелмени? Син нәрсә, үз шкураңда татыган читенлекләрне башкалар да татысын дисеңмени?!

Чернов гайре табигый нәрсәгә караган сыман таң калып Фәизгә карады да аның яныннан тиз генә китүне хуп күрде. Фәиз курилкада калды һәм пилоткасының ярыгыннан инде кичтән үк әзерләп куелган һәм вакыты булмау сәбәпле һаман тартылмаган «Астра» төпчеген капты.

Чернов сержантка барып әләкләде: «Сибгатуллин мондагы тәртипләр белән канәгать түгел, сак булырга кирәк. Андый кеше, гадәттә, стукач була».

Черновның да Фәизгә ачуы килә иде, «ярты ел буена учебкада ял итеп яткан да», дип уйлады ул. Расчеттагы үзара мөнәсәбәтләр үзгәрүенә Чернов та каршы. Ул инде иләшкән, тагын биш-алты айдан соң үзе дә «картаячак» һәм җиңел тормышка чыгачак. Ә менә бу Сибгатуллин килеп әллә нинди шикле сүзләр сөйләгәч, калыплашкан системалар какшамагае. Шуңа күрә ул, табигате буенча әләкче, шикаятьче булмаса да, үзенең шик-шөбһәләрен Павловка әйтеп бирергә кирәк дип тапты.

## 7

Кич белән отбойдан соң Павлов караңгылык эченнән дәште:

— Рядовой Сибгатуллин!

— Мин!

— Минем янга кил!

Фәиз сержант караваты янына килде.

— Мин.

— Әйдә коптеркага.

— Киенимме?

— Киен.

Коптерка — киемнәр, шинельләр, противогазлар һәм ротаның тагын әллә нәрсәләре саклана торган универсаль бүлмә. Армиядә иң әһәмиятле вакыйгалар коптеркада була. Монда дембельгә әзерләп «картлар» үзләренең чемоданнарын саклыйлар, монда яшьләрне алып кереп акылга утырталар. Монда кереп киңәшәләр, качып тәмәке тарталар. Бигрәк тә яшьләрне алып кереп аларга нотык укырга һәм кирәк чакта суккалап алырга коптеркадан да җайлырак урын армиядә мөгаен бүтән юктыр да.

Коптеркага кергәч Павлов сүзне нәрсәдән башларга белмәде.

— Утыр каршыма!

Кыршылып беткән өстәл янына, бер-берсен аңларга тырышып, ике кеше кереп утырды.

— Син, Сибгатуллин, армиядә икәнлегеңне онытып җибәрдең мәллә? — дип гадәттәгечә башлады сержант әңгәмәне.

— Онытмадым.

— Ә нишләп алайса киреләнәсең?

— Мин киреләнмим. Фәкать башка иптәшләр алдында гел берүземә муштра оештыруыгыз, миннән генә таләп итүегез, авыррак эшләрне миңа кушарга тырышуыгыз аңлашылмый.

Павлов бу хак сүзгә ни әйтергә дә белми калды.

— Чөнки син мудак! — диде ул, аптырагач. — Син — чмо!

Мондый сүзләрне ишетүе бик авыр булса да, Фәиз көлеп җибәрде:

— Мин бу сүзләргә лаекмыни соң? Иптәш сержант, ни өчен мине андый сүзләр белән мыскыл итәсез?

Павлов үзе белән болай тыныч, зыялы итеп сөйләшүгә күнекмәгән, шул сәбәпле югалыбрак калды.

— Мин синең начальнигың! — диде ул ни әйтергә белмәгәч.

— Мине учебкада да берәү менә шулай интектергән иде — Кулиш. Тиктомалга бәйләнеп җелегемне корытты.

— Менә бит, тикмәгә түгел, димәк.

— Юк, мин аңлый башладым хәзер. Миндә башкаларда булган кайбер сыйфатлар җитеп бетми, ахрысы. Башкаларга охшамаганмындыр мин.

Асылда исә аңа башка сәбәп белән бәйләнә иде Павлов. Иң элек аны Фәизнең фәнне тиз отучан, акыллы булуы сагайтты. Шуннан соң, күзәтә торгач, уйлары белән кайвакыт дөньясын онытып җибәрә торган татарның, тыштан буйсынса да, кушкан эшләрне җиренә җиткереп эшләсә дә, күңеленнән буйсынып бетмәвен абайлады ул. Карап торуга буйсынган сыман булса да, эчтә, үзегендә буйсынмый, алай гына да түгел, буйсындырырга теләүчене күралмый иде бу Сибгатуллин.

Ә инде Чернов курилкадагы әңгәмә хакында килеп әләкләгәч, Павловның җен ачулары кабарды. Димәк, Сибгатуллин күп еллар дәвам иткән тәртипкә каршы... «Стариковщина»ны әле беркемнең җиңалганы юк! Бит мондый фикер йөртүче солдатның барып әләкләве дә ихтимал. Калыплашкан тәртипне какшатырга мөмкин. Казарманың үз законнары бар һәм дә ул кануннарны җимерергә маташучыларны урынына тиз утырта бу система.

Менә шуны ничектер әйтәсе килде Павловның, ләкин һич кенә дә аңлата алмады. Гадәти сүзләр, сүгенү белән алдырмакчы булды һаман да.

— «Башкаларга охшамаганмын»,— дип үчекләде ул аны.— Автоматыңны начар чистартып куйгансың..

— Тагын юкка бәйләнәсез,— диде Фәиз, көлемсерәп. Һәм кинәт тавышын күтәрде.— Син миңа бәйләнмә! Кыерсытма! Мин болай да инде кыерсытылган. Нишләп син мине җәберләргә курыкмыйсың?

Сорауның соңгы өлеше ничек килеп чыкканны Фәиз үзе дә сизми калды.

— Нәрсәдән куркырга тиеш мин?! — диде сержант гаҗәпләнеп.— Син нәрсә, Сибгатуллин... Тагын онытыла башладыңмы? Ни сөйләгәнеңне аңлыйсыңмы соң син? Син үзеңне кем дип саныйсың?! Нишләп әле мин куркырга тиеш?!

— Онытылмадым, иптәш сержант. Күңел болай да яралы. Җәберләмәгез мине.

Фәиз шундук шәлберәйде, хәле бетеп китте. Башын аска иде.

Әмма нечкә күңелле кешене аңлый торган түгел иде ат хәтле гәүдәле сержант.

— Син үзеңне җәлләтергә маташасыңмы әллә?! — диде ул, борын тишекләрен киңәйтеп.— Мин куркырга тиеш, имеш. Тор! — Фәиз торып басты.— Аңлат миңа, нәрсәдән куркырга тиеш мин?

— Мәсәлән, гөнаһтан. Кеше кыерсытканнан соң үзеңне тыныч хис итеп буламыни?

— Туктале, туктале. Син нәрсә, Аллага ышанасыңмы әллә? Син әллә берәр руханимы?

— Мин соңгы вакытта уйлана башладым бу хакта. Бер вакыйгадан соң.

— Сез, салабоннар, хезмәт авыр булгач, мәлҗерәясез дә, мәрхәмәт эзли башлыйсыз. Синең кебек күккә карап Алла эзли башлаучы ублюдоклар элегрәк тә булгалады монда. Берничә тапкыр бавырларына суккач, алар да җиргә төшteләр һәм хәрби хезмәтне аңлап чын солдат булып киттеләр.

— Мин армияне болайдыр дип уйламаган идем. Дөрес, мин әллә нинди җәзаларга да лаеклымындыр, әмма мине башкача хөкем итәргә тиешләр. Һәм сез түгел! — Ул тагын башын аска иде.— Армияне болайдыр дип уйламаган идем.

— Һе, син нәрсә, монда бушка ботка ашап кына ятармын дип уйлаган идеңме әллә! Җитәр, учебкада ярты ел трай тибеп йөрдегез.

Павлов белә иде: учебкада трай тибеп йөреп булмый, анда режим каты, хезмәт авыр. Ул бит үзе дә учебкадан килгән кеше. «Учебкада трай тибеп йөргәнсез», дип, сүз җаеннан гына әйтте ул. Үзенең садизмын аклар өчен генә.

— Армиягә үзе теләп китми бит кеше, аны алып китәләр. Кешеләр бит бертөрле булалмыйлар. Ничектер, дөрес түгел бугай бу. Нәрсәдер дөрес түгел монда тамырыннан ук.

— Нәрсә, нәрсә? Армиядә хезмәт итү — синең изге бурычың! Син моңа каршымы әллә? Әгәр дә безне замполит тыңлап торса, сине төрмәгә утыртулары мөмкин бит. Нәрсә дөрес түгел?! Мондый сәер солдатны әле беренче тапкыр күрәм. Син гражданкада кем идең?

— Кеше үтерүче идем,— диде Фәиз тыныч кына.

Һәм шундук үзенең җавабыннан калтыранып куйды.

Павлов аның болай шаяруына ничек җавап бирергә дә белми торды.

— Син кем белән сөйләшкәнеңне онытма. Төрмәгә моннан да алып китеп утыртып була.

— Ә мин төрмәгә утырырга әзер. Чөнки минем урын төрмәдә. Телисеңме, мин сиңа бер вакыйга сөйлим.

— Мин синең шикелле идиотны беренче мәртәбә күрәм. Болай карап торуга акыллы сыман да үзең, шул ук вакытта психка да охшагансың.

Фәиз текәлеп карап торды да, ничектер шатланган шикелле, кырт кисеп әйтеп куйды.

— Мин сиңа бернинди вакыйга да сөйләмәячәкмен! Ни өчен төрмәгә утырырга теләвемне бәян итмәкче идем. Син барыбер дөрес аңламаячаксың.

— Син җүләргә сабышмакчы буласың, ахрысы. Симулянт!

— Мин сабышмыйм. Ничек бар — шундый инде мин.

Павлов, ямьсез елмаеп, ысылдады:

— Мин сине туган илеңне яратырга өйрәтермен!

Бу мәгънәсез җөмләне ул гел яратып әйтә иде.

— Мин аны болай да яратам,— диде Фәиз.

— Ник миңа каршы әйтәсең?

— Мин сиңа каршы әйтмәдем.

— Нишләп «син» дип сөйләшәсең? Син нәрсә, артык грамотный, шустрый мәллә?!

Фәиз бу надан кеше белән сөйләшүнең мәгънәсезлеген аңлады.

— Гафу итегез, иптәш сержант.

Гафу итү урынына ул эченә, күкрәгенә, муен тамырына тукмак кадәрле йодрык алды.

Фәиз идәндә ыңгырашып ятканда сержант тешләрен шыгырдатып ысылдады:

— Мин сине каршы әйтмәскә өйрәтермен! Гаебеңне танышсыңмы?

Фәиз башын күтәреп ыңгырашты:

— Нинди гаепне?

Һәм шундук «гаеп» сүзеннән соң вакытлыча каядыр югалып торган гаеп хисе кыйналудан авырайган башына китереп орды.

Болар, нәрсә, әллә чыннан да тикмәгә кыйнамыйлармы мине? Әллә минем гаебем беленеп, күренеп торамы?

— Таныйм гаебемне, иптәш сержант. Гаебем зур минем,— диде ул һәм торып басты да стенага таянды.— Минем гаебем зур. Һәм мин шул гаебем өчен теләсә нинди җәза алырга да ризамын. Әмма ләкин хөкемдар син булырга тиеш түгел. Чөнки син лаеклы түгел мине ул гаебем өчен җәзаларга.

Сержант вазифаларын үтәү дәверендә Павлов кыйнарга өйрәнгән иде — каты да суга, кан һәм шешләр дә юк. Эз-мазар калдырмый.

— Утыр,— диде Павлов тыныч кына.— Мин сине аңларга тырышып карадым, аңладым.

Фәиз тәне авыртудан чыраен сытты, кайсы төше авыртканны да анык аңламады.

— Ә син мине аңлый алмаячаксың,— диде ул һәм шундук курку хисе вөҗүден биләп алды. Павловтан курку түгел, киләчәктән, бигрәк тә алдагы ел ярым гомердән курку.

Аңлашылмый торган кеше Павловка кирәк түгел.

— Мин синнән аңлашыла торган кеше ясыйм,— диде ул ямьсез елмаеп.— Син фәкать ялкауланмакчы буласың, хәрби хезмәт синең өчен коточкыч авыр.

— Алай түгел. Хәрби хезмәт түгел, мораль яктан түбәнсетергә маташуыгыз авыр. Сез мине мораль яктан, рухымны сындырып кол итмәкче буласыз. Кирәк түгел. Мин бит болай да үз вазифаларымны башкарам, буйсынам. Таптарга тырышмагыз кешене. Мин бу частька килгәч, гел күзәтәм: монда кеше кешене, бигрәк тә картлар яшьләрне үзләренә буйсындырудан бигрәк мораль яктан изәргә, бетерергә, ниндидер бер бөҗәккә әверелдерергә телиләр. Кешене бер мескенгә калдырырга маташалар. Дөресрәге, кешегә: «Син мескен!» — дип тукыйлар. Югыйсә бит кеше үзе яхшырак белә: мескенме ул, юкмы. Гаеплеме, юкмы. Җәзага дучар ителергә тиешме, юкмы.

— Да-а-а-а, күп нәрсә күрергә, күп нәрсә аңларга өлгергәнсең син. Автоматың пычрак, ОЗК кия алмыйсың, ә кеше күрми торган нечкәлекләрне күргәнсең.

Автоматы пычрак түгел иде аның, ОЗКны да кия белә, тик каршы әйтеп ат хәтле гәүдәле бу сержанттан үзен кыйнатасы килми Фәизнең.

— Иптәш сержант, һәркемнең үз уйлары, үз кайгылары, үз язмышы бар. Шуңа күрә саграк булырга кирәк түгел микән кешеләр белән?

— Син, Сибгатуллин, акылга бөтенләй үк тулы түгел, ахрысы,— диде сержант никтер кызмыйча һәм ярсымыйча.— Син нәрсә, килеп, берүзең үзгәртмәкче буласыңмы әллә армиядәге тәртипне?! Синең сөйләгәннәреңне ротага җиткерсәм, акырып көләчәкләр һәм сиңа көн күрсәтмәячәкләр. Син минем расчет солдаты. Ә мин расчет начальнигы! Алга таба күз күрер, уртак тел табалсак әйбәт яшәрсең, әгәр инде булмый икән, үзеңә үпкәлә.

— Мин ничек бар — шулай булачакмын инде. Әгәр киләчәктә дә күралмасаң?

— Ә син үзеңнең начальнигыңа ошарга обязан! Мин синең нутроңны тиз арада күреп алдым. Сиңа мондагы тәртип ошамый.— Ул сынаулы итеп озак карап торды.— Расчетыбыздагы хәлләрне офицерларга әләкләп тормассыңмы?

— Нишләп әле алай уйлыйсың?

— Син стукачка охшагансың. Син ихтыярсыз, тотрыксыз холыклы, ниһаять, хәлсез. Җеп, гадәттә, нечкә җиреннән өзелә.

— Нишләп мин стукач булыйм!

— Син стукач булырга охшагансың. Күренеп тора — синдә протест бар.

— Курыкма, иптәш сержант, мин детдомда үстем. Детдомда әләкчеләрне мондагыдан яманрак дошман итәләр.

— Ничектер әңгәмә барыбер килеп чыкмады әле синең белән,— диде Павлов канәгатьсезләнеп.

Фәиз кинәт бөтен нәрсәдән туйды: армиясеннән, бу сержанттан, мәгънәсез әңгәмәдән, тынчу коптеркадан һәм... үзеннән. Аның башы әйләнеп китте, сержант суккан урыннары сулкылдап авыртып куйды. Күз карашын олтан чырайлы сержантта туктата алмый җәфа чикте. Ниһаять, ул аның чыраена карап катты.

— Беләсеңме нәрсә. Әгәр дә синең белән сазлык аша чыгарга туры килсә һәм син бата башласаң, мин сине коткармас идем. Киресенчә, мин синең башыңа басар идем — син тизрәк дөмексен өчен. Алай гына да түгел, мин сине үзем батырып үтерер идем.— Ул күзләрен йомып үзалдына мыгырданды.— Ник болай дидем соң әле мин? Инде бер җинаять җитмәгәнмени?!

Павлов аптырашта калды:

— Син, чыннан да, ычкынып куясың, ахрысы. Әллә юри кыланасыңмы?! Ә-ә-ә-ә, син симулянт... Тиле булып кыланучылар булды бездә.

— Бәлки сиңа сөйләргәдер...— диде Фәиз, уйга калып.

— Йә, йә, сөйлә.

— Беләсеңме, ни өчен генә түзәм мин бу мыскыллауларга? Ни өчен учебкада теге чуашка түздем?

— Белмим.

— Ә мин беләм.

Павлов түземсезлек белән көтте, Фәиз инде *теге вакыйганы* сөйләргә тәмам җыенган иде. Әмма ул үзе дә сизмәстән алдашуга кереп китте:

— Сазлыкка мүк җыярга баргач, детдомда чакта алып бардылар җәй көне. Мин чак кына батып үлмәдем. Мине бер иптәшем коткарды. Аннары ничектер без аның белән дошманлаштык. Хәзер мин үземне гафу италмыйм. Шуңа күрә, хәзер инде нинди генә авырлыклар китермәсен, түзәм.

Фәиз *теге вакыйганы* сөйләргә җыенгач, күңел күзе белән бакты һәм күреп алды: бу сай акыллы сержант алдында тәүбә итәрлек түгел, мондый кеше алдында тәүбә итү мәгънәсезлек булыр иде.

— Синең әкиятләрең тәмам туйдырды мине.

Ул бар көченә Фәизнең эченә китереп сукты. Фәиз хәтта ыңгырашмады да эчен тотып бөгелеп төште.

— Рядовой Сибгатуллин!

Фәиз бөгәрләнеп яткан килеш аваз салды:

— Ми-и-и-н.

— Коптеркада тәртип урнаштыр, җыештыр, идәнен ю! Ун минуттан үзем кереп тикшерермен. Аннары йокларга ятарсың.

— Е-е-есть,— дип ыңгырашты Фәиз.

Сержант чыгып китте, Фәиз исә торырга уйламады да. Ул тәмам оеп, үзенең уйларына чумды. Авыртулар да, сызланулар да юк, бары тик физик хәлсезлек һәм караңгы уйлар чатыры гына бар иде. Ел ярым буена шулай дәвам итәрме? Болайга китсә түзеп булмас. Гаеп бар инде ул, гаеп зур, гаеп күп. Сержант хаклы кебек, әмма Устав бит болай интектерергә кушмый. Устав, закон, имеш, бу дөньяда законнар, уставлар буенча бармый шул тормыш. Нишләп утырам әле мин?.. Ә-ә-ә, Павлов шушында кертеп утыртты, ахрысы. Алга таба да хезмәт әүвәлгечә авырдан барса, ничек түзмәк кирәк?

Аңа хәрби хезмәтнең чиге-кырые юктыр кебек тоелып китте. Булмый. Монда, аңны тәртипкә китереп, ахири дустын югалтуы турында уйланып, үзе һәм *теге вакыйганы* аңлау насыйп булыр кебек иде. Киресенчә, мондагы мөнәсәбәтләр тәэсирендә *теге вакыйга* искә төшкәч, уйлар тагын да ныграк чуалып китә. Күңелдәге төенне чишү түгел, киресенчә, аның ныграк тыгызланганы тоела. Монда «дедовщина» тәэсирендә син үзеңне гел булдыксыз, бернигә яраксыз, көчсез, хокуксыз итеп тоясың. Бу халәттә үзеңә бикләнеп, гаебеңне уйлап, аны үрчетеп, күпертеп, үзеңнеүзең бимазаларга уңай шартлар гына туа.

Аңлар өчен исә шартлар юк монда!

Менә, армиягә атлыгып торган идем. Кем белгән мондагы тәртипләрне. Хезмәт итә башлагач, армиясе дә армиягә охшамаганлыгы аңлашыла.

Күпме вакыт утыргандыр — хәтерләми, бераздан ишек ачылды да бусагада, яктылыкны тулысынча гәүдәсе белән каплап, сержант Павлов хасил булды. Һаман бер урында, идәндә стенага сөялеп утыручы Фәизгә ул ниндидер бер аңлаешсыз нәрсәгә караган сыман төбәлеп торды. Аннары коптеркага күз йөгертеп чыкты.

— Син нишләп приказны үтәмәдең? — диде ул, гаҗәпләнүдән хәтта елмаеп.

Фәиз, үз уйларыннан арына алмыйча, аптырап, сорады:

— Нинди приказны?

Һәм әкрен генә торып басты. Ул, чыннан да, әле чынбарлыкка кайтып җитмәгән иде.

— Мин бит сиңа коптерканы җыештырырга куштым! — диде сержант инде елмаюдан туктап.

Фәизнең яңа гына исенә килеп төште.

— Хәзер җыештырам,— диде ул һәм эшлекле кыяфәт белән як-ягына каранды, чиләк-чүпрәк эзләве булды, ахрысы.

Сержантның күз карашыннан, аның алагаем гәүдәсен күрүдән тизрәк котыласы килде. Әмма котылу юк икән ул — Павлов түшеннән шытырдатып тотты. Китель кайсыдыр җиреннән ертылды.

— Син, сука, приказны үтәмәдең! Син киреләнеп нишләмәкче буласың?!

Ул бар көченә Фәизнең эченә китереп сукты. Күрәсең, ул эчкә, күкрәккә, касыкка сугарга өйрәнгән — эзе дә калмый, кан да күренми. Торгызып, тагын касыгына бер-ике тапкыр оргач, Фәиз егылды.

Шул вакытны:
— Иптәш сержант!!! — дигән тавыш коптерканы дер селкетте.
Павлов сискәнеп борылды һәм котсыз калды — коптеркага полкның замполиты майор Степаненко кереп килә иде. Павлов ишекне бикләргә оныткан! Ул хәтта майор каршында үрә катып басарга да онытты — чөнки тәмам коелып төшкән иде.
Майор да нык курыккан иде. «Дедовщина» турында көн саен лекцияләр укып, яшь солдатларны кыерсытмаска өндәп гомер узса да, сержантның солдатны кыйнавын турыдан-туры күрүе әле беренче тапкыр. Яшьләрне кыйнап, эшләр трибуналга барып җиткән очракларда иң беренче чиратта замполитлар җавап бирә һәм аларның погоннарындагы йолдызлар кайчак кими, кечерәя торган була. Шул сәбәпле коптерка идәнендә кыйналган солдатның бөгәрләнеп ятуын күрү аны бик куркытты.
— Сержант Павлов! — дип кычкырып җибәрде замполит һәм ни әйтергә белмичә беркавым аптырап торды. — Исәнме ул?
Сүзнең үзе турында барганын аңлап, Фәиз ыңгырашып куйды һәм торырга маташты. Майор аңа ярдәмгә ашыкты. Фәиз торып басты һәм чыраен сытып әле сержантка, әле майорга карады.
— Нәрсә булды?
— Булмады-ы-ы, — дип ыңгырашты Фәиз.
— Ничек булмады?! Кыйнадылармы? — диде майор, Фәизнең хәлләтен аңларга тырышмакчы булып, аңардан күзен алмыйча.
— Юк, кыйнамадыла-а-ар, — дип мыгырдады Фәиз.
Әләкләү — солдатлар арасында иң зур җинаять саналганлыктан, майорны теләсә ничек алдаларга әзер иде.
— Фамилияң?
— Сибгатуллин.
— Сез күптән түгел учебкадан килдегез, шулаймы?
— Так точно.
— Өченче ротагамы?
— Так точно.
— Сержант Павлов!
— Мин!
— Рядовой Сибгатуллин сезнең расчет солдатымы?
— Так точно!
— Ник кыйныйсың аны?
Павлов чыраена гаҗәпләнү чыгарды:
— Мин... кыйнамадым. Этеп җибәргән идем, егылды.
— Молчать!
Майорның кыяфәте яман иде. Ул гәүдәгә дә, тазалыкка да Павлов хәтле бар иде. Аның куе кара кашлары тирләп чыкты, калын иреннәре дер-дер килде.
— Рядовой Сибгатуллин!
— Мин.
— Сержант Павлов сезне ни өчен кыйнады?
— Кыйнамады ул мине.
— Иптәш рядовой! — дип ярсып кычкырды замполит. — Ник ялганлыйсың! Мин бит карап тордым. Үз күзләрем белән күрдем сине дөмбәсләгәнен.
Павлов коелып иңде. Аның гәүдәсе Фәизнеке кадәр генә калган шикелле тоелды. Җавап бирүче булмады, ә майорның соравы исә икесенең дә башлары өстендә кылыч сыман асылынып кала бирде.
Фәизнең бу матавыктан тизрәк чыгасы килде, чөнки бу матавыкның ни ахыры, ни азагы күренмәде.
— Иптәш майор, — диде ул, борынын лышкылдатып. — Мин үзем гаепле.
Майор ишекне ачты да, инде отбой булганлыгын да онытып, казарманың теге башына кычкырды:

— Дежурный по полку! Ко мне! Быстро! Бегом!

Казарманың икенче башыннан яшь лейтенант йөгереп килде.

— Дежурный по полку лейтенант Старков!

Замполит берни аңламыйча күзләрен челт-челт йомып торучы лейтенантка нәфрәт белән карады:

— Полкта ЧП, ә сез, часть буенча дежур офицер, нәрсә карыйсыз?

— Дивизия буенча дежур офицер элемтәгә чыкты. Аның белән элемтәдә булдым. Бу тирәгә күз-колак булалмадым әлегә.

— Барыгыз урыныгызга! — дип кул селтәде майор.

Лейтенант юк булды.

Майор Степаненко замполит буларак та, кеше буларак та «дедовщина»га каршы үзенчә тырышып-тырмашып көрәшүче офицерларның берсе иде. Дедовщина турында көн саен гәп куертылып, бу тискәре күренеш белән формаль яктан көрәш игълан ителсә дә, көрәш сүздә генә кала бирде. Степаненко кебекләр бик аз булсалар да, алар үзләренчә көрәшергә маташтылар. Көрәшү дип... Лекция укып кына яшьләрне кыерсытудан туктамаячакларын Степаненко белә. Тик шулай да, лекцияләр уку, нотык сөйләү — аның эше, хезмәте, профессиясе. Дөресрәге, аның бабайчылык белән көрәшүе — бу күренешкә күңелендәге нәфрәте иде. Шуннан да артык түгел. Һәрбер яшь солдатны саклап, янында йоклап булмый, җәберләмәсеннәр дип артларыннан да ияреп йөрү мөмкин түгел. Башыңны читкә борырга гына өлгерәсең — карт солдат яшьрәк солдатка сугып җибәрә, сизми дә каласың. Инде аптырагач әләкләү системасын җайга салып карадылар, ләкин замполитның җен ачуларын китергән, стукачлыкны иң түбән нәрсә дип санаучы казарма «закон»нары комачаулады. Шул сәбәпле «картлар» белән яшьләр арасына әләк дигән киртәне һич кенә дә төзеп куеп булмады. Стукачлар бар алар, әмма аларны иптәшләре тиз фаш итәләр һәм срогының ахырына кадәр бәдрәфтән чыгармыйлар. Алай гына да түгел, әләк белән генә дедовщинаны җиңеп булмауның төп сәбәбе — шикаятьченең кем икәнен күп очракта белгертергә туры килә, мәсәлән, уголовный эш ачкан очракларда. Стукач әйткән белән генә дә җинаятьне исбат итү мөмкин түгел бит әле. Хөкем бар. Судта исә барысы да ачыклана, хәтта әләкче дә.

Әләкләүнең казармада калыплашып нормага кереп китә алмавы замполитның нәфрәтен, бабайчылыкка караганда, күбрәк уята. Күңеленнән чагучылыкны Степаненко да күралмый, ләкин полкта тәртип урнаштыру өчен кирәк бит ул. ЧПларны булдырмас өчен ниндидер чара кирәк. Әләкләү түгел икән, башка төрле чара да ярый, бары тик нәтиҗәсе генә булсын. Трибуналларга барып җитәрлек җинаятьләр башкарылмасын, яшьләрне кыйнап имгәтүләр бетсен, солдатларның ата-аналары килеп җитмәсеннәр: «Улымны кыйныйлар икән монда»,— дип. Андый очраклар да күп — монда әләкләмиләр, ә өйләренә зарланып язалар. Кайбер ата-аналар килеп тә җитә. Прокуратура да бар бит әле армиядә. Аларга да бит эш кирәк. Алар да һәрбер полктан берничә кешене ай саен төрмәгә утыртып торалар, йә дисбатка җибәрәләр.

— Павлов, барыгыз расположениегә! Йокларга ятыгыз!

Павлов урыныннан кымшанырга курыкты, чөнки замполит белән Фәиз күзгә-күз калгач, әңгәмә булачак.

— Ишетмәдеңмени?!

— Есть,— диде сержант ишетелер-ишетелмәс һәм әкрен генә чыгып китте.

— Утыр, Сибгатуллин, каршыма. Хәзер сөйлә, ни өчен кыйнады ул сине?

— Үзем гаепле,— диде Фәиз, башын иеп.

— Башыңны имә. Туры кара. Нәрсәдән гыйбарәт соң гаебең?

Фәиз сораулы карашын замполитка төбәде.

— Мин...

— Син курыкмыйча барысын да сөйлә. Мин полкның замполиты — майор Степаненко.
— Мин сержантның әмеренә буйсынмадым.
— Нинди боерыгына?
Фәиз каушады, чөнки шундый үҗәтлек белән, бер-бер артлы сорау бирүчегә ялганлавы бик авыр.
— Автоматымны начар чистартканмын...— дип мыгырдады ул һәм кинәт авыртып куйган эчен тотып, бөгелеп төште.— Аннары, ОЗКны вакытында киеп җитешә алмадым. Менә, коптерканы җыештырмадым...
— Син әле генә сөйләгән нәрсәләр командага буйсынмау дип аталмый. Автоматны чистартырсың, ОЗКны да вакытында кия аласыңдыр, чөнки син алты ай учебкада булдың. Ә коптерка бөтен ротаның бүлмәсе, шуңа күрә нишләп син чистартырга тиеш әле аны? Коптерканың махсус җаваплы кешесе бар.
Фәиз аңлады: замполитны алдап булмый икән.
— Ул мине кыйнамады,— дип кенә өсти алды Фәиз.
Павловны хөкем итәрләр дип курыкты ул, шуннан соң бөтен полк Фәизне күралмаячак. Аның аркасында «карт» сержант җәза алса, бу бит стукачлыкка тиң булачак.

Майор, фуражкасын салып, ачу белән өстәлгә атты:
— Ник ялганлыйсың, солдат! Мин бит күреп тордым үз күзләрем белән.
— Ул миңа бер тапкыр гына сукты.
— Бер тапкыр гына түгел!
— Ну... берничә тапкыр.
— Менә, менә, берничә генә тапкыр түгелдер әле. Ул сине гел менә шулай кыйныймы?
— Юк, беренче тапкыр.
— Син әле яңа гына полкка килдең... Син дә карап торуга акыллы егет, шушы казарма законнарына буйсынып, дедовщинаны яшермәкче буласыңмыни? Сине рота командиры мактый — специальностьны яхшы үзләштергәнсең, дежурствода инде бөтен нәрсәне, бөтен операцияләрне өйрәнгәнсең тиз арада... Әйт әле, тагын кемнәрне кыйный Павлов?
— Беркемне дә кыйнамый,— дип, Фәиз башын читкә борды.
Бер караганда, замполиттан игелек көтеп була шикелле, бу майорда ниндидер кайгыртучанлык, теләктәшлек бар кебек. Әллә сөйләргәме замполитка? Ни өчен Павлов аны кыерсыта, нишләп ул үзе кешеләрдән читләшә, нишләп ул башкаларга охшамаган... Сәбәбен үзе аңлаганча әйтеп карарга микән әллә?.. Аңларга тиеш, акыллы кешегә охшаган замполит. Гражданкада нинди вакыйга булганны сөйләсәм, барысы да аңлашылачак аңа, дип уйлады Фәиз. *Шул вакыйга* аркасында ул үги бала сыман бер коллективка да сыя алмый — моңа Фәиз инде үзе тәмам инанган иде. Ә майорга сөйләгәч, нәрсә үзгәрәчәк соң? Аңа мәгълүм булгач, ул нәрсә үзгәртә алыр соң? Фәизнең фәкать кайгысы белән уртаклашасы килү генә иде бу. Гаебен үзе тану гына җитмәгән, башкаларның да хәбәрдар булып, аның гаепле икәнен танулары кирәк иде аңа.
Бу ихтыяҗга каршы саклану инстинкты эчтә нык көрәште.
Ул эре сөякле, олы борынлы, калын иренле, кue кашлы майорга игътибар белән карады. Юк, замполит бит ул! Җинаятемне сөйләсәм, ул минем башымнан сыпырмаячак, тиешле органнарга шылтыратачак. Юу-у-ук, ярамый, үзем кылган гөнаһны үзем а ң л а р г а тиеш мин.
Степаненкога, ниһаять, барып җитте: сөйләшеп утыруда мәгънә юк монда, рядовой Сибгатуллин да дедовщинага каршы көрәшергә җыенмый.
— Сездә... Мәсәлән, бу очракта, кешедә булырга тиешле горурлык бераз бармы синдә? Совет Армиясенә килеп, уставка түгел, «картлар»ның

йодрыкларына буйсынып яшәү коточкыч күренеш кебек тоелмыймы?! — диде майор җан ачысы белән.

Башын аска иеп, ихлас күңелдән сөйләшергә теләмәгән рядовойны үзенең дә бу минутларда тотып кыйныйсы килде аның.

— Марш казармага, караватыңа!

— Тыңлыйм! — диде Фәиз һәм авыртудан чыраен сытып, аксаклап коптеркадан чыгып китте.

Майор коптеркада озак утырмады, сигаретын тартып бетерде дә казармага чыкты. Бу тынчулыкта, кысанлыкта озак торып булмый, аның тизрәк саф һавага чыгасы килде. Ыштыр, күнитек, тир исе киемгә сеңә, хәтта өйгә дә ияреп кайта. Полк дежурные лейтенант үрә катып честь бирде, замполит җавап кайтармады, бары тик аның акайган күзле ябык чыраена җирәнеп карады да ишекне атып чыгып китте.

Дедовщинага каршы солдатның көрәшәсе килми, чөнки хезмәтнең икенче елы бик татлы булырга вәгъдә итә. «Карт»лар өстеннән әләкләү сирәк очракларда була.

Әмма ләкин чагучылык армиядә юк дигән сүз түгел бу. Ләкин «картлар» — «яшьләр» арасында түгел. Башка юнәлештәге, үзгә сәбәпләр аркасында туган стукачлык яшәп ята иде армиядә.

Бу чагучылык нык калыплашкан, каты һәм какшамас бер системаны тәшкил итә иде.

## 8

Особый отдел КГБның иң көчле оешмасы булгандыр, мөгаен. Хәрби контрразведка белән шөгыльләнүче Аерым бүлек һәр дивизиядә бар һәм аның оперуполномоченныйлары полк саен эт шикелле иснәнеп йөриләр иде. Ләкин алар бабайчылык белән шөгыльләнми, солдатларның үзара мөнәсәбәтләре, гадәти җинаятьләр һәм башка «бытовухалар» белән вакланып ятмыйлар иде. Алар фәкать идеологияне, сәяси яктан тотрыклылыкны һәм коммунизм идеалларына тугрылыкны саклаучылар иде. Солдат яки офицер партиянең сәясәтен дөрес аңлыймы-юкмы — оперуполномоченныйлар өчен шунысы мөһим иде.

Ә инде бер-берсен кыйныйлар икән, бу — КГБ эше түгел.

Баллистик ракеталар полкында чит илгә хәрби серне тапшырырдай кеше юкмы, советларга каршы мәзәкләр сөйләмиләрме, социалистик системадан канәгать булмаган кешеләр юкмы — менә нәрсә кызыксындыра Аерым бүлекне.

Оперуполномоченный шушы ук ракета гаскәрләре формасын киеп, чак кына елмайган төстә авызын кыйшайтып, честь бирүчегә җавап биреп, офицерлар белән җылы исәнләшеп казарма буйлап үтә, аннары берәр бүлмәдә — йә «кызыл почмак»та, йә «коптерка»да, йә «бытkомната»да туктап берәм-берәм солдатларны, сержантларны әңгәмәгә чакыра. Әлбәттә, ул бер көндә бөтен полк белән сөйләшә алмый, шул сәбәпле атнага бер килеп унар-унар солдат белән очраша.

Һәркемгә мәгълүмдер — Аерым бүлеккә эшләүче шикаятьчеләр полкта күп була, ләкин аларның кемнәр икәнен әйтү мөмкин түгел. Чөнки әләкләрен әңгәмә вакытында тапшырып бетерәләр. Һәркем белән очрашып сөйләшү гадәткә кергәч, кемнең стукач икәнлеген шайтан белсен!

Әләкчеләрнең төрлесе бардыр инде: кемдер идеологиягә табынып, патриотик хисләр белән шикаятьләр язгандыр, кайсысы кемгәдер ачу итеп, икенче берсе нәрсәдер өмет итеп, кайсыларыдыр иптәшләреннән үзенчә өстенлек эстәп, башка берсе стукачлыкка ризалашмасам, үземә начар булыр дигән хайвани куркаклык белән... Бәлки һәр стукачның үз сәбәбе һәм әләкчелеккә үз мөнәсәбәте бардыр.

Бәлки, шулайдыр. Ничек кенә булмасын, казармадагы һәр сәяси анекдотның эчтәлеге Аерым бүлекнең оперуполномоченныена барып жи-

тә иде. Совет гаскәренә тел-теш тидергән кешенең фамилиясе оперга кичкә таба ук мәгълүм була. Чит ил тормышын мактарга җөрьәт итүчене опер инде киләсе очрашуда ук «капшый» башлый.

Бабайчылык нәрсә ул! Проблема түгел ләбаса! Дөнья икегә бүленеп, менә-менә сугыш чыгарга торганда кайсыдыр солдатның эченә тибүләре кемне кызыксындырсын?! Халыкара хәлләр киеренкеләнгән чакта солдатларның йоклар алдыннан бер-берсенә нәрсә әйтүләре, нинди мәзәк сөйләүләре әһәмиятлерәк!

...Ракета гаскәрләре капитаны формасыннан йөрүче Трошкин Алексей Васильевич тугызынчы полк өчен җавап бирүче оперуполномоченный иде. Трошкин беренче әңгәмәдә үк рядовой Сибгатуллинның күңел тынгысызлыгы белән яшәвен күреп алды. Профессиональ контрразведчик буларак, ул, әлбәттә, бик яхшы психолог та иде. Уйга батып йөрүче бу солдат турында аңарда инде, әлбәттә, мәгълүмат та, полктагы шымчыларның фикерләре дә бар иде. Ләкин әле бу гына аз, аның нинди уйлар белән яшәвен дә белергә кирәк!

Беренче әңгәмәдә Фәиз нык каушады. Ул инде бу капитанның кем икәнлегенә дә, аның нинди ният белән полкта йөрүенә дә төшенде. Өстәвенә, китаплар аша гына таныш булган чекистлар белән аралашырга туры килүе дә аңа әллә ничек тәэсир итте. Трошкин сигарет тартатарта, ягымлы итеп аның хәл-әхвәлләре белән кызыксынды. Кайсы яктан, нинди шәһәрдән... Әйтерсең лә белми. Югыйсә бит инде ул полктагы һәрбер кешенең биографиясен белә. Фәиз исә зыялы һәм ягымлы кешенең сорауларына ихлас күңелдән җавап биреп утырды. Оперуполномоченный аңа үзенең агенты булырга тәкъдим итәргә ашыкмады — егетнең психикасы тотрыксыз күренде. Аның ниндидер күңел конфликты бар — контрразведчик моны тиз арада абайлады. Бу солдатның күз карашы, кул хәрәкәтләре, сөйләшү интонациясе — барысы да әле өйрәнүне таләп итә. Трошкин икенче очрашуда аны тагын күзәтергә ниятләде. Беренче әңгәмә исә рядовойга яхшы хезмәт һәм уңышлар теләү белән тәмамланды.

Икенче очрашу Павлов белән чыккан матавыктан соң булды.

Трошкин, сары кашлары астында тирәнгә кереп поскан зәңгәр күзләрен Фәиздән алмыйча, текәлеп утырды.

— Сигарет тарт,— дип ымлады ул өстәлдә яткан «Родопи» пачкасына ымлап.

— Рәхмәт, тартасы килми,— диде Фәиз дулкынланудан карлыккан тамагын кырып.

— Ишеттем... Павлов белән булган күңелсез хәлне...

Трошкин алдан пеләшләнә башлаган маңгаена кульяулыгын тигергәләп алды. Аның, иреннәрен бөрештереп, уйланып утыруыннан (асылда ул уйланган булып кыланып утыра гына) файдаланып Фәиз әйтеп куйды:

— Күңелсез хәл килеп чыкты шул. Үзем гаепле.

Трошкин сары кашларын өскә күтәрде, аның түгәрәк йөзендә гаҗәпләнү чагылды (гаҗәпләнгән булып кыланды, әлбәттә):

— Ничек инде гаепле? Нәрсәдә гаепле?

— Разжаловать итмәскә иде аны,— диде Фәиз башын аска иеп.— Кызгандым мин аны. Ул бит бик нык кайгыра...

Трошкин инде икенче сигаретын кабызды.

— Трибуналга җибәрмәгән өчен рәхмәт әйтсен,— диде ул бер бүрек төтен чыгарып.— Менә шундый хулиганнар аркасында армиядә тәртип юк.

Трошкин моны юри генә әйтте. Армиядәге мондый вак тәртипсезлекләрнең тирәндә яткан серләре бар. Ул армиянең төзелешенә бәйле нәрсә. Павловларның шуклыклары аны кызыксындырмый. Аны бу минутларда Сибгатуллинның үзен гаепле санавы һәм кыйнаучысын кызгануы шикләндерде. Сибгатуллинның тирән уйга чумып йөрүе (бу турыда ул инде

агентларыннан да ишетте) белән үзен җәберләүчене акларга маташуы аркасында ниндидер психологик бәйләнеш бардыр сыман тоелды аңа.

Дөресен генә әйткәндә, контрразведка капитаны Трошкин Павлов белән бәйле бу вакыйгага да битараф калалмады. Хәзер Сибгатуллинны полкта куралмый башлаулары ихтимал. Ә Сибгатуллин түзалмаса... Рухы сынса, нервылары чыдамаса? Сибгатуллин яшерен аппаратурада хезмәт итүче белгеч, аның хәтта армиядән соң да биш ел дәвамында чит илгә чыгарга хокукы юк. Полктагы мөнәсәбәтләргә чыдый алмыйча качса? Болай да дезертирлар җитәрлек ракета гаскәрләрендә! Кытайга чыгып качарга маташучылар да бар. Әллә ни зур серләре булмаса да, солдатлар шактый күп белә. Аннары, ни дисәң дә, андый вакыйгалар бөтен армия өчен — ЧП.

Бу очракта инде оперуполномоченныйлар җавапка тартыла. Шулай итеп, казармадагы кыйнашулар да кайвакыт еракларга алып китәргә мөмкин, кем әйтмешли. Шуңа күрә кичекмәстән Сибгатуллинны «өйрәнергә» кирәк. Беренчедән, аның армиядән җаны бизеп, «картлар»дан шүрләп хәрби хезмәттән качмаячагына ышанырга һәм солдатның үзенә дә рухи тотрыклылыгын сакларга ярдәм итәргә кирәк. Икенчедән, бу егеттә чишеләсе тагын бер мәсьәлә бар, аны чишәргә кирәк. Аңарда нәрсәдер бар. Ул нәрсәдер белә. Контрразведка өчен теләсә нинди серлелек — табыш. Контрразведка шундый серләрне эзләп кенә йөри. Чөнки гадәти күренешләрдән аерылып торган серлелектән күп нәрсә башлана, ачышлар барлыкка килә, аңлыйсы нәрсәләр аңлашыла. Кешенең серен ачу — иң зур ачыштыр, бәлки. Серне уку — ул бит кешене уку. Ә контрразведканың төп эше шул түгелмени?!

Фәиз, дулкынланудан бераз арынып, сигарет алып кабызды. Трошкин аңлады — сорауларны бер-бер артлы бирергә ярый хәзер.

— Кыерсытучы юктыр бит?

— Юк.

Капитан ясалма, җитди кыяфәт белән юатып куйды:

— Түзәргә кирәк инде. Хәрби хезмәт рәхәт түгел. Бигрәк тә безнең гаскәрләрдә.

Һәрбер әйткән җөмләсеннән соң ул каршысында утыручыга яшен тизлегендә карап-карап алды. Сорауның кирәклесен биреп, үзенә әһәмиятле җавапны көткәндә исә күз карашын озаграк тоткарлады.

— Гражданкада берәр туганың калдымы?

Фәиз ашыгып җавап бирде:

— Калды.

Туганың калдымы дип сорагач, әлеге сорау конкрет кеше турында түгел, күңелгә якын нәрсә турында (инде булган яисә әле киләчәктә булачак, үзенә генә мәгълүм, күңелендә асрап йөрткән халәт), дөресрәге, күңеленең бер өлеше калган төбәккә һәм... вакыйгага бәйле дип аңлады ул.

Трошкин сагайды, читкә караган булып:

— Кемең калды? Син бит детдомныкы,— дип сорады да кинәт Фәизгә текәлеп карады.

— Кем калды? — дип аптырап калды Фәиз, үзенең җавабы турында шундук онытып.

— Туганым калды диден син.

— Юк минем туганнарым,— диде Фәиз, бу сүзләрне инде әллә ничә тапкыр кабатларга туры килгәнлектән авыр сулап.

— Сөйгән кызың көтәчәкме соң кайтуыңны? — диде Трошкин хәйләкәр елмаеп.

Тик аның дустанә елмаюы Фәизгә уңай тәэсир ясамады, киресенчә, ул үзен тагын да уңайсызрак хис итеп куйды.

— Кызларым булгалады минем... ләкин армиягә киткәндә озатып калганы, «көтәм» дигәне булмады.

— Кайткач, менә дигән кыз табарсың, борчылма,— дип капитан аны юаткандай итте.
— Мин борчылмыйм.
— Дусларың хат язамы соң? — диде оперуполномоченный һәм игътибар белән Фәизнең күзләренә карады.
Фәиз бу әзәрлекләүче күзләрдән куркып калды, башын читкә борды:
— Язалар, ләкин сирәк,— дип ялганлады ул.
Трошкин бик яхшы белә — Сибгатуллинга беркем дә хат язмый, үзе инде әллә ничә тапкыр яза башлады хатны, тик һәммәсен беренче битеннән үк ертып ташлый. Кемгәдер хат язарга маташа Сибгатуллин — Трошкинга бу турыда инде күптән хәбәр иттеләр.
Тик менә кемгә? Кая? Ник һаман язып җибәрми инде?
— Сирәк язалар дисеңме? Бәлки, үзең җавап бирмисеңдер? — диде капитан күзләрен чекрәйтеп.
— Әйе, җавап бирмим.
Фәиз сизенде — капитан аның ялганлап утыруын аңлады бугай. Әнә бит ничек җентекләп карый, күз карашы тишеп керә торган. Туктале, болар бит кемнең кемнән хат алганын беләләрдер. Алар бит секретный войска булгач, хатларны ачып укыйлар ди. Димәк, беләдер ул аның беркемнән дә хат алмаганын һәм үзенең дә язмаганын... дөресрәге, язып салмаганын.
— Нишләп кәефең кырылды? — дип кызыксынды капитан врачларга хас хәстәрлек белән.
Фәизнең бите кып-кызыл булды:
— Беркемнән дә хат алганым юк минем. Беркем дә язмый миңа. Үзем дә язмыйм.
— Якын дустың да юкмыни?
Бәрәч, нишләп якын дус турында сорый соң әле бу? Бигрәк куркыныч кеше. Карале, күзләре ничек тирәннән ук сыман кадалып карыйлар.
— Юк,— диде Фәиз һәм кинәт хәлсезләнеп өстәлгә терсәкләре белән таянды.
Ә капитан аны җентекләп күзәтте. Фәиз моны сизде һәм үзен инде ятьмәгә эләккәндәй хис итте.
Чекист Трошкинны, Фәизнең япа-ялгыз булып, беркем белән хат алышмавы, бер генә кеше белән дә элемтәдә булмавы кызыксындырды. Кыйтгаара баллистик ракеталар полкының команда пунктында, идарә пульты урнашкан бинада хезмәт итүче солдат өчен бу бик сәер һәм... куркыныч та. Димәк, бу егетнең бер генә якын кешесе дә юк (исәннәрдән), аны монда үз иткән, якын иткән, яраткан кеше юк. Ул теләсә кайсы вакытта бу илдән ваз кичә ала. Кайчан тели — шунда теләсә нинди көтелмәгән нәрсә китереп чыгаруы ихтимал. Якын дус турында сорагач, Фәизнең хәлсезләнеп китүе капитанның игътибарын җәлеп итте.
— Хезмәт болай бик авыр түгелме соң? — диде Трошкин сүзне җиңелчәрәк агымга кертергә тырышып.
— Юк, күнегеп киләм инде.
— Туган яклар сагындырадыр?
— Туган якның кайбер урыннары сагындыра,— диде Фәиз бер ноктага текәлеп.— Һәм кайбер мизгелләре.
— Син гафу ит сораштырганым өчен. Минем кем икәнемне беләсең инде... Миңа кызык. Мине һәрберегезнең тормышы, кәефе кызыксындыра. Аңлыйсыңмы?
— Аңлыйм.
— Ярый, мин сине тоткарламыйм. Башыңны югары күтәр. Барысы да яхшы булыр. Анда, сезнең расчетта, Шадрин бар.
— Әйе, ул безнең расчет башлыгы.
— Зинһар, керсен әле минем янга.
— Ярар,— диде Фәиз һәм пошаманга калып чыгып китте.

Шадринны минем турыда сөйләшергә чакырмыймы икән? Берәр ялгыш сүз ычкындырмаганмындыр бит?

Юк, Шадринны Трошкин чираттагы әңгәмәсенә генә чакырды һәм ул әңгәмәдә Сибгатуллин турында бер генә сүз дә катмадылар.

Ә Фәизне шул кичтә, икенче көнне дежурствога барганда һәм дежурствода да бер генә сорау борчыды: нишләп оперуполномоченный, сөйләшә торгач, якын дус турында сорады?

...Очрашулар әле тагын булды. Әңгәмәләр солдат тормышы тирәсендә, хәл-әхвәлне белешү рәвешендә барды. Һәр очрашуда дус, дуслар темасына Трошкин кагылып узмый калмады. Мәсәлән, әңгәмә барышында сорау бирер алдыннан, көтмәгәндә сүзне болайрак башлый:

— ...Менә, мәсәлән, гражданкада син дусларың белән мондагы шикелле мөнәсәбәтләрдә түгел идең бит инде. Анда бит танцыга барасың, аракы эчәсең. Дуслар, компания.

Бу — мисал өчен, көнкүреш темаларына сөйләшкәндә генә әйтелә торган гыйбарә. Шул сүзләрне әйткәч, чекист күзәтә, җентекләп күзәтә Сибгатуллинны.

Яисә болай:

— Серләреңне иң якын дустыңа да әйтергә ярамый шул. Менә, мәсәлән, якын дустыңнан яшергән ниндидер изге серләрең булгандыр бит гражданкада?

Кайвакыт шулай, сүз башлагач, сорау бөтенләй башка нәрсә турында килеп чыга. Әмма ләкин Трошкинның дуслар турында, аның гражданкадагы элемтәләре турында беләсе килә; кайвакыт шулай әңгәмәдәше бик кирәкле информацияне әйтеп ташлый.

Мәсәлән, бер тапкыр Трошкин армиядән соң киләчәк тормыш турында сүз башлады.

— Армиядән соң кайсы шәһәрдә тукталмакчы буласың соң?

— Белмим әле. Бәлки Т... да урнашырмын.

— Ә-ә-ә, анда синең дусларың бардыр? — диде Трошкин һәм күзләрен чекерәйтте. Югыйсә белә бит инде дуслары юк икәнне.

— Нинди дуслар, әйттем бит инде дусларым юк дип! — диде Фәиз, ачуын яшерә алмыйча.

Трошкин реакцияне күрде дә, тагын кайсы яктанрак килергә икән дип уйлый-уйлый, әңгәмәне дәвам итте.

— Син гафу ит, Сибгатуллин. Мин бит теге очрашуларда ниләр сөйләшкәнне онытам, полкта бит ике йөзгә якын кеше, кайвакыт буталам да. Әйе шул, дусларым юк, дип әйткән идең. — Ул тиз генә Фәизгә карап алды да, өстәп куйды. — Бер генә дустым бар иде дигән идең бугай син.

«Бер дус» турында сүз барганда Фәиздә үзгәрешләр башлана — чекист моны белә, шуңа күрә «полкта кеше күп, буталам диюе» хәйләкәрлек, ә «бер дус» турында сүз катуы — бераз тәвәккәллек күрсәтүе иде.

Фәиз исә сискәнеп аңа карап торды да:

— Мин... кайчан әйттем дустым турында? — дип тотлыкты.

— Ничектер бер әйтеп узган идең шунда, бер сөйләшкәндә. — Трошкин кашларын җыерып хәтерендә казынган булып кыланды. — Ничектер, гражданкада бер якын дустым белән каядыр, нәрсәдер... Ярар ла, әһәмиятле нәрсә түгел. — Һәм сүзне элекке юнәлешенә кертергә ашыкты. — Әлбәттә, туган якка кайтырсың инде. Ни дисәң дә, туган як, туган як инде ул. — Ул авыр сулап куйды. — Мин бит үзем Воронеждан. Отпускыда һәрвакыт шунда кайтып киләм. Сагындырды-ы-ы. Туган як, туган як инде ул.

Ләкин Фәизне чекистның туган яклары инде кызыксындырмады:

— Сез кем беләндер бутагансыздыр, — диде ул тавышында яңгыраган куркуны тойганнан соң тагын да ныграк шүрләп.

Трошкин кеткелдәп көлеп куйды:

— Аптырамасана. Никләр әйттем. Бутаганымдыр сине кем беләндер.

Фәизнең башы әйләнеп китте, тәмәке төпчеген сытканда бармагын пешерде, ләкин бармак никтер авыртмады, бөтен игътибар, бөтен нервылар кайдадыр башка нәрсә белән мәшгуль иде. Бу кешегә сөйләсәм дә буладыр. Трошкин — яхшы кеше, күренеп тора. Аннан барысы да куркалар. Хөрмәт итәләр. Ул күп белә. Теләсә кемне аңлый. Сөйләргәме әллә? Дөрес аңлармы? Трибуналга җибәрмәсме? Бәлки, ул инде беләдер. Нәрсә белсен соң ул? Каян белсен? Нишләп дус турында сораштыра соң ул алайса?

Аның икеләнеп утыруын Трошкин аермачык күрде: моның өчен разведчик булу да, психолог булу да зарур түгел. Ул тагын читтәнрәк башлады:

— Син, Сибгатуллин, миннән әле һаман шүрлисең бугай. Мин сине аңлыйм һәм полкта исән-имин, уңышлы гына, матавыкларсыз хезмәт итеп гражданкага кайтуыңны телим. Синең белән әңгәмәләр кызыклы үтә. Син күп укыйсың, дивизиянең китапханәсендә син укып чыкмаган китаплар калмагандыр инде. Син акыллы, эрудицияле егет. Әгәр дә үзеңнең сәләтлелегеңне саклый алсаң, сине зур киләчәк көтә. Синең киләчәгең хәтта бөек булачак. Үзең дә күрәсеңдер, мин синнән расчеттагы иптәшләрең турында сораштырмыйм, төрле хәбәрләр ташырга кушмыйм. Миңа синең белән кызык. Син башка солдатлардан аерылып торасың. Дөресен әйтәм, шул ук вакытта минем сине аңлыйсым да килә.

— Иптәш капитан, ә нигә сезгә мине аңларга?!

— Ну-у-у, ни дисәң дә, мин бу полкка беркетелгән оперуполномоченный.

— Сезне мин кызыксындырам инде, алайса?

— Мине полктагы һәрбер кеше кызыксындыра.

— Минем бик якын дустым бар иде, детдомда бергә булдык аның белән.

— Кайда соң ул хәзер?

— Белмим.

— Армиядә түгелме?

— Юк. Югалды ул.

— Шул дустың югалганга кайгырып йөрисеңме әллә син һәрвакыт?

— Әйе.

— Аны табарга, бәлки, мин ярдәм итә алырмын.

— Юк. Чөнки ул исән түгел инде. Исән түгелдер дип уйлыйм.

— Ник алай уйлыйсың? Шундый хәбәр бармы әллә?

— Сезгә нәрсәгә минем дустым турында белү?

— Мин синең турыда белергә телим.

— Белмим, исән дә шикелле үзе... Ләкин ул үлде инде.

— Үзең күрмәгәнсеңдер бит үлгәнен?

Фәизнең йөрәк турысыннан нәрсәдер кысып алды, йөрәкнең хәле бетеп китте.

— Юк, мин аның үлгәнен күрмәдем. Ишеттем генә. Бәлки, исәндер... Минем аны бит эзләп караганым юк. Армиядән соң мин аны эзләячәкмен.

— Әлбәттә... Һәм табарсың да.

— Табарга тиешмен мин аны.

— Йә, ярар, Сибгатуллин, бар ял ит. Ачуланма кайбер сорауларым күңеленә хуш килмәсә. Болай кыерсытучы, кимсетүче юк инде, алайса?

— Юк.

— Мин ротадагы иптәшләрем турында гына түгел, офицерлар белән дә кызыксынам. Мәсәлән, рота командирының, аның урынбасарларының мөнәсәбәте ничек?

— Аларны мин көнгә бер мәртәбә генә күрәм. Иртән разводка киләләр дә...

— Ә дежурствода?

— Ә дежурствода алар үз эшләре белән мәшгуль, ә безнең расчет үз эше белән. Анда аралашырга да вакыт юк офицерлар белән.

— Алай-болай, яшерен информация турында кычкырып сөйләшмиләрме?

— Юк.

— Офицерлар арасында зарланучылар юкмы?

— Юк.

Трошкин әңгәмә вакытында көтмәгәндә, офицерлар турында тискәре мәгълүматлар өмет итеп, Фәизгә шундыйрак сораулар әйтеп куя иде. Ләкин Фәиз бу сорауларга беркайчан да әһәмият бирмәде, чөнки, беренчедән, ул үзенең уйлары белән мәшгуль — Трошкин аның күңелендәге авыртып торган яраларга кагыла, икенчедән, офицерларның берсе дә контрразведка бәйләнерлек компроматка ия түгел иде.

Трошкин, тора-бара, Фәиздән агент чыкмасына тәмам ышанды. Ләкин аның табышмагын барыбер чишәргә кирәк иде.

## 9

Коптеркадагы вакыйгадан соң Павловны икенче көнне үк разжаловать иттеләр. Өченче рота өчен ЧП иде бу. Обед узуга аның погоннарында инде лычкалар юк иде, ул рядовой булып калды. Бу — бөтен полк күләмендәге вакыйга иде, Фәиз үзе дә моны бик авыр кичерде.

— Сибгатуллин — стукач!

— Павловны әләкләгән!

— Бер тапкыр суккан өчен званиесеннән мәхрүм иткәннәр!

— Сибгатуллин — сволочь!

— Стукач!

Бу хәбәр казарманың һәр почмагына тулды.

Срочный хезмәттәге кеше өчен сержант званиесе бик кадерле. Бигрәк тә вазифасы булса. Ә Павловның вазифасы исә шактый зур һәм түләү дә яхшы иде. Рядовой солдат өч сум сиксән тиен алса, ул утыз сум чамасы ала иде. Бигрәк тә мораль ягы авыр дәрәҗәдән мәхрүм булуның.

Өченче ротаның расположениесеннән, бигрәк тә техрасчет яши торган почмактан көне буе кеше өзелмәде. Яңа стукачны күрергә һәм Павловның кайгысын уртаклашып аз гына булса да аны тынычландырырга башка роталардан да килеп-китеп тордылар.

Фәизгә һәммәсе янады — «картлар» да, үзенең призывы да, хәтта үзеннән яшьрәкләр дә. Павлов исә үзенә урын табалмыйча әле «кызыл почмак»ка керде, әле туалетка барып тәмәке тартты, әле казарма буйлап йөренде. Расположениедә бөкрәеп куркып утыручы Фәиз янына да берничә тапкыр барып килде.

— Нәрсә, сука! Сөйләдеңме барысын да?! — диде ул йодрыкларын төйнәп. Ләкин сугарга курыкты.

Фәиз әллә ничәнче кат Павлов алдында һәм башкалар каршында акланды:

— Сөйләмәдем мин замполитка бернәрсә дә! Ул үзе күреп торган!

Павлов ярсудан тыш әле курка да иде: җинаять эше башлаулары ихтимал, чөнки полкның замполиты үзе күрде кыйнаганын.

Фәиз үзен бик начар хис итте. Бөтен полк аңа каршы бит. Сержанттан рядовойга калып, вазифасыннан алып ташлангач, Павлов ачудан казарма буйлап кычкырып йөрде:

— Әләкче! Стукач! Мин аны расчетыма килү белән сизенгән идем — артык акыллы, артык намуслы булып күренде ул миңа.

Павловны кызганып «фазан»нар һәм хәтта алардан да яшьрәкләр вәгъдә бирделәр: Сибгатуллинга көн булмаячак бу полкта, хезмәтенең ахырына кадәр яшьләр рәтендә кара эшкә йөриячәк, кыскасы, «карт»

булу язмаган аңа. Димәк, бер ел хезмәт иткәннән соң да башкалар шикелле рәхәт тормышка чыкмаячак, яшьләрне үзенә буйсындырырга хакы булмаячак.

Хәрби хезмәт Фәизгә кичеп чыккысыз булып тоелды. Бөтен полк күралмаса, ничек яшәмәк кирәк? Павловның асылынып дәрәҗәгә житеп кайгыруы да бик авыр тәэсир итте аңа. Бәлагә тарыган сержантны, дөресрәге, элекке сержантны жәлләде ул чын күңелдән. Аның аркасында шушы хәлгә калды. Алай-болай җинаять эше башламасыннар инде берүк.

Павловны техрасчетта калдырмадылар, ракета установкаларын саклый торган каравыл расчетына билгеләделәр.

Беркөнне Павловның елаганы күзгә чалынды. Фәизнең барып гафу үтенәсе килде, ләкин кыюлык тапмады. Павлов урынына, учебкадан килгән, Фәиз кебек ярты ел гына хезмәт иткән кече сержант Шадринны билгеләделәр. Шадрин бөтен полк йогынтысы астында Фәизгә яман караса да, киләчәктә бергә ел ярым хезмәт итәсе булгач һәм Фәизнең тырыш, акыллы, сәләтле белгеч икәнен белгәч, аның мөнәсәбәте әкренләп үзгәрде. Тора-бара ротада үзенең призывыннан булган солдатлар, сержантлар белән сөйләшеп, Фәизнең стукач түгеллеген исбатларга тырышты. Шулай килеп чыккач нишләтәсең, замполит үзе күргән һәм Павловны шуңа разжаловать иттергән.

Барыбер Фәизгә кырын карадылар. Бигрәк тә Павлов призывындагылар.

Әмма ләкин вакыт үтә торды. Көннәр бер-бер артлы каядыр сопкалар артына очтылар да очтылар. Җәй җиткәч, ракета шахталарында һәм КПда ремонт эшләре башланды. Дежурстволардан соң калып шул регламент эшләрендә катнашырга куштылар. Фәиз шатланып кала торган булды. Башкалар калмыйча полкка кайтып киткәндә дә ул рәхәтләнеп, үзе теләп монда, КПдагы җиһазларны буяп, буяу һәм ацетон исен рәхәтләнеп иснәп, онытылып эшләде. Үз ротаң кайтып киткәч, монда башка рота килә. Ә башка ротага син буйсынмыйсың, үз көеңә обедка барып, үз көеңә эшләп, үз көеңә ял итәсең. Ремонт эшләре өчен җавап бирүче капитан Лысенко Фәизнең эшеннән бик канәгать булды — кушканны җиренә җиткереп, тырышып башкара. Әле үз чиратында үзенең расчеты белән дежурда да тора.

— Полкка, частька кайтып ял итмисеңме соң? — диде капитан Лысенко бер тапкыр. — Ял ит бераз.

— Юк, иптәш капитан. Ремонтлар беткәнче монда тотыгыз инде мине.

Фәизнең полкка кайтасы килмәгәнне Лысенко белә, чөнки Павлов белән булган матавыкны ул да ишеткән иде.

— Үзеңә кара, Сибгатуллин. Мин синең эшеңнән канәгать. Көзгә тәмамларбыз инде бу ремонт эшләрен. Синең буйыйсы аппаратура шактый әле. Шулай да октябрьгә тәмамларга иде.

Фәиз исә ремонт эшләренең мәңге бетмәвен теләде. Белсә иде капитан Лысенко, монда аңа гына буйсынып, кушкан аппаратураны төрле төсләргә буяп йөргәндә җанның ничек рәхәтләнеп ял иткәнен.

Бер көнгә бирелгән эшне тиз арада тәмамлап, ул җир асты бинасыннан чыга да тирә-яктагы сопкаларга карап сәгатьләр буе уйланып утыра. Чәнечкеле тимерчыбыклар, электр тогыннан сызгырып торган куркыныч челтәрләр артында утырырга туры килсә дә, монда ничектер ирекле иде ул. Бу минутларда чын мәгънәдә ИРЕКЛЕ булу турында да хыяллар туа. Нәрсәдән, кемнән азат булу кирәк соң кешегә? Бу сорауны ул үзенә еш бирә, чөнки белә — армиядән азат булган сурәттә дә ирекка ирешмәячәк.

Нәрсәдән котылырга кирәк икән ирекле булыр өчен?

Ә-ә-ә, әйе, әйе, КОТЫЛЫРГА тиеш кеше.

КОТЫЛУ насыйп булса гына ирекле булачак ул. Ирекле кеше генә җан тынычлыгына туеначак — ул әле моны аңлап бетермәсә дә, сизенә.

Үзендәге мең катлы чәнечкеле тимерчыбыклардан, коточкыч тирән чокыр-шахталардан, миллион ваттлы ток булып янында гүләгән «ирексезлекләрдән» котылсаң гына газаплануларга чик куелыр. Барысы да үзеңдә бит, бары тик үзеңдә. Котылырга! Хәлдән килер микән?

### 10

Кайвакыт полкта кемдер кырын карап, аның аркасында Павловның рядовой булып кайтып китүен исенә төшергәләсә дә, Фәиз «фазан»нар рәтенә керде. Үзенең сабырлыгы, түземлелеге, башлы булуы белән барыбер расчетта һәм ротада абруе булмады түгел. Аны ротада, расчетта бигрәк тә, беркем кыерсытмый башлады.

Көзге демобилизация Павловны да, аның призывын да котылгысыз рәвештә өйләренә алып кайтып китте. Павлов полк белән саубуллашканда Фәиз дежурда иде. Башка ротадагылар сөйләделәр, имеш, казармадан чыгып киткәндә Павлов әйткән: «Сибгатуллин гражданкада очраса, үтерәм!» Ләкин аның соңгы сүзләре Фәизнең үзенә зур тәэсир ясамады. Ротада да моңа алай игътибар итмәделәр.

Әмма инде армиядән соң, еллар узгач, Павлов белән килеп чыккан матавык һәм аның янап кайтып китүе ничектер башка күзлектән күренде. Павловның каргышлары уйландырды, нык уйландырды.

Башка роталардан әйткәләүче булды:

— Әй, өченче рота! Сез нәрсә, стукачыгызны да «фазан» иттегез мәллә? Нишләп ул картлар рәтенә кереп йөри?

Моны ишетүе авыр иде Фәизгә. Ләкин расчет башлыгы Шадрин андый вакытларда һәрвакыт яклады һәм, тавыш күтәрүче белән әйбәтләп сөйләшеп, Фәизнең стукач түгеллеген аңлатырга тырышты.

Дошман итүчеләр булса да, Фәиз «фазан» булды, «карт» солдатлар рәтенә керде. Казармада кара эшләргә аны инде йөртмәделәр, нарядларга куймадылар, куйсалар да, аның вазифаларын яшьләр үтәде. Ләкин ул беркайчан да яшь солдатларга кул күтәрмәде. Үзенең күнитеген чистарттырмады беркемгә дә. Үзенең йомышлары өчен беркемне дә йөгертмәде. Яшьләрне кызгану гына түгел иде бу. Үзе моңарчы ишәк сыман эшләгәч, аның кайвакыт яшьрәк солдатны үзе өчен йөгертәсе, йомышын башкартасы да килде. Әмма ләкин үзе аркасында Павловның «харап» булуы мәңге исеннән чыкмады, һәм шул сәбәпле, үзен гаепле санап, башкаларны җигәргә хакым юк дип уйлады.

Тормыш җиңeләеп китте Фәиз өчен. Буш вакыты артты. Режимның формаль якларын исәпкә алмаганда, солдатның икенче елы кинәт җиңеләя, яхшыра икән ул.

Дежурга башка рота расчеты белән дә үзе теләп бара башлады, чөнки сопкалар арасында, дивизиядән еракта күңел иркен сулый иде. Полк казармасында сәгать саен тезелеп, йә полк командирының әйтер сүзен тыңларга туры килә, йә үз ротаң командиры килеп, берничә әмер бирә, йә берәр эшкә алып чыгып китәләр.

Буш вакыты чыгуга китапларга ябышып, Фәиз вакытның тиз үтүенә хәтта кайвакыт гаҗәпләнеп тә куя иде. Казармадагы тормыш та алай ук дөм караңгы түгел хәзер. Иң авыр чоры узгандыр, ахрысы, бу идиотизмлы хезмәтнең.


Вакыт чаба. Белоруссиянең томанлы нарат урманнары аша да, Бурят иленең шәп-шәрә сопкалары арасыннан да вакыт үзе генә белгән сукмаклар белән, беркемгә дә мәгълүм булмаган тарафларга, күз күрмәс атын уңнан-сулдан камчылап, бертөрле үк чаба икән ул.

*Дәвамы киләсе санда.*

# ТАТАРСТАНДА БЕРЕНЧЕ

**Былтыр республикабызда чит илләрнең беренче рәсми вәкиллеге — Төркия консуллыгы ачылды. Шул уңайдан без аның житәкчесеннән:**

**— *Консуллык эшли башлау Татарстан-Төркия мәдәни бәйланышларын үстерүгә нинди йогынты ясар?* — дип сорадык.**



— Татар-төрек халыкларының кардәшлеге, телләребез, мәдәниятләребез якынлыгы, динебез уртаклыгы күпләргә мәгълүм. Идел-Кама Болгарстаны белән Госманлы мәмләкәте дәвереннән үк килә торган дусларча бәйланышларыбыз заманнар агышында төрле үзгәрешләр кичерә — ләкин беркайчан да бер-беребезгә мәхәббәтебез сүнми. Татарлар Русия империаторлыгы эчендә калгач та, аралашу дәвам итә. Бәйсезлеген югалткан кардәшләребезнең бер өлеше Госманлы дәүләтенә күчеп килә һәм безнең ватандашларыбызга әйләнә. XIX йөз ахыры — XX йөз башында мәгариф, мәдәният өлкәсендәге элемтәләребез аеруча көчәеп китә. Әмма мондый бәйланышлар Совет дәверендә тәмам өзелеп кала. СССРның таркалуы, Татарстанның да Русия белән килешү төзеп, үз статусын күтәрүе безне чын-чыннан шатландырды — Төркия Татарстанга да кочагын ачты, кардәшләребезгә визасыз килеп-китеп йөрү мөмкинлеген тудырды. Тиз арада сәяси, икътисадый, мәдәни элемтәләр ныгыды, үзара файдалы сәүдә эшләре киңәя башлады. Казан-Истанбул һава юлы салыну, Татарстан-Төркия уртак ширкәтләре барлыкка килү, Идел буенда төрек-татар гимназияләре, көллиятләре, «Заман-Татарстан» гәзите ачылу кебек күңелле һәм файдалы башлангычлар канат җәя. Менә шулар тагын да зуррак колач алсын өчен Төркия Казанда үз консуллыгын ачарга карар бирде.

Консуллыкның төп максаты — Төркия белән Татарстан һәм аның якын күршеләре арасындагы хезмәттәшлекне ныгыту. Бу бигрәк тә сәүдә өлкәсенә карый. Киң куллану товарларын житештерү, төзелеш, банклар челтәрен заманчалаштыру һәм тагын кайбер тармакларда Көнбатыш тәҗрибәсен, технологиясен алданрак үзләштергәнлектән, Төркия Татарстанга булышырга омтыла.

Хәзерге вакытта Төркиядә Татарстанның 160 лап баласы белем ала, чыгымын тулысынча без күтәрәбез. Быелның май-июнь айларында Казанда Төркия университетларына кабул итү имтиханнарын оештырабыз — мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлегебез тагын да үсәр, иншалла. Татарстанда байтак төрек укытучылары, төзүчеләре, эшкуарлары хезмәт итә, Төрек мәдәни үзәге эшли. Ике арада әдәбият-сәнгать кыйммәтләрен алмашу көчәя. Без аларга яңа сулыш өрү, кыенлыкларны күмәкләп җиңү өчен барын да эшләргә җыенабыз.

Шушы уңайдан, 75 еллыгын бәйрәм итә торган «Казан утлары» журналының татар-төрек әдәби бәйланышларын киңәйтүгә, төрек әдәбиятын, тулаем Төркияне таныткуга аеруча күп әһәмият бирүе сөендерә. Төркия матбугатына да яхшы үрнәк бу. Журналыгызга яңадан-яңа казанышлар телим, ул киләчәктә дә татар-төрек мәдәни күпере хезмәтен үтәүдән туктамасын иде. Чөнки дәүләтара, халыкара дуслыкны ныгытуда мәдәниятнең, матбугатның роле зур.

**Алпхан ШӨЛӘН,**
Төркиянең Татарстандагы баш консулы.

## Фәрит Габдрәхим

### «Бир!» дибез

И ашкындык якты киләчәккә —
Яшәмәккә бушлай, акчасыз...
Фәрман белән генә җир сөрелеп,
Чишмә булып хәмер аксачы.

Яшиселәр килә җиңел генә,
Түләмичә сукыр бер тиен.
Бармы-юкмы — анда эшебез юк,
Бир син безгә икмәк, бир кием.

Күптән үлгән бушның ата-анасы,
Әйтерсең лә, шуны белмибез.
Мәзәктәге теге мулла кебек,
«Мә!» димибез, бары «Бир!» дибез.

Бәхетне дә хәтта бушлай гына
Без алырга әзер кушкуллап.
Беләсеңме, кордаш,
Капкындагы
Калҗа гына фәкать «буш» була...

*Уфа шәһәре*

*

## Басыйр Рафиков

* * *

Күпме гасыр инде — бабамнарның
Җырларына күчкән елгалар,
Гүя уелып-уелып, уйга талып,
Халкым йөргән юлдан агалар.

Ярлар нәүмиз, онытканнар күптән
Татар телен, татар тавышын...

Тик таллары тыңлый, өнсез калып,
Уел белән Уйның сагышын.

*Троицк шәһәре.*

*

## Әдхәт Синугыл

### Баккал йолдызы

*Кырымтатар халкының атаклы хореографы*
*Рәмзия Баккалга багышлыйм.*

Күкнең азмы йолдызлар гаиләсе,
Һәрбер йолдыз — төпсез серләр дәрьясы.

Төнен алар нурлар булып явалар,
Йөрәкләргә сүнмәс утлар ягалар.

Йолдызлар, без сездән илһам алабыз,
Сезнең кебек җирдә көн-төн янабыз.

Кайчак дөрләп янган утка керәбез,
Йолдызлардай, атылып та үләбез...

Фанилыгын хаятнең без беләбез,
Гомер өчен, гомерне дә бирәбез.

Үлмәс өчен — үлемсез ат алабыз,—
Без сәнгатьтә йолдыз булып калабыз!

*Кырым. Симферополь шәһәре.*

*

## Рөстәм Султи

* * *

Бу кадәр гамьгә түзмәде сазы,
Әйтелми калды әйтәсе сүзе,
Яшь белән тулды, әй, ике күзе —
Кол гариб Рөстәм инде нишләсен?

Күңленә сыйды җәннәт-җәһәннәм,
Сыймады күңеле ике галәмгә,
Ай белән кояш китте күгеннән —
Кол гариб Рөстәм инде нишләсен?

Күз яше тамып җан гөле кипте,
Ул гөле кипкәч былбылы китте,
Җаны яралы, күңеле китек —
Кол гариб Рөстәм инде нишләсен?!

*Төркия. Истанбул шәһәре.*

*

## Рәшит Гатауллин

### Авылга кайткач

Авыл тыныч. Бөтен дөнья тыныч,
Ник борчулы икән бу җаным?
Ничек кенә җайга салырга соң,
Мәңге тузгып торган дөньяны?!
Әле иртә. Үләндәге чыклар
Кемнәрнеңдер кебек күз яше.
Ә дөньялар әле шундый матур,
Ә дөньялар әле ямь-яшел.
Бөтен нәрсә түм-түгәрәк кебек,
Бөтен нәрсә җирдә ак, якты.
Бар нәрсәне төгәл, камил кылып
Яраткансың җиргә, йә раббым!
Шундый тыныч. Үләннәргә ау да
Бер җылачы җаның тынганчы,
Үләндәге чыклар югалганчы,
Шул тамчыга кояш чумганчы.
Авыл тыныч. Бар тирә-як тыныч.
Тынмас инде, тынмас бу җаным.
Акыл гына җитеп бетмәс кебек
Тынычлатыр өчен дөньяны.

*Уфа шәһәре.*

*

## Фоат Мортазин

### Бүләк ит миңа...

Җирнең барлык авазлары,
Күкнең барлык төсләре
Синсез чит булып киттеме? —
Тибрәтми уй-хисләрне...

Мең аваз урынына бер
Авазың ишетсәмче!

Салават күперен түгел,
Ал яулыгың күрсәмче!

Күзләрдә гел яшь элпәсе,
Сагыну, сагыш томаны.
Тик шул томан аша күрәм
Миңа «ят» бу дөньяны.

Кайт инде, кайт! Алып ташла
Күзләрдән бу элпәне!
Бүләк ит миңа ал таңны,
Сандугачлы иртәне!

*Ялта шәһәре.*

*

## Рәис Риян

### Олы Ока

Беләм, элек Бөек Сөн бабайның
Иделләрдә атлар сугарып
Яшәгәнен... Шуның нәселе ул
Татар-мишәр-болгар-суарым.

Һәм мин беләм Урал кочагында
Олы Ока дигән су барын.
Шунда озак тордым хозурланып,
Бунтарь йөрәгемне сугарып.

Башымда уй: Көнбатышта Ока,
Себердә дә Ока — чал елга.
Ә монысын Олы Ока диләр,
Хәтерме бу яки бер йола?

Алкын су буйларын урадым да
Тирәкләргә шунда сүз куштым:
Телгә килеп, елга шавын җиңеп,
Болай диде миңа бер дустым:
«Бик ашкынып һәрчак чаба-йөгерә
Иделләргә таба — киң юлга.
Суы тәнгә шифа, олы җанлы,
Шуңа Олы Ока бу елга.
Күрәсеңме, әнә җәйрәп ята
Бер мең йортлы татар авылы?
Ул да Олы Ока. Шушы суда
Сугарыла йөрәк-бәгыре».

Уйдаш булган өчен гел эчкерсез
Халкыбызга кыен елларда,

Рәхмәт әйтәм — җирем «ука»сына —
Олы Ока дигән елгага.

*Башкортстан. Караидел районы.*

*

## Халисә Мөдәррисова

* * *

Тәрәзәмне каерып давыл керде,
Дер селкетеп тынган күңелне,
Йокы баскан күзне чагылдырып
Давыл үтте, телеп күгемне.

Тәрәзәмне каерып давыл керде,
Давыл эзли үзенә тиңнәрен.
Син сагаеп күзләремә бактың,
Тик аларда курку күрмәдең.

Син алардан юаш курку көтмә,
Ул күзләрдә — ялкын, куз-күмер,
Тын күлеңнең төнбоегы түгел,
Диңгез акчарлагы бу күңел.

Тәрәзәмне каерып давыл керде,
Давыл аңлый минем җанымны.
Тәрәзәмне барып ябып куйдың...
Тик, туктатып кара — давылны!

*Башкортстан, Нуриман районы*

*

## Иделбикә

### Сагынам

Сагынамы йөрәк кайтмас назын:
үз көенә кучә тагын сазым,
җанландырып, куя күзалдыма
бәхет чорларының кайтавазын.
Оча уем Кавказ итәгенә,—
күрәм гөлтаҗ үргән яшьлек тавын.
Очып кайтам сыман яшьлегемә,
тыңлар өчен дулкыннарның шавын.
Үтәбез күк кулга-кул тотынып,
тагын парлап шаулы яз эзеннән.
Умырзая, энҗе чәчәкләре
нигә моңсу карый... аһ, күзеңнән?

...Көннәр-төннәр үтмәс төсле — озын.
Кышы-җәе — синсез түгел кызык...
Нигә ярсып, янган әле гомер?
Кайда безне кавыштырган сызык?

*Сембер шәһәре*

*

## Ринас Гайфин

### Моң

*«Сәхраләрдә ялгыз йөргән чакта*
*Яратам мин чәчәк исләрен...»*
(җырдан).

Искә төшә кылганнардан атлап
«Моң артыннан чапкан» мизгелләр,
Күңелемә сеңгән җырны ятлап
Барган чакта юлдаш — мең гөлләр...

Аһ, ул җырлар, чорлар ялкынында
Гасырларга таба очалар.
Тыңлаганда, хисләр дулкынында
Моңлы җанны назлап кочалар.

Кылганнардан, сөмбел чәчәкләрдән,
Сыкрап калган нәүмиз моң алар...
Кайнар мәхәббәтле йөрәкләрдән
Кайнап чыккан җырлар — мең алар.

Ә син, сазым, шул моңнарга кайтып,—
Җырла әле, җаным, җырлачы,
Төпсез күктә йөзә көмеш Ай тын...
Байтак җырның тугры юлдашы.

*Чувашстан. Батыр районы.*

Рифат Сверигин

# ПРОЗА ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

Әдәбиятның гомуми хәлен-торышын — ул бераз гына утыра төшкәч, читтәнрәк һәм вакыт күзлеге аша карап, җиңелрәк һәм дөресрәк бәяләп була. Болай эшләү җайлы, уңайлы булып тоелырга да мөмкин. Тик, уйлабрак карасаң, әлеге «алым»ның хәзерге әдәбият үсешенә уңай тәэсире, файдасы әллә ни зур түгел икәнлегенә төшенәсең. Әгәр дә башкарылган эш (шул исәптән әдәбият эше дә) үз вакытында тиешле бәясен алмыйча кала икән, ул, гадәттә, җиңел генә төзәтелерлек ялгышларыннан, хаталарыннан озак вакытлар арына алмыйча интегә, яисә әле генә ирешкән уңыш-табышларының чын кыйммәтен аңлап җиткермичә, тиз арада аларны югалтып та бетерә. Яшерен-батырын түгел: бүген әдәби җәмәгатьчелек, тәнкыйть яңа әдәбиятка, яңа прозага шактый ук битараф хәлдә яши, кайсыдыр яклары белән әнә шул яман аты чыккан «вакыт дистанциясе» тарафдарларын хәтерләтә. Шушы уңайдан мин журнал редакциясенең хәзерге проза турында зур сөйләшү башлап җибәрүен бик урынлы дип саныйм.

Чыннан да, ни хәлдә яши соң безнең бүгенге, ягъни туксанынчы еллардагы, башкачарак итеп әйтсәк, гасыр тәмамланып барган бер чорда туып килүче прозабыз? Бу сорауга кистереп кенә җавап бирү җиңел түгел, хәтта мөмкин дә түгел, ахры. Шулай да, кайбер яңа әсәрләр мисалларында төп тенденцияләр, юнәлешләр, казанышлар, югалтуларны билгеләргә, хәлләребезне ачыкларга тырышып карыйк.

Бүгенге татар прозасы өч тармак рәвешендә яши. Беренчесен, шартлы рәвештә, публицистик проза дип атарга мөмкин. Икенчесе — автобиографик язмалар — аларның кайберләре шул язма рәвешеннән күтәрелә алмасалар да, бездә ни өчендер, аларын да повесть яисә роман дип атап, укучыга тәкъдим итү гамәлгә кергән. Өченчесе исә уйлап чыгарылган, ягъни язучының иҗат фантазиясе белән туган саф, чын әдәбият — нәкъ шушы төр проза озак еллар дәвамында зур урын биләп торды — бүген исә аны алда әйтелгән ике тармак яхшы ук кысрыклый.

Публицистика һәм автобиография рәвешендә язылган әсәрләр аша укучыга байтак кына тарих һәм тормыш мәгълүматлары җиткерелсә дә, әдәбиятның чын йөзе, зурлыгы, кыйммәте, нигездә, язучының иҗат фантазиясе ярдәмендә тудырылган әсәрләр белән билгеләнә. Әле күптән түгел генә аның шунысы гына әдәбият дип саналып, тегеләрен публицистика дип йөртү гамәлдә иде. Мөгаен, бу бүленеш дөрес тә булгандыр, чөнки әдипләрнең иҗат мөмкинлекләре дә бар куәтенә чын әдәбиятта, ягъни уйлап чыгарылган әдәбиятта эшкә җигелә, әдәби осталыклары да бар булганынча күренә, югары уку йортлары өчен язылган әдәбият теориясе дәреслекләре дә әнә шундый чын, саф әдәбиятка нигезләнеп төзелгәннәр — шулар буенча күп меңләгән укучылар, студентлар әдәбият-сәнгать кануннарын-кагыйдәләрен өйрәнәләр.

Әгәр дә без журнал укучысы белән шул типтагы әдәбиятны беренчел дип санарга килешсәк, чыннан да, бәлки иң алдан шуларга мөрәҗәгать итәрбез. Бәхеткә, андый әсәрләр дә языла тора. Миңа калса, хәтта публицистика белән артык мавыгу якын киләчәктә инде кими төшәр төсле тоела.

Ә «саф» әдәбиятта татар прозасының укучыларны сөендерерлек уңышлары бөтенләй үк юк түгел. Күп булмасалар да, бар алар. Сүзнең, образлы сурәтләрнең кадерен белеп, әдәби әсәрнең искиткеч нәфис һәм тылсымлы иҗат уйланмасы, гаҗәеп могҗиза-конструкция икәнлегенә иманып язучы әдипләребезнең

шушы буталчык, тупаслык шартларында да үз кыйблаларын югалтмыйча, фидакарь хезмәтләрен күреп, ничек сокланмыйсың да, ничек сөенмисең?!

Шундыйларның берсе — Мәгъсум Хуҗин. Аның соңгы елларда дөнья күргән хикәяләре татар прозасының иң гүзәл энҗеләре дип саналырлык әсәрләр. Язучы үзенең һәр хикәясе белән укучыны матурлык дөньясына алып керә, образлы лирик сурәт-табышларына тирән эчке мәгънә сала һәм көнкүрештәге яхшылык, гүзәллек тойгыларын үтә бер табигый хәлдә укучыларына тәкъдим итә. Озын иҗат гомере дәвамында ул хикәягә гел тугрылыклы булып калды — жанрның иң күркәм традицияләрен югалтмыйча, бу өлкәдә үз юлын-сукмагын салды. М. Хуҗинның лирик хикәяләре искиткеч төгәллек, конструкция җиңеллеге, композицион тигезлек һәм тәэсир көче белән аерылып торалар. Мәсәлән: «Һомай кошлары», «Айның уты сүнгән», «Укалы карлар», «Төннең бикле тәрәзәсе», «Бәрәңге чәчәге», «Пшыяцулька» һ. б. Ә инде «Юл өзеге», «Урак өсте болытлары», «Чөй» исемле повестьларында һәм «Кулаклар колхозы», «Куларада кәлтә уйный» кебек хикәяләрендә автор татар кешеләренең язмышларын ерак чорлар, аерым алганда, утызынчы еллар фаҗигалары белән бәйли һәм шул хәлләргә үз мөнәсәбәтен бик ачык итеп белдерә.

Шушы уңайдан күңелне борчып торган күренеш хакында да әйтергә кирәк: олы әдип Мәгъсум Хуҗин иҗатына җәмәгатьчелек озак вакытлар буена шактый ук салкын димәсәң дә, бик ваемсыз һәм битараф булды... Мәктәпләр өчен төзелгән өр-яңа дәреслекләр, программаларда да бу язучы исемен хәзер дә очрата алмассыз. Ә менә нәкъ шундый осталар тәҗрибәсе, аның әсәрләрендәге әхлакый тәрбия көче яшь буыннар өчен кирәк булыр иде. Соңгы еллар прозасының үсеп, күтәрелеп килә һәм күзгә нык ташланып торучы тагын бер вәкиле — әлбәттә, шактый уңышлар казанган (бәхеткә, бу уңышлар нигездә объектив, дөрес бәяләнеп килә) Нәбирә Гыйматдинова. Бу очракта да эстетик яхшы әзерлек, әйләнә-тирәдәге тормыш күренешләренә хатын-кыз затларының кайберләрендә генә була торган ниндидер бер эчке сизгерлек, дөнья серләрен төрле яклап ачарга-аңларга тырышу, кабатланмас индивидуальлек һәм боларның барысы белән бергә чын профессиональ осталык бу әдибәне бик күп башка каләм тибрәтүчеләрдән аерып тора. Әлеге сыйфатлар янына тагын Нәбирә Гыйматдинованың кеше буларак та, автор буларак та табигый кыюлыгын өстәргә кирәк. Кеше психологиясенең тирән төпкелләрен яктыртканда Н. Гыйматдинова төрле рәсми, катып калган, схемачыл алым-мөнәсәбәтләрдән арынырга тырыша, ә үзенең геройларын җәмгыять үги иткән, читкә тибәргән, беренче карашка гади кешеләр өчен ятрак тоелган затлар арасыннан таба. «Күке төкереге», «Болан», «Кыргый» исемле яңа әсәрләре белән танышкач, бу авторның әлегәчә ачылып җитмәгән зур иҗат мөмкинлекләре барлыгына тагын бер кат ышанасың.

1996 ел прозасын барлаганда, китап сөючеләр шулай ук «Мөһер» исемле маҗаралы повестька (Госман Гомәр), «Кыйбла» (Айдар Хәлим), «Кыңгырау» (Фәрит Нәгыймов) хикәяләренә дә игътибар итәрләр дип уйлыйм. Аерым алганда, яшь автор Ф. Нәгыймовның күңелдә янганны көчле, тәэсирле динамик образ-сурәт, куе, ачык буяулар ярдәмендә әйтеп бирү осталыгы җәлеп итте («Казан утлары», 1996, 11 сан).

Соңгы вакытта прозаның публицистика рәвешендәгесе киң таралу хакында алдарак әйтеп үткән идем. Андый әсәрләрдән укучы, гадәттә, тормыш, тарих һәм социаль вакыйгалар турында кызыклы һәм дөрес мәгълүматлар ала, шулар ярдәмендә үзен информация-эрудиция ягыннан баета, үстерә. Әгәр ул мәгълүматлар тәҗрибәле, дөньяга киң карашлы авторның уйлануларЫ яктылыгында дәлилләп, тасвирлап та бирелсә, мавыгып укырдай әсәрләр туа. Шундыйлар рәтенә «Утлы таба өстендә» (Ринат Мөхәммәдиев), «Догалы еллар» (Марсель Галиев), «Тимерханның авыл юллары» (Гариф Ахунов) әсәрләрен кертергә мөмкин. Беренчесендә илебез тарихында әле күптән түгел генә булып узган куркыныч, дәһшәтле көннәр хронологиясен шул хәлләрнең шаһите булган, аларны үз йөрәге аша кичергән шәхеснең дулкынланып сурәтләве укучы күңелен дә тетрәтә. Икенчесендә исә язучы Марсель Галиев үзенең укытучыларын-остазларын яратып искә төшерә: Хәсән ага Туфан, Гази ага Кашшаф, Ибраһим ага Нуруллин, Мансур Хәсәнов кебек шәхесләр — бүген дә мәдәният-мәгариф өлкәләрендә эшләп йөрүче бик күп зыялылар тормышына уңай йогынты ясаган, якты эз калдырган затлар. Шулай булгач, мондый зыялыларның Марсель Галиев сурәтләмәләрен үз тәэсир-карашлары белән чагыштыру мөмкинлекләре дә бар. Мондый хәл, әлбәттә, аерым бер кызыксыну уята. Ә инде яшь укучыларны әдипнең ышандыру сәләте, тасвирлау осталыгы да үзенә җәлеп итә.

«Догалы еллар» әсәрендә мәшһүр балет биючесе Рудольф Нуриевка багышланган сәхифәләр дә бар. Шулай да, миңа калса, бу өлеш, авторның турыдан-туры үз күзәтүләренә таянып язылмаганлыктан микән, әлеге әсәргә читтән килеп кергән, бигүк ябышып, ятышып бетмәгән кебегрәк тәэсир калдыра. Минемчә, М. Галиев атаклы татар биючесе турында күләмле аерым әсәр дә иҗат итә алыр иде. Әлбәттә, бу очракта жанр һәм стильнең башка төрлерәк рәвеш-формаларын эзләргә туры киләчәк. Гомумән, бу кызыклы һәм игелекле эш булыр иде.

1996 ел прозасының бик үзенчәлекле һәм яңа казанышы булып Зәки Зәйнуллинның «Ат караклары» романы саналырга хаклы. Халкыбыз үткән юлда, чыннан да, билгеле эз калдырган, аннан да бигрәк күп төрле риваятьләр-әкиятләр, легендалар, уйдырмалар, шомлануларга сәбәпче булган ат урлау, ат караклары темасына, әлбәттә, теләсә кем (мәсәлән мәктәп, вуз эскәмияләреннән килеп, хәзер биек йортлардагы кабинет тәрәзәләреннән карап, тормышны өйрәнүче, анализлаучы каләмдәшләребез) тотына алмый. Беренчедән, материал үзенең хәвеф-хәтәрлеге белән әллә каян өркетеп тора. Икенчедән, күзләреңне йомып алынсаң да, күп нәрсә майтара алмаячагың көн кебек ачык — тормыш тәҗрибәсе җитенкерәми. Бирелә каләм усал айгырларны иярләрлек гайяр, дуамал холыклы ир-егетләр кулында гына бии ала! Интеллигент табигатьле, тәртипле-инсафлы әдипләребез үпкәләмәсеннәр. Чөнки әдәбиятта һәркемнең үз темасы була. Бу — алар темасы түгел. Бу — Зәки Зәйнуллин темасы.

«Ат караклары» романында укып туймаслык урыннар, күренешләр, искитәрлек характерлар, башкисәр геройлар бар. Кайберәүләр өчен төп максатка әверелгән шөгыльнең үсеше-тарихы, эволюциясе, һәлакәте һәм ат урлау романтикасы турында гына түгел бу әсәр. Аңардан ниндидер бер тыелгысыз омтылыш, ирек даулау, бер кемгә дә баш бирмичә, үзенчә яшәү теләге дә бөркелеп тора. Мәсьәләнең бу ягына эчкәре кермәстән, мин З. Зәйнуллинның язу осталыгы әсәрдән-әсәргә камилләшә һәм чарлана баруына гына игътибар иттем. Ә мондый камиллеккә материалны, теманы яратып, бирелеп язганда гына ирешеп була.

Мәгълүм ки, Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң бер 10—15 еллар дәвамында булса кирәк, әдәбиятта тормышның гел матур якларын гына сурәтләү өстенлек итте. Бу берьяклы күренеш әдәбиятны тормыштан шактый ераклаштырды, яшь буынны тәрбияләү эшенә зур зыян китерде — мондый әсәрләрне укып үскән кайбер яшьләр тормышның беренче бусагаларын атлаганда, аптыраштa калып, рухи кризис кичерделәр.

Бүген исә куркыныч икенче яктан яный: тормыш күренешләрен гел карага, пычракка манчып укучыга тәкъдим итү. Әйләнә-тирәдә гел юньсезлек күренешләренә күнегеп үсхән яшь кешене монысының да соңрак адаштыруы ихтимал. Тормышта явызлык, әшәкелек аз түгел анысы. Ләкин әлеге хәл әдипләребезгә, тормыштагысын язам дип, начарлык күренешләрен күп тиражлар белән тарату хокукын бирми бит.

Кызганычка каршы, татар прозасы бу басымга каршы тора алмады — «негатив проза» үрнәкләренә әдәби басмаларда урын көннән-көн күбрәк бирелә. Чыннан да, тормыш шыксызлыгы, аның ямьсез якларын иркенләп, тәфсилләп сурәтләү аркасында ташы-пычрагы, сазлы ләмнәре бергә буталган масса әдәбиятыбыз инкүлекләренә, кырларына, болын-тугайларына җәелә. Озакламый бу тугайларда матур кошлар сайравын да, түбәндә басылып калган күп төрле бөҗәкләр кыштырдавын да, хәтфәдәй хуш исле үләннәр күтәрелүен дә күреп, ишетеп булмас, ахры.

Мәшһүр журналыбыз — «Казан утлары»ның — 1996 елгы төпләмен кулыбызга алыйк. Шунда ук теге «негатив проза» үрнәкләренә юлыгырбыз: «Тәүбә» (Тәлгат Галиуллин), «Ирекле тоткыннар» (Роберт Айзатуллин), «Җимерелгән хыяллар» (Әнәс Галиев).

«Тәүбә» романында алдалаучылар, махинаторлар, җинаятьчеләр тирәлегенең бик күпләребезгә бөтенләй билгеле булмаган яклары күрсәтелә. Әсәрдә криминаль дөньяның үзе, шул дөньяның кешеләрне җинаятьчеләргә әверелдерүе бөтен нечкәлекләре белән ачып салына. Бу дөньяны автор шактый оста итеп сурәтли. Гомумән, Т. Галиуллин күренешләрне дә, геройларны да тасвирлый белә. Аның бу сәләте күп төрле эпизодларда, шул исәптән «пикантлы» янсә эротик дип йөртелүче күренешләрдә дә, персонажларның белем, эрудиция чамасын, зыялылык дәрәҗәләрен күрсәтергә кирәк булганда да бик теләп эшкә җигелә. Торабара, әсәрнең финалына якынлаша төшкәч сюжетның динамикасы янсә хәрәкәте тизләнә, криминаль вакыйгалар өермәсе безне, ягъни укучыларны, үз стихиясендә бөтереп йөртә башлый. Әллә нинди бер сәер тойгы да уянгандай була: гүя

без бар булган зыялылыгыбызны, күренешләрне объектив бәяләү сәләтебезне дә югалтып, онытып бетергәнбез дә, шул җинаятьләр тезмәсенең гап-гади шаһитларына әйләнеп калганбыз. Романның искитмәле шушы тәэсиренә шаккатып, монысы «негатив проза» дип аталган яңа жанр формасының акылгазиһенгә күп нәрсә бирмәсә дә, мавыктырып укыттыра торган бер хасиятедер дип үз-үзебезне ышандырып, әсәрнең тәмамлануына бераз уфтангандай да булып, соңгы битен ябып куябыз. Ә гел маҗаралы әсәрләр рухында тәрбияләнеп үскән яшьрәк укучыларыбыз «шәп детектив булды бу» дип нәтиҗә чыгарырлар, мөгаен.

Тәлгат Галиуллинның романчы буларак ясалган тәҗрибәләре белән танышкач, ирексездән Мөхәммәт Мәһдиев искә төшә. Алар икесе дә әдәбият фәне галимнәре, педагоглар, әдәбият-сәнгать серләрен яхшы белүчеләр. Икесе дә гомер юлының икенче яртысына баскач кына язучы булырга җөрьәт иттеләр.

Мөхәммәт Мәһдиев, үзенең тормыш финалы якынлашуын алдан сизенгәндәй, озын булмаган иҗат дәверендә әйтәсе сүзләрен халкына, яраткан укучысына җиткерергә ашыкты һәм әдәбиятыбызның алтын хәзинәләре рәтендә сакларлык гүзәл әсәрләр калдырырга өлгерде.

Тәлгат Галиуллинга исә исәнлек һәм озын гомер теләп, колагына гына шушы сүзләрне өстәп әйтәсе килә: әгәр ул шушы мәшәкатьле, тынгысыз язучылык шөгыленә үзенең кыйммәтле академик сәгатьләрен багышлый ала икән, бу яңа хезмәте дә төп эше шикелле үк тирән мәгънәле була күрсен. Үзенең эрудициясе, дөньяны аңлавы, тормыш законнарын белүе, яңа, әле генә без күргәннән шәбрәк, үрнәк булырдай образларга, геройларга күчсен һәм туачак, язылачак әсәрләрен тагын да баетсын иде.

Гомумән алганда, мин үзем бу караңгы прозаны татар әдәбиятына, аның традицияләренә бигүк ярашлы күренеш түгел һәм аны артык үрчетү кирәкмәс иде дип саныйм. Тема «Кенәри — читлек кошы» (Ринат Мөхәммәдиев), «Балта кем кулында?» (Аяз Гыйләҗев) әсәрләрендә шактый тулы итеп ачылган иде бит инде. «Чернуха» тибындагы мондый әдәбиятка булган моданың инде үтеп барырга тиешлеге һәркемгә аңлашылсын иде. Әмма бу фикер белән килешмәүчеләр дә бар. Мөхтәрәм «Казан утлары» журналыбыз үзе дә караңгы прозаны хуплый булса кирәк. Югыйсә кыска гына вакыт эчендә мәсләк-мәүзуглары, төзелешэшләнешләре белән бер-берсенә охшаган шул типтагы күләмле ике әсәрне бербер артлы тәкъдим итүен ни белән аңлатырга?

«Ирекле тоткыннар» һәм «Җимерелгән хыяллар» романнарының сюжет схемаларында ике тамчы су шикелле охшашлыклар бар. Мәсәлән, һәр ике әсәрдә дә авыл хуҗалыгын күтәрү максатыннан авылга читтән рәис җибәрелә. Яңа килгән иптәшкә хуҗалыкны җайга салу, эшкә, кешеләргә гадел мөнәсәбәт урнаштыру аша абруй казану өчен, әлбәттә, байтак кына тир түгәргә туры килә. Ике әсәрдә дә яңа рәисләрнең хәләл җефетләре ирләре артыннан күченеп килергә ашыкмыйлар һәм... бик нык ялгышалар. Яңа рәисләребезне яңа урында «ауларга», үзенеке итәргә теләүче чая, чибәр хатыннар сагалап тора. Унай героебыз шул яңа сылу кочагына килеп төшәрме, әллә законлы хатынына тугрылыгын саклый алырмы? «Җимерелгән хыяллар»да шундый ук сынауны вакытлыча иреннән аерылып, шәһәрдә калган хатынның үзенә дә үтәргә туры килә.

Әнә шундый кайбер аермаларны исәпкә алмаганда, авторлар үз укучыларын бер үк эзләрдән яисә сукмаклардан йөртергә тырышалар. Әнәс Галиев романының баш герое карьера, көнкүреш һәм мәхәббәт маҗараларыннан исән-имин котыла. Олы хыяллары җимерелгән кебек булса да, әсәр бик өметсез, ямьсез тонда тәмамланмый. Шунысын да әйтим: бер укый башлагач, мин бу әсәрне яратырга да өлгердем. Сәбәбе нәрсәдә икән? Мөгаен, сәбәпләре берничәдер. Әнәс Галиев бик табигый, аңлаешлы итеп яза — аның татар классик прозасы рухында тәрбияләнүе сизелә. Икенчедән, ул баш героеның төп профессиясенең (финанс инспекторы) нечкәлекләрен яхшы белә. Өченчедән, бу автор тормышның ямьсез якларын сурәтләгәндә дә, аны ниндидер эчке әдәплелек көче тыеп тора.

Шулай да, бер-ике урында Әнәс Галиев тә чама хисен югалтып җибәргәли: бигрәк тә элеккеге партия әгъзаларын, җитәкчеләрен сурәтләгәндә. Менә кайбер мисаллар:

«Икенче секретарь Фәйзуллин — чәчләренә ак кергән, кысык күзле, табак битле, урта яшьләрдәге ир... Уң кулының бармаклары махорка төтененә саргайган, авызыннан бер чакрымга сасы ис аңкый».

«...карт большевик Иванов чыгыш ясады. Аның тешләре юк. Сөйләгәндә селәгәе ага. Утырышта катнашучылар чирканып, аның йөзенә күз төшермәскә тырышалар, ул чыгышын Лениннан цитата китереп башлады».

Болар янына «Ирекле тоткыннар» романындагы райком секретаренең дә авызы, йомшаграк итеп әйткәндә, тирә-юньнең һаваны «озонлаштырмаганлыгын» өстәсәк, бу урындагы картина шактый тулыланыр.

Менә шулай — заманында әдәбиятыбыз партия әгъзаларын, житәкчеләрен өсләренә кер кунмастай затлар итеп күрсәткән булса, бүген алар әнә нинди хәлгә төшкәннәр!

Роберт Айзатуллинның романы әйбәт кенә башланып китә. Әсәрнең идеясе дә төсмерләнеп килә сыман: ул — тоталитар система тудырган түрәләргә, житәкчеләргә, аларның намуссызлыгына, икейөзлелекләренә, ялганлашуга, әшәкелекләренә нәфрәт уяту һәм фаш итү. Авторның үзе сурәтли торган өлкә — авыл хужалыгы хәлләре, проблемалары белән дә хәбәрдарлыгы аңлашыла. Бер мәлгә вакыйгалар да төенләнеп, эзлекле генә үсеп килә башлыйлар. Әмма тора-бара хәзерге романнарның күбесендә очрый торган житешсезлек үзен сиздерергә керешә. Бу кимчелек «композиция таркаулыгы һәм күпсүзлелек» дип атала.

Еш кына менә нәрсә күзәтелә: авторларның укучыга әйтергә теләгәннәре бик зурдан түгел, кайбер очракларда исә әсәрдә роман жанрын күтәрерлек олы фикерләр, тема-идеяләр дә булмый. Әмма хезмәтеңне роман дип атагансың икән, бу исемне ничек тә акларга кирәк бит: менә шуннан инде өстәмә вакыйгалар уйлап чыгару, аларны өсте-өстенә тезү башлана. Һәм әсәр күзгә күренеп озыная, калыная бара. Әмма бу кабатланып торучан вакыйгалар әсәр сюжетына зур яңалык өстәмиләр, сюжет үсеше туктала, автор һәм геройлар бер урында тапанып торалар — нәтиҗәдә, сюжет, композиция җепләре буталып бетә, әсәрнең бөтенлеге юкка чыга, идеясе тоныклана.

«Ирекле тоткыннар» романы да алдан уйланылган рәвешендә финалга барып житә алмаган. Баштарак уңайрак булып күренгән геройлар-героинялар житәкчеләренең, бигрәк тә секретарьнең кабахәт кыланышларына, шулай ук үзләренең аянычлы хәлләренә дә битараф карый башлыйлар, түбәнлеккә төшәләр. Хәтта баш герой Ленар да характер буларак үзен югалта.

Кимчелекләрнең төп сәбәбе — роман кебек катлаулы организм төзегәндә жанр, сюжет, композиция таләпләренең күп төрле якларын, эчтәлек һәм форма категорияләренең төгәл, тигез ярашырга тиешлеген исәпкә алып бетермәү. Минемчә, бу ике әсәрнең авторларына повесть жанрына тукталып, төзәтеп эшләргә тәкъдим иткән булсалар, бәлки, отышлырак булган булыр иде.

Вакыйгалылык һәм вакыйгаларның куелыгы, чытырманлылыгы бөтенесен хәл итә дигән карашның күләмле жанрларга үтеп керүен нык тәнкыйтьләргә кирәк. Чыннан да, соңгы елларда дөнья күргән бик күп романнар һәм повестьлар сюжет-композиция бөтенлеге, идея җегәре, проблемалар куелышы җәһәтеннән шактый зәгыйфьләр.

Бу урында яңа тип роман, повесть дебютантларына Гариф Ахунов, Айдар Хәлим, Фәнис Яруллин кебек әдипләрнең иҗат алымнарына игътибар беләнрәк карасыннар, өйрәнсеннәр иде дип әйтәсе килә. Мәсәлән, Гариф Ахунов Тимерхан турындагы әсәрләре циклын җыйнак эшләнгән кечкенә повестьлардан төземичә, зур роман-эпопеяга әйләндерә алмас идемени? Юк шул, әдәбиятыбыз аксакалы әсәр компонентларын, өрлекләрен, баганаларын әйбәтләп, шыплап үз урынына утыртып барырга кирәклеген бик яхшы белә. Һәр кисәген, һәр өлешен ашыкмыйча эшләп бетерми торып, укучы хөкеменә бирергә ашыкмый. «Идел кызы» трилогиясенең әле һаман язылып бетмәвен дә фәкать шуның белән — авторның әдәбият-сәнгать кануннарына олы ихтирамы янсә үз укучысы алдында үтә җаваплылык хисен тоеп эшләве белән генә аңлатып була торгандыр.

Янсә Айдар Хәлимнең «Кыйбла» исемле яңа әсәренә игътибар итик. Хикәянең фикер-идея йөкләмәсе, ташып торган куәте аның җыйнаклыгына, образлы сурәтлелегенә искиткеч матур тәңгәл килеп тора.

Фәнис Яруллинның прозадагы казанышлары, оригиналь эшләнгән повестьлары («Кайту» h. б.) һәм хикәяләре әле һаман да әдәби җәмәгатьчелекнең кулы тимәгән бер өлкә булып кала бирә. Бу иҗат махсус өйрәнүне, тикшерүне сорый.

Мондый үрнәк мисалларны хәзерге прозабыздан тагын да китерергә мөмкин булыр иде. Бу урында төп фикеремне кабатлап әйтәсем килә: әдәбият дөньясын-

да үз сүзләрен яңа әйтә генә башлаган иптәшләребез үзләренең әйләнә-тирәсендә кемнәрнең ничек итеп әдәбиятка, халыкка хезмәт итүләре турында да белеп торсыннар, мыекларына чорнасыннар иде.

Тырышып эзләгәндә прозабызның якты якларын да табарга була. Тик халык җырындагыча:

Эзләсәң лә маллар, һай, табыла,
Йөрәкләргә каннар савыла...—

дигәненңне сизми дә каласың.

Әйе, татар прозасының үзенә бик авыр йөкләр салып, «эһ» тә димичә тарткан чаклары бар иде. Бүген исә «атларыбызның» кайсы арык, кайсы өшәнгән, кайсы карт. Сәләтлеләре дә битарафланды...

Көн кадагына суктырырдай мәсьәләләрне кем үз-үзен аямыйча прозада биеккә күтәрер? Татар теленең, китабының аяныч хәлләре, сәнгате-мәдәниятенең үз йөзен югалта баруы, авыл һәм шәһәр яшьләренең рухи ярлылануы, милләт үзәкләреннән аерылып калган татар кешеләренең язмышлары, гаилә эчендәге һәртөрле мөнәсәбәтләр белән бәйләнештә тәрбия проблемалары, киләчәгебез, алдагы буыннар, табигать алдындагы җаваплылыгыбыз, вәхши сугышлар каршындагы көчсезлегебезнең сәбәпләре, илаһи дөнья һәм үзебез...— саный китсәң, алар әле тагын бик күп булачак. Аларны кем, кайсы язучы кузгатачак? Сүз гади фактларны теркәп чыгу турында гына түгел, ә күренешләрне Еникиләрчә, Бәшировларча тамырларыннан тикшереп, сәнгатьчә анализлап, иҗтимагый фикерне уяту турында бара!

Аеруча борчыганы: аянычлы хәлләрне күреп, бүген берәү дә чаң сукмый. Киресенчә, әдәбият дөньясында ниндидер үз-үзеңнән канәгатьлек, артта калган гомер юлының азмы-күпме күзгә эленгән түмгәкләрен барлап, җыештырып, бар булганына шөкер кылып, сөенеп, бәйрәм итү рәхәтлеге хөкем сөрә. Мәгълүм ки, җәмгыятьнең намусы, йөзенең аклыгы булырга тиешле әдәбият үз-үзенә соклану, артык канәгатьләнү хәленә төшә икән, ул чын әдәбият сыйфатларын югалта. Заманында Лев Толстой, Федор Достоевский, Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан кебек изге, олы затлар шул хәлдән сакланырга чакырганнар һәм чын әдәбият эшенә бар көчләрен, тормышларын багышлап көрәшкәннәр.

Ә бүгенге татар прозасы үткен, хәтәр тема һәм мәсьәләләрдән читтәрәк йөрергә тырыша. Хәер, үтә дә мескен бер хәлгә куелган әдәбият кешесеннән күп нәрсә таләп итәргә мөмкинме икән? Бүген акча капчыгы хакимлек итә. Кая ул гражданлык сүзеңне әйтү? Акчалы кешеләрнең авызларына карап, аларча җырласаң, бәлки китаплар да чыгара алырсың... Элекке гасырларда фикерләр хакиме саналган әдип һәм бүгенге көннең хәерче язучысы арасында никадәр аерма! Ә шулай да, шундый шартларда да язалар, нәрсәдер иҗат иткән булалар. Рәхмәт инде шунысы өчен дә аларга!

Әдәбиятның үз проблемаларына әйләнеп кайтыйк. Хәзерге татар прозасының иң зур җитешсезлекләре түбәндәгеләр:

— авторларның гражданлык позицияләренең ачык булмавы, аларның тар, шәхси мәнфәгатьләрдән чыга алмаулары, проблемалар сайлыгы;

— әдәби әзерлекнең җитешмәве, әдәби техниканың ярлылыгы һәм кайбер язучыларның үзләренең шуны аңларга теләмәүләре;

— публицистика, автобиографияләр, мемуарлар белән артыграк мавыгу һәм классик әдәбият традицияләреннән беркадәр читкә төшү;

— әсәрләрдәге төссезлек, бертөрлелек, тема, проблема, ситуацияләрнең эчпошыргыч рәвештә кабатланулары, иҗат фантазиясенең ярлылыгы;

— хикәя жанрында талымсызлык, аның миниатюра рәвешендәге энҗе икәнлеген онытып җибәрү;

— повесть һәм роман жанрларында күпсүзлелек, композиция һәм сюжет таләпләрен санга сукмау, әсәргә караңгы, ямьсез буяу-сурәтләрне артык мул салу;

— талантлы стиль осталарын бүтәннәрдән аерып күрсәтә белмәү — монысы күбрәк тәнкыйть өлкәсенә карый.


Әдәбият үсешенә, аны өйрәнү-аңлатуга бәйләнешле тагын бер күңелсез күренеш хакында әйтеп китмичә булмый: соңгы вакытта мәктәп программаларыннан ашыгыч рәвештә әдәбиятыбызның мактанычы булган язучыларның әсәрләре «идеологик яктан искергән» дигән сылтау белән алып ташлана (Галимҗан Ибра-

һимов, Шамил Усманов, Кави Нәҗми, Әхмәт Фәйзи, Гадел Кутуй, Ибраһим Гази, Гариф Гобәй һ. б.). Шуннан соң барлыкка килгән бушлык хәзерге көннең урта кул язучылары иҗат иткән уртача яисә түбән сыйфатлы әсәрләр белән алмаштырыла башлады. Болай барса, классик әдәбиятыбызның зур өлешеннән мәхрүм калган укучы буыннар яхшыны — уртачадан, яисә начардан аера алмастай булып үсәчәкләр. Әлбәттә, монда ныклап бәхәсләшерлек урыннар да бар, әмма гомумән алганда, бу — зарарлы тенденция.

Мәкалә ахырында дөнья әдәбиятыннан мисал китерәм: Норвегия классигы Кнут Гамсунның бер романында берничә ел гына элегрәк сукырайган бер кеше образы күренеп китә. Җәйге тымызык кичләрдә ул, капка төбенә чыгып, рәхәтләнеп авыз гармуны кычкырта. Сукыр булса да, ни өчендер, үз хәленнән, үз тормышыннан бик канәгать бу яшь кеше: күп ашый, гамьсез, үзе теләгән вакытта чыгып, музыка уйный. Киләсе елга бәлки аны шәһәргә алып барырлар һәм күзенә операция ясатырлар..., бәлки алып бармаслар да..., алып барсалар да, операция әллә уңышлы чыга, әллә юк... Тик героебызны бүген болар берсе дә борчымый — ул ишек алдына чыгып — үз музыкасына үзе хозурланып, үзе өчен уйный («Странник играет под сурдинку»).

Туксанынчы еллар татар прозасы әнә шул, вакытлыча сукырайган ваемсыз кешене хәтерләтә сыман. Аны вәхшиләр, сугышлар да, халыкның бүгенге өметсез халәте дә, галимнәр, язучылар, башка зыялыларның хәерчелекнең соңгы чигенә җитеп, акча капчыклары өстендә утыручыларның елмаюлы карашын ауларга мескенләнүләре дә, туачак гасырга нинди рухи кыйммәтләр белән керәчәгебез дә борчымый, ахры. Киләчәктә тормыш үзеннән-үзе яхшы булачак дигән хыял белән яши ул.

Ә шулай да, кем белә: гасырлар чиген атлаганда бәлки без — ваемсыз сукырларның да — күзләре яңадан ачылыр, дөньяда үзебез генә түгеллекне, әйләнә-тирәбездә башкалар хәсрәте барлыгын да күрербез, үткәнебезгә, алдагысына карап, «аһ» итәрбез. Күзләрдән пәрдә төшәр. Кем белә?.. Ә бүген без Кнут Гамсун персонажы хәлендә — үзебез чыгарган көйгә үзебез оеп утырабыз сыман.



## Әмирхан Еники

# МАТУРЛЫК

*(Бер карт әдип авызыннан)*

Күптән, бик күптән булган вакыйга, әмма бүгенгедәй күз алдымда: без, өч шәкерт, бер атка утырып, өяз мәдрәсәсеннән авылыбызга кайтырга чыктык. Дөресрәге, Гыйлемдар белән без икәү бер авылга — Чуаркүлгә кайтабыз, ә Бәдретдинне юл өстендәге Ишле авылында калдырып китәргә тиешбез. Тагын шуны да әйтим, безне ялкау гына юыртып алып кайткан күк алаша Гыйлемдарларныкы иде. Без авылда алар белән күрше генә торабыз. Шул сәбәпле Гыйлемдар белән мине алырга бер язын безнең ат килсә, икенче язда алар аты килә торган иде.

Ә Бәдретдин — безнең очраклы юлдашыбыз. Дөрес, без мәдрәсәгә бер вакытта җыелабыз, бер вакытта таралабыз, ләкин моңарчы аның белән бергә кайтырга туры килгәне юк иде әле. Бәдретдин кешегә бер дә йөк булырга яратмый иде. Укулар беткәч тә ул базарга килгән авылдашларының берсенә ияреп китә дә бара яки ялгыз үзе генә утыз чакрымдагы авылына җәяүләп сыптыра торган иде. Бу юлы инде без аны, үзебез сорап, дигәндәй, бергәләп кайтырга күндердек.

Бәдретдин безнең мәдрәсәдә иң ярлы шәкерт иде. Аңа авылыннан бернинди дә ярдәм килми иде. Тик Ишледән базарга килүче берәрсе бик сирәк кенә аңа әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде. Бәдретдин шуны да бик кыенсынып: «Нигә инде бу? Әнкәйгә әйтегез, мин ач түгел, үзеннән өзеп җибәрмәсен!» — дип алып кала иде. Һәм шул майны ул ни өчендер без белән чәнчеп ашый иде. Шәкертләр аңардан: «Нигә алай итәсең?» — дип сорасалар, Бәдретдин көлгән булып кына: «Без белән ашагач, озакка җитә ул!» — дип җавап бирә торган иде.

Илдә чыпчык үлми, дигәндәй, безнең Бәдретдин дә, бик интегеп, ачка киселеп булса да, укуын әнә шулай алып бара иде. Һәм бик яхшы укый иде ул. Хәер, бу күп сыналган нәрсә: рәхимсез нужада торып укыган ярлы шәкерт гадәттә бик сәләтле булып чыга. Башкача аңа мөмкин дә түгел. Бай шәкерт, әйтик, туң күчән булса да, мәдрәсәдә теләсә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була... Аннары ярлы шәкерт бик яхшы укыса гына үзенең матди хәлен дә беркадәр җиңеләйтә ала.

Менә безнең Бәдретдингә дә, ул замандагы тел белән әйтсәк, истикамәтле вә иҗтиһатлы шәкерт булганга күрә, байлар иганәсеннән ара-тирә ярдәм тия иде; начар укучыларның дәресләрен хәзерләшкән өчен дә аңа аз-маз тама иде, Хәлфәләргә дә ул булышкалый иде, аннары авыру-сырхауларга догалыклар, аятел-көрсиләр күчереп тә азрак

бакырлар төшергәли иде. Кыскасы, эшсез тормый иде шәкерт. Ләкин эшне дә, ярдәмне дә ул үзе бервакытта да сорап алмый иде. «Мин бит ярлы, миңа ярдәм итү — сезнең вазифагыз»,— дигән әрсез мескенлекне без аның йөзендә беркайчан да күрмәдек.

Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк — андыйлардан үзен ничектер бөтенләй читтә тота белә иде. Тагын шунысы кызык, никадәр генә ярлы булмасын, ул берәүдән дә бернәрсә дә сорарга яратмый иде. Гадәттә шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе — энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, пәкесе дә, эскәге дә, көзгесе дә, төрле каләмнәре дә, кәгазь-дәфтәрләре дә, хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде. Ничек җыйгандыр ул аларны, ләкин, һаман шул ярлылыгым кешегә йөк булмасын, дип, тамагыннан өзеп булса да, тырышкан күрәсең инде. Дөрес, ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.

Ул заманда, ягъни революция алды елларында, шәкертләрнең яңа әдәбият белән мавыгуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк шикелле үк зарури бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә. Ике шәкертнең берсе шигырь яза. Бик күпләр Сәгыйть Рәми белән тилерә. Аңа ияриәләр, аңа охшарга тырышалар, аны яттан сөйләп йөриләр... Дөрес, безнең барыбыз өчен дә бөтенесеннән өстен, бөтенесеннән якын — Тукай иде, иң күп күчерелгән, иң сөеп укылганы да Тукай иде.

Шигырь чире безнең Бәдретдингә дә йоккан иде, ул да яза иде, ләкин язганын бервакытта да күтәреп, очраган берәүгә укып йөрми иде. Аны сорап та укырга күндерүе читен иде. Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешен гади генә сурәтләгән яки үзенчә берәр тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде.

Әнә шундый сәер генә, серле генә һәм сөйкемле генә бер егет иде безнең Бәдретдин шәриктәшебез!

Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз. Юл такыр, тузан юк, күк алаша, эченә кату төшүдән «горт-горт» иткән тавыш чыгарып, үз көенә салмак кына юырта... Күптән түгел, май урталарында, беренче җылы яңгырлар явып узган иде. Хәзер бөтен нәрсә дәррәү кузгалып, күтәрелеп, үсеп бара: арышлар сабакка сузыла башлаган, бодайлар куе булып, кучкыл-яшел булып, егетләр мыегыдай, сызылып кына чыгып килә; сөрелмәгән чирәмнәрдә яшь үлән былтыргы корыган үләнне басып, каплап та киткән, кайберләре инде чәчәкләрен дә ачарга өлгергән... Юл буенда әнә эт эчәгесенең беренче ал «кыңгыраулары»... Әйтәсе дә юк, табигатьнең иң саф, иң садә, иң ямьле чагы!..

Безгә, кыш буе мәдрәсәдә кибеп яткан шәкертләргә, бу чиксез иркен, якты, җылыкай дөнья искиткеч тансык иде, шифалы-рәхәт иде, без аны иснәп тә, сулап та, күзләребез белән күреп тә туя алмый идек. Баштарак без әледән-әле тарантастан төшеп, аякларыбыз җирнең йомшаклыгын бер рәхәтләнеп татысын, дигәндәй, чирәмгә кереп киттек, йөгерештеккуыштык, иелеп чәчәкләр өздек. Бәдретдин тау юасы тапты, аны өзеп чәйнәдек. Мин безнең авылда «тәмлекәй» дип йөртелә торган сабагы дүрт кырлы, озын гына бер үсемлекне җыеп алдым. Аны да, тиресен суеп,

ашап карадык. Бәдретдин әйтә, моны башкортларда «кияү камчысы» дип йөртәләр, ди, чөнки очындагы менә шушы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул чынлап та чуклы камчыга охшап китә, ди.

Ә безнең Гыйлемдар, озын сыйрак, гел йомран эзләп чапты, туктап, ике учын кушлап сызгырып та карады, ләкин хәйләкәр җәнлек шәкерт сызгырганын сизә иде ахрысы, оясыннан чыгып, колакларын торгызып, арт тәпиләренә утырмады.

...Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнеп-чыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда җир өстенә җинелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең, барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт калып, тәмам мәкиббән китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья ничектер искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...

Белмим, бу вакытта бүтән кошлар сайрый торгандырмы — игътибар иткәнем юк, әмма бер кошның тавышы, бөтен җир өсте тургайлар сайравыннан өзлексез чыңлап торса да, безне сискәндереп, колагыбызга килеп керә. Бу — кәккүк! Кешеләрнең исләренә ниндидер бик мөһим нәрсәне төшерер өчен табигать тарафыннан яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Юлдан шактый читтә торган күксел урман яныннан узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кәефләнеп, күңелле генә кайта торгач, без, ниһаять, кызыл ярлы тауларга каршы тигез үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына да якынлаштык. Юлга чыккач та Бәдретдин безне, Ишледә туктап, чәй эчеп чыгарга чакырган иде. Без, билгеле, кыстатып тормадык, шәрикташенә кереп, чәй эчеп, күңел ачып чыгу шәкертләр өчен табигый бер низам инде ул.

Авылга җиткәндә генә Бәдретдин, дилбегәне үзенә алып, атны олы юлдан уңга каерды да бәбкә үләне түшәлгән җир өстеннән генә иң арткы урамга таба алып китте. Һәм озак та үтмичә, шул урамның иң читендәге, бүтән йортлардан аерылыбрак, ялгызы гына торган бер өйнең каршысына безне китереп тә туктатты.

Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек, әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. Хәер, моның хуҗалык дип атар җире дә юк иде. Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән. Салам түбәсе череп, каралып, тирескә әйләнә башлаган. Әйтерсең, шуның авырлыгыннан өйнең кайбер бүрәнәләре бүселеп чыккан, ишек-тәрәзәләре кыйшайган, ә тәрәзә пыялалары тора-тора инде яшькелт-зәңгәр төскә кергән... Капка юк, койма юк, тик урам яклап та кыр яклап кына ике рәт киртә сузылган... Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк.

Без инде хәйран булып, гаҗәпләнеп калуыбызны Бәдретдиннең үзенә ничек тә сиздермәскә тырыштык. Арба эзе төшмәгән ачык ишегалдына узып, түбәсе чыбык-чабыклар белән ябылган иске генә бер читән абзар алдында атыбызны туктаттык. Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты. Аның өстендә киндер күлмәк, тез башларына зур ямаулар салынган киҗеле ыштан, башында мескен бүрек, аякларында тула оек белән тузган чабаталар иде. Ул, тарантас янына килеп, бары: «Улым!» — дип кенә Бәдретдин белән күреште, ан-

нары безгә дә шулай сүзсез генә ике кулын сузды һәм, шунда ук ат башына барып, аны тугара да башлады...

Бәдретдин сандыгын күтәреп өйгә ашыкты. Өй ишегендә бер хатын күренде, ләкин ул ни өчендер тиз генә кире борылды. Бу — Бәдретдиннең әнисе булгандыр инде, тик менә аның ишектән чыгар-чыкмас кире чигенүе безне бераз гаҗәпләндерде.

Атны тугарып бетерүгә, Бәдретдин өйдән чиләк белән су, чүмеч һәм тастымал күтәреп чыкты. Чирәм өстендә генә чиләктән бер-беребезгә су коеп юынып алдык. Күңелгә: «Комганнары да юк, күрәсең»,— дигән уй килде. Һәм без бернәрсә күрмәгән, белмәгән булып кыланырга яки ваемсыз гына сөйләнергә ничектер сүз дә, сәләт тә таба алмый идек. Ләкин Бәдретдин үзе тыныч иде, һәрхәлдә, оялу-уңайсызлану кебек бернәрсә дә сиздерми иде.

Юынып беткәч, сәлам биреп, өйгә кердек. Бәдретдиннең әтисе бер читтәрәк торган килеш безне бик гади генә: «Әйдәгез, шәкертләр!» — дип каршы алды.

Караңгырак кына өй эче дә тышкы ягы кебек үк искереп, тузып беткән икән инде. Ләкин күпме генә искереп-тузып бетмәсен, аның бүрәнәләре тома балавыздай сары-көрән иде әле, тапталып, кырылып ашалган идәне дә чип-чиста иде... Өйнең бөтен түрен иңләп, өстенә киез җәелгән зур сәке тора, ике урындык, бер эскәмия, мич буенда тагын бер бүкән тора — менә җиһаз дигәне бары шул гына. Мич алды иске генә чүпрәк чаршау белән бүленгән, анда кемнеңдер озын гына итеп чыра телүе ишетелә.

Өйгә кергәч тә безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә генә утырган бер бабай булды. Бабай Хозыр-Ильяс төсле ап-ак сакаллы, ап-ак күлмәк-ыштаннан иде. Бары тик башындагы беленгә әйләнгән түбәтәе генә аның күксел-кара иде.

Без бабайга күрешер өчен кулларыбызны суздык. Бабай селкенмәде. Бәдретдин ашыгып әйтеп куйды:

— Бабакай, шәкертләр синең белән күрешергә телиләр.

— Ә, шулаймыни, бәрәкалла! — диде бабай, аз гына җанланып, һәм безгә кипкән, зур каты кулларын сузды. Күзләре ачык булса да, ул дөм-сукыр иде.

Без утырышып дога кылдык һәм, шәкертләрчә кулларыбызны тез өстенә куеп, бер мәлгә тынып калдык. Безнең үзебезгә сүз башлавы, билгеле, кыенрак иде, аннары нидер менә телебезне һаман бәйләп тора иде. Ләкин, гаҗәп хәл, хуҗалар үзләре дә сүзсезләр иде. Гомумән, бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк — ничектер бик тиз без шуны сизгәндәй булдык. Бабай, үзенең эчке дөньясына киткәндәй, текә каткан килеш тып-тын утыра. Бәдретдин әрле-бирле йөренә, нидер әйтмәкче дә шикелле, ләкин сүз таба алмый кебек... Әтисе башта мич буендагы бүкәндә безгә бераз шаккатып утырды да аннары, торып, сәке кырыена чәй урыны әзерли башлады. Иске генә кижеле ашъяулык китереп җәйде, мич кашагасыннан кайсы замазка белән ябыштырылган, кайсының сабы кителеп төшкән өч кенә чынаяк алып куйды, кыска гына чалгы пычагы, чүпрәккә төргән ярты ипи, тустаган белән сөт китереп куйды. Шуннан соң тагын бүкәненә барып утырды. Бәдретдин, үзенең сандыгыннан бер-ике уч шикәр алып, шуны ашъяулык уртасына салды.

Бераздан чаршау эченнән әкрен генә: «Булды, улым!» — дигән сүз ишетелде. Бәдретдин, кереп, самоварны алып чыкты. Бу самоварның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.

Бәдретдин безгә сәкегә менеп утырырга кушты. Без, менеп, аякларны бөкләп утырдык. Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде. Без әле ашка сузылмыйча хуҗаларның утырганын көтә идек. Ләкин бабай да урыныннан кузгалмады, абзый кеше дә бүкәненнән тормады. Шул чагында Бәдретдин, йомшак кына, чаршау эченә дәште:

— Әнкәй, чәй ясарга үзең чык инде.

— Әткән соң?—диде чаршау эченнән әнисе акрын гына.

— Әткәйме?.. Юк, син үзең яса инде безгә,—диде Бәдретдин, ничектер бик ихластан үтенгәндәй итеп.

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук киндер алъяпкыч буган, оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самовар артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора кебек иде. Әйтерсең, бу һич йомылмас яшьле-моңсу күз—аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән?.. Без бит гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да, бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самовар артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин безне кыстап:

— Йәгез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына!—диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне капладык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үз алдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

— Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле,—диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде.

Без, бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык. Монда яңа әдәбияттан ике-өч роман, дүрт-биш шигырьләр мәҗмугасы, иске әдәбияттан шактый тузган «Бүз егет», «Тутыйнамә», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Каһарман катыйль» кебек китаплар һәм гарәп, фарсы телендә берничә дәреслек бар иде. Без күбрәк вакыт үтсен өченгә бу китапларның кайсы укылган, кайсысы укылмаган, кызыкмы-түгелме—шул турыда сөйләшкәләп, карап чыктык.

— Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар,—диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

— Кайдан бу синдә?

— Үзем мәтәштергән булдым инде,—диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тонык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чирткәләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

— Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең?—дидек без.—Мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

— Оста барда кулың тый!—диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шул чакта мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы — гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге сихри карашта, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хас ниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, аның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Бәдретдин, маташа торгач, ахырда скрипкәсен көйләде, иңбашына терәде, җәя сыман смычогы белән сызгаларга тотынды. Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез-нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып, тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң — мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабайны уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кешене кичерә — моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

— Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагын да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

— Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит! — диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә» көен уйный башлады.

Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләремне дә чәлпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкәсен уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән житди-җылы карашында, әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырга рөхсәт сорадык. Абзый кеше ямаулы тез башларын ышкып куйды, ә Бәдретдин, бабасына үрелеп:

— Бабакай, шәкертләр бездән фатиха бирүебезне сорыйлар,— диде.

Бабай башын какты, һәм без кулларны күтәрдек.

...Күк алашаны җигеп, капкасыз-коймасыз, кыр үләне басып киткән «ишегалдыннан» урам уртасындагы тигез юлга чыктык. Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез ниндидер тирән сере — бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өмете-бәхетеме — торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп, тагын да сузыбрак, ярсыбрак берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа!.. Берни эшли алмыйм үзем белән: самовар артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

*1964*

**ИСКӘРМӘ**

Әмирхан Еники әсәрләрендә сафлык, игелек, мәрхәмәт мәсьәләләре нәүбәткә тезелми, болар үзәктә тора. Бу сыйфат-хәл әдипнең башлангыч чор иҗаты өчен дә, бүгенге әсәрләре өчен дә хас. Тормышны ямьсезләндерүче күренешләрне, кеше күңелен гарипләндерүче нәрсәкәйләрне тасвирлавы да әнә шул бер мәсләкне тотудан — тормышыбызны-яшәешебезне бизәүдә язучының җиң сызганып, бирелеп эшләвеннән килә.


Әйе, яктылык бөркүче әсәрләре күп Әмирхан абыйның. Шулай да «Матурлык» хикәясе эчкерсезлеге, самимилеге, миһербанлыгы белән алдыра төшә.

Әмирхан Еникинең бу хикәясе 1964 елда язылa. Шул ук елда «Азат Хатын» («Сөембикә») журналының дүртенче санында, башкортча «Агыйдел» журналының да дүртенче санында басыла. Русча беренче басмасы Азалия Бадюгина тәрҗемәсендә — Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Рассказы 1964 года» исемле китапта (1965 ел). Шуннан соң «Матурлык» хикәясе, үзгәртелмичә, Казанда һәм Мәскәүдә татарча һәм русча күп тапкырлар басыла, телевидениедән һәм радиодан еш тапшырыла.

Хикәя, шулай ук үзгәрешсез, язучының ике томлык «Сайланма әсәрләр»енә һәм өч томлык «Әсәрләр»енә кертелә. Ике вакытта чыккан китаплардагы бу хикәяне Әмирхан абый белән бергәләп караштырып чыктык. Кайбер тыныш билгеләре генә үзгәртелде.

Татарстанның халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге бүләк иясе, хикәя остасы Әмирхан Еникинең (1909 ел) «Матурлык» исемле әсәре язучының ике томлыгының икенче томыннан (1971 ел) алынды.

Бүлекне **Мәгъсүм ХУҖИН**
алып бара.



КАЗАН УТЛАРЫ

# ЖУРНАЛНЫ КЕМНӘР ҖИТӘКЛӘГӘН?

Мәгълүм булганча, «Казан утлары» журналының элгәрләре «Безнең юл», «Атака», «Совет әдәбияты» исемнәре белән чыгып килгән. «Безнең юл» журналының беренче саны 1922 елның май аенда дөнья күргән. Беренче мөхәррире Гасыйм Мансуров булган һәм журнал шул исем белән 1930 елның июль аена кадәр яшәгән.

1928 елда «мөхәррир» сүзе «редактор» сүзенә алыштырылган һәм, ни өчендер, «Редакторы — коллегия» дип бирелеп барган. «Редакционный коллегия рәисе — **Галимҗан Ибраһимов**» дип күрсәтелгән. Димәк, Галимҗан Ибраһимов гамәлдә мөхәррирлек вазифасын башкарган, дип уйларга нигез бар.

Алга таба 1926 елның унынчы санынннан мөхәррирсез-нисез генә «Редколлегия» дип бирелә, ә 1927 елда шулай ук исем-фамилияләрсез «Редактор» һәм



*Әдипләр Г. Ибраһимов, М. Гафури.*

«Редколлегия» дип куела килә. 1928 елдан исә «Редактор» һәм «Редколлегия» сүзләре янына Гомәр Гали, Шәриф Камал, Г. Толымбайский, Галимҗан Сәгъди исем-фамилияләре теркәлгән.

1929 ел өчен Татарстан китап палатасында журналга кагылышлы белешмәләр табылмады.

1930 елда янә «Редактор — редколлегия» дигән сүзләрне генә укыйбыз.

Сигез ел дәвамында чыгып килгән «Безнең юл» журналы 1930 елның июль аеннан исемен алыштыра һәм ул «Атака» исеме белән яңарып китә. «Атака»

журналының беренче мөхәррире **Гомәр Гали** була. Шул ук 1930 елның 8—9 нчы саннарында без «Редколлегия: Кави Нәҗми, Г. Толымбайский, Ибрай Гази, С. Каратай» дигән сүзләрне укыйбыз. Мөхәррире аерып күрсәтелмәгән. Бу хәл 1931 елның 5—6 нчы санына кадәр күзәтелә. Аннары ел азагына чаклы җаваплы мөхәррир **Кави Нәҗми** була.

1932 елда «Атака» журналының һәр уникс санында җаваплы мөхәррир булып **Закир Гали** тора. Редколлегия составында Закир Гали, Кави Нәҗми, Ибрай Гази, Мөхәммәт Садрилар була.

«Атака»ның гомере кыска булып чыга — ул нибары ике ел ярым гына яшәп кала. 1933 елдан башлап журнал «Совет әдәбияты» исеме белән йөртелә башлый. Ике ел дәвамында җаваплы мөхәррире — Кави Нәҗми. Аннан соңгы ике ел — 1935—1936 елларда журналга янә Гомәр Гали җаваплы мөхәррирлек итә.

Ниһаять, 1937 ел... Ил-халык өчен дә, журнал өчен дә иң авыр, иң кара чор башлана: Сталин һәм иярченнәре котырынганнан котырына, алар корбан арты корбан сорыйлар.

«Совет әдәбияты» журналының 1937 елгы икенче саны мөхәррирсез — «Редколлегия» тарафыннан гына чыгарыла. Аннары өченче санда — вакытлы җаваплы редактор **Г. Разин** (Гомәр Бәширов), дүртенче-бишенче саннарда — җаваплы редактор **Газиз Иделле**, алтынчы-унберенче саннарда — вакытлы җаваплы редактор янә Г. Разин, уникенче санда вакытлы җаваплы редактор **Рәхман Ильяс** була.

Шушы бер ел эчендәге «вакытлылар» аша да журналның нинди тетрәнүләр кичергәнен аңларга мөмкин.

«Совет әдәбияты»ның 1938 елгы беренче дүрт саны янә вакытлы җаваплы редактор Г. Разин җитәкчелегендә чыга. Шул елның бишенче саныннан башлап журналга җаваплы редактор итеп **Т. Имаметдинов** билгеләнә.

Т. Имаметдинов журналда 1938 елның бишенче саныннан алып 1941 елның җиденче санына кадәр җаваплы мөхәррир булып тора.

Бөек Ватан сугышы елларында күп кенә газета-журналлар ябылып бетсә дә, «Совет әдәбияты» журналы сакланып кала. 1941 елның июленнән 1942 елның августына кадәр аңа, алышына-алышына, өч язучы мөхәррирлек итә: Г. Разин, Г. Кашшаф, И. Гази.

1942 елның августыннан 1945 елның гыйнварына кадәр журналны **Гази Кашшаф** җитәкли. Ә инде 1945 елны, Бөек Җиңү көне килгәч, «Совет әдәбияты»ның алтынчы саныннан башлап җаваплы мөхәррирлек эше Газиз Иделлегә тапшырыла. Газиз Иделле бу вазифаны 1947 елның ноябренә кадәр башкара. Ә 1947 елның унберенче саныннан алып 1949 елның бишенче санына кадәр журналның җаваплы мөхәррире янә Кави Нәҗми була.

1949—1950 елларда — май аеннан май аена хәтле — вакытлы җаваплы мөхәррирлекне **Афзал Шамов** башкара.

Аннары журналга яңадан Гази Кашшаф килә. Һәм ул 1950 елның май саныннан башлап 1958 ел тәгәлләнгәнче — сигез ел ярымнан артык җаваплы мөхәррир булып эшли. Гази Кашшаф озак эшләгән мөхәррирләрнең берсе.

Шуннан соңгы дүрт ел дәвамында (1958—1963) җаваплы мөхәррир Абдулла Гомәр була. Аннары ел ярым — 1964—1965 елның алтынчы санына кадәр җаваплы мөхәррирлекне **Газиз Мөхәммәтшин** алып бара. Газиз Мөхәммәтшинның мөхәррирлеге «Совет әдәбияты» журналының соңгы чорына туры килә.

1965 елның июнь саныннан журнал яңа исем ала — ул «Казан утлары» исеме белән чыга башлый һәм бүгенге көнгә кадәр шул исемне саклап килә.

«Казан утлары»ның 1965 елгы алтынчы санына җаваплы мөхәррир буларак **Сибгат Хәким** кул куя, җиденче санына исә, «җаваплы редактор өчен» дип, журналның ул вакыттагы җаваплы сәркатибе Әхсән Баян имза сала.

1965 елның август саныннан журналның җаваплы мөхәррире итеп **Рафаэль Мостафин** раслана. Ул мөхәррирлек вазифасын 1969 елга кадәр алып бара.

1969—1971 елларда мөхәррир «Баш редактор» дип йөртелә башлый. Һәм бу вазифаны **Зәки Нури** үтәп килә.

1972—1974 елларда журналыбызның баш мөхәррире — **Гариф Ахунов.**

1975—1983 еллар — баш мөхәррир янә **Зәки Нури**.

1983—1989 еллар — баш мөхәррир **Ренат Харис**.

1989 елдан алып бүгенге көнгә кадәр «Казан утлары» журналы **Равил Фәйзуллин** баш мөхәррирлегендә дөнья күреп килә.

Бу мәгълүматларны редакциягә Татарстан
Республикасы китап палатасының архив бүлеге
мөдире **Раушания САФИНА** тапшырды.

# РЕДКОЛЛЕГИЯ ӘГЪЗАЛАРЫ

*(1997 елның май аена карата)*



**Гариф Ахунов** — Татарстан халык язучысы.



**Нәҗип Бакиров** — Татарстан Министрлар Кабинеты аппараты җитәкчесе.



**Хәлим Гайнуллин** — Татарстан матбугат һәм информация министры урынбасары.



**Тәлгат Галиуллин** — КДУның татар филологиясе һәм көнчыгыш телләр факультеты деканы.



**Миркасыйм Госманов** — КДУның татар халкы тарихы кафедрасы мөдире.



**Аяз Гыйләҗев** — Татарстан халык язучысы.



**Флүс Латыйфи** — «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары.



**Салих Маннапов** — «Мәгариф» нәшрияты директоры.



**Туфан Миннуллин** — Халыкара ПЕН клубының татар үзәге президенты.



**Хатип Миңнегулов** — КДУ профессоры.



**Ринат Мөхәммәдиев** — Татарстан Язучылар берлеге рәисе.



**Рашат Низамиев** — «Казан утлары» журналының проза бүлеге мөхәррире.



**Наҗар Нәҗми** — Башкортстан халык шагыйре.



**Булат Солтанбәков** — Укытучыларның белемен күтәрү институты кафедрасы мөдире.



**Равил Фәйзуллин** — «Казан утлары» журналының баш мөхәррире.



**Ренат Харис** — Татарстан Дәүләт Советы рәисе урынбасары.




**Розалина Шаһиева** — «Казан» милли-мәдәни үзәгенең директор урынбасары.



**Харрас Әюпов** — Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире.

## Равил Гайнетдин

# БАРДЫР, БЕРДЕР...



*Мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин.*

**Узган ел без журналыбызда («Казан утлары», № 6, 1996) язучы Әхәт Мушинскийның Татарстан телевидениесе аша урыс телендә алып бара торган «У зеленого камина» («Яшел камин янында») дигән телевизион тапшыруларының берсен — Россия Дәүләт гуманитар университеты профессоры, күренекле тарихчы Әгъдәс Борһанов белән әңгәмәсен иркле язма рәвешендә бастырып чыгарган идек. «Кая бара бу Россия?» дип аталган ул язма укучыларда зур кызыксыну тудырды.**

**Без алга таба да Әхәт Мушинскийның сәяси эшлеклеләр, иҗат әһелләре, галимнәр, эшмәкәрләр, дин әһелләре һ. б. белән үткәргән әңгәмәләренең кайберләрен журналыбызда бирен баруны кирәк таптык.**

**«Казан утлары»ның бу санында укучыларга Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Мәскәү җәмигъ мәчете имам-хатыйбы мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин белән әңгәмәне иркле язмада тәкъдим итәбез.**

* * *

**Әхәт Мушинский.** Кеше инанусыз, имансыз яши алмый. Мәҗүсилек чорында адәмнәр сыннарга табынганнар, ут, су, җир, күк аллалары барлыгына ышанганнар; дин тыелган-кысылган чорда совет халкы Маркс-Энгельс-Ленин-Сталин тәгълиматына ышанып, коммунизм килерен көтеп яшәде, юлбашчыларны алла урынына күрде. Ә асылда күпчелек халыклар, диннәре төрле булуга карамастан, бер илаһи затка — бердәнбер Аллага инаналар, аңа иман китерәләр. Көндәлек тормышта исә без дуслыкка, мәхәббәткә ышанабыз, кешеләргә ышанабыз — алардан яхшы гамәлләр генә көтәбез. Бу дөньяда якты киләчәккә, бәхетле тормышка өмет итәбез, Аллаһы Тәгаләгә иман китерүчеләребез исә теге дөньяда — ахирәттә үзенең җәннәттә булырына инанып яши. Кыскасы, һәркемнең — үз иманы, үз инануы. Һәркемнең инануы ихтирам-хөрмәткә лаек, яшәргә хокуклы.

Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие Равил хәзрәт Гайнетдин белән очрашуга барганда мин әнә шундый уйлар кичердем. Без хәзрәт белән Мәскәүнең җәмигъ мәчете бинасында очраштык (ул анда имам-хатыйб), әңгәмә корып, фикер алышып утырдык.

**Әхәт Мушинский.** *Равил хәзрәт, әңгәмәбез башында мин шуны белергә теләр идем: Сезнең карашка нәрсә ул — иман?*

**Равил хәзрәт Гайнетдин.** Бисмиллаһир-рахманир-рахим, әлхәмдел-лилләһи-раббел-галәмин, галәме нигъмәте Ислам, галәме нигъмәте Коръән.

Әссәламәгаләйкүм, Татарстан Җөмһүриятендә яшәүче ватандашларым! Сезгә Аллаһы Тәгалә вә Тәбарәкәнең мәрхәмәте иңсен, гаиләләрегезгә иминлек, саулык-сәламәтлек, бәхетле-рәхәт тормыш телим, кадерле дин кардәшләрем! Бүген Сезгә изге дога сүзләре белән мөрәҗәгать итәргә мөмкинлек биргән Аллаһы Тәгаләдән гөнаһларымны ярлыкауны сорыйм, Хак Тәгалә Раббыбызга рәхмәтләремне юллыйм.

Әхәт әфәнде, инде соравыгызга җавап биреп карыйм. Беләсезме, «Нәрсә ул иман?» — дигән сорауга җавап эзләп, күп кенә дин галимнәре калын-калын фәнни-дини хезмәтләр язганнар, әмма тулы-төгәл җавапны бирәү дә табып бетерә алмагандыр. Чөнки «иман» сүзенең мәгънәсен һәркем үзенчәрәк аңлыйдыр. Мин үзем, дин әһеле буларак, аны ислам дине фәлсәфәсе, ислам дине карашлары яктылыгында аңлыйм. Иман — гарәп сүзе. Ул ышану, инану дигәнне аңлата. Ул шулай ук Аллаһы Тәгаләгә инануны белдерә торган дога сүзләре дә, ягъни мөселман кешесенең Аллаһы Тәгаләгә иман китерүен үз теле белән әйтеп бирүе. Төрле идеологик тәгълиматларга, мәсәлән, коммунизмга да инанырга мөмкин; мөмкин матурлыкка, яхшылыкка, изгелеккә инанырга-табынырга; һәм, әлбәттә, бу дөньяны булдыручы, бар итүче, яратучы бөек илаһи затка — Аллаһы Тәгаләгә инану, аңа иман китерү — иң көчле инанудыр. Нәкъ менә шул чын мәгънәсендә И м а н буладыр да инде. Шуңа күрә дә, мөселман кешесе үзенең иман китерүен телдән генә әйтеп калмаска, ә бәлки аны йөрәге белән, чын күңелдән, бөтен кальбе белән тоярга тиештер. Без мөселманнар иманны шулай аңлыйбыз. Кешеләр меңнәрчә еллар буена Атабыз Адәм галәйһиссәлам белән Анабыз Һаваны яратучы, бар итүче, алар аша бөтен кешелекне булдыручы, иксез-чиксез галәм белән, галактикалар белән идарә итүче илаһи зат барлыгына инанып яшәгәннәр. Кеше үз кальбендәге иманны эзләгән, һәркемнең күңелендә изгелек белән яманлык барлыгына ышанган. Без һәрвакыт шул ике төшенчә арасында — игелекле гамәлләр белән яман гамәлләр арасында. Иманлы булу — динаятьле, диндар булу ул. Миңа калса, хәзерге чорда кешеләргә диндарлык бик тә кирәк. Аллаһы Тәгалә бардыр, бердер...

**Ә. М.** *Кайсыдыр бер акыл иясе — философ әле узган гасырда ук, кешелек дөньясы инде үсеп җиткән, балигъ булган һәм ул илаһи затның күзәтеп-кайгыртып торуына мохтаҗ түгел, дигәнрәк фикер әйтеп калдырган. Равил хәзрәт, Сез бу хакта ничек уйлыйсыз?*

**Р. Г.** Мондый фикер белән мин һич килешә алмыйм. Кешелек һәрвакыт кайгыртып торуга мохтаҗ. Без хәзер еш кына Аллаһы Тәгалә бар иткән Җиребезне, аның табигатен якларга-сакларга кирәклеген искәртеп торабыз. Шул ук вакытта кешенең җаны, аның рухи дөньясы турында онытабыз. Кеше җаны, кеше рухы бик нәзберек, бик тиз яралanучан, яклауга-кайгыртуга башка бар нәрсәләрдән дә мохтаҗрак түгелмени? Әйе, табигать экологиясе, Җир шары экологиясе безне бик борчый, әмма кешеләр рухи гарип булса, вөҗдансыз-намуссыз булса, алар Җир шарындагы Табигать-ананың борчулы экологик мәсьәләләре хакында уйлап та бирмәячәкләр бит. Шуңа күрә дә, иң беренче чиратта, кешеләрнең рухи сәламәтлеге турында кайгырту лазем. Без кайгыртучанлыкны илаһи гали затның безне тормышта кулдан җитәкләп йөртүе дип кабул итмибез. Юк, без аны бар галәмне, Җирдәге бөтен тереклекне, сулаган һавабызны, эчкән суыбызны, тукланган ризыгыбызны, үзебез файдалана торган җир асты байлыкларын — кыскасы, һәр нәрсәне бар иткән, аларны кешеләрнең игелекле рәхәт тормышы өчен булдырган Аллаһы Тәгаләнең кайгыртуы дип аңлыйбыз, аңа рәхмәтлебез. Әгәр дә дөньяны бар иткән, һәммәсен күреп-белеп торучы, күзгә-кышкы йокысыннан соң Җир-анабызны уятучы, аңа җан өрүче илаһи зат булмаса, тәүге язгы кояш нурларыннан, тәүге яңгырлардан соң Җир-анабыз уяныр идеме? Кешеләр күңе-

лендә иман да шулай яңара, иман да уяна. Шуның өчен безгә илаһи яклаучы кирәк, Аллаһы Тәгаләнең ярлыкавы кирәк.

**Ә. М.** *Равил хәзрәт, әйтегез әле, ислам дине белән башка диннәр, аерым алганда христиан дине арасында нинди уртаклыклар бар һәм нинди җитди аерымлыклар бар?*

**Р. Г.** Без бүген, мөгаен, күбрәк төрле диннәрне берләштерә торган уртаклыкларны эзләргә тиешбездер. Бу очракта ислам диненең барлыкка килү тарихына бер караш ташлап үтү мәслихәттер. Ислам — Аллаһы Тәгалә тарафыннан үзенең илчеләре — пәйгамбәрләре аша Җиргә иңдерелгән игелек-изгелек дисбесенең дәвамы ул. Христиан һәм яһүд диннәре олылаган пәйгамбәрләр ислам дине өчен дә иң олуг, хөрмәтле пәйгамбәрләр: Муса (Моисей), Гайса (Иисус), Ибраһим (Авраам) һ. б. Христианнар һәм яһүдләр инана-табына торган изге китаплар — Зәбүр, Тәүрат, Инҗил — мөселманнар өчен дә изге, Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән саналалар. Әмма шул ук вакытта без ул китапларның соңыннан бозылган булуын да беләбез, аларны шулай кабул итәбез. Диннәребез арасында үзенә күрә бер аерымлык та шуннан торадыр. Ә менә христианнар һәм яһүдләр безнең Коръән Кәримебезне танымыйлар, аны изгегә санамыйлар, ислам динен инкяр итәләр. Без исә аларның диннәрен юкка чыгармыйбыз, изге язмаларын кире какмыйбыз. Монысы — тагын бер аерымлык. Аннары, без Аллаһы Тәгаләне, христианнар һәм яһүдләр шикелле, өчкә бүлеп — ата алла, угыл алла, изге рух алла дип тә кабул итә алмыйбыз. Без: «Сезнең Бог белән безнең Аллаһыбыз — бердер»,— дибез. Һәм без шуңа инанабыз: Аллаһы Тәгалә бардыр, бердер. Изге Коръән Кәримдә шулай әйтелгән. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына инану, пәйгамбәрләребезнең уртаклыгы, барыбыз өчен дә уртак Ватаныбызда яшәү, Хак Тәгалә Раббыбызның барыбызны да кардәшләр итеп яратуы — безне якынайткан-берләштергән дәлилләр шулар. Изге Коръән Кәримдә: без сезне бер-берегезне танысын-белсен өчен ирләр вә хатын-кызлар итеп яраттык, кавемнәр вә халыклар иттек, дип әйтелә. Димәк ки, без барыбыз да бер Аллаһы Тәгалә тарафыннан яратылганбыз. Шунлыктан, без бүген төрле диннәр арасындагы каршылыкларны, аерымлыкларны эзләп баш ватмаска тиешбез. Җир шары — кешелекнең уртак Ватаны. Без изгелек-игелек хакына яшәргә тиешбез, Аллаһы Тәгалә безне шуңа өнди. Христиан дине дә шуны хуплый: яхшылык кылырга, яман гамәлләр кылмаска чакыра. Хак Тәгалә Коръән Кәрим аятьләре аша безгә: игелекле эш-гамәлләрдә, диндарлыкта бер-берегезгә ярдәмчел булыгыз, әмма яманлык вә дошманлыкка юл куймагыз, дип өйрәтә. Миңа калса, бүген безне — христианнарны, яһүдләрне, мөселманнарны гына түгел,— ә барлык диндәгеләрне дә нәкъ менә шул инану берләштерергә тиеш.

**Ә. М.** *Кешелек дөньясындагы барлык диннәрнең дә топ асылы кеше кальбенә, кеше рухына юнәлтелгән булудамы? Фәнни тел беләнрәк әйтсәк, кеше рухының экологиясе...*

**Р. Г.** Һичшиксез, шулай. Кеше рухынын экологиясе, дип Сез бик матур әйттегез. Әйе, безгә кешенең рухын саклап калырга тырышырга кирәк. Шуның өчен дә, мәсәлән, 1995 ел һәрбер дингә түземле караш, теләсә нинди дин тоту ирегең тану елы, дип игълан ителгән иде. Әмма, ни кызганыч, кешеләрнең иманнары какшаган, түземлекләре тәкәнгән хәзер, төрле төбәкләрдә кан коела... Юкса, барлык диннәр дә түзем-сабыр булырга өнди, дин тоту ирегең танырга чакыра. Бу нисбәттән, ислам дине, бәлки, иң сыгылмалы, иң түзем диндер. Аллаһы Тәгалә мөселманнарга башка диндәгеләрне дә ихтирам итәргә, түзем-сабыр булырга боера. Коръән Кәрим аятьләрендә, берәүне дә ирексезләп-көчләп иман китерергә өндәмәскә кирәк, диелә. Кешегә камил акыл бирелгән икән, димәк, аңа иманга килергә дә ирек куелган, күңеле-кальбе нинди дингә тартылганын ул үзе эзләп табарга тиеш. Кеше Аллаһы Тәгаләгә бар барлыгы белән инанганда гына аның иманы хак, аның иманы кадерле була. Шуны әйтәсем килә: халкыбызны көчләп чукындыруларга карамастан, тоталитар режим һәм сугышчан атеизм, ягъни алласызлык-динсезлек елларындагы кысу-җәберләүләр, мохтаҗлык-мәхрүмлекләргә карамастан, борынгы Болгар дәүләте чорында ата-бабаларыбыз моннан мең еллар элек кабул иткән ислам дине — безнең Хак динебез чиста-саф хәлендә сакланып калды. Чөнки халкыбызның күңелендә-кальбендә иман яшәде, шул иман безгә рухи көч биреп торды. Әйе, иман — ул көч. Иманлы кеше иң авыр шартларда да түзем булыр, ахырдан Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте илән барыбер авырлыкларны җиңеп чыгар, җанына тынычлык табар.

Ислам дине барлык кыйтгаларга да таралган икән, ул бары тик тыныч юл белән генә таралган. Ислам дине тарихында тәре походларына охшашлы яусугышлар булмаган. Бер Аллаһы Тәгаләне танучы өч монотеистик дин: яһүд дине, христиан дине һәм ислам дине өчен дә изге шәһәр Иерусалим — Әл Мөкаддәс бар. Мөселманнар өчен ул, Мәккә-Мәдинәләрдән кала, өченче изге шәһәр. Менә шул шәһәр, кяферләрдән азат ителеп, мөселман шәһәренә әверелә. Шәһәргә изге хәлиф Гомәр керә. Аның янына христиан дине рухание — патриарх килә һәм: «Бу изге шәһәрнең яклаучысы-сакчысы хәзер Сез булачаксыз, шәһәр Сезнең кулга күчте. Рәхим итеп, безнең гыйбадәтханәбезне алыгыз, аны мөселман мәчете итегез, догаларыгызны-намазларыгызны шунда укыгыз»,— ди. Изге хәлиф Гомәр әйтә: «Юк,— ди,— безнең динебез башка диннәргә дә ихтирам белән карый. Барыбыз өчен дә бердәнбер Аллаһы Тәгаләгә инаныгыз, гыйбадәтләрегезне үз чиркәвегездә башкарыгыз, ә без исә янәшәдә үзебезгә изге мәчет төзербез»,— ди. Шулай итеп, мәчет төзелә. Иерусалимга баргач, үзем дә күрдем: анда килүче гарәпләрнең христиан булганнары (андыйлар да бар) чиркәүгә кереп гыйбадәт кылалар, мөселман гарәпләр мәчеткә киләләр. Менә бу күренеш тә безнең диннәребез арасында шактый уртаклыклар булуына бер дәлилдер. Әйтеп киткәнемчә, ислам дине башка диннәргә дә түзем-сабыр карый, аларны ихтирам итә һәм, шуңа күрә дә, бездә дин тотарга ирексезләү-көчләү юк, кеше ирекле, ул үзе эзләгән хак динне үзе табарга тиеш.

**Ә. М.** *Мөфти хәзрәт, ә Сез үзегез диңгә ничек килдегез?*

**Р. Г.** Авылда туып үскән кешеләр дингә якынрак була, минемчә. Мин, эшләмәсә дә, манарасы киселмичә сакланып калган мәчетле татар авылында дөньяга килгәнмен. Манара башында ялтырап торган ярым ае да бар иде...

**Ә. М.** *Кайсы авыл ул?*

**Р. Г.** Шәле авылы. Татарстан Җөмһүриятенең Питрәч районында. Бала чагымда мин әбием тәрбиясендә үстем, бик диндар, изге карчык иде, мәрхүм. Аңардан кыска-кыска догалар өйрәндем, йокларга ятканда һәр кичне шул догаларны кабатлый идем, әбием тыңлап-тикшереп тора иде. Бәлки, Аллаһы Тәгаләгә инануым, иманым шул вакытларда уяна башлагандыр. Казанда дөньяви уку йортларында укыганда мин динебездән бераз читләшеп тордым, әмма кальбемдә һәрвакыт иман бар иде. Аннары тәкъдирем мине беренче мөгаллимем, остазым, Казан җәмигъ мәчетенең ул вакыттагы имам-хатыйбы мөфти Тәлгать Таҗетдин белән очраштырды. Шулай итеп, мин Казан җәмигъ мәчетенә йөри башладым, ислам дине нигезләрен өйрәнергә тотындым, Коръән Кәримне укып, аны шәрехләргә тырыштым, гарәп телен, аның грамматикасын өйрәндем. Тәлгать хәзрәт Таҗетдинда мин ел ярым укыдым, аннары, ул Уфадагы Диния



*Мәскәүдәге Җәмигъ мәчет.*

нәзарәте идарәсе рәисе булып китеп баргач, танылган дин белгече, Казан җәмигъ мәчетенең яңа имам-хатыйбы Әхмәтзәки хәзрәт Сафиуллададан гыйлем алдым. Ул хәзер мәрхүм инде, урыны җәннәттә булсын. Әнә шул ике остазым миңа ныклы дини гыйлем нигезләрен салдылар, киләчәгемә ышанычлы юл күрсәттеләр. Шуннан соң мин дини уку йортына — Бохарадагы Ислам мәдрәсәсенә укырга барып кердем, шәкерт булдым. Анда җиде ел укып кайткач, Казанның иkенче мәчетендә (ул ачылган гына иде әле) беренче имам-хатыйб булдым. Аннары Уфада — СССРның Европа һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәтендә җаваплы сәркатип вазифаларын башкардым, мөфти хәзрәт Тәлгать Таҗетдинның ярдәмчесе урынбасары булдым.

Мәскәү җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы, дин галиме Әхмәтҗан хәзрәт Мостафа вафатыннан соң (урыны җәннәттә булсын), мине аның урынына Мәскәүгә чакырдылар. Менә хәзер, инде унбер ел мин Мәскәүдәге мөселманнар җәмгыятен җитәклим, Мәскәү җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы вазифаларын үтим. 1994 елда Мәскәүдәге Ислам Үзәге җирлегендә Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте оештырылды, мине шунда мөфти итеп сайладылар. Шулай итеп, миңа гаҗәеп зур, җаваплы эшләр йөкләтелде: Россиянең Үзәк Европа өлеше мөселманнары (алар өч миллионга якын) белән Мәскәү мөселманнарын (алары 800 йөз меңгә якын, шуларның яртысыннан артыгы — татарлар) җитәкләүне ышанып тапшырдылар. Изге Коръән Кәримдә әйтелгәнчә, Аллаһы Тәгаләгә иман китергән мөселманнар асылда барысы да туганнар, дин кардәшләр — аларга хезмәт итү — минем изге бурычым.

Дин юлындагы кыскача тәрҗемәи хәлем шундыйдыр. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтлемен!

**Ә. М.** ***Равил хәзрәт, Сезне тыңлаганда, барысы да бик әйбәт, шома гына булган икән, дигәнрәк тәэсир кала. Ә бит, чынлыкта, Сез дин юлына бик катлаулы заманда аяк баскансыз. Диннәрне төрлечә эзәрлекләүләр, кысулар заманында...***

**Р. Г.** Әйе, берсүзсез шулай, берсүзсез. Әле менә хәтерләп утырам: Казан телевидениесендә эшләгән чагым иде, ә ул, үзегез беләсез, идеологик эш — мин исә ислам нигезләрен өйрәнеп йөрим, Коръән Кәримне укыйм. Дини уку йортына — Бохарадагы Ислам мәдрәсәсенә укырга керергә гариза яздым. Бу хәл бик күпләр өчен бер шартлау булды, аяз көнне яшен суккан шикелле тәэсир ясады. Кайбер дусларым да миннән йөз чөерде. Мине СССР Министрлар Советы каршындагы Дини эшләр идарәсенең вәкаләтле вәкиле Михайлов дигән бәндә Мәскәүгә чакыртып алды. Бик газаплы, бик каты сөйләшү-тарткалашу булды. «Син бит дипломлы белгеч, зыялылар белән — язучылар, галимнәр, төрле сәнгать әһелләре белән аралашып, алар белән эшлисең. Кая барырга җыенганыңны аңлыйсыңмы, син кем булырга телисең? Сиңа бит берәү дә иярмәячәк. Имам дәрәҗәсе алсаң да, синең үз мәхәлләң булмаячак. Без бит егерменче гасыр азагында яшибез, егерме беренче гасырга аяк басып киләбез. Диннәр сүнеп-бетеп бара. Кая омтыласың? Ни өчен син андый юл сайларга булдың? Акылыңа кил!» — дип, бик озак үгетләделәр-игъделәр мине. Әмма, Хак Тәгаләгә шөкер, мин нык тордым. Аллаһы Раббыбызга, ислам диненә хезмәт итәргә дигән теләгем-мәсләгем катгый иде. Аллаһы Тәгалә мине рәхмәтеннән ташламады: Ислам мәдрәсәсендә укып чыгып, гыйлемле имам-хатыйб булдым. Инде мин Аллаһы Тәгаләгә чиксез рәхмәтлемен. Хәзер без ул заманнарда миңа «акыл өйрәтергә» теләүчеләр сөйләгәннәрнең киресен күрәбез: диннәр бетми, диннәр яңара-үсә, халык әкренләп иманга килә. Җәмгыятьтәге үзгәрешләр гаять зур. Коръән Кәримдә әйтелгән: әгәр дә сез үзегезне-үзегез үзгәртмәсәгез, җәмгыять тормышын вә үз тормышыгызны үзгәртергә керешмәсәгез, Аллаһы Тәгалә сезнең рухи халәтегезне, сезнең матди хәлегезне үзгәртмәячәк, диелгән. Димәк ки, минем дин юлына аяк басуым, дин әһеле булып китүем дә җинелдән булмады. Аллаһыга шөкер, укып чыкканнан соң инде менә унөч ел чамасы мин мөселманнарга үгет-нәсихәт бирәм, бу игелекле изге эштә иманым нык булгангадыр, мөгаен, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен вә мәрхәмәтен даими тоеп торам.

**Ә. М.** ***Сез бит әле, дин юлына аяк басканчы, Казанда театр училищесы да тәмамлаган кеше. Ул Сезгә эшегездә ярдәм итәме?***

**Р. Г.** Шулай шул, күп кенә мөселман кардәшләрем минем нинди дөньяви уку-йортында укып чыгуым белән кызыксыналар. Әйе, мин театр училищесында татар драма театры актерлыгына укыдым. Мин моның белән горурланам, чөнки

актерлыкка уку миңа бик күп нәрсә бирде. Аннары мин Ленинградтагы (хәзерге Санкт-Петербург) Театр музыкасы һәм кинематография институтының режиссура факультетында укыдым. Анда уку да бик күп нәрсәләргә өйрәтте, зиһенемне-фәһемемне арттырды, аңымны-белемемне үстерде. Хәзер үзем дин әһелләре — руханилар әзерлим. Мәскәүдә без Югары Ислам көллияте ачтык. Ул — Россия Федерациясенең Югары белем Дәүләт комитеты тарафыннан лицензия-рөхсәт алган бердәнбер югары мөселман дини уку йорты. Ул шулай ук Россиянең юстиция министрлыгында да теркәлде. Инде без үзебезнең шәкертләребезне башка мөселман илләрендәге уку йортларына да укырга җибәрәбез. Шулай да мин шәкертләребезнең үзем өйрәнгән сәхнә сөйләме, логика-мантыйк, ораторлык сәнгате — риторика кебек курсларны үтүләрен дә теләр идем. Шул чагында муллаларыбыз, имам-хатыйбларыбызның сөйләгәндә сүз һәм иҗекләрне ачык әйтүләренә — әйбәт дикциягә ирешүләрен, логик дөрес фикер йөртүләрен күрер идек. Яхшы артист залдагы тамашачыларның сулышын тойган шикелле, алар да мәчетләребезгә йөрүче мәхәллә халкының сулышын тоярлар иде. Синең вәгазьләреңне тыңлыйлармы, мөэмин мөселманнар аны аңлап кабул итәме? Син аларның күзләренә карап, сөйләгән вәгазеңнең җилгә очмаганын, мөселманнарның күңеленә сеңә барганын, синең вәгазьләрең аша Аллаһы Тәгаләгә тагын да якынайганнарын күрә аласыңмы? Мин боларның барысына да театр училищесында укыганда өйрәндем. Һәм мин, Мәскәү җәмигъ мәчетенә җыелган кардәшләремә,— ә алар икс меңгә якын җыела! — вәгазь укыймы, йә булмаса башка төбәкләрдәге — әйтик, Ярославль, Тверь, Түбән Новгород һ. б. мәчетләрендәме — мин залны тоям, мәчет рухын тоям, мөселман кардәшләремнең миннән нәрсә ишетергә теләгәннәрен, нәрсә көткәннәрен аңлыйм. Шуның өчен дә мин алган белемнәрем белән горурланам.

Сүз уңаенда әйтеп үтим: католиклар Папасы Павел Иоан Икенче дә үз заманында югары театраль уку йорты тәмамлаган, ул да дипломлы режиссер. Һәм шуңа күрә дә ул үзен диндарлары — тыңлаучылары алдында иркен тота, аларның күңелен-кальбен аңлый. Кызганыч, безнең күп кенә дин әһелләребезгә әнә шул сыйфатлар җитенкерәми.

**Ә. М.** *Равил хәзрәт, хәзер Россиядә берничә Диния нәзарәте барлыкка килде. Шуңа бәйле рәвештә әле бер төбәктә, әле икенче төбәктә үзләрен баш мөфти дип игълан итүчеләр бар. Сез моны ничек аңлатыр идегез?*

**Р. Г.** Беләсезме, СССР дигән бөек дәүләтнең таркалуы безгә дә — җәмгыятьнең дини тормышына да зур йогынты ясады. СССР дәверендә җәмгысы дүрт Диния нәзарәте бар иде: алар — СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте, Урта Азия һәм Казагыстан мөселманнары Диния нәзарәте, төньяк Кавказ мөселманнары Диния нәзарәте һәм Кавказ арты мөселманнары Диния нәзарәте иделәр. Инде элекке союздаш Җөмһүриятләр бәйсез дәүләтләр булып аерылып чыктылар. Россия Федерациясе эчендә дә Татарстан, Башкортстан кебек суверенитет алган җөмһүриятләр барлыкка килде. Бу җөмһүриятләрдә мөселманнарның мөстәкыйль Диния нәзарәтләрен оештыру мәсьәләсе көн тәртибенә килеп басты. Шул рәвешле, 1992 елда Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Башкортстан мөселманнары Диния нәзарәте оешты. Әмма иң кызганычы шул: мөфти Тәлгать Таҗетдин хәлнең катлаулылыгын бөтен тирәнлеге белән аңлап бетерә алмады. 1992 елда Уфада үткәрелгән мөселманнар корылтае алдыннан булган пленум-киңәшмәдә мин Татарстан һәм Башкортстан Диния нәзарәтләрен танырга кирәклеген әйттем. Әмма минем тәкъдимем кабул ителмәде. Нәтиҗәдә корылтай Тәлгать Таҗетдингә ышанычын югалтты, аны баш мөфти итеп танудан баш тартты. Ике арада каршылык, дошманлык көчәйде. Ахыр чиктә СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте таркалды. Аның урынына Россиядә Себер мөселманнары Диния нәзарәте, Башкортстан мөселманнары Диния нәзарәте, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, Түбән Идел мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россиянең Үзәк Европа өлеше вә Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте дигән биш яңа Диния нәзарәтләре оешты. Шуннан соң мөстәкыйль-бәйсез дип саналган бу Диния нәзарәтләре идарәсе рәисләре итеп сайланган кайберәүләр үзләрен үзләре баш мөфти, югары мөфти дип атап йөртә башладылар. Әмма Россия дәүләте тарихында патшалар заманында да, советлар заманында да мөселманнарда берничә баш мөфтиләр һәм шәйхелисламнар булмаган. Гарәпчә «шәйх» сүзенең беренче мәгънәсе — «карт кеше, аксакал» булса, икенче мәгънәсе — «башлык, юлбашчы», өченче мәгънәсе — «дин башлыгы» һәм дүртенче мәгънәсе «ишан»

булыр. Үзләрен «шәйхелислам» дип йөртүчеләр, янәсе, ислам динендәгеләрнең башлыгы — юлбашчысы итеп танылырга тиешләр. Моны аңлап та, кабул итеп тә булмый. Бүген Россиядә яшәүче барлык мөселманнар исеменнән үзенне баш мөфти дип атау һич килешә торган гамәл түгел. Без, мәсәлән, Төньяк Кавказ халыкларының милли холык-характерларын яхшы беләбез, андагы мөселманнарның үз Диния нәзарәте бар, аларның беркем тарафыннан да сайлап куелмаган ниндидер «баш мөфти»гә буйсынуларын күз алдына да китереп булмый. Шуңа күрә ышанып әйтәм: Россиядә әлегә бернинди дә баш мөфти юк. Әгәр дә кемдер шундый исем белән теркәлгән икән — димәк, аның таныклык кәгазьләре ялган. 1992 елның ноябрендә, ягъни Россиядәге барлык мөселманнарның корылтаенда без ниндидер баш мөфти хакында сүз дә алып бармадык, чөнки корылтай әле яңа мөфтиләрне дә танымаган чак иде һәм безгә баш мөфти сайлау мохтаҗлыгы да юк иде. Ә инде соңыннан, башкаларга әйтми-нитми генә, үзен кемдер ниндидер юллар белән баш мөфти итеп теркәткән икән — бу ялган гамәл, гөнаһлы гамәл. Һәм бүген үзләрен, бернинди вәкаләтләре һәм хокуклары булмаган килеш, Россиядә яшәүче барлык мөселманнарның баш мөфтие дип атап йөрүчеләргә оят булырга тиеш. Безгә бердәмлек кирәк. Без яңа нигездә берләшергә тиешбез. Бүген үзәкләштерелгән бердәнбер Диния нәзарәте була алмый, Уфада яки Казанда, Самарада яки Түбән Новгородта утырып, Россиядә яшәүче барлык мөселманнар белән идарә итәргә мөмкин түгел. Аерым төбәкләрдәге Диния нәзарәтләренең булуы кирәк, алар үз эшчәнлекләрен алып барырга тиешләр. Әмма шул ук вакытта безнең әлеге Диния нәзарәтләрен берләштереп-килештереп торучы оешмабыз — әйтик, Россия мөфтиләренең Югары Ислам Шурасы булырга тиештер. Шул чагында без берләшер идек, барлык мәсьәләләр буенча да бер фикергә килә алыр идек. Шул оешма мөфтиләрнең кайсына булса да берсенә,— бәлки, әлеге фараз ителгән Россия мөфтиләренең Югары Ислам Шурасы рәисенәдер,— барлык Россия мөселманнары исеменнән дәүләт органнарына мөрәҗәгать итү, халыкара ислам оешмаларында, ислам дөньясында Россия мөселманнарының мәнфәгатьләрен яклау өчен тулы вәкаләт бирә алыр иде.

**Ә. М.** *Хәзрәт, Мәскәүдә яшәгәч, Сез бит Россия хөкүмәтенә башкалардан якынрак торасыз һәм, тегеләйме-болаймы, чит илләрдә дә Россия мөселманнары вәкиле буларак тәкъдир ителәсез.*

**Р. Г.** Әйе, без — Үзәктә, Россия башкаласы Мәскәүдә. Биредә кырыктан артык мөселман дәүләтләренең илчелекләре бар. Миңа, Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте мөфтие буларак, әлбәттә, мөселман гарәп илләре илчеләре белән даими очрашып-аралашып торырга туры килә. Шулай ук халыкара ислам оешмаларының чакыруы буенча еш кына чит



*Җәмигъ мәчеттә Корбан бәйрәме.*

илләргә дә чыгам, халыкара форумнарда-конференцияләрдә катнашып, Россия Федерациясе флагы астында Россия мөселманнары исеменнән чыгышлар да ясыйм. Әмма мин бер генә җирдә дә үземне Россиянең баш мөфтие дип тәкъдим итмим. Юк. Мин Россия мөселманнарының бер өлеше вәкиле генә, чыгышларымны да шулар мәнфәгатеннән чыгып ясыйм. Әгәр дә инде нинди булса корылтайдамы, конференцияләрдәме Россиядәге барлык Диния нәзарәтләре мөфтиләре катнаша икән, аларның ризалыгы белән мин бөтен Россия мөселманнары исеменнән дә чыгыш ясый алам. Чөнки бу очракта мөселман кардәшләрем миңа хәер-фатиха биргән була.

Россия Федерациясенең төрле хөкүмәт комиссияләре эшендә катнашканда, Россия мөселманнарының мәнфәгатьләре һәм хокукларына кагылышлы ниндидер закон проектлары әзерләгәндә, мин, әлбәттә, алар исеменнән чыгыш ясыйм, алар мәнфәгатен яклыйм. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәктер, Россия Федерациясе Президенты Борис Ельцин тарафыннан мин, дини конфессияләрнең үзара бәйләнешенә нисбәтле рәвештә, Президент каршысында оештырылган Совет әгъзасы итеп тә расландым. Ул Совет эшендә Россиянең барлык мөселманнары исеменнән, аларның мәнфәгатен яклап чыгышлар ясарга Татарстан, Башкортстан, Себер, Түбән Идел, Төньяк Кавказ, Россиянең Үзәк Европа һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәтләре мөфтиләре миңа үзләренең хәер-фатихаларын бирделәр, тулы вәкаләтле иттеләр. Шуңа күрә дә анда инде мин үземне Россия Федерациясе мөселманнарының вәкаләтле вәкиле дип әйтә алам. Әмма бер вакытта да баш мөфти дип әйтергә хакым-хокукым юк.

**Ә. М.** *Аңлашылды, хәзрәт. Инде тормыш-көнкүрешкә кагылышлы бер сорау: күп хатынлылыкка Сез ничек карыйсыз? Ислам дине, мөселманнарга берничә хатын белән торырга рөхсәт итеп, хатын-кызларның хокукларын кысмыймы? Аларны түбәнсетмиме?*

**Р. Г.** Мондый сорауны гадәттә миңа христианнар бирә, чөнки алар ислам дине тарихыннан хәбәрдар түгелләр. Изге Коръән Кәримдә болай диелгән: Аллаһы Тәгалә әйтә: әгәр дә сез үзегезгә лаеклы пар табасыз икән, ул сезнең белән янәшә тормыш юлын кайгыда да, шатлыкта да бергәләп үтәргә әзер икән, ир вә хатынга йөкләнгән йөкне бергәләп тартырга разый икән — сез шәригать буенча рәсми рәвештә никахлашырга тиешсез. Аннары Коръән Кәрим аятендә санап күрсәтелә: бер хатын, икенче, өченче, дүртенче хатын... Бу кайчан әйтелгән? Ислам диненең тәүге чорында, төрле сугышлар аркасында хатын-кызлар һәм аларның балалары яклаучысыз тол-ятим калып, яшәргә мөмкинлек таба алмыйча, ачлык-ялангачлык кичергәндә, яклауга мохтаҗ булганда әйтелгән. Әнә шул чагында Аллаһы Тәгалә берничә хатын тотарга мөмкинлеге булган мал-мөлкәтле ирләргә хәер-фатихасын биргән. Бу зина кылу, уйнаш итү кебек төрле гөнаһлы гамәлләргә юл куймас өчен дә, сабый балаларны ятим-җилпе калдырмас өчен дә шулай эшләнгән дип уйларга кирәк. Хәзерге чорда исә ислам дине кануннары — шәригать кануннары белән яшәүче саф мөселман илләрендә дә, әгәр бер ир икенче хатынга өйләнергә теләп икән, ул моның өчен беренче хатынының ризалыгын алырга тиеш була. Ул ир хатыннарының һәркайсын йортлы итәргә, туйдырып торырга, һәркайсын тигез яратырга һәм аларга тигез карарга бурычлы. Әмма, миңа калса, бу мөмкин эш түгел. Ике-өч хатынны тигез яратуны мин үзем башыма да сыйдыра алмыйм. Россия законнары, башка дәүләтләрнең законнары кешеләргә аңлаешлы законнарга таянып яшәргә куша.

Ислам дине хатын-кызны түбәнсетә-кимсетә, дисәгез, мин моның белән дә килешә алмыйм. Һич тә. Үз фикеремне яклап күп дәлилләр китерә алыр идем. Менә бер генә мисал. Рәсүлебез Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең бер хәдисендә: «Җәннәт сезнең аналарыгызның аяк табаны астындадыр»,— ди. «Аналар» сүзенә ул безнең әниләребез, хатыннарыбыз, кыз туганнарыбыз, кызларыбыз дигән мәгънәне сала. Әгәр дә без аларның хәер-фатихасын алабыз икән, алар бездән разый һәм безгә рәхмәтле икән — димәк, без Аллаһы Тәгаләнең дә хәер-фатихасын алабыз, аның мәрхәмәтенә һәм җәннәткә өмет итә алабыз, димәк, без савaплы гамәлләр кылабыз дигән сүз.

**Ә. М.** *Хәзрәт, без Сезнең белән алданрак очрашырга тиеш идек. Әмма, Чечнядә гадел булмаган сугыш башланып китү сәбәпле, уй-ниятләребез җимерелгән иде. Сез Чечняга барырга булдыгыз. Шул сәфәрегез, анда баруыгызның изге максаты турында да бераз сөйләп үтмәссезме?*

**Р. Г.** Россиянең Чечнягә каршы гаделсез сугыш башларга җыенуын белгәч, без бик борчылдык. Андагы мөселман кардәшләребез нишләр? Шуның өчен кичекмәстән анда барырга, Россия гаскәрләре тыныч авыл-шәһәрләрне утка-бомбага тотмасын, Чечнягә сугыш белән кермәсен, ике арадагы хәлләрне тыныч юл белән хәл итсен, дип үгетләргә ниятләдек. Җоһар Дудаев һәм Чечня Җөмһүрияте парламентарийларының чакыруы бар иде, Россия парламенты делегациясе составында мин дә Чечнягә юл тоттым. Безнең самолетыбыз Моздок шәһәре тирәсендәге хәрби аэродромга барып төште. Самолетыбыз да хәрби иде. Инде самолеттан чыгып, Грозный шәһәренә сәфәребезне дәвам итәрбез, дип җыена башладык. Самолет ишеген ачып җибәргәч, ни күрик: пулемет һәм автоматлар белән коралланган солдатлар төялгән автомашиналар самолетыбызны чолгап та алды, ниндидер бер хәрби начальник: «Урыннарыгыздан кузгалмаска! Сезне самолеттан чыгармаска дигән боерык бар»,— дип игълан итте. Шулай итеп, безнең юлыбызны кистеләр. Безнең белән килгән дүрт депутатка гына рөхсәт ителеп, аларны вертолетларга утыртып алып киттеләр. Ә безгә исә: «Сезнең тормышыгызга куркыныч янавы мөмкин. Премьер-министр Черномырдинның сезне Мәскәүгә кайтарып җибәрергә дигән әмере бар»,— дип аңлаттылар. Асылда инде сугыш башланган, утка-бомбага тотулар булган, Грозный шәһәренә беренче һөҗүм оештырылган икән. Безне кире Мәскәүгә кайтарып та җибәрделәр. Шул рәвешле, мин Җоһар Дудаев һәм Чечня Җөмһүрияте парламентарийлары белән, андагы мөселман кардәшләрем белән күрешеп сөйләшүдән мәхрүм ителдем. Грозныйга булган беренче һөҗүм нәтиҗәләрен дә үз күзем белән күрмәдем. Мәскәүгә кайткач, безнең Диния нәзарәтебез Россия Президенты Борис Ельцинга мөрәҗәгать кабул итте. Мин ул мөрәҗәгать-кисәтү белән чыгыш ясап, әгәр дә чынлап торып сугыш башланса, аның озакка сузылачагын, сугыш әфәте Төньяк Кавказ халыкларына гына түгел, ә бәлки бөтен Россия халыкларына төшәчәген искәрттем. Сугыш дистәләгән меңнәрчә гаиләләргә, ата-аналарга кайгы-хәсрәт китерәчәк, урыслар да, чеченнар да, татарлар һәм башка халыклар да әйтеп бетергесез зыян күрәчәк, дидем. Кызганыч ки, нәкъ шулай булып чыкты да: Чечнядә ике елга якын кан коелды, безнең мөселман кардәшләребезнең, христиан кардәшләребезнең газиз каны... Тормыш безгә илаһи зат — Аллаһы Тәгалә тарафыннан бүләк итеп бирелгән, яшәү бәхетен, яшәү рәхәтен тартып алырга беркемнең дә хакы юк.

**Ә. М.** *Равил хәзрәт, Татарстан Җөмһүрияте белән бәйләнышларыгыз турында да сөйләсәгез иде.*

**Р. Г.** Беренчедән, әйткәнемчә, мин үзем чыгышым белән Татарстаннан. Анда минем әнием, туганнарым яши, минем тамырым анда. Мин үз Ватанымны яратам, Татарстан мөселманнары белән тыгыз бәйләнештә торабыз. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте белән даими хезмәттәшлек итәбез. Татарстан Җөмһүриятенең беренче Президенты хөрмәтле Минтимер Шәймиев белән дә, башка дәүләт җитәкчеләре белән дә очрашып торабыз. Һәм, әлбәттә, Татарстан зыялылары — галимнәр, фән һәм сәнгать әһелләре белән аралашабыз. Шулай ук Мәскәү җәмигъ мәчете һәм Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте, ислам диненә кагылышлы олуг бәйрәмнәребезне үткәргәндә, мәчетләребез белән генә чикләнмичә, ул бәйрәмнәргә күбрәк мөселман кардәшләребезне тарту йөзеннән, кино-концерт залларында ураза бәйрәме, корбан бәйрәме, гашура бәйрәме, мәүлид кичәсе, бәраәт кичәсе кебек тантаналар үткәрәбез. Ул тантаналарга Татарстан һәм Башкортстан сәхнә йолдызларын чакырабыз. Казаннан яки Уфаданмы, башка авыл-калалардanмы — мөселман кардәшләребез кайдан гына килмәсен, алар һәрвакыт Мәскәү җәмигъ мәчетенә аяк басалар. Алар Россиянең һәм Мәскәүнең бердәнбер үзәк мәчетендә Җир шарының төрле почмакларыннан җыелган мөселман кардәшләребез белән бергә, Мәскәү мөселманнары белән бергә җомга вәгазе тыңлыйлар, җомга намазы укыйлар.

**Ә. М.** *Әле 1995 елда мәчетегездә зур төзелеш-ремонт эшләре бара иде. Хәзер инде бу изге бинаны танып та булмый, ул шул кадәр гүзәл-матур, бер сүз белән әйткәндә, чын сәнгать әсәре!*

**Р. Г.** Әлхәмделиллаһы, хәзерге икътисади авыр заманда Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән без ул кыен эшне әйбәт кенә башкарып чыктык. Бу бинада Россиянең Үзәк Европа өлеше һәм Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте мөф-

тиенең резиденциясе, Мәскәү Ислам көллияте дә урнашкан. Килгән кунакларыбыз бик канәгать, алар безгә рәхмәтләр укыйлар. «Әйе, Мәскәүдә мөселманнарның падишаһларны да кабул итәрлек мәһабәт изге биналары бар!» — дип куаналар. Сүз уңаеннан әйтеп китим: без бирeдә исмаилитлар принцы — шаһзадә Ага-ханны кабул иттек. Шулай ук Кувейт, Ирак, Иран Ислам Җөмһүрияте Милли мәҗлесләренең (безнеңчә, Дәүләт Думасы буладыр) рәисләре дә кунак булды бездә. Татарстан Җөмһүрияте Президенты Минтимер Шәймиев белән очрашу бигрәк тә онытылмаслык, истәлекле булды. Президент Мәскәү мөселманнары белән аралашты, без аның белән Россиядә ислам диненең бүгенге хәле турында бик җитди, әһәмиятле фикер алышу үткәрдек, илебез мөселманнарының Диния нәзарәтләре арасында бердәмлек җитенкерәмәвенә борчылуыбызны белдердек, Мәскәү янындагы Табыну тавында (урыслар аны Поклонная гора дип йөртәләр) булачак мәчетне төзү мәсьәләләрен уртага салып киңәштек. Ул мәчет Шәһадәт мәчете дип аталачак, ягъни Бөек Ватан сугышларында һәлак булган — шәһит киткән ата-бабаларыбыз рухына багышланган булачак. Әле бит телгә «Наполеон сугышы» дип кергән 1812 елгы Ватан сугышында да безнең татар һәм башкорт мөселман полклары катнашкан. Бу Шәһадәт мәчетен төзүдә безгә Татарстан хөкүмәте дә матди ярдәм күрсәтер дигән өметтә калабыз.

(Татарстан Президенты М. Шәймиев бу мәчетне төзү өчен 1 млрд. сум акча бүлеп бирде. *Ред.*) Мәчетебезгә, Диния нәзарәте идарәсенә рәхим итегез!

**Ә. М.** *Рәхмәт, мөфти хәзрәт! Бик рәхмәт!*

**Р. Г.** Хөрмәтле газиз дин кардәшләрем, кадерле милләттәшләрем! Очрашу минутлары кыска, мин бу мөмкинлектән файдаланып, сезгә үземнең иң хәерле догаларымны, иң изге теләкләремне җиткерәсем килә. Аллаһы бәрәкә Тәгалә ил-көннәребезгә тынычлык вә иминлек әйләсен. Күп милләтле Татарстан Җөмһүрияте халыклары арасында аңлашып яшәү, бер-берләренә хөрмәт булса иде, аларга кайгы-хәсрәтләрен уртаклашып, шатлык-сөенечләрдә бергә булып яшәргә Раббыбыз насыйп әйләсә иде. Киләчәктә без мөселманнар кайда гына булсак та, бердәмлегебезне Раббыбыз насыйп кылса иде, дип изге теләкләремне телим! Һәм без татарлар кайда гына яшәсәк тә — Казандамы, Уралда-Себердәме яки Россиянең үзәк өлешендәме — без барыбер Татарстанны, Казанны үзебезнең икенче кыйблабыз итеп саныйбыз. Мәккәи Мөкәррәмә барлык мөселманнарның кыйбласы булса, татарларның кыйбласы — ул Казан, дибез. Мин үземне, Мәскәүдә яшәсәм дә, Мәскәүдә эшләсәм дә, Татарстан вәкиле, Татарстан илчесе итеп саныймын. Шуның өчен дә сезгә Аллаһы Раббыбыз тормышларыгызда иминлек, байлык, саулык, тынычлык, иман ныклыгы насыйп әйләсә иде, дип, изге теләктә, хәер-догада каламын.

Вәссәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи, вә бәрәкатү!

## ПУБЛИЦИСТИКА

# БИЕКТАУ ЙОЛДЫЗЛАРЫ

*«Әдип вә галимнәре булмаган кавем бәхетсез,*
*мәшһүр кемсәләрен оныткан халык көчсез,*
*әдәбияты булмаган милләт рухсыз».*

Риза Фәхретдин.

I

Татар галәмендә «Казан арты» дигән төбәк күпләргә билгеле — ул мәдәниятебезне, гыйлем дөньябызны баетуга мул өлеш кушкан күренекле шәхесләре белән дан тота. Әмма «Казан арты» дигәндә гадәттә күбесенчә хәзерге Арча һәм Әтнә районнарына кергән җирләр күздә тотыла. Югыйсә башкалабызга орынып торган һәм шулай ук Казан артын тәшкил иткән район — Биектау. Мин бу язмамда нәкъ менә җәмәгатьчелеккә азрак билгеле шушы Биектау ягы, аның данлы уллары һәм кызлары турында сүз алып барачакмын.

Тарихтан билгеле: бу якны ата-бабаларыбыз бик борынгы заманнарда ук үз иткән. Урманнары җәнлек-киеккә бай, челтер чишмәләре шифалы, яланнары игенчелеккә уңайлы. Менә шундый җирләрдә тамыр җибәреп, өлкән буын шигъри исемле бик күп авылларга нигез салган. Айбаш, Бөреле, Дөбъяз, Кодаш, Мәмдәл, Сая, Юртыш, Әлдермеш, Өбрә — бу исемнәрдә серле легендалар яшеренеп ята. Берәүләр аларны Казан ханлыгы заманыннан ук билгеле дисә, икенчеләр Болгар патшалыгына һәм аннан да элгәреге заманнарга бәйләп телгә ала. Татар дәүләтләре архивлары, бу яктагы мәгърифәт оясы булган мәчет-мәдрәсәләр 1236, 1552 еллардагы аеруча рәхимсез яулар тарафыннан туздырылганлыктан, халкыбызның даһилары тирегә һәм кәгазьгә язган язулар гына түгел, ташка уйган мәгълүматлар да юкка чыккан. Тыныч тормыш башка чакларда да еш өзелгән, шунлыктан үткәнне җанландыру хәзер инде бер дә ансат түгел. Әмма археологик казынулар, фольклор экспедицияләре, фәнни тикшеренүләр борынгы дәверләргә дә юллар сала. Бу эшнең бер йомгагы Биектау районы хакимияте ярдәмендә 1995 елның декабрендә оештырылган гыйльми конференциядә ясала. «Казан арты: тарихы һәм мәдәнияте» дип аталган бу конференциянең материалларын кичектермичә бастырып чыгаруга булышып, Биектау хакимияте үз төбәген танытуга гына түгел, халкыбызның гомум үткәнен өйрәнүгә дә күркәм өлеш кертә.

Берничә дистә галим катнашкан шушы гыйльми конференция Биектау ягының халкыбыз үткәнендә тоткан урынын төрле яктан ачыклый. Докладчылардан Н. Гәрәева, мәсәлән, Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстафәдел әхбар», җиде томлы «Вафиятел әслаф» әсәрләренә таянып, Р. Исламов Риза Фәхретдиннең унбиш кисәктән гыйбарәт «Асарь» хезмәтенә нигезләнеп, киң җәмәгатьчелеккә билгеле булмаган, әмма Биектау ягының шөһрәтен арттыра торган күп кенә тарихи шәхесләрне телгә алалар.

Ш. Мәрҗани «Вафиятел әслаф»ының җиденче томында хәзерге Биектау районын караган авылларда туып-үскән яки эшләгән дистәләгән күренекле кешене санап китә. Кавалдан Габдессәлам улы Габдерәшит, Габдерәшит улы хаҗи Гобәйдулла, Габделкадыйр улы Әхмәт, Дөбьяздан Яхъя улы Якуп, Чуваш Иледән Сәеткол улы Гомәр, Җәгъфәр улы Габдерәхим, Саядан Җәгъфәр улы Габдерәхим, Юртыш белән Мәмдәлдән Ислам улы Хәмит, Хәмит улы Хөсәен, Әлдермештән Исхак улы Сәлим һәм Сәлим улы Хәсәннәр XIX йөзнең беренче яртысында укымышлы мулла, мәгърифәтче сыйфатында танылалар. Алар дини йолаларны үтәү белән бергә, халык арасында күркәм гореф-гадәтләрне, әхлакый

сафлыкны саклауда көч түгеп, балаларга белем-тәрбия биреп, яшәгән авылларында гына түгел, бөтен тирә-якта абруй казаналар. Габдессәлам улы Габдерәшит, мәсәлән, дөнья кууга артык илтифат бирмәстән, бөтен күңелен халыкны иманлы һәм белемле итүгә багышлаган, гарәпчәне яхшы белә торган зат була. Хаҗга баргач, бер ел Мәккәдә яшәп кала һәм икенче хаҗ сәфәреннән кайтканда, Сарытау шәһәре тирәсендә дөнья куя. Яхъя улы Якуп Бохарада белем ала, Кышкар мәдрәсәсендә ун ел чамасы шәкертләр укыта, замандашлары аны тыйнак, әйбәт фигыльле булган өчен хөрмәт итә. Шиһабетдин Мәрҗани мөнә шуның өчен әлеге шәхесләрне энциклопедик хезмәтендә сурәтләп, киләсе буыннар хәтерендә дә калдырырга тырыша.

Биектау төбәге кешеләре арасыннан һөнәр осталары, эшкуарлар да күп үсеп чыга. Әйтик, Битаманнан сәүдәгәр Садретдин Мифтахетдин улы Нәзирев исеме заманында күпләргә билгеле була. Ул хезмәт юлын туган авылында башлап, соңрак Казанда приказчиклык шөгыленда елгырлык күрсәтә. Мөстәкыйль сәүдә эшенә Уфада керешә — тукымалар, иген-тару, тире-яры алыпсатарлыкка күңелен сала һәм тиз арада баеп китә. Аңа хөрмәт китергән сыйфат — халык мәнфәгатьләрен кайгырту була. Ул хәләл табышын мохтаҗларга ярдәм күрсәтүгә, туган ягында һәм Уфада мәктәп-мәдрәсәләр тотуга, Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург югары уку йортларында татар студентларын укытуга сарыф итә. Садретдин бай Уфадагы атаклы «Галия» мәдрәсәсен коруга иганәлек кыла. Җәмгыяте хәйрия, төрле банк комитетлары эшендә актив катнашуы өчен аны император хөкүмәте медаль белән бүләкли. Тарихчы галим Җәүдәт Миңнуллин аның хакында алда искәртелгән гыйльми конференциядә юкка гына сокланып сөйләми, билгеле.

Унтугызынчы йөзнең икенче яртысында Биектау төбәге сәләтен тагын да куәтлерәк ача — аның тырыш, тынгысыз уллары, татарның беренче мәгърифәтчеләре һәм фикер ияләре Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри эшчәнлеге белән рухланып һәм алардан аң-белем туплап, үрнәк алып, сәүдә, мәгариф, әдәбият, тел, тарих, фольклор гыйлеме, ислам мәдәнияте мәйданына кыю аяк басалар, җәдитчелек хәрәкәтенә саллы өлеш кертәчәк биреләр һәм милләт күләмендә танылуга ирешәләр. Укымышлылык буыннан-буынга күчеп, рух һәм дәрман байый — аның матур нәтиҗәләрен Галиев-Баруди, Максуди, Габәшиләр нәселләре тәэсирле рәвештә күрсәтә.

Исеме татар дөньясыннан тыштa да билгеле биектаулыларның берсе — Селәңгер авылында туган Мөхәммәтгали Мәхмүдев (1824—1891). Ул Казан мәдрәсәләренең берсендә заманының мәгълүм укымышлысы Хәйбулла хәзрәттән сабак ала — гарәп, фарсы һәм төрек телләрен, матур язу сәнгатен камил үзләштерә. Шәрекъ гыйлемен әйбәт белүе белән ул Казан губернасы укыту округы түрәләренең дә игътибарын җәлеп итә. Халык мәгарифе министрлыгы аңа гарәп, фарсы һәм төрек-татар каллиграфиясе укытучысы вазифасын башкарырга ризалык бирә, чынлыкта ул шул эшне 1843 елның февраленнән үк үти башлый. 1849 елда салым түли торган игенче катламыннан укытучы-хезмәткәрлеккә күчерелә. Казан университетында каллиграфия укытудан тыш, М. Мәхмүдев студентларга гарәп, фарсы, төрек телләре буенча белемнәрен киңәйтүгә дә булыша.

Казан университетының тарих-филология факультеты шәрекъ бүлеге С.-Петербургка күчерелгәч, яшь галим 1855 елдан башлап Казанның беренче гимназиясендә төрек-татар теле һәм каллиграфия укыта. Җитмешенче елларда күренекле тюрколог В. В. Радлов белән Казан укытучылар мәктәбен оештыруда катнаша һәм шунда 1876—1891 елларда инспектор булып хезмәт итә. Бу уку йорты татарлардан башлангыч мәктәпләрдә эшләр өчен урыс теле укытучылары, патшага турылыклы, христиан диненә теләктәш чиновниклар әзерләргә тиеш була. Әмма бу уку йортын оештыруда катнашкан Ш. Әхмәрев, И. Терегулов, Ш. Таһиров, аның эшендә якты эз калдырган Ш. Мәрҗани, К. Насыйрилар тырышлыгы белән Татарская учительская школа дип даны таралган мәктәп милләттәшләребезнең дөньяви белем алу учагына әйләнгән, аннан күп кенә егетләребез туган халкына файдалы хезмәт итәчәк шәхесләргә әверелеп чыкканнар. Мөхәммәтгали Мәхмүдев исә монда күренекле милләттәшләре белән даими аралашып, заманының ихтыяҗын кадәри хәл капларга тырыша — татар телен өйрәнү буенча кулланма, урысча-татарча сүзлек төзи, урыс һәм төрек телләреннән кирәкле материаллар тәрҗемә итә. Казан университеты типографиясендә басыла торган гарәпчә, фарсыча һәм төрекчә китапларны чыгаруда (корректор!) катнаша. Аның ихтирамга лаек эшчәнлеге хакында Мөхәммәт Гали («Совет әдәбияты», 1946, № 1), П. Дульский, Гульбин, Загоскин, Мәҗитова һ. б. галимнәр матбугатта байтак мәкаләләр бастыра.

һәвәскәр тарихчы Ә. Җәләлиев хәбәр итүенчә, М. Мәхмүдев гармунда оста уйный, эскрипкәне хәтта үзе дә ясый. Аның бу һәвәслеге кызларына да күчә — Бибигайшә шулай ук гармун уйнарга ярата торган була.

М. Мәхмүдевнең ике кызы — Бибигайшә һәм Фатыйма үсеп җитәләр, шуларның беренчесе мәгърифәтче галим Ибраһим Терегуловка кияүгә чыга. Л. Толстойның «Рассказ солдата», А. Островскийның «Без вины виноватые» әсәрләрен тәрҗемә итеп, ул да туган халкының күңел дөньясын баетуга хезмәт итә.

Кече Кавал авылында туган Мөхәммәтҗан Ибнеәмин улы Галиев (1832—1908) 1861 елда Казанның Дары бистәсенә килеп урнаша. 1869 елда ул баш һәм аяк киемнәре сатарга керешә. Әйтергә кирәк, уңышлы сәүдә итә, бераздан инде ул Казанда кибет ачып кына калмый, Уфа, Эрбет якларында да эш йөртә һәм тора-бара беренче гильди купецка әйләнә. Үзе артык укымышлы булмаса да, китапка ихтирамлы, кызыксынучан Мөхәммәтҗан абзый җәмәгать эшләрендә дә катнашырга тырыша. Динле, күркәм холыклы сәүдәгәр мохтаҗларга шәфкать күрсәтә, үзенә зур ташпулат салганда янәшәдәге мәчетне киңәйтүгә дә малын кызганмый. Улларын исә укымышлы, ил-күз алдында абруйлы җаннар итеп күрергә тели — икесен дә Күлбуе мәдрәсәсенә бирә. Аны тәмамлагач, Галимҗан белән Салихҗан Галиевләр белемнәрен тирәнәйтер өчен Бохарага юнәләләр. Кардәшләрнең кечесе Салихҗан Бохарадан кайткач Казанның Яңа бистәсендә унынчы мәхәллә имамы булып сайлана. Абыйсы кебек шөһрәт казана алмаса да, ул монда алдынгы карашлы мулла сыйфатында яшь буынга белем, мәхәллә халкына тәрбия бирергә җиң сызганып тотына. Дини һәм милли рухтагы тырышлыклары кадимчеләргә һәм миссионерларга ошамаганлыктан, Казан губернаторы әмеренчә, 1908 елда ул да абыйсы белән бергә Вологда өлкәсенә сөрелә.

Кардәшләрнең өлкәне Галимҗан исә Күлбуе мәдрәсәсендә укыганда ук (1862—1874) гыйлемгә зур һәвәслек күрсәтә — унбиш яшендә ул инде гарәпчәне камил үзләштерә. Бохараның Миргарәп мәдрәсәсендә янә җиде ел белем алу аны Шәрекъ рухында чын укымышлы егеткә әверелдерә. Әйтергә кирәк, ул үзлегеннән мәгълүмат җыюын да онытмый, әнә шулай Хөсәен Фәезханов, Исмәгыйль Гаспралылар алга сөргән җәдитчә укыту, дөньяви белем алу хаҗәтлегенә дә ихлас ышана һәм шул юлда тырышлык күрсәтергә әзерләнә.



*Галимҗан Баруди*

1881 елда Бохарадан кайткан Галимҗан Казанның дүртенче мәхәлләсендәге Акмәчет имамы вазыйфасына сайлана. Шунда мәдрәсә ачып, хыялын тормышка ашыру эшенә дә керешә. Казанның Дары бистәсендә туып үскәнлектән, ул үзенә Баруди («Баруд» — гарәпчә «дары») кушаматын ала. Менә шулай Галимҗан Баруди (1857—1921) утыз биш елга сузылган укытучылык эшен башлап җибәрә.

Казанда җәдитчә укытырга керешкән улы өчен ата кеше мәдрәсәнең яңа бинасын салдыра, шуннан соң бу мәгърифәт учагы иганәче хөрмәтенә «Мөхәммәдия» исемен ала. Яңа мәдрәсә тиздән үрчиячәк җәдит мәктәп-мәдрәсәләр өчен укытучылар әзерләүне күздә тота.

Г. Баруди, Көнбатыш илләрендәге мәгариф челтәре эшеннән җитәрлек дәрәҗәдә хәбәрдар булмаса да, «Мөхәммәдия» программасына байтак дөньяви фәннәр кертеп, кыю адым атлый. Аның татар җирлегендә укытуны яңартып җибәрүе — ысул җәдитне кертүе «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шөһрәтен гаять киң тарата — монда ерак-ерак тарафлардан шәкертләр агыла һәм тиздән аларның саны 400 гә җитә. Баруди аларның ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен әзерлекле укытучылар тартырга тырыша. Мисалга, Сорбонна университетын (Париж) тәмамлап кайткан мәшһүр Йосыф Акчура 1904/1905 уку елында монда тарих, география, төрек әдәбиятыннан сабак бирә.

Г. Барудиның эшчәнлеге, әлбәттә, мәдрәсә тоту, мулла вазыйфаларын үтәү белән генә чикләнми — ул 1906 елда «Дин вә әдәб» журналын нигезли, мәктәп-

мәдрәсәләр өчен яңачарак эчтәлекле дәреслекләр язып бастыруга зур әһәмият бирә. Аның туган халкына әнә шулай канатланып һәм тырышып эшләве, тиз арада уңыш казануы озын сакаллы кадимче руханиларның, карагруһ патша түрәләренең һәм миссионерларның ачуын кабарта — алар Галимҗан мөдәррисне энесе белән бергә ерак төньякка сөргенгә олактырырга ирешәләр.

Канун нигезендә җәзага тартыр өчен сәбәбе булмаган Г. Барудиның һәм аның энесенең язмышы алдынгы татар җәмәгатьчелегенә тынгы бирми, аларны аклау һәм Казанга кайтару тартышы башлана. Дәүләт Думасы депутаты Садрый Максуди тырышлыгы 1910 елда, ниһаять, уңай нәтиҗәсен бирә — кардәшләр туган шәһәрләренә әйләнеп кайта.

Г. Барудиның татар мәгарифе тарихында тоткан мәртәбәле хезмәтләренә гадел бәя бирер өчен шуны белү кирәк ки: «Мөхәммәдия» шәкертләре математика, химия, биология, зоология, география, тарих, урыс теле кебек дөньяви фәннәрне өйрәнеп яткан вакытта күпчелек татар мәдрәсәләре әле һаман дә чирек гасыр дәвамында искечә укытуга ябышып ята, ягъни схоластик рәвештә дини фәлсәфә, пәйгамбәрләр тарихы, Коръән тәфсирләрен ятлату белән мавыга. «Мөхәммәдия» исә ислам дине нигезләрен, гарәп-фарсы телләрен үзләштерүдә дә әлеге мәдрәсәләрдән калышмый. Яңа ысул укырга-язарга тизрәк өйрәнергә, дөньяви фәннәрне башка елдам сеңдереп, заманча тормыш итәргә тизрәк яраклашырга мөмкинлек бирә. Г. Баруди тырышлыгы белән «Мөхәммәдия» татар галәменең иң алдынгы хисапланган «Галия» (Уфа), Иж-Бубый, «Хөсәения» (Оренбург) мәдрәсәләре белән бер сафка баса. Халкыбызның атаклы язучылары, сәнгатьчеләре, нәшир-журналистлары һәм галимнәреннән Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал, Бакый Урманче, Кәрим Тинчурин, Фәтхи Борнаш, Газиз Гобәйдуллин, Гыйльметдин һәм Борһан Шәрәфләр, Нәкый Исәнбәт һәм бүтән күпләрнең мактаулы иҗат юлына нәкъ менә «Мөхәммәдия»не тәмамлагач кереп китүләре Г. Баруди эшчәнлегенә иң югары бәя булып тора.

Г. Баруди 1917 елда Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәтенә мөфти итеп сайлана, болганчык заманның катлаулы шартларында милләттәшләренә рухи тотрыклылык сакларга ярдәм итә. 1921 елда Идел буенда ачлык фаҗигасе җәелгәч, ул бөтен көчен мохтаҗларга булышырга сарыф итә, шул юлда йөргәндә үзе дә Мәскәүдә дөнья куя.

Галимҗан Барудиның ихтирамга лаек эшчәнлеге Җамал Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар» (М.—Пг., 1923), Габделбари Баттал-Таймасның «Казанлы төрек мәшһүрләреннән» сериясендә басылган «Галимҗан Баруди» (Истанбул, 1959) китапларында яктыртыла. Г. Баттал-Таймасның «Бән бер ышык арыюрдым» (Истанбул, 1962) китабыннан Г. Барудига багышланган бер бүлекчә соңгы дәвердә «Татарстан» журналында да дөнья күрде. Биектаулыларны армый-талмый туган як үткәне белән таныштырып килүче һәвәскәр тарихчы Әгъзам Җәләлиев хөрмәтле якташына шулай ук махсус мәкаләсен («Ильич юлы» г., 16.VII.1993) багышлаган.

* * *

Мәшһүр биектаулыларның онытыла төшкәнрәк берсе — Галимҗан Барудиның якын танышы һәм замандашы Хәсәнгата Мөхәммәт улы Габәши (II.X.1863—1936) Кече Солабаш авылында дөньяга килгән. Алдарак телгә алынган Биектау гыйльми конференциясендә Казан галиме Г. Макаров Хәсәнгата Габәши нәселенең XVI йөз башында Бохарадан килгән музыкант аталы-уллы Хәбәшиләргә бәйләнү ихтималлыгын бәян итә. Шәйбани хан тарафыннан Казан ханы Мөхәммәт Әмин сараена бүләк итеп җибәрелгән бу музыкантлар шушында яшәп калган, ханлыктагы болганышлар вакытында Дәрвиш Шади Хәбәши суга батырып үтерелә, аның улы Голәм Шади исә Казан артындагы авылларның берсенә китеп югалып, шунда гомерен саклап калган булырга тиеш, имеш. Исемнәреннән күренгәнчә, музыкантлар Хәбәштаннан килеп чыкканнар, имеш. Әмма бу романтик тарихның Хәсәнгата Габәшигә ни дәрәҗәдә катнашы барлыгы томанлы — нәсел шәҗәрәсе сакланмаган. Ул гына түгел, без хәзер бу нәселнең соңгы дәвердә яшәгән буыннарын, хәтта Хәсәнгата Габәшинең тормышы һәм эшчәнлеген дә җентеклә п белмибез. Хәсәнгатаның атасы — Мөхәммәт, Мөхәммәтнең атасы — Гобәйдулла (1790—1874?), Гобәйдулланың атасы Кәлимулла булган, имеш, яшь буынның фамилиясе Гобәйдулладан кыскартылып, Габәшигә әйләнгән булырга тиеш икән.

Кайбер мәгълүматлар буенча, Кәлимулла Әлдермеш авылында яшәгән һәм Кавал авылы кызына өйләнгән, аның шул никахтан туган улы Гобәйдулла исә Буа ягындагы Тинчәле авылы хәзрәте Сәйфелмөлек кызы Фатыйма белән гаилә корган. (Сәйфелмөлекнең оныгы Баһаветдингә кияүгә чыга, шул никахтан Шиһабетдин Мәрҗани туа). Мөхәммәт Кече Солабашка мулла булып килеп урнашкан.

Хәсәнгата Габәши Казанның Күлбуе мәдрәсәсендә укыган, гомере буе гыйлем эстәп яшәгән, бай гына шәхси китапханә туплауга ирешкән. Атасы урынына мулла булгач (1893) та төрле фәннәрне өйрәнүдән туктамаган, аннары үзе дә милләттәшләрен агарту өчен әсәрләр язарга керешкән. Ул халык алдында төрле темаларга вәгазьләр, нотыклар сөйли, матбугатка мәкаләләр яза, заманында барлыкка килә башлаган төрле җәмгыятьләрне оештыруда актив катнаша. Х. Габәшинең 1889 елда Казанда нәшер ителгән «Тәрбияле бала» әсәре хакында Галимҗан Ибраһимов: «Китап баштанаяк шундый садә, Насыйрины тәмам рәхәтләндерерлек, үз юлының көчәя башлавын күрерлек саф татарча тел белән язылган», дип уңай бәяли. Г. Ибраһимов Хәсәнгата абзыйның ислам динен яңарту, милли тарихыбызны яктырту өчен яңа материаллар һәм ысуллар куллануын да хуплап телгә ала.

Җамалетдин Вәлиди исә: «Ул ике тарихи әсәр — төрек-татар халкының кыскача һәм тулы тарихын язды. Ул хезмәтләр мәгълүматка бай», дип билгеләп уза.

Хәсәнгата Габәши заманының алдынгы фикер ияләре, мәгърифәтчеләре Шиһабетдин Мәрҗани, Риза Фәхретдин, Галимҗан Баруди, Фатих Кәрими, Фатих Әмирхан, Таһир Ильяс, Шәһәр Шәрәф һ. б. белән хатлар язышып, форсаты чыкканда аралашып яши. Аның башлангыч мәктәпләр өчен язылган «Төрек ыруглары» (Казан, 1912) хезмәте җәмәгатьчелек тарафыннан аеруча җылы каршылана. «Мәрҗани хәзрәтләрен искә төшерү» мәкаләсе исә «Мәрҗани» (Казан, 1915) мәҗмугасендә дөнья күрә. «Миссионерлык хәрәкәте турында», «Исламның җыр һәм көйгә-музыкага карашы» хезмәтләрен язган галим эзләнүләре нәтиҗәсен вәгазьләрендә дә файдаланырга өлгерә.

Х. Габәши 1895 елда Диния нәзарәтенә эшкә алыну уңаеннан Уфага күчеп китә, монда да ул намуслылыгы, халыкка ихлас хезмәт итүе белән хөрмәт казана. Беркадәр вакыттан соң ул туган ягына әйләнеп кайта, 1917 елда исә Казанга килеп урнаша. Совет дәверендә үз фикере булган мондый дин әшлеклесенә, миллионер Әхмәт Хөсәенов ярдәмендә туган авылында өч катлы йорт салган «бай»га мөнәсәбәт, әлбәттә, яхшы булмый. Килә вакыт, аны гаепләргә сылтавы да табыла. Җәзасы — Соловки сөргене. Галим мулланың картлыгы, шул буын татар мәгърифәтчеләренекенә хас булганча, мохтаҗлыкта һәм фәкыйрьлектә үтә — аның кара күләгәсе балаларына да бик мул төшә.



*Солтан Габәши*

Татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе булган Солтан менә шушы укымышлы Хәсәнгата гаиләсендә дөньяга килә. Башта — атасыннан, аннары Казан мәдрәсәләренең берсендә белем ала. Уфага күчкәч, «Галия» мәдрәсәсендә укуын дәвам итә. Атасының бай китапханәсе рухи эзләнүләренә мул азык бирә. Казан артының җыр-моңы ана сөте белән күңеленә сеңгәнлектән, ул Казанда чакта ул эскрипкәдә, Уфада исә шәхси укытучы яллап, пианинода уйнарга өйрәнә. Гаиләдә аның бу шөгыленә теләктәшлек белән карыйлар. Әмма бу чакта әле татар яшьләренә профессиональ музыка белеме алуның ихтыяҗы сизелми — мөселманнар арасында андый һөнәр иясенә тамак туйдыру гарантияләнмәгән була. Менә шунлыктан Солтан Габәши 1915 елда Казан университетының хокук факультетына укырга керә. Ул инде бу вакытта гарәп, төрек, урыс телләрен

яхшы белә, казакъ, үзбәк, француз һәм алман телләрендә дә аңлаша ала торган була.

Уфада чакта ук көйләр чыгара башлаган Солтан, Казанга килгәч, алдынгы милләттәшләре мәҗлесләрендә кайный, шәрекъ кичәләренең, татарча спектакльләрнең музыкаль бизәкләрен иҗат итәргә керешә. Г. Исхакыйның «Зөләйха», Ф. Борнашның «Таһир—Зөһрә», К. Рәхимнең «Бүз егет» спектакльләренә С. Габәши иҗат иткән музыканы тамашачылар кул чабып каршылый, аларга күренекле әдип Галимҗан Ибраһимов та югары бәя бирә.

С. Габәши революциядән соң Казанда Вахитов мәктәбендә, укытучылар курсында, Шәрекъ консерваториясендә, педагогия һәм музыка техникумнарында музыка укыта башлый. Шуның белән бергә, ул концертларда башкаручы, музыка сөючеләр өчен дәреслекләр һәм программалар төзүче буларак та таныла. Аның «Кәккүк» (Гөлсем Сөләйманова башкаруында тыңлаучылар мәхәббәтен казана) «Рокыя-гөлкәем» һ. б. җырлары да халык арасында киң тарала. Газиз Әлмөхәммәтев, Василий Виноградовлар белән бергә 1925 елда — «Сания», 1929 елда «Эшче» операларын иҗат итү С. Габәшинең композитор буларак тагын да үсә төшүен раслый. Әмма шушы дәвердә аның эшчәнлегеннән милләтчелек, ят идеология гонсерләрен эзләү композиторны бик авыр хәлгә куя — ул 1932 елда Казаннан Уфага күчеп китәргә мәҗбүр була. Монда ул Башкорт сәнгать техникумында укыта, шул ук вакытта татар-башкорт музыкаль фольклорын җыйнарга, укыту-методик кулланмалар язарга тотына. Ләкин монда да аның артыннан кара сакалы сөйрәлеп килә — эшеннән куыла. Милли башкаласында яшәп, туган халкының профессиональ музыкасын үстерергә тиешле, моңа дәрте дә, дәрманы да җитә торган асыл зат хәзер инде Уфа шикелле зур мәркәздә яшәүдән дә мәхрүм ителә — ул Башкортстанның Борай районы Челкак авылында гади мөгаллим рәвешендә көн күрергә һәм шунда сүнәргә мәҗбүр була.

Солтан Габәши (1891—1942) кыска һәм тынычсыз гомерендә татар профессиональ музыйкасы тарихында беренче буразналарны сызучы талантлы композитор, оста башкаручы, сәләтле педагог, милли сәнгатебезгә күп кенә үзенчәлекле әсәрләр бүләк иткән кадерле зат булып кереп кала. Ләкин вакытында әсәрләрен нотага салып җыеп бармаганлыктан, аның күпчелек иҗат хәзинәсе эзсез югала. Әсир халыкның талантлы улы табигый сәләтен ачып бетермәстән, совет империясенең азчылык милләтләрнең иҗат көчләрен бастыру сәясәте аркасында, вакытсыз гүргә керә.

* * *



*Габдрахман Ильяси*

С. Габәши татар профессиональ музыйкасына нигез салучыларның берсе булса, биектаулылар тагын бер тармакта «беренче» данын казанган якташлары белән горурлана алалар. Рәсми белешмәлекләрдә Казанда туган дип теркәлгән Салих Сәйдәшев, Әнвәр Бакиров кебек, татар драматургиясенә нигез салучы Габдрахман Ильяси (1856—1895) да дөньяга килүе белән башкалабызга беркетелгән. Бу өч шәхеснең һәммәсе ата-бабасы аркылы авылга бәйләнгән — аларның һәркайсының тамыры Биектау төбәгенә тоташуы замандашларыбызда шик уятмый. Әле дә арабызда яшәгән композитор Әнвәр Бакиров үзе «мин — Әлдермеш малае» дип саный икән, моны кире кагырга хакыбыз да юк!

Татар мәдәнияте эшлеклеләрен һәм аларның эшчәнлеген барлап, «Әдәби сүзлек» төзегән Исмәгыйль Рәминең раславынча («Татарстан» ж., 1993, № 1, 86 бит), Габдрахман Ильясиның бабасы Әлдермештә гомер итә. Атасы Мөхәммәтдәмин хаҗи Казанда кызыл

малчы сәүдәгәр булып китсә дә, атасы йортына еш кайтып йөри. Шунлыктан яшь Габдрахманның да Әлдермеш һавасын сулавын, аның ризыгын җыюын, телеҗыры моңын күпмедер дәрәҗәдә шуннан алуын фараз кылу табигый.

Габдрахман белемен Казанның Күлбуе мәдрәсәсендә алуы да якташлары традициясенә туры килә. Билгеле, зиһенле һәм эзләнүчән бала буларак, ул шушы иске типтагы мәдрәсә гыйлеменә генә канәгатьләнеп калмаган, заманаиың бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйри белән танышып, аның йогынтысында дөньяви белем эстәүгә дә күңелен биргән. Үзлегеннән һәм укытучы яллап урысча өйрәнгән, урыс театры спектакльләренә йөргән һәм дөнья күтәргә яраклы әзерлек бирә торган китаплар белән танышкан. К. Насыйри кебек, матур язу, рәсем ясау һәм балта эше һөнәрләрен дә үзләштергән. Бөек мәгърифәтче белән авылларга йөреп, халык иҗаты үрнәкләрен җыюда да катнашкан, туган ягы һәм халкының тарихы белән дә җитди кызыксынган. Шунлыктан ул Казан археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә әгъза итеп алынган, аның утырышларында катнашып, үзе дә чыгышлар ясаган. Мисалга, аның Казанга Пугачев явы килүе хакында бер татар кульязмасын табуы һәм шул турыда җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирүе заманының урыс матбугатында да теркәлеп калган.

Сәүдәгәр Мөхәммәтдәмин Ильяси бөлгенлеккә дучар булып, шактый бурычын улы җилкәсенә калдырып, 1883 елда вафат булгач, укымышлы Габдрахманның тормышы бик нык кысенлаша — ул барлык мирас малны атасы бурычын түләүгә тотып бетерә дә, үзе башка байларга кәнсә-хисап эшләрен башкаручы сыйфатында ялланып яшәргә мәҗбүр була. Шулай да ул мәгърифәтчелек эшчәнлегеннән баш тартырга теләми — сиксәненче елларда татарча газит чыгарырга омтылыш ясый. Патша хөкүмәтенең колонизаторлык сәясәте моңа юл куймагач, ул хәленнән килгәнен эшли — 1886 елда туган телендә беренче сәхнә әсәре булган «Бичара кыз» драмасын яза һәм аны киләсе елда бастырып чыгара. Шул ук 1887 елда «Яшь кыз вә хатыннарга һәдия» китапчыгын да нәшер иттерә. Шиһаб Мәрҗанинең «Мөстәфадел әхбар»ы дөнья күргәч, ул урыс җәмәгатьчелеген шуның белән таныштыруга көчен сала — махсус доклад сөйли.

«Бичара кыз» драмасында Г. Ильяси кадимчелеккә нәфрәт уяту, шәхес иреген, кешелеклелек һәм азатлык фикерләрен һәм гамәлләрен яклаучы буларак чыгыш ясый. Татар җәмгыятендә яңалыкка юл ачу, хатын-кызларның ирләр белән тиңлегенә ирешү кирәклеген тамашачыларга да сеңдерү бурычын куя. Аның пьесасында Казан арты сөйләшенә хас үзенчәлекләр дә чагыла.

Габдрахман Ильяси беренче сәхнә әсәре иҗат итеп, татар драматургиясенә яңа көчләрнең килүенә илһам һәм этәргеч бирә, театр сәнгатебезнең аякка басуына беренче нигез ташын сала. Хөрмәтле драматургның тормыш юлын һәм иҗатын яшь буынга таныту юлында Мөхәммәт Гайнуллин, Латыйф Җәләй байтак эш башкара, Г. Ильяси хезмәтләре татар әдәбияты дәресләрендә өйрәнелә.

* * *

Биектау төбәгенең иң якты йолдызлары — Ташсу авылыннан күтәрелгән Максудилар. Бу атаклы нәселнең хәзер инде ун буыны җәмәгатьчелеккә билгеле дип әйтергә мөмкин. Мәгълүм шәҗәрәнең тамыры — Булат. Аның улы — Исмәгыйль, Исмәгыйль улы — Корбангали, Корбангали улы — Максуд, Максуд улы — Гайнетдин, Гайнетдин улы — Низаметдин. Менә шушы Низаметдин мулла Максуди туган халкы иҗтимагый тормышында күренекле урын тотачак ике ул (уртанчы улы Салихҗан сәүдәгәрлекне сайлый — Печән базарында кибет тота, тире, күн әйберләре белән сату итә) үстерә. Аларның өлкәне Әхмәтһади (1868—1941), башлангыч белемне атасыннан алганнан соң, укуын 1881 елдан Казанның Күлбуе мәдрәсәсендә дәвам итә. Шунда укыганда Кырымда чыгарылган «Тәрҗеман» газите һәм Төркиядән килгән вакытлы матбугат, китаплар белән дә тынышып бара, хосусый укытучыдан урыс телен өйрәнә, тагын бик күп нәрсәләр белән кызыксына. 1894 елда исә Истанбулга китеп, анда алты ел буе белемен тулыландыра. Кайту уңаенда Кырымда тукталып, Бакчасарайның «Зынҗырлы» мәдрәсәсендә гарәп теленнән сабак бирә. Монда ул урыс телен өйрәнүгә дә күп көчен сала.

1902 елда Казанга өйләнеп кайткач, Әхмәтһади экстерн тәртибендә урыс теле мөгаллимлегенә имтихан тота, аннары Казан университетының тарих-филология факультетында ирекле тыңлаучы булып дәресләргә йөри.



*Әхмәтһади Максуди*

1906—1918 елларда Әхмәтһади «Йолдыз» газитен чыгарып, укучыларга киң таныла. Демократик рухта һәм халыкчан телдә нәшер ителгән бу басма тиз арада иң күп тарала торган газиткә әйләнә. «Ят кавем» телендәге вакытлы матбугатка патша цензурасы аеруча каныккан, тырнак астыннан кер эзләү белән шөгыльләнгән шартларда «Йолдыз»ны өзлексез чыгарыр, аны яптырмас өчен, Әхмәтһадига гадәттән тыш саклык, сәяси уяулык күрсәтергә туры килә. Моның өчен аны бер яктан суллар тәнкыйтьли, икенче яктан уңнар канәгатьсезлек белдерә. Әмма бу дәвердә әнә шундый урта юлдан бару гына «Йолдыз»ны вакытсыз ябылудан коткара һәм ул күпчелек укучылар өчен файдалы мәгълүмат һәм хәбәр чыганагы булып чыга ала.

Әхмәтһади Максудига аеруча киң танылу китергән икенче хезмәт татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен дәреслекләр иҗат итү була. Аның «Мөгаллим әүвәл» китабының утыздан артык басмасы дөнья күрә — шушы әлифба буенча татарлар гына түгел, күп кенә кардәш халыкларның да яше-карты укырга-язарга өйрәнә. Әхмәтһади абзый әлеге әлифбасыннан тыш, туган теленең байтак грамматика китапларын, гарәп, урыс, француз телләре үзөйрәткечләрен дә яза. Ул шушы дәреслекләре белән туган халкы арасында җәдит мәктәп-мәдрәсәләре ачылуга, аларның киңәюенә тиңсез өлеш кертә. Ул хәтта җәдитчелек җәелүенә байларның матди ярдәм күрсәтүенә дә ирешә. Аның туган тел грамматикасы дәреслекләре заманы өчен иң уңышлы беренче хезмәтләрдән санала.

Эшчәнлеге менә шулай ташкын кебек көчле дәвам иткәндә, илдә революция була. «Буржуаз эшлекле» дигән ярлык тагылган мәгърифәтче, ничек кенә сак эш итмәсен, советларның салкын мөнәсәбәтенә дучар була. Мулла баласына әкренләп эшчәнлеген даими тарайтырга туры килә. Әмма канына сеңгән саклыгы аны рәхимсез нахак җәзалардан өлешчә саклап кала. Ул сәясәткә күпмедер җайлашырга мәҗбүр булса да, күпчелеккә файдалы эшләрен дәвам итәргә тырыша — энциклопедик төстәге зур күләмле атамалар сүзлеген төзи һәм бастырып чыгара. Мәгърифәтче Әхмәтһадиның төрле тармакларда аң-белем бирә торган бүтән хезмәтләре дә дөнья күрә. Аның шушы эшчәнлеген замандашлары югары бәяли. Билгеле, ясалма киртәләр куелмаса, ниятләренә аяк чалмасалар, Әхмәтһади Максуди иҗат дәрте ташып, белеме тирәнәеп җиткән дәвердә тагын да күбрәк эш күрсәтә алган булыр иде. Әмма ул, яхшыга өметләнеп, революциядән соң да ватанында кала. Милли матбугатыбыз, мәгарифебезне үстерүдә сәләтен тулысынча ачарга өлгермәсә дә, аның мирасы безнең кадерле хәзинәбезне тулыландырып, үсешебезнең кыйммәтле этәргече икәнлеген даими исебезгә төшереп тора.

Күлбуе мәдрәсәсендә кардәшләрнең кечесе Садретдин (5.VIII.1879—20.II.1957) дә укый — 1888—1895 елларда ул монда дин гыйлеме, гарәп-фарсы телләрен үзләштерә. Абыйсы Кырымга кайтып урнашкач, Садрый да «Зынҗырлы» мәдрәсәсенә барып, ел буе урыс теленнән сабак ала. Шул әзерлек аңа 1897 елда Казанда Укытучылар мәктәбенә укырга керергә мөмкинлек бирә. 1898 елда шушында Күлбуе мәдрәсәсенең икенче бер сәләтле шәкерте Гаяз Исхакый да белемен күтәрә башлый. Мәдрәсәдә чакта ук К. Насыйри һәм бүтән галим, язучыларның әсәрләре белән танышырга өлгергән егетләр, Укытучылар мәктәбендә укыганда урыс һәм Европа халыклары әдәбияты белән тагын да ныграк мавыгалар һәм үзләре дә беренче иҗат тәҗрибәләрен ясыйлар. Әнә шулай Садрый Максудиның «Мәгыйшәт» («Тормыш») романы дөньяга килә.

1901 елда Учительская школаны тәмамлаган Садрый белем алуын дәвам итәргә теләп, Төркиягә китә — Истанбул шәһәрендә бер елга якын француз, латин телләрен өйрәнә. 1902 елда Парижның Сорбонна университетына керүгә ирешә. Монда ул берьюлы хокук һәм әдәбият факультетларында укый. Дүрт ел



*Садрый Максуди*

дәвамында зур тырышлык куеп, юрист дипломын ала.

1906 елда иленә кайткан С. Максуди Икенче Дәүләт Думасына депутат итеп сайлана, ләкин ул монда эш күрсәтергә өлгерә алмый кала — бу Дума өч ай унике көн генә яши. Садрый Өченче Думага да үтә — монысы 1907—1912 елларда эшен уңышлы дәвам итә. Монда ул хөкүмәтнең эчке һәм тышкы сәясәтен тәнкыйтьләп байтак чыгышлар ясый — империядәге мөселманнар хокукын якларга тырыша. Шушы дәвердә Дума вәкиллеге эчендә Англиягә бара (1909), юл тәэсирләрен 1912 елда китап итеп басылган «Англиягә сәяхәт» әсәрендә тасвирлый. 1913 елда Рәсәйдә дә юрист дипломы танылсын өчен, урыс телендә университет программасы буенча имтихан тота һәм Казанда адвокат ярдәмчесе булып эшли башлый.

1911 елда мәшһүр миллионер Шакир Рәмиев кызы Камиләгә өйләнгәч, Садрыйның татар байлары катламы алдында да абруе күтәрелә. Әмма 1913—1917 елларда ул сәясәт һәм матбугаттан ерак тора. Вакытлы хөкүмәтнең «Төркестан комитеты»нда бераз эшләп алгач кына, милли хәрәкәткә катнашып китә. Мәскәүдә узган Мөселман корылтаенда катнаша алмаса да, аны Мөселман Үзәк Бюросына сайлап куялар. Җәен ул Рәсәй мөселманнарының «Милли-мәдәни автономиясе» проектын яза. Икенче Мөселман корылтае Эчке Рәсәй һәм Көнбатыш Себер вәкилләреннән генә тора, алар Максуди проектын хуплый. Аны гамәлгә ашырыр өчен Автономия комитеты сайлана, Садрый Максуди аның рәисе итеп билгеләнә. Эчке Рәсәй һәм Себер төрек-татар Милли Мәҗлесе С. Максуди җитәкчелегендә Милли Идарә сайлый, ул өч министрлыктан корыла. Бу Идарә өч ай алты көн генә яши — Советлар аны тиз арада гамәлдән чыгара — өч министрлыктан Мөселман Диния нәзарәте генә танылa. С. Максуди Мәскәүгә барып Советлар карарына протест белдерсә дә, кулга алынганчы, Нижгар ягы татар авылларына китеп югалуны хуп күрә, аннары Мәскәү һәм Петроград аша яшерен төстә, Петроград мулласы Муса Бигиев ярдәмендә, 1918 елның җәендә Финляндиягә качып китә.

Садрый әфәнде Финляндиядә ун ай чамасы яшәгәч, Франциягә барып урнаша. Вакыт-вакыт Берлиндә яшәп алгаласа да, 1925 елга кадәр ул Парижда тора һәм Сорбонна университетында укыта, төркиләр тарихын, мәдәни истәлекләрне өйрәнү һәм тикшерү белән шөгыльләнә. Шул дәвердә Эчке Русия мөселманнары автономиясен яклау буенча халыкара конференциягә документлар әзерләп бирә. Франция һәм Төркия матбугатында гыйльми мәкаләләр бастыра, Төркиягә барып лекцияләр дә сөйли. Ул шулай Төркия президенты Мостафа Кәмал Ататөрекнең дә игътибарын җәлеп итә һәм 1925 елда, аның тәкъдиме буенча, Анкарага күчеп килә. Монда төрле комиссияләр эшендә катнаша, хокук фәнен укытуга җәлеп ителә. 1930—1934, 1934—1938, 1950—1954 елларда өч тапкыр Төркия парламенты депутаты итеп сайлана, милләт вәкиле буларак, халыкара конгрессларга җибәрелә. Әнә шулай ул Төркияне яңарту хәрәкәтендә актив катнаша. Анкара университетында — унсигез, Истанбул университетында ике ел укыта. Шул дәвердә хокук, тарих, тел һәм башка темаларга багышланган күп кенә хезмәтләр язып бастыра. Ататөрекнең киңәшчесе, дәүләт һәм җәмәгать эшләрен башкаручы, аерым алганда, Төрек тарих корымын (тармак академиясе!) төзүне башлап җибәргән була.

С. Максудиның барысы 16 исемдә китаплары басыла, шуларның икесе — Казанда, калганнары Төркиянең Анкара һәм Истанбул шәһәрләрендә дөнья күрә. Аларның кайберләре исә ике-өч тапкыр нәшер ителә.

С. Максуди каләм эшчәнлеген язучы һәм журналист сыйфатында башлап җибәрә, соңрак ул төп игътибарын хокук мәсьәләләренә юнәлтә, бигрәк тә төрки халыкларның хокукый төшенчәләрен, чыгарган кануннарын өйрәнүгә зур

илтифат күрсәтә, шушы өлкәдә төпле тикшеренүләр алып барып, «Фарабиның хокук фәлсәфәсе» (1945), «Төрек тарихы вә хокук» (1947), «Төрек хокукы тарихы» (1928) монографияләрен иҗат итә, шуның белән бергә, ул бай халыкара тәҗрибәне истә тотып, төрек телендә университетларда укытыр өчен «Хокук тарихы дәресләре» (1927), «Хокукның гомуми әсаслары» (1937), «Гомуми хокук тарихы» (1941) хезмәтләрен бастырып чыгара. Тел, тарих, фәлсәфә буенча да әһәмиятле тикшеренүләр ясый һәм шушы тармакларда Төркия иҗтимагый фикере, дәүләт төзелеше сәламәт нигездә үсә һәм алга китә алсын өчен, җәмәгатьчелек югары бәя биргән китапларын нәшер итә. «Котадгу белег» (1947), «Төрек теле өчен» (1930), «Скифләр-сакалар» (1933), «Урта Азия түрек дәүләтләре» (1934), «Хокук фәлсәфәсе» (1946), «Миллият тойгысының социологик әсаслары» (1955), «Теократик дәүләт вә лаик дәүләт» (1940), «Инглиз гаммә хокукының үсеше сәхифәләре» (1940) нәкъ менә шундыйлар хисабына керә. Аның вакытлы матбугатта басыла торган күп санлы мәкаләләрен Төркия җәмәгатьчелеге һәрвакыт игътибар белән каршылый, авторны хуплап яки аның белән бәхәскә кереп, С. Максуди күтәргән мәсьәләләрнең актуаль һәм әһәмиятле булуын раслый.

С. Максуди сәләтенең университет укытучысы, кыю тикшеренүче, дәүләт сәясәтчесе вазифаларын үтәүгә, җәмәгать эшләрендә катнашуга җәелүе замандашлары һәм яшь буын тарафыннан югары бәяләнүен без аңа багышланып басылган махсус китаплар, вакытлы матбугатта чыккан күп санлы мәкаләләрдән күрә алабыз. Алар төрек, инглиз, фин, француз телләрендә тәкъдим ителә, бу язмаларның авторлары арасында күп кенә төрки халыкларның күренекле эшлеклеләрен очратырга мөмкин. Атаклы төрек язучысы Пәями Сафа, төрек профессорларыннан З. Фындыкуглы, Ә. Әрҗиласун, Ә. Кабаклы, Х. Иналчык, румыйнияле М. Өлкесал, кырымлы Җ. Сәетәхмәт, кафказлы Кадыйрҗан, төркестанлы М. Чокай, милләттәшләребездән Г. Исхакый, Г. Баттал, Х. Кошай, Ә. Курат, Н. Дәүләт һ. б. С. Максуди хезмәтләрен танытуга зур игътибар бирә. Г. Айда «Садрый Максуди Арсал» (Анкара, 1991) китабын «Төрек бөекләре сериясе»ндә бастырып чыгара, Габделбари Баттал «Ике Максуди» (Истанбул, 1959) әсәрен нәшер иттерә. С. Максуди исеме соңгы дәвердә дөнья күргән барлык төрек энциклопедияләрендә лаеклы урын алып килә.

Мөһаҗир милләттәшебез, мәгълүм сәбәпләр аркасында, ватанында җитмеш ел чамасы телгә алынмады, алынган хәлдә милләтче, совет дошманы, буржуа эшлеклесе итеп танытылып киленде. Күяшны иләк белән томалап булмаган шикелле, Садрый Максуди исемен дә мәңге каралтып тору мөмкин түгел иде. Аның «Мәгыйшәт» романы һәм «Англиягә сәяхәт» әсәре «Казан утлары» журналында, кайбер бүтән хезмәтләре шулай ук вакытлы матбугатыбыз битләрендә укучыларга тапшырылды. С. Максудиның эшчәнлеге белән таныштыруга Я. Абдуллин, И. Таһиров, Ә. Кәримуллин һ. б. инде байтак тырышлыгын җикте, без хәтта күренекле шушы шәхесебезгә багышлап махсус гыйльми җыйналышлар уздыруга да ирештек. Ләкин бу әле эшнең башы гына. С. Максуди мирасын халкыбызга тулырак күләмдә кайтару — киләчәктәге бурычыбыз.

Үзе дә изелгән бер халыкның улы булган кешенең, Рәсәй парламентында агрессив омтылышлар ясалганда, финнәрнең автономиягә хокукы барлыгын, Төркия җирен басып алуның әхлаксызлык, тарихи гаделсезлек булачагын кыю рәвештә исбатлап чыгыш ясавын Финляндия һәм Төркия җәмәгатьчелеге бүген дә онытмый. Әсирлектә калган халыкның улы беркайчан да бәйсезлеген югалтмаган дәүләткә барып урнашып, аның гуманитар фәннәрен ныклы нигезгә куеп, үсешенә кыйммәтле өлеш кушкан, Төркия Җөмһүриятенең дәүләт сәясәтен дөрес юлдан алып баруда президент Ататөрекнең терәге булган. Үзара капма-каршы рухтагы ике зур мәмләкәтнең парламентларына җәмгысе биш мәртәбә сайлана алган шәхес тарихта бүтән бармы икән? Мин белмим. Менә шуның өчен дә Садрый Максуди исеме безнең өчен кадерле, биектаулыларның гына түгел, бөтен татар халкының горурлыгы булып тора.

С. Максуди Гадилә һәм Наилә исемле ике кыз үстерә, шулардан Гадилә Айда (1913—1992) атасы юлыннан китеп, байтак уңышларга ирешә. Ул да, Анкара университетында белем алганнан соң, атасы кебек, Сорбонна университетына юнәлә. Соңыннан тел, әдәбият, тарихка караган хезмәтләр яза һәм вакытлы матбугатта бастырып чыгара. Төрек һәм француз телләрендә унике китап нәшер иттерүдән тыш, ул озак еллар Анкара һәм Истанбул университетларында укыта һәм доцент дәрәҗәсен казана. Француз әдәбияты белгече Гадилә ханым Төркиянең беренче хатын-кыз дипломаты булып танылa — Италиядә Төр-

кия илчесенең киңәшчесе була. 1976 елда сенаторлыкка сайланган Г. Айда ике бала үстерә.

Садрый Максудиның оныгы Гөнүл Пултар да бабасы юлыннан киткән— ул Анкара университетында укыта, бер үк вакытта иҗат белән дә шөгыльләнә— 1979 елда «Дөнья—бер кәмит» романын бастыра, аның башка әсәрләр язуы да билгеле.

Садрый Максудига да, аның кызларына да ата-баба туфрагына баш ию совет дәверендә мөмкин булмый. Әмма Гөнүл ханым балалары белән һәм С. Максудиның кызы Наилә Турханнан туган оныклары Татарстанны күрә алдылар. Г. Пултар ханым бабасы хөрмәтенә уздырылган симпозиумда катнашып, башкалабызда тирән эчтәлекле доклад та сөйләп китте. Яшь буынның Биектау төбәгенә, Ташсу авылына аяк басуы киләчәктә дә дәвам итәр, дип өметләнәбез.

* * *

Тамыры тирәнгә киткән һәм нык булган агач тиз һәм куәтлерәк үсә, корылыкка да, җил-давылларга да бирешми. Халык та шулай. Тарихи хәтере ераграк дәверләргә тоташкан саен, аның тормыш тәҗрибәсе юмартрак байый, гореф-гадәтләре, теле һәм мәдәнияте тотрыклырак үсә, шуның нәтиҗәсендә аның тышкы басымга карышу көче дә дәрманлырак һәм дәртлерәк баскычка күтәрелә.

Миссионер Николай Ильминскийның (В. Ульянов-Ленинның чукындырган атасы, гаилә дусты) азчылык халыкларны христианлаштыру һәм урыслаштыру программасын, бераз иннек-кершән ягып, гамәлгә алган большевиклар, Совет хакимияте менә шуның өчен дә татарның тарихи хәтерен җуярга ашкынды— аның барлык прогрессив казанышлары Октябрь революциясеннән соң гына барлыкка килә, диюгә кадәр барып җитте. Кайбер «белгечләр» яшь буыныбызга: «Революциягә кадәр татар телендә китаплар басылмаган», дип кабатлаудан да оялмады. 1917 елга кадәр миллионнарча тираж белән унбиш мең чамасы исемдә татар китабы нәшер ителгән хәлдә, шул китапларны язучылар яки чыгаручылар, аларны укучылар исән чакта! Әлеге укучыларның һәммәсен тиз арада юк итеп бетерү ансат түгел иде, әмма язучыларын һәм нәширләрен гүргә кертү ашыгыч тәртиптә башкарылды. Шуның аркасында татарның берничә буыны кадерле затларын оныта башлау гына түгел, тарихы белән кызыксынуын да йомарга, туктатырга мәҗбүр булды.

Мәмдәл авылында XIX йөздә Мөхәммәтзыя Бәхтияр улы яшәгән, заманның әгъләә укымышлысы булган. Милләттәшләренә хаҗәт белемне бирергә омтылып, 1897 елда ул «Арифметика» дәреслеген язган (Кульязмасы КДУның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана). Атамаларны гарәпчә куйса да, бу китап укучыларга туган телебездә математикадан башлангыч белем бирергә тиеш була. Кайчан туган Мөхәммәтзыя әфәнде, ничәнче елга кадәр яшәгән, тагын нинди хезмәтләр иҗат иткән? Кызганыч ки, кызыксынуларыбызны кандырырлык мәгълүматлар юк.



*Салих Сәйдәшев*

Ярый әле 1917 елда бәхетле Совет дәвере башланган, шул заманда сәләтләре ачылган шәхесләргә беркадәр илтифат күрсәтү рөхсәт ителгән! Өбрәдә нигезләнгән Салих Сәйдәшев (1900—1954) музее менә шуңа мисал булып тора.

«Казанда туган» дип танытылган сөекле композиторларыбызның тамырлары ничек шушы авылга тоташуы Өбрә музеенда шактый тәфсилле күрсәтелә. Музей бер генә бүлмәне тәшкил итсә дә, анда С. Сәйдәшевнең

кайбер шәхси әйберләре, документларының һәм әсәрләренең фотокүчермәләре, атаклы композиторга баглы китаплар һәм вакытлы матбугат үрнәкләре тупланган. Композитор кайтып йөргән йорт, Салих әфәнденең кардәшләре һәм аралашкан танышлары хакында да мәгълүмат табарга мөмкин монда. «Маяк» күмәк хуҗалыгы (рәисе — Маннаф Сәгъдиев) корган, Республикабыз мәдәният министрлыгы һәм Казандагы С. Сәйдәшев музей-фатиры булышлыгында экспонатлар җыйналган бу хәтер йорты күңелдә матур хисләр уята. С. Сәйдәшев тормыш һәм иҗаты җәмәгатьчелеккә яхшырак билгеле булганлыктан, ул турыда җәелеп язуның хаҗәте юктыр дип уйлыйм. Халкыбызның рухын күтәргән, музыйка сәнгатебезнең алтын хәзинәсенә кергән кайбер әсәрләрен санап китү исә, мөгаен, артык булмас. Кәрим Тинчуринның «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе», Хәбибулла Ибраһимовның «Башмагым», Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану», Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә», Таҗи Гыйззәтнең «Наемщик», «Изге әманәт» һәм башка күп кенә әсәрләргә — җәмгысе илледән артык пьесага нәкъ менә С. Сәйдәшев музыйка яза, тамашачылар аның талантына әле бүген дә бик рәхәтләнеп кул чаба. Композиторның «Тукай маршы», «Совет Армиясе маршы» һәм байтак сандагы җырлары шулай ук күпләрнең яраткан әсәрләре булып күңелләрдә яши. Татарстанның халык артисты исемен казанган композиторыбыз иҗаты чәчәк аткан көннәрдә вакытсыз рәвештә арабыздан китә.

Өбрәгә күрше Әлдермеш авылы — күренекле композиторыбыз Әнвәр Бакировның (7.VII.1920) ата-бабалары гомер иткән җир. Хәер, ул үзе дә шушында балачагын үткәрә (1924—1934) — гаиләләре белән кире Әлдермешкә әйләнеп кайткач, атасы Закир абзый сельпода, абыйлары мәктәптә эшли башлый. Аларның гаиләсендә берәр уен коралында көй чыгара белмәгән кеше булмый, шунлыктан Әнвәр дә бик яшьли музыйкага хиресләнеп үсә, сигез яшендә үк спектакль куюда катнаша башлый. Авыл белән бәйләнешен гомер буе өзмәве аңа милли моңнарны, милли тормыш сулышын җанына тирән сеңдерергә бай мөмкинлек бирә — шуның нәтиҗәсендә композиторның иҗаты халыкчан аһәңнәргә бай сыйфатта үсеп җитлегә.



*Әнвәр Бакиров*

Тулы профессиональ белем алган Ә. Бакиров музыйканың төрле жанрларында уңышлы әсәрләр иҗат итә. «Кемгә сөйлим», «Әниемнең җылы кочагы», «Әйткән идең», «Әгәр белгән булсам», «Тамчылы гөл», «Кыр казлары киткәндә», «Мәк чәчәге» — ул язган җырлар өч йөздән артык. Моннан тыш, төрле уен коралларында башкарыр өчен сонатина, сюита һәм пьесалар да, симфоник әсәрләр дә, «Су анасы» балеты һәм «Гөлзадә», «Тукай» опералары да туа аның каләменнән. Мәктәпләр өчен музыйка дәреслекләре һәм методик кулланмалар да яза, вакытлы матбугатта музыйка темасына мәкаләләр дә бастыра. Аның әсәрләре авыл һәм шәһәр сәхнәләрендә, радиотелевидениедә, якташы С. Сәйдәшевнеке кебек, бик еш яңгырый. Унбишләп җыентыгы Татарстан китап нәшриятендә, «Су анасы» балеты һәм тагын кайбер әсәрләре Мәскәүнең «Музыка» нәшриятендә дөнья күрә. Композиторның «Су анасы» балеты тамашачыларның кайнар мәхәббәтен яулап алып, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була. Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Ә. Бакировның якты иҗаты бүген дә уңышлы дәвам итә. Шунысы игътибарга лаек: үзенә танылу китергән беренче әсәрен — «Иртәнге серенада» көен ул якташы Хәй Вахит сүзләренә 17 яшендә язган була!

«Маяк» күмәк хуҗалыгы күптән түгел Әлдермеш авылы уртасында ике катлы, зур залы һәм дистәгә якын кечерәк бүлмәләре булган затлы мәчет корып өлгертте. М. Сәгъдиевнең әйтүенчә, аның икенче катында авыл тарихы музее

урнашачак. Анда инде күпләрнең горурлыгы булган Г. Ильяси, Ә. Бакиров һәм башка күренекле шәхесләрнең тормыш һәм иҗат юллары, казанышлары лаеклы рәвештә күрсәтелер. Әлдермешлеләрнең соңгы елларда игенчелектә һәм терлекчелектә, көнкүрешне уңайлаштыруда ирешкән сокланырлык казанышлары тиздән рухи тормышка да үзгәрешләр кертәчәгенә өмет ула.

Татар: «Ат аунаган җирдә төк кала», диярге ярата. Г. Ильясиның Әлдермешеннән ерак түгел урнашкан Мәмдәл авылында күренекле драматургыбыз Хәй Вахитның (1918—1978) тууы шушы әйтемне куәтли шикелле.

Г. Ильяси беренче сәхнә әсәребезне язса, Х. Вахит инде якташы эшен яңа заманда дәвам итә һәм, профессиональ осталыкның биек үрләренә күтәрелеп, татар драматургиясен СССРның дистәләрчә милли театрлары сәхнәләренә алып менә. Тамашачыларыбыз театрга сусыган илленче еллардан соң Хәй Вахит әсәрләре милли сәхнәбезгә дәртле сулыш өрә — Мәмдәл егете алтмышынчы-җитмешенче еллар дәвамында берсеннән-берсе кызыклырак пьесалар язып, тамашачыларның яңадан театрга кайтуына сәбәпче була.

Х. Вахитның иҗади уңышы, табигый сәләтеннән тыш, бай тормыш тәҗрибәсенә һәм киң кырлы, тирән профессиональ белем алуына да бәйләнгән. Театр һәм музыйка училищеләрендә, Казан консерваториясендә һәм Мәскәүдәге ике еллык Югары әдәби курсларда уку, мөгаллим, җырчы, фронтта тупчы булып хезмәт итү аның үзенчәлекле шәхес, кызыклы фикер иясе сыйфатында җитлегүен тизләтә. Шигырьләр һәм поэмалар, балалар өчен сәхнә әсәрләре язу аны киң колачлы җитди иҗатка әзерли. Х. Вахитның сәхнәләребездә уңыш казанган барлык әсәрләрен санап тормастан, «Беренче мәхәббәт» һәм «Күк капусы ачылса» пьесаларын телгә алу да җитәр кебек. Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган «Беренче мәхәббәт» пьесасы йөзләрчә мәртәбә уйналып, яңа буын тамашачыларның да игътибарын җәлеп итеп килә.

Биектау төбәге әдәбият-сәнгатебезгә яңадан-яңа иҗади көчләрне тудыруы белән хаклы рәвештә горурлана ала. Олы Солабаштан шагыйрь Галимҗан Мөхәммәтшин (1911—1941), Кече Битаманнан Габдулла Шәрәфи (1926), Рафис Корбанов (1957), Кече Кавалдан Альберт Хәсәнов (1937), Суыксудан Солтан Шәмси (1956), Бикнараттан Зиннур Хөснияр (1961) да әдәбият сөючеләргә байтактан таныш. Музыйка уен кораллары ясавы, җыр-көйләребезне сакчыл җыйнавы белән мәшһүр Гыйләҗетдин Сәйфуллин (1884—1946) Иске Рәс авылында туган. Милли театрыбызның беренче карлыгачларыннан Ситдыйк Айдаров (1895—1938) әнисе аша Чыршы авылына, академик, Казагыстан ФА вице-президенты Шәүкәт Ибраһимов (1923—1989) Өбрәгә, СССР халык артисты Азат Аббасов (1925) Курсага тоташкан. Биектау төбәге музыйкант Ярулла Әхмәдуллин (Кече Солабаш, 1906—1976, Казан), Татарстанның атказанган артисты Асия Харисова (Өмбә, 1923), Татарстанның халык артисты Клара Хәйретдинова (Өнсә, 1948) кебек сәхнә осталарын, радио-телевидениебезгә Татарстанның һәм Рәсәйнең атказанган мәдәният хезмәткәрләре Бибикамал Саттарова (Торнаяз, 1923—1985, Казан), Әминә Сафиуллина (1925, Ямаширмә) шикелле дикторларны да бирде ич әле. Бу якта туып-үскән игелекле җаннардан авыл хуҗалыгы, сәнәгать, табигать һәм башка фәннәр өлкәсендә җитешкән галимнәрне, дәүләт эшлеклеләрен, әйтик, Айбаштан контр-адмирал Исхак Исламов (1865—1923), Ямаширмәдән СССР Герое исемен татарлар арасында беренче булып алган Гыйльфан Батыршин (1914—1947)[1], Татарстан премьер-министрының урынбасары Илгиз Хәйруллин (1940) исемнәрен дә онытмаска кирәк. Аларның һәммәсенә җентекләбрәк тукталынса, бу язмам бик озынга китәр иде. Шулай да атаклы Габәшиләр нәселеннән Рөстәм Солтан улының тарих фәннәре кандидаты, Кодаштан Фирдәвес Гарипованың филология профессоры һәм күп кенә китапларның, фәнни хезмәтләрнең авторы икәнлекләрен искәртмичә, сәнгать фәннәре докторы Фуат Хөсәен улы Вәлиев хакында кинрәк мәгълүмат бирмичә мөмкин түгел.

Кече Кавалда туган Ф. Вәлиев (1921—1984) Казан артының үткәнен, рухи һәм матди казанышларын җентекләп өйрәнгән галим иде. Туган ягының халкыбыз тарихында тоткан урынын калку күрсәткән хәлдә, ул татарның гомүм үсешен, һөнәрчелеге һәм сәнгате үзенчәлекләрен ачуга бөтен йөрәк ялкынын биреп эшләде. Мәскәүдә билгеләнгән дәрәҗәләр баскычы буенча өченче сортлы, ягъни чикләнгән автономиягә генә ия милләтнең зур тарихы да, матур казанышлары да булырга тиеш түгел дип хисапланган дәвердә Ф. Вәлиев эшчәнлеге алтмышынчы елларда ук кайбер уяуларда шик-шөбһә уята. Аның Казанда эшләп

[1] Донбасста (Голубовка руднигы) туа. Ямаширмә — ата-анасы ватаны, шунда кайтып йөри.



*Фуат Вәлиев*

торган бердәнбер мөселман гыйбадәтханәсен — Мәрҗани мәчетен яңартуда, аңа янкорма салуда архитектор буларак катнашуы Алласыз хакимиятнең отыры ачуын кабарта. Шунлыктан аның «Казан татарлары орнаменты» (1969) монографиясе төрлечә һәм бик озак аяк чалулардан соң, нәзек иләктән иләнеп, зур кыенлык белән генә дөнья күрә. Көчәя барган эшчәнлегендә милләтчелек «микроблары» барлыгын тойган мәгълүм оешма бераздан аңа каттый таләп куя: «Казаннан күчеп киткән хәлдә генә күзәтү астыннан чыгачаксың, гыйльми тикшеренүләреңә шул чакта гына иркен юл ачылачак». Республикабызда милли сынлы сәнгатебез буенча әзерлекле бердәнбер татар галиме әнә шулай Татарстанны ташлап китәргә мәҗбүр ителә.

Тарих фәннәре кандидаты Фуат әфәнде шуннан соң Йошкар-Олага барып урнаша, мари халкы сәнгатен өйрәнергә керешә. Әмма ул монда да Казанда башлаган эшләрен дәвам итү әмәлен таба, Йошкар-Олада дөнья күргән «Урта Идел буеның борынгы һәм урта гасырлардагы сәнгате» (1975) монографиясенең төп өлешен татар кавеме казанышларын яктыртуга багышлый. Шушы ук елда Мари республикасы башкаласында «Казан татарларының архитектура-декоратив сәнгате» дигән зур күләмле тикшеренүен дә бастырып чыгара. Институтта укыту, мари сәнгать белгечләрен тәрбияләү белән бергә, ул монда докторлык диссертациясен дә язып тәмамлый. Әмма ул диссертацияне яклау чынлыкта күзәтү астында яшәүдән котыла алмаган галимгә яңа михнәт чигүләр аша гына мөмкин була — аны югары профессиональ әзерлеге, сокланмгыч тырышлыгы һәм юмарт табигый сәләте, максатка ирешү өчен үҗәт көрәшә белүе генә җиңүгә илтә.

Ниһаять, ул — сәнгать фәннәре докторы, татар мәдәниятенең тулы бер тармагын теоретик һәм гамәли яктан тирәнтен тикшергән, югарыда саналган монографиялардән тыш, матбугатта татар һәм урыс телләрендә йөзләрчә мәкалә бастырган, инде рәсми танылган бердәнбер зур абруйлы татар белгече. Татарстанга шундый зат, мөгаен, кирәктер, хәзер инде милли кадрга Казанда да юл ачылырга тиештер, дигән өмет белән Фуат әфәнде сиксәненче еллар башында туган ягына, даими фатиры булган башкаласына әйләнеп кайта. Әмма... Казан аңа мохтаҗ түгел икән! Аның докторлык диссертациясенә рәсми бәяләмә дә яза алмаслык кемсәләр татар сынлы сәнгате тарихын тикшерүгә бик тә житә икән!! Кыскасы, милли сынлы сәнгатебезне әтрафлы өйрәнгән беренче фән докторыбызга Казанның бер генә гыйлем учагында да урын табылмый — Ф. Вәлиев көч-хәл белән бер төзелешкә гади прораб булып кына урнаша ала. Татарстанда милли рухлы чын татар белгечләренә карата дистә еллар дәвамында тормышка ашырылып килгән мөнәсәбәт менә шундый була. Үзе кебекләрне әзәрлекләү сәясәтен яхшы аңлаганлыктан, Фуат әфәнде бөтен ихтыяр көчен бер йодрыкка туплап, төзелештәге вазифасын үтәүдән бушаган һәр минутын гыйльми тикшеренүләренә багышлый — «Татарстанның халык декоратив сәнгате», «Татарстанның борынгы сәнгате» хезмәтләрен яза, ул хезмәтләр өчен гадәттә лаборантлар әзерләргә тиешле барлык сурәт, схемаларны үз кулы белән генә ясый. Бу кыйммәтле хезмәтләр, автор дөнья куйганнан соң, 1984 һәм 1987 елларда Казанда басылып чыга һәм тиз арада кадерле рәсми кунакларга гына бүләк ителә торган затлы хәзинәгә әйләнә.

Казанда һәм Йошкар-Олада ара-тирә аралашып торган танышы буларак яхшы беләм: Фуат Вәлиев татар сынлы сәнгатен, һөнәрчелеген тикшерү һәм аны киң җәмәгатьчелеккә таныту буенча озак еллар буе тиисез эшләр башкарды, тарихыбызның байтак ак тапларын юкка чыгарып, ата-бабаларыбызның мәртәбәле казанышларын замандашларыбызга өлешчә булса да кайтарып бирүгә ирешге. Әмма аның ашкын ниятләре тагын да колачлырак, иҗади куәте бүтән

зуррак эшләргә дә житәрлек күләмдә мул иде. Ифрат кызганыч ки, тоталитар режим эскәнжәсендә бәргәләнгән татар жәмгыяте талантлы бу улына да канат жәеп ижат итәргә тиешле мөмкинлек тудыра алмады.

Безнең бер юанычыбыз бар хәер: галимнең тормышка ашмаган кайбер хыялларын чынбарлыкка әйләндерергә кызы үсеп житте. Сәнгать фәннәре кандидаты Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова борынгы һәм хәзерге казанышларыбызны өйрәнүдә атасы салган бәрәкәтле юлдан атлый, матбугатыбызда даими катнашып, Казанда гына түгел, ерак чит илләрдә дә халыкара конференцияләрдә чыгышлар ясап (инглиз телендә!), туган халкы сәнгатен киң дөньяга танытып килә.

Заманында матбугатта татар мәдәниятен, күренекле шәхесләребезне төбәкләп өйрәнү мәсьәләсе күтәрелгән иде. Бу эш дәвамлы һәм жентекле алып барылса, күңел күгебез яктырак, рухыбыз сәламәтрәк булачагы шиксез.

Биектау ягы — татар иленең нәни бер почмагы гына. Шулай да аның барлык йолдызларын бер язмада телгә алып бетерү мөмкин түгел. Әгәр башка тарафларга да күз салсак? Алар — күп, бик күп! Шуңа сөенеп, шулар нурында яктырып, шуларны маяк итеп яшисе иде безгә.

**Тәүфикъ ӘЙДИ.**
*фоторәсемнәр автор архивыннан алынды.*

## Әдипләр һәм журнал укучылар игътибарына

«Казан утлары» журналы язучылар тормышыннан төрле мәзәк хәлләр турындагы язмаларны байтактан урнаштырып килә. Алар, безнең карашка, әдипләр һәм укучылар тарафыннан да яратып кабул ителә. Быел исә без бу рубриканы «Имеш-мимеш түгел» дигән яңа исемдә һәм яңа бер шәкелдә яңартырга булдык. Хикмәт шунда, даими биреп барылачак бу сәхифәләрдә әдипләр үз тормышларында, дус-ишләре белән аралашуда, ижат процессында һәм укучылар белән очрашулар вакытында булган кызыклы хәлләрне нәни хикәячек-истәлек рәвешендә үзләре язарга тиеш дип фараз ителә. Аларның беренче һәм өченче заттан язылган булулары да ихтимал, күләме 1—1,5 биттән артык булырга тиеш түгел. Ә беренче сәхифәләр белән журнал укучылар көз айларындагы саннарда таныша алырлар.

Киләчәктә бу язмаларны туплап аерым китап итеп бастырып чыгару да күздә тотыла. Сездән кызыклы язмалар көтәбез, хөрмәтле язучылар!

P. S. Редакция шулай ук журнал укучылардан килгән язмаларны да укып өйрәнергә әзер.

*Редакция.*

## ӘДӘБИ МИРАС

Илбарис Надиров

# «ИДЕГӘЙ» ДАСТАНЫНЫҢ ШИГЪРИЯТЕ ТУРЫНДА

«КАЗАН УТЛАРЫ»Н ОЛУГ ЮБИЛЕЕ БЕЛӘН КОТЛАП...

**«Казан утлары» минем рухи тормышыма гыйбрәтле һәм файдалы йогынты ясаган бердәнбер журнал. Мин аны менә 48 ел инде даими рәвештә өемә яздырып укып киләм. Шушы вакыт эчендә шәхси хәзинәмдә журналның ярты меңнән артык саны җыелган. Аларның һәркайсында күңелемә кагылган, аңымны тирәнәйткән берәр әдәби әсәр яисә берәр мәкалә булмый калмады...**

**Ватан сугышында йөреп илгә кайткач, мин Казан университетының татар филологиясе бүлегенә укырга кергән идем. Сабакташым һәм дустым Нил Юзиев белән дүрт ел буена хосусый квартирада яшәдек. Ул елларда журналны («Совет әдәбияты» дип аталган чагы иде) бергә яздырып ала идек һәм үзебезнең беренче тәнкыйть мәкаләләрен дә бергәләп шул чорда яздык. Алар журналда басылып чыккач, без куанып туймый идек. Шулай итеп, ул елларда журнал безнең өчен үзенә бер иҗат мәктәбе дә булды, рәхмәт төшкере.**

**Университетны тәмамлагач, Тел, әдәбият һәм тарих институтының аспирантурасында укыганда, журнал белән бәйләнешем тагын да ныгыды. «Бөек Ватан сугышы чорында татар фольклоры» дигән диссертациямнең төп өлешләре журналда басылып чыкканнан соң, хезмәтемне Гыйльми совет алдында якларга да мөмкинлек туды. Ничек рәхмәт белән телгә алмыйсың журналның шул игелекле эшен!**

**Аннан соң инде кырык ел чамасы вакыт узган. Фольклор галиме буларак, шуны әйтә алам: «Казан утлары» татар халык иҗатына гомере буе тугрылыклы хезмәт итеп килә. Шул җәһәттән, «Идегәй» дастанын халыкка җиткерү тарихын искә төшерим. Халык иҗатының йөзек кашы булган әлеге тарихи-героик дастанның Нәкый ага Исәнбәт төзегән беренче зур җыйналмасын журнал 1940 елда ук бастырып чыгарган иде. Әмма ул чагында аңа китап булып чыгу бәхете эләкмәде, дастанны сәяси әзерләү эше башланды һәм ул кара чор илле елга якын «дәвам итте». Шуңа да карамастан, үз заманында журналны укыган кешеләр халык иҗаты мирасында «Идегәй» кебек гүзәл дастан барлыгын күңел түрләрендә сакладылар. 1988 ел ахырында «Казан утлары» дастанның кыскартылган вариантын матур рәсемнәр белән бизәп яңадан бастырды. Тагын бер кат ничек рәхмәт белән телгә алмыйсың журналның бу күркәм хезмәтен!**

**«Казан утлары» чит илләрдә гомер итүче милләттәшләребез турында да бай мәгълүмат бирергә омтылып яшәүче бердәнбер олпат журнал. Мин үзем, мәсәлән, журнал битләрендә Финляндиядәге татарлар хакында өч мәкалә һәм Хәсән Хәмидулланың «Тәкъдир каршында» дигән романын журналга әзерләп бирдем. Т. Әйди, Р. Батулла Төркиядәге татарлар тормышына багышланган кызыклы мәкаләләрен чыгардылар.**

**Белүемчә, редакциядә бу эшне һәрдаим хуплап, кочак җәеп каршылыйлар.**

**Форсаттан файдаланып, журнал укучыларына үземнең әлегә беркая да басылмаган һәм «Идегәй» дастанының шигърияtенә багышланган бер мәкаләмне тәкъдим итәм.**

«Идегәй» дастаны — Алтын Урда дәүләтенең аерым бер чорындагы (XIV — гасыр ахыры — XV гасыр башы) фаҗигале вакыйгалар вә шул вакыйгаларда катнашкан тарихи шәхесләр язмышы турында бәян итүче бөек бер әсәрдер. Әмма ул тарихи хроника да, елъязма да түгел. Ул ерак тарихның сәнгатьле бер авазы; аны укыганда күз алдында шул чал заманнарда бер-берләренә яу чапкан кабилә-кавемнәрнең фаҗигале язмышлары җанлангандай була, меңләгән атларның җирне тетрәткән тояк тавышлары ишетелеп куя, йөз меңләгән җайдакларның сөңге, уклары сызгыргандай, кылычлары чыңлагандай тоела. Андагы сурәтле сүз хәзинәсе төрки халыкларның Алтын Урда чорындагы көнкүреш төсмерләре, йолалары һәм ышанулары белән сугарылган. Аның олуг диңгезгә тиң шигърияте татар халкының чиксез бай тел бизәкләрен, хикмәтле гыйбарәләрен, мәкаль-әйтемнәрен, очкынлы сүзләрен үзенә җыйган.

Мәгълүм булганча, «Идегәй»нең татар, нугай, башкорт, каракалпак, казакъ, кырым татарлары һ. б. төрки халыкларда үз милли юрамалары һәм вариантлары бар. Шуның белән бергә, дастанның хикәяләү алымнарына да төрлелек хас. Вариантларның бер өлеше, эпик традицияләргә хас булганча, чәчмә хәлдә саклана, икенчеләрендә исә, чәчмә белән тезмә формалар аралашып бара. Аннары, «Идегәй»нең безнең көннәргә бары тик тезмә хәлдә килеп җиткән шигъри вариантлары да мәгълүм. 1941 елда Нәкый Исәнбәт төзүендә «Совет әдәбияты» журналында дөнья күргән җыйналма вариант һәм шуның нигезендә кабат редакцияләнеп, аерым китап рәвешендә 1988 елда Казанда басылган соңгы вариант шуларның берсе.

Татар халкының героик һәм тарихи дастаннары арасында «Идегәй» эпик традицияләргә аеруча бай булуы белән аерылып тора. Аның поэтикасын эпос кануннары билгели. Ягъни дастанда тасвирланган вакыйгаларны һәм каһарманнарның язмышы халык фантазиясе белән сәнгатьчә үрелеп бирелә, образлар системасы, әсәрнең композициясе һәм шигъри теле дә шушы нигезгә буйсындырылган.

Әйдәгез, дастан композициясенә хас төп үзенчәлекләргә күз салыйк әле. Искә алынган җыйналма вариант җиде меңгә якын шигъри юлдан гыйбарәт булып, андагы хәл-вакыйгалар аерым эпизодларга төркемләп тасвирланган. Бу уңайдан академик А. Н. Веселовскийның «Тарихи поэтика»[1] дигән мәгълүм әсәрендәге бер фикере искә төшә. Ул эпосларның ничек бербөтен булып оешуына карата: «Төрле җырчы-чичәннәр тарафыннан аерым-аерым иҗат ителгән төрле эпик җырлар соңрак туачак эпопеялар җыйналмасы өчен нигез булып торалар»,— дип яза. Димәк, шушы юнәлештә хәрәкәт итсәк, «Идегәй» кебек күләмле эпосның (дастанның) ничек оешуын күз алдына китерергә булыша торган бик тә әһәмиятле бер чыганак булып тора ала. Бу чыннан да, дастанда Идегәй образы белән бәйле эпизодлар күп һәм төрле кимәлдә булсалар да, аның безгә килеп җиткән вариантында композицион бөтенлек, бердәм сюжет һәм динамика бар. Бу бөтенлек исә, үз чиратында, дастанны иҗат иткән, башкарган һәм килер буыннар өчен саклаган халык җырауларының, чичәннәренең олы талант ияләре булуына шөбһәсез бер дәлил. Шунсы үкенеч, без ул чичәннәрнең бик күбесен белмибез. Алай да «Идегәй»нең безгә мәгълүм җыйналмасын берничә вариантта телдән сөйли алу куәсенә ия булган Себер карты, чичән Ситдыйк бабай Зәйнетдиновны без бүген олы рәхмәт хисе белән телгә алырга тиешбез. Соңыннан журналист Хафиз Рәхмәтуллин дә, тел галиме Нигъмәт Хәким дә, язучы һәм галим Нәкый Исәнбәт тә дастанның нәкъ шул бабай сөйләгән җыйналмасы нигезендә эш итәләр.

«Идегәй» өчен төрки халыкларның күп кенә дастаннарында очрый торган традицион композиция өлгеләре — эпик башлам, вакыйгалар төенләнеше, үзәк каһарманнар арасында барган туктаусыз низаг-орышлар, талаш-тартышлар, җиңү һәм җиңелүләр, трагик чишелеш хас. Дастан сюжетында Идегәйнең эпик биографиясен кабарынкы итеп, төрле яклап сурәтләүгә омтылыш бигрәк тә нык

[1] Веселовский А. Н. Историческая поэтика.— Л.—1940,— С.— 476.

сизелә. Аның зирәклеге, гаделлеге, батырлыгы һәм нечкә күңеллеге күп төрле трагик һәм лирик ситуацияләрдә сынала. Шул ук вакытта, дастанда Идегәйнең фаҗигале язмыш иясе булуын, кырыслык һәм рәхимсезлек сыйфатларын хикәяләгән эпизодлар да бар. Мондый хәлнең бу дастан өчен генә түгел, гомумән, төрки халыкларның эпик канунннарына хас булуын әйтергә кирәк. Дастанда Идегәй образы гомумиләштереп бирелсә дә, ул барыбер җанлы шәхес булып күз алдына килә. Алтын Урданың төрле тарафларында туган җырлар һәм риваятьләр аны батыр-каһарман итеп кенә түгел, ә игелекле шәхес итеп тә сурәтләгәннәр. Шулар нигезендә дастанда шактый идеаллаштырылган Идегәй образы барлыкка килгән. Моның өчен дастанчы чичәннәр гипербола кебек стилистик алымны иркен файдаланганнар. Әйтик:

Ятимнәргә — яр булган,
Колчурага — дус булган,
Аты юкка — ат булган,
Чүлләгәнгә — су булган,

Адашканга — юл булган,
Ялгызга — ясак булган,
Җәяүгә — таяк булган,
Карны ачканга — тамак булган

Идегәй ир бар икән.[1]

Эпик традицияләргә хас булганча, Идегәй ялгыз гына хәрәкәт итми, аның әкияти-тылсымлы көчкә ия булган Тим Чуар исемле аты, сузылмалы Шам кылычы бар. Аның якын дуслары да, дошманнары да аз түгел. Аларның һәркайсысы Идегәй образына җан өрә, аңа тарихи чынлык төсе бирә.

Дастан композициясендә шигъри янәшәлекләр мөһим генә урын тота. Янәшәлек сурәтләре функциясен дастанда Идел, Җаек, Чулман буйларының, Болгар, Сарай җирләренең, нугайлар, болгарлар, кыпчаклар биләгән киң далаларның күптөрле үлән-агачлары, кош-кортлары, елга-күлләре, ерак Алтын Урда чорларында төрки бабаларыбыз ашаган-эчкән аш-сулар, кигән кием-салымнар, кулланган сугыш кораллары үтәп, алар дастанның буеннан-буена сибелгәннәр.

Телгә алган сурәтләрдән Иделгә аерым тукталыйк. Дастанда Идел образы шигъри янәшәлек кенә түгел, ул Туган җир, Ватан төшенчәләрен үзенә җыйган символ да. Дастан дәвамында Идел, Идел-йорт, Идел-ана образлары бербөтен мәгънә алып, төп каһарманнар телендә күп тапкырлар кабатлана. Идегәйнең Аксак Тимердән аерылып үз иленә кайткач һәм Идел-йортны күргәч, аның туфрагын үбеп, дулкынланып әйткән лирик тулгавын искә төшерик. «И, Идел-йорт, Идел-йорт» дип башланган бу тулгауда Идел-йорт газиз ата-баба йорты да, татарның яшәвенә куәт, матурлык биргән мөкатдәс һәм гүзәл бер урын да. Шуңа күрә Идегәй бу изге җирләрне басып алган дошманын куарга атлыгып, ярсып тора. Мәгълүм ки, Идегәйнең бу шигъри тулгавына безнең заман композиторы музыка язгач, ул тарихи хәтерне яңартучы зирәк мәгънәле бер җыр булып яши башлады.

Диалог һәм әйтеш формасы — дастан композициясенең күзгә бәрелеп торган һәм эстетик яктан җитди вазифа башкаручы бер билгесе. Бу алым әсәрнең буеннан-буена кулланылып, арада тоташ диалогка корылган бүлекләр дә очрый. Мәсәлән, «Туктамыш ханның сарайдан качып киткәндә тулгап әйткәне» дигән бүлекләр турыдан-туры әйтеш традицияләренә нигезләнгән. Мисалга бер өзек китерик:

Субра алай дигәндә,
Җанбай уйга килгәндә,
Идегәй алып балны эчте,
Субра ерау анда әйтте:
— Афәрин, батыр икәнсең,
Ханга дуслык иткәндә
Дуслыгың ничек итәрсең?
Ханга хаслык иткәндә
Хаслыгың ничек итәрсең?

Идегәй торып анда әйтте:
Ханга дуслык иткәндә
Чыгып кала бозармын,
Казнадан казна китереп,
Ханның күңелен табармын.
Ханга хаслык иткәндә
Арсаеп атка менәрмен,
Карчыга булып очармын,
Ханны куып басармын...

Дастанда еш кабатланучы әйтеш формасының бер үзенчәлеген билгеләп үтик. Бу үзенчәлек әйтешнең сорау һәм җавап интонацияләрен берләштергән ком-

[1] Китерелгән һәммә мисаллар да «Идегәй» китабыннан алынды. Казан, 1988.

позицион калыпка корылган булуында. Мондый корылыш сюжетка драматик төсмерләр биреп, әйтелә торган фикернең капма-каршылыклы якларына төшенергә мөмкинлек ача.

Дастанда тарих белән фантастика, әкияти-хыялый күренешләр белән реаль тормыштан алынган күренешләр тыгыз үрелеп бара. Идегәйнең әкияти зат Кара Тиен Йосынчы белән очрашуын хәтергә төшерик. Үзенең килеш-килбәте һәм табигате белән Кара тиен иләмсез зур, ямьсез һәм явыз бер персонаж. Дастанда ул «балта салсаң, башы каерылмас, кылыч чапсаң, муены өзелмәс» Алып кыяфәтле бер батыр дип бәянлә. Менә шул килбәтсез һәм искиткеч куәтле мифик зат белән орышка керә Идегәй, Кара Тиенне юк итә, Шаһ Тимер кызы гүзәл Акбеләкне коллыктан коткарып әтисенә алып кайта. Бу сюжетта тылсымлы әкиятләргә хас традицион эпизодны абайлау авыр түгел. Шушы уңайдан татар халкының «Турай батыр» дигән әкиятен искә төшерик. Анда да әкият герое дию белән сугышып аны юк итә, үзе коткарган патша кызын әтисенә илтеп тапшыра. Әлеге әкияттә дә, дастанда да тоткындагы кызлар үзләрен коткарачак геройга дәһшәтле дошманын җиңүдә булышалар, аның «җаны» кайда яшерелгәнен әйтәләр. Искә алган эпизодта Идегәй тарихи герой булудан бигрәк, гайре табигый көчкә ия әкият каһарманы булып күзаллана.

Идегәйнең Туктамыш хан гаскәре белән сугышын тасвирлаган эпизодта ул шулай ук әкият батырын хәтерләтә.«Аждаһадай сулый» торган Шам кылычы белән: «Бер селтәде, бер ауды, Бере ауганда уны ауды. Ун ауганның җиле бар, Уны белән йөзе ауды, Йөзе ауганда меңе ауды».

Икенче бер сугышта Идегәй Шаһ Тимернең ун мең санлы гаскәрен үзенең «тукмагы белән тукмаклап» кырып ташлый.

Дастан тукымасына үрелгән төш күрү мотивын да аның халык әкиятләре, кыйссалар белән уртаклыгын раслаган бер күренеш дип санарга була. Төш күрү һәм юрау дастанның үзәк геройлары Идегәй белән Туктамышның булачак язмышында җитди роль уйнаган бер хәл буларак тасвирлана.

Тамырларында төрле мифик ышанулар һәм ырымнар яткан эпик саннарның еш кулланылуы дастанга шулай ук тылсымлы төс бирә. Бу саннар — 3, 6, 7, 9, 30, 40, 50, 1000 — арасыннан бигрәк тә ике сан — 9 (9 йорт, 9 солтан, 9 илче, 9 тешле батман, 9 байрак, 9 башлы көбә) һәм 40 (40 ил, 40 ир, 40 ат, 40 үгез, 40 бия, 40 дөя, 40 кол, 40 көн туй ясау, 40 кое, 40 колачлы аркан, 40 көнлек юл) дастанның башыннан ахырына кадәр кулланыла. Алар күп кенә очракларда киңәйтелгән метафора ролен уйнап, әсәргә борынгылык һәм эпик серлелек рухы сирпиләр.

Мәгълүм ки, борынгы заманнарда төрки халыклар тормышында хикмәтле сүз әйтү йоласы киң таралган булып, бу традиция турыдан-туры халык шагыйрьләре чичәннәр һәм акыннар, җыраулар һәм тел осталары иҗаты белән, алар арасында булган җыр ярышлары, айтыслар-әйтешләр белән бәйләнештә яшәгән. Әдәбият галиме Нил Юзиев татар шигыренә багышланган китапларның берсендә хикмәтле сүзне халыкның дөньяны танып-белү табигатеннән килеп чыккан акыл-хис шигърияте дип атый.[1] Бу чыннан да шулай.

Сурәтле сүзнең кеше күңелен сихерли ала торган тылсымы-сере бар. «Идегәй» дастанында хикмәтле сүзләр һәм гыйбарәләр, тапкыр әйләнмәләр һәм канатлы тәгъбирләр тулып ята. Алар дастан рухының шигъри баганалары, аның мәгънәви-хисси кыйммәтен мәңгеләштергән асылташлары. «Идегәй» — нәкъ менә шушы сыйфаты — хикмәтле сүзләрне әйтә, куллана белүдә халыкның таң калырлык шигъри осталыгына, тагы да тулырак әйткәндә даһилыгына бер дәлил булуы белән татар фольклорында үзенә аерым урын тотучы иң гүзәл әсәр санала. Идегәйне үлемнән саклап калган Җантимер картның Туктамыш ханга мөрәҗәгате (1 бүлек), Алтын Урдада танылган оста чичән Субра җырауның хак мәҗлесендә җырлаган җыры (4 бүлек), Идегәй белән Норадын арасындагы шигъри диалоглар (9, 16 бүлекләр), Идегәйнең Идел-йортка багышланган тулгау җыры (9 бүлек), Туктамыш ханның Сарайдан киткәндә монланып әйткән аерылу сүзләре (12 бүлек) — болар һәммәсе дә дастанның хикмәтле фикерләр, канатлы гыйбарәләр белән сугарылуын дәлилли торган мисаллар. Моңа гаҗәпләнергә урын да юк кебек, чөнки дастанның төп каһарманнары берүк вакытта чичәннәр, тел осталары итеп тә сурәтләнә. Арада иң истә калганы, әлбәттә, Субра җырау, үзе әйткәнчә, Иделдәге илле ханны күреп белгән 195 яшьлек хикмәтле шагыйрь һәм хәким-күрәзәче.

Чичәннәр турында сүз чыккач, тагын шуны әйтергә кирәк. «Идегәй» дастанын иҗат иткән һәм берсеннән-икенчесенә тапшырган чичәннәр, җыраулар

---

[1] Юзиев Нил. Татар шигыре. — Казан, — 1991, 248 б.

ас китәрлек зирәк зиһен ияләре, укымышлы кешеләр дә булган. Дастан дәвамында алар «Шаһнамә» герое Рөстәмне, библиядә тасвирланган Сөләйман патшаны (Соломон), Искәндәрне (Александр Македонскийны) телгә алалар. Дастан каһарманнары еш кына Коръәнне һәм пәйгамбәрләрне искә төшерәләр, ислам диненә турылыклы булуларын әйтәләр.

Дастанда халык теленнән алынган янсә халык теленә күчеп җәүһәрләр кебек балкучы йөзләгән мәкальләр бар. Алар да әсәрнең хикмәтле сүзләргә гаҗәеп бай икәнен раслыйлар. Берничә мисал:

Читтә солтан булудан
Илдә олтан булу артык,
Күктә чулпан булудан
Суда чуртан булу артык.

Нинди юан булса да
Ялгыз агач өй булмас,
Нинди ятыш булса да
Ялгыз егет би булмас.

«Ат омтыла туйган җиренә, ир омтыла туган җиренә», «Ил сүзен тоткан — ир булыр», «Яудан качкан — ир булмый, ил эчендә көн күрми» һ. б. Шигырь төзелеше ягыннан «Идегәй» аерым игътибарга лаек. Дастан төрки халыкларның иң борынгы шигырь калыбына — җиде иҗекле үлчәмгә (дастан шигыренә) нигезләнгән. Моның асылында дастанның тулгау рәвешендә әйтелеп (көйләнеп) яшәү ихтыяҗы, ә җиделе шигырьнең хәтердә тизрәк уелып калу үзенчәлеге ята. Үз заманында дастан аерым җырлаулар, акыннар телендә думрага, сазга кушылып, көйләп әйтелә торган булган. Кайбер урыннарда моңа «сарын белән сөйләү» дигәннәр. Көйләп әйтү, үз чиратында, импровизациягә киң юл ачкан. Шуның аркасында, урыны белән ритмик төрлелек тә очрый, иҗекләр саны күнегелгән калыптан чыгып китә. Әммә, ни гаҗәп, бу хәл әсәрнең агышына, янгырашына хилафлык китерми, шигырьне, ничектер, табигый сөйләм интонацияләре белән баетып, төрләндереп җибәрә.

Дастанны иҗат итүчеләр импровизациягә таянып, әсәрдәге вакыйгалар үсешенә, образлар дөньясына яңадан-яңа өстәмәләр, төсмерләр кертә барганнар, аны гармонияле бербөтен итәргә омтылганнар. Нәтиҗәдә, төрки халыкларның кайбер дастаннары, мәсәлән, «Манас» миллионлаган тезмәләрне эченә ала. Бу хасият безнең «Идегәй»дә дә чагыла. Аның да күләме, алда әйтеп узганча, җиде меңгә якын тезмәдән тора.

Дастанга хас шигырь строфикасы, ритмик калыбы, рифмалар төрлелеге, кабатланулар һәм градацияләрнең тигез рәвештә чиратлашуы — болар бар да «Идегәй»гә озын гомер биргән һәм онытылудан сакларга булышкан күркәм сыйфатлар булып санала алалар. Шуларның берсе — аллитерация турында аерым сүз әйтик. Мәгълүм ки, аллитерация тел сәнгате әсәренең телен авазлар ягыннан оештыруның бер төре булып санала һәм охшаш тартык авазларны кабатлау юлы белән ясала. Аллитерация төрки халыкларның иң борынгы шигырьләрен бизәүче стилистик алым. Аның туган җире төркиләрнең бишеге булган Алтай һәм Себер яклары. Кайбер төрки халыкларның дастан иҗатында аллитерация хәтта рифманы да алмаштыру көченә ия булган. «Идегәй» дастанының берничә өлешен гомумән аллитерацион шигырь дияргә була. Мисал китерик:

Боларып яткан күлләрнең
Балыгын алды дулатып,
Сыланып яткан суларның
Суларын эчте болгатып;

Күгәреп үскән күксавыл —
Күксавылны кыдырып,
Кыларып үскән кау кылган —
Кау кылганны кыдырып,
Килә бирде яу кыргып.

Дастанның шигъри калыбы катлаулы, ул без күнеккән дүртьюллы строфалардан тормый, гомумән аның шигъри калыбын строфа дип атап булмый. Монда әдәбият белемендә кулланыла торган тирада дигән термин искә төшә. Бу термин белән бер сулыш-интонациягә хисапланган ирекле шигырьне атыйлар. Андый шигырь тезмәләре кайвакыт егермедән артып китәләр һәм үзләренә күрә, аерым симметрик төркемнәр тәшкил итәләр. Әдәбият белемендә кулланыла торган атаманы халык шигыренә карата файдалану үзен акламаска да мөмкин. Әмма шунсы бәхәссез, дастанның шигырь төзелеше аерым игътибарга лаек.

Гомумән, «Идегәй» дастанының шигърияте гаҗәеп бай һәм гүзәл. Әлегә без аның аерым үзенчәлекләренә бер күзәтү генә ясадык. Киләчәктә моңа багышлап махсус хезмәтләр язылыр әле дигән өметләр бар.

**Надир Дәүләт**

Истанбулдагы Мәрмәрә университеты профессоры

# ТАТАР ДИАСПОРАСЫ ҺӘМ ТУКАЙ

Бай тарихка ия булуларына карамастан, татарларның соңгы йөз елда, аеруча совет чорында, үзләренең үткәннәре белән бәйләнешләре шактый йомшарды. Режим мөмкинлек биргән кадәр милли гореф-гадәтләрен, әдәбиятларын һәм тарихларын өйрәнгән, тикшергән һәм яшь буынга житкерергә тырышкан татарлар һәм алар хәлендә калган башка милләтләр, этник җыелмалар, үз-үзләрен саклап калыр өчен, бик еш кына бер төркем символлар кулланырга мәҗбүр булдылар. Бәйсезлек алганнан соң кыргызларның «Манас» дастанына, үзбәкләрнең (Әмир) Тимурга, казахларның Абай Кунанбаевка, башкортларның профессор Зәки Вәлиди Туганга, төрекмәннәрнең Мәхтум Кулигә һ. б. сарылып, бу шәхес һәм дастаннарны гадәттән тыш идеаллаштырулары, алар белән бәйле юбилейларны милли бәйрәм дәрәҗәсенә җиткереп үткәрүләре, алар исемендәге премияләр оештырулары, һәйкәлләр куюлары асылда шул — милләтнең аерымлык билгесе булган милли символларга ихтыяҗлары белән аңлатыла ала. Милләт булып формалашу яки бәйсезлек алу чорында ул дәүләтнең яки милләтнең барлыгын күрсәткән байрак, гимн кебек заманча символлардан мәхрүм булган милләтләр исә үзләренә генә хас символларга таяналар. Бу күренеш аңлы рәвештә дә, аңсыз рәвештә дә яшәп килә.

Менә 444 елдан бирле рус хакимияте астында яшәгән һәм чит илләрдә, бигрәк тә Төркиядә «Казан төрекләре», «Идел-Урал төрекләре» кебек төрле-төрле исемнәр белән аталса да, үзен «татар» дип атап йөрткән бу төрки милләт, үзенә генә бер төрле моң-сагыш белән, үзенчәлекле символлар җыелмасы барлыкка китерде. Гәрчә 1992 елдан бирле Татарстан Җөмһүриятенең дәүләт символы буларак «канатлы ак барс» фигуралы тугъра һәм яшел, ак, кызыл төсләрдән гыйбарәт булган байрак кулланыла башласа да, боларның халык тарафыннан тулысынча кабул ителүенә шактый озак вакыт кирәк булачак. Башка төрки җөмһүриятләрдәге кебек, Татарстанда да бу төр яңа рәсми милли символларны кабул итү «булды-бетте»гә әйләндерелде. Чынлыкта һаман һәр татар өчен аңлаешлы милли символлар буларак, беренче урынны Казан Кремлендәге Сөембикә (Хан мәчете) тотса, икенче урында милли шагыйрь Габдулла Тукай (1886—1913) тора дип әйтергә була. 1988 елда башланган бәйсезлек өчен көрәштә «Тукай маршы (гимны)» буларак билгеле «И туган тел» исемле шигыре милли җыелышларда, Төркиядәге «Истиклял маршы» кебек, аягүрә басып җырлану дәрәҗәсенә житте. Хәтта ул вакытка кадәр бу шигырьнең тыелган соңгы дүрт юлының да аерым бер горурлык белән җырлануы, белмәгәннәргә өйрәтелүе, режимның күрсәткән золымына һәм кысуларына карата татар халкының бер протесты буларак та аңлашыла ала. Табигый ки, монда шул хакыйкатьне дә ассызыклау урынлы булыр: совет режимы милли шагыйрьне тыймады, киресенчә, аңа атап һәйкәлләр салуга, музейлар ачуга, премияләр бирүгә рөхсәт итте, ләкин аның «Васыятем», «Тәэссир», «Аллаһ-ы Тәбарәкә Тәгалә» кебек дини мотивлы шигырьләрен яки «И туган тел» шигырендәге кебек аерым юлларны бастырмыйча, аларга карата цензура булдырды. Икенче төрле әйткәндә, режим татар халкы өчен сөекле улын тыймады да, әмма аның әлеге темага багышланган шигырьләрен үзе теләмәгән формада төшендерелүе өчен мөмкинлек тә бирмәде.

Диаспорадагы татарларга килгәндә исә, аларны якын һәм ерак диаспора дип икегә бүләргә мөмкин. Беренчесенә Татарстанның тышында элекке СССРның

төрле җөмһүрият һәм өлкәләрендә яшәүчеләрне, икенчеләренә исә, болардан кала, чын аңламдагы чит илләрдә яшәүчеләрне кертергә була. Без хәзер тикшерергә теләгән тема — ерак диаспорадагы, ягъни 1950 елларга кадәр башлыча Кытайда, Япониядә, аннан соң Төркия, Финляндия, АКШ кебек дәүләтләрдә яшәгән аз сандагы татарлар һәм аларның Тукайны танып белүләре мәсьәләсе. Югарыда саналган дәүләтләр демократик яки советларга каршы позициядә торганга күрә, анда яшәүчеләр Тукайны үзләре теләгәнчә искә алу (яки искә алмау) ирегенә чын мәгънәсендә ия иде. Бу иректән файдаланып, алар нинди дер режимның рөхсәт итүен яки итмәвен көтеп тормыйча, Тукайны һәр җәһәттән теләгән кадәр искә алып тордылар. Хәтта чит илләрдә җитешкән яшь нәсел, «бәгъзан татарларның башка шагыйрьләре әллә бер дә юкмы?» дип шөбһәләнеп тә карый башлады. Ватанны сагыну газабы тойган карт буын үз балаларына Тукай шигырьләре аша туган илгә мәхәббәт тәрбияләргә, аның шигъри юллары (мәсәлән, «И туган тел» шигыре) белән ана теленә игътибар уятырга тырышты. Икенче сүз белән әйткәндә, Тукай милли телне, милли әдәбиятны, ватан тойгысын, кыскасы, татарлыкның мәдәни кыйммәтләрен чагылдыручы бер исем булып торды.

Тукайның мондый көчкә ия булуын бәлки шул рәвешле аңлату дөрес булыр. Сәбәп аның шигырьләренең теле гаять гади, ягъни ана телен бөтен нечкәлекләре белән белмәгән, чит илләрдә, чит мохитта туган кешеләр дә җиңел аңлый алырлык дәрәҗәдә садә булуында, әсәрләрендә күтәрелгән мәсьәләләрнең халык әкиятләреннән башлап, иҗтимагый һәм милли проблемаларга кадәр киңәеп китүендә. Социаль яраларны, мәгънәсез кебек күренгән, ләкин турыдан-туры халыкны кызыксындырган көндәлек вакыйгаларны, азатлык тойгыларын чагылдыруы, кешенең туган теле, тарихы белән горурланырга тиешлеген саф һәм җиңел аңлаешлы телдә аңлатуы үз илендә дә, диаспорадагы татарлар арасында да Тукайны баш таҗы итте. Үз дәвере шагыйрьләре Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд, Зариф Бәшири, Нәҗип Думави, Укмасый, Зыя Ярмәкиләрдән аерылып торуының бер сәбәбе дә, бәлки, аның һәр иҗтимагый сыйныфка, һәр буынга атап, аерым дәшеп иҗат итүендәдер.

Менә бу үзенчәлекләре ерак диаспорадагы татарларның Г. Тукайны туган һәм үлгән көннәре туры килгән апрель аенда искә алулары өчен сәбәп булды. Кайда гына, кечкенә булса да бер татар якташлыгы оешмасын, кайда гына мәдәни фәгалият (чара үткәрү) форсаты тумасын, анда «Тукай кичәсе» үткәрү традициягә әверелде. Бу милли кичәләрдә Тукайның тормыш юлы сөйләнгәннән соң, аның шигырьләреннән берничәсен үрнәк итеп китерү мәҗбүри. «И туган тел», яисә икенче исеме белән «Тукай маршы» хор белән җырлана. Гомумән, Тукай кичәсе булсын, башка милли кичәләр булсын, бу җырның җырланмый калуы бик сирәк була иде. Чөнки бу марш (гимн) азатлыктан мәхрүм татар халкының бәйсезлеккә омтылышы кебек тоела иде. Бу «Тукай кичәләренә» өстәмә рәвештә махсус китап-журналлар да нәшер ителә иде. Шул рәвешле диаспорада да Тукайның үлемсез калуы тәэмин ителә иде.

Башта ерак диаспорада яшәгән татарларның Тукайга мөнәсәбәтле эш-гамәлләренә күз салыйк. Иң әүвәл Япониядә Тукайның вафатына 20 ел тулу уңае белән басылган мөһим бер басмага тукталыйк. «Токио Матбага-и Исламия» 1933 елда, ягъни шагыйрь үлеменең 20 еллыгында Тукайның бөтен әсәрләрен эченә алган «Габдуллаһ Тукай. Мәҗмуга-и Асары» исеме белән 4 томлык бер җыентык бастырды. Барлыгы 543 битлек бу җыентык ул чакта татарлар тарафыннан кулланылган гарәп хәрефләре белән нәшер ителде. Бу мөһим юбилей мөнәсәбәте белән, Япониядә яшәгән бик аз санлы татар-башкортның искиткеч зур тырышлыгы белән мәйданга чыккан бу 4 томлы җыентыкны хәзерләү бер дә җиңел булмый. Моның шулай икәнен Токиода чыккан «Япон мөхбире» исемле журналда басылган язмадан да күрергә була. Япониядәге мөселманнарның дини лидеры ролен үтәгән Габделхай Корбангалиның әлеге журналда басылган мәкаләсеннән һәм башка хәбәрләрдән Тукайның үлеменә 20 ел тулуны билгеләп үтү өчен зур күләмле чаралар үткәрелүе аңлашыла. Бер елдан соң исә Тукайның нибары бер шигыренең генә басылуын күрәбез.

Ерак Көнчыгышта Тукай белән бәйле, дөресрәге, аның үлеменең 25 еллыгын искә алу өчен басылган икенче бер әсәр исә 20 мәкалә һәм аңа багышланган шигырьләрне эченә алган 98 битле «Габдулла Тукай (1913—1938) (Вафатына 25 ел тулу белән)» исемле җыентык иде. «Ерак Шәрык Идел-Урал төрек-татар мөселманлыгының дини милли мәркәз мәгариф шогъбәсе» тарафыннан 1938 елда Мукденда нәшер ителгән. Шул ук вакытта Мукденда 1935—1945 еллар арасында чыккан «Милли байрак» газетасы төрле уңайдан аның шигырьләреннән

үрнәкләр биреп бара, Тукай хакында төрле мәкаләләр яки аңа багышланган шигырьләр бастыра. Исхакый мөхәррирлегендә чыккан (башта «Милли юл» буларак) «Яңа милли юл» исемле айлык журналда да Тукайга бик еш урын бирелә.

Ерак диаспорадагы татарларның икенче бер мәркәзе булган Финляндиядә шагыйрьне искә алу кичәләре үткәрелеп килсә дә, беренче басма эше 1953 елда Төрек халык мәктәп һимая корумы тарафыннан Хельсинкида Тукайның «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» исемле әсәрен нәшер итү булды бугай. Һәм 1969 елда Хөсәен Садыйкның «Габдулла Тукай шигырьләре» исемле 102 битле җыентыгы шулай ук Хельсинкида, элек Кытай һәм Япониядә чыккан җыентыкларның латин хәрефләренә күчермәсе рәвешендә басылды.

Ерак диаспорадагы татарларның иң тыгыз утырган җире булган Төркиягә килгәндә, монда Тукай һәм Тукайны таныту буенча алып барылган эшләр түбәндәгечә. Төрек укучысы беренче тапкыр буларак Тукай исемен «Төрек йурду (йорты)» журналының 1913 елдагы «Габдуллаһ Тукаевның вафаты» исеме астында басылган хәбәрдән белде. Аннан соң журнал «Тукаевның җеназасы» хакында мәгълүмат бирде. Иң әһәмиятлесе, һичшиксез, Фуад Көпрүлүнең Тукай хакында язган мәкаләсе булды. Ләкин Фуад Көпрүлүнең күләмле мәкаләсендә «бары тик «Тасвир-и Әфкар» белән «Ислам дөньясын»да гына Тукаевка берничә колонка язма бирелде» дип хәбәр итүе ул вакытларда Төркиядә Габдулла Тукаевның әле танылмавына ишарә иде. «Төрек йурду» ул санында «Төрекләрнең яшь халык шагыйре (Габдулла Тукаев) мәрхүм») дип язып, нәкъ бер битлек фотографиясен һәм румынияле Нуман Байбуриның аңа атап язган «Габдуллаһ Тукаев» исемле шигырен бастырды. Биш ел узганнан соң «Кырым» журналында бик кечкенә генә бер мәкалә чыкканын беләбез. Ягъни Көпрүлүдән соң Тукайга җитди игътибар күрсәткән кеше булмады. Монда шигырьләренең төрекчә тәрҗемә ителмәвенең дә йогынтысы булган, күрәсең. Озак вакытлардан соң Җөмһүрият дәверендә яңадан чыга башлаган «Төрек йурду» 1926 елда «Габдуллаһ Тукайның «Мәҗмуга-и асары» дигән баш астында төрек укучысына Казанда аның сайланма әсәрләре басылуын хәбәр итсә дә (IV, № 20, август 1926, 189 б.), бу да тәэсирле булмады. Гаяз Исхакый 1933 елда (ягъни Тукайның 20 еллыгында) «Азәрбәйҗан йорт билгесе» журналында Тукай турында тагын язып чыкса да, моның да әллә ни йогынтысы булмавы аңлашыла. Нәтиҗәдә төрек матбугатындагы бу бер-ике мәкаләдән соң ярты гасыр буена Тукай турында һичбер нәрсә басылмавын, тулы бер бушлык хөкем сөргән күрәбез. Бары 50 елдан соң гына Тукайның үзләре татар нәселле булган тикшеренүче һәм галимнәр тарафыннан көндәлек тормышка кире кайтарылуына шаһит булабыз. Болар — тарихчы Габдуллаһ Баттал Таймас, профессор Рәшид Рәхмәти Арат, профессор Әхмәт Тимер иделәр. Алардан соң өч ел узгач, профессор Хәмзә Зөлфикар шул ук журналда «Габдулла Тукай (1886—1913)» исемле җитди гыйльми бер мәкалә бастырганын күрәбез.

Шул ук елларда, ягъни 1963 елда, Истанбулдагы татар-башкорт яшьләре «Тукай яшьлек клубы»н оештырганнар иде. Бу яшьләр оешмасы 1965 елның мартыннан башлап, 1968 елның сентябрь-ноябренә кадәр барлыгы 24 сан — һәр саны якынча 10—12 битлек — «Тукай бюллетене» чыгарды. Бу бюллетеньнең 1965 ел апрель (№ 2) санында профессор Әхмәт Тимернең «Габдулла Тукай» исемле (3—7 битләр) мәкаләсе басылды. Әлеге бюллетеньнең 4 саныннан алып иң соңгы санына кадәр (ләкин 1965 елның ноябрь нөсхәсе «Рәшид Рәхмәти Арат хөрмәтенә махсус сан» булып чыкканга, бу саннан калганнары барысы (Надир Дәүләт оештырган «Тукай почмагы»нда Габдулла Тукайның шигырьләреннән шактые татарча оригиналы һәм төрекчә тәрҗемәләре белән басылды.

Шул ук «Тукай бюллетене» 1966 елда Наилә Бинарк тарафыннан иҗат ителгән «Тукайның хәяте» исемле балалар өчен дүрт пәрдәле пьесаны 16—19 саннарында бастырды. Соңрак бу спектакль Анкарада сәхнәгә дә куелды. Шул араларда Гали Акыш, Сәгыйдә Арысланбәк, Наилә Бинарк тарафыннан хәзерләнгән «Тукай брошюрасы» дигән 8 битлек бер хезмәт дөньяга килде. Бу брошюрада Арысланбәк һәм Бинаркның «Габдулла Тукай», шул ук шәхесләр тәрҗемәсендә Тукайның «Туган тел», «Гомер юлына керәчәкләргә», «Таз» шигырьләре, Гали Акышның «Бөек төрек-татар шагыйре Габдуллаһ Тукайның халыкчылык вә милләтчелек җәпһәләре» исемле мәкаләсе урнаштырылган иде. Бу нәшрият эшләреннән тыш, «Тукай яшьлек клубы» тарафыннан 1964, 1965, 1966 һәм 1967 елларның апрель аенда «Тукай бәйрәме» дип аталган милли кичәләр оештырылды. Бу милли кичәләрдә Тукайны искә алу белән бергә, аның шигырь-

ләре укыла, кечкенә спектакльләр күрсәтелә һәм фольклор уеннары уйнала торган иде. 1967 елгы «Тукай бәйрәме»нең башка еллардагыдан аермасы Гаяз Исхакыйның (Иделле) «Җан Баевич» исемле 4 пәрдәлек зур пьесасын Истанбулдагы Чагалоглунда Милли төрек студентлар берлеге сәхнәсендә куелу булды. Бераз соңрак (28 октябрь 1967) «Тукай бәйрәм»нәре «Казан төрекләре шәнлиги (шатлыгы)» исеме астында дәвам иттерелде. Ләкин бу әле Тукайның онытылмавын тәэмин итә дигән сүз түгел.

Чөнки 1968 елда «Тукай яшьлек клубы» «яшьлек срогын тутырып», «Казан төрекләре культура (мәдәни) һәм ярдәмләшмә җәмгыятенә» әйләнгәч, мәрхүм Әхмәт Вәли Мәңгәрнең матди булышлыгы белән өч айга бер мәртәбә «Казан» журналы чыгарыла башлады. Бу журнал да Тукайны укучыларга таныту эшеннән ваз кичмәде һәм «Тукай бюллетене»нә караганда да киң күләм укучыларга таралганга күрә, тагын да үтемлерәк булды. «Казан» журналы беренче санында ук Надир Дәүләт тәрҗемәсендәге Тукайның «Сак-Сок бәете» исемле әсәрен бастырып чыгарды. Тукайның тууына 85 ел туры килгән өченче санында исә (март 1971) «Казан» үз сәхифәләренең күп өлешен Тукайга багышлады.

Татарлар Тукайны һәр төрле уңайдан искә алырга тырышканга күрә, «Казан» журналы да Габдулла Тукайның үлеменә 60 ел тулу уңаеннан 10 нчы санын (1973) тулысы белән аңа багышлады.

Моннан соң да «Казан» журналының 11 нче санында (1974) «Таз», «Теләнче», «Нәсихәт», 12 санында (1974) «Мөхәрриргә», 14 санында (1975) «Театр», 17 санында (1976) (бу санда 90 еллык юбилее котлана) «Су анасы» белән «Кадер кич» шигырьләренең Наилә Бинарк тәрҗемәсендә нәшер ителүен күрәбез. 17 санда шул ук вакытта Сания Ишыкайның шагыйрьгә атап язган «Габдуллаһ Тукайның 90 еллыгы» исемле шигыре дә урнаштырыла. Аннан кала 18 нче санда (1976) Нәркиз Деуш-Гиелингнең «Тукайга хөрмәтләр белән» һәм 22 нче санда (1978) Минһаҗның «Даһи Тукайны искә алу» дигән шигырьләре бирелә.

Ләкин 1978 елның 10 ноябрендә журналны матди яктан яшәткән Әхмәт Вәли Мәңгәрнең вафат булуы «Казан» журналының басма хәятына чик куелуга, 1980 елның 12 октябрендәге хәрби переворот исә Истанбулдагы «Казан төрекләре культура һәм ярдәмләшмә җәмгыятене»ң ябылуына сәбәп булды. Бу үзгәрешләр Тукайны төрек җәмәгатьчелегенә таныту эшен тагын да кыенлаштырды һәм бу вазифаны чикләнгән мөмкинлекләргә ия булган аерым шәхесләр үз өсләренә алырга мәҗбүр булдылар.

Төркия тышындагы төрки милләтләрнең әдәбиятларына төрле сәбәпләр аркасында игътибарның артык зур булмавына карамастан, әлеге вазифаны, мөмкинлекләре чикле булса да, фидакарь рәвештә үз өстенә алган «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1982 елда Тукай исемен яңадан төрек укучысына житкерә. Дүрт елдан соң, 1986 елда, ягъни Тукайның тууына 100 ел тулганда исә, бу юллар авторының бер төркем танытма мәкаләләре басылып чыга.

Югарыда күрсәтелгән журналларда чыккан мәкаләләрдән тыш, «Кардәш әдәбиятлар» журналының да 16 нчы санын (1987) Тукайга багышлау татар шагыйренең тагын да киңрәк территориядә танылуы булды.

Тукайның 100 еллык юбилеен шулай билгеләп үтәргә тырышканнан соң 1988 елда Гали Акышның «Төрек йурду» журналында басылган Тукайны хәтерләтү фикере белән язылган бик кыска (бер битлек) кечкенә мәкаләсеннән башка, 3—4 ел буена бернинди дә житди хезмәт чыкканы күренми. Тукайның 100 еллыгына хәзерләнеп тә, университетларның матди мөмкинлекләре булмавы аркасында, үз вакытында басылмый калган ике гыйльми эш бары тик 1991 һәм 1993 елларда тар аудитория укучыга барып иреште. (М. Өнәр һәм Н. Дәүләт хезмәтләре).

Төркиядә Габдулла Тукай белән бәйле иң зур алга китеш, һич шөбһәсез, Фатма Өзканның кандидатлык диссертациясе (докторлык тезисы) булды. Шул рәвешле, Фуад Көпрүлү, Хәмзә Зөлфикар һәм Мостафа Өнәрдән соң һәм татар нәселеннән чыкмаган төрек галиме Тукай темасына академик хезмәт яза һәм Төркиянең мәдәни тормышына, «Гомуми төрек әдәбияты»на гаять әһәмиятле өлеш кертә. Әлеге диссертациянең төрек культурасын өйрәнү институты тарафыннан« Габдулла Тукайның шигырьләре. Анализ. Текст. Тәрҗемә» (Анкара, 1994) исеме белән басылып чыгуы исә аның тагын да киңрәк күләм укучы тарафыннан танылуына сәбәпче була. Бу — бөек казаныш булып хисапланырга хаклы күренеш. Мостафа Акбаш тарафыннан язылган «Татар шагыйре вә язучысы Габдуллаһ Тукайның әсәрләреннән сәчмәләр (сайланма әсәрләр) вә алардагы

тел үзенчәлекләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе исә яклау өчен Истанбул университеты Иҗтимагый фәннәр институтының иске төрек теле бүлегенә тапшырылуын да ишеттек.

1991 елда, ике арадагы «тимер пәрдә» юкка чыгып, нибары биш ел вакыт узганнан соң, Төркиядә ике кандидатлык диссертациясе язылу — гаять зур алга китеш. Бу төр академик хезмәтләр белән Төркия тышындагы төрле төрки кавемнәрнең (халыкларның) әдәбиятларын да фәнни юнәлештә өйрәнү һәм бәяләү мөмкинлеге ачылды. Табигый ки, Төркиядәге бу үсешкә 1991 елда Советлар Берлегенең таркалуы һәм төрек дөньясының яңадан берләшә башлавының зур йогынтысы булды. Аеруча Төркиядә яшәгән һәм нигездә артык вәкаләтләре булмаган шәхесләр үз нәсел-нәсәбләре белән бәйле мәгълүматларны эзләргә тырышулары тиешле нәтиҗәне бирмәгәнен дә искә алсак, университетларыбыздагы яшь галимнәребезнең, академикларыбызның һәм ирекле (шәхси) тикшеренүчеләрнең мондый темаларга алынулары кардәш халыклар белән элемтәләребезнең ныгуына уңай йогынты ясаячак дип өметләнергә кирәк.

Соңгы елларда яшь галимнәребез арасында Тукай исеме тагын да күчлерәк ишетелә башлады. «Кардәш әдәбиятлар» журналы 1994 елда (28 нче сан) Мостафа Өнәр тәрҗемәсендә Әмди Гәрәйбәйнең «Тукайга» исемле шигырен һәм 1995 елда (32 нче сан) доктор Фатма Өзкан тәрҗемә иткән Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәрен бастырып чыгарды. «Төрек культурасы» журналы исә быелгы 395 нче санында (март 1996) Тукайның тууына 110 ел тулу уңае белән тагын Фатма Өзканның «Гомеренең язында вафат иткән бөек бер шагыйрь: Габдуллаһ Тукай» исемле мәкаләсен бастырды.

Кыскасы, үз илендә бик мәшһүр булган татар халык шагыйре Габдулла Тукай әкрен-әкрен Төркиядә дә танылa башлады. Бу исә тугандаш халыкларның якынлыгы аеруча мәдәни чаралар ярдәмендә артачагына инанган безләр өчен бик зур сөенеч. Бу хәлдә Тукай, бары ерак диаспорада яшәгән татарлар өчен генә түгел, ә бәлки Татарстан белән Төркия арасында да мөһим бер мәдәни элемтә юлы салынуга этәргеч булып торыр.

*Истанбул, июнь 1996.*

Язманы матбугатка **ӘЛФИНӘ СИБГАТУЛЛИНА** хәзерләде.



КАЗАН УТЛАРЫ

## «КАЗАН УТЛАРЫ» АРХИВЫННАН

# ӘДИПЛӘР ХАТ АЛЫША...

**«Казан утлары» журналы эшчәнлеге әдипләребезнең иҗади хәятыннан, уй-фикерләреннән аерылгысыз. Журналда гамәли эшләүчеләрнең дә күбесе — күренекле язучылар. Эш бүлмәләрендәге рәсми сөйләшү, аралашу, иҗади бәхәсләшүләрдән тыш, әдипләрнең үзара хат алышулары — шушы хезмәттәшлекнең тагын бер үзенчәлекле чагылышы.**

**Мондый хатлар үзләренең ихласлыгы, гамь-борчулары, әсәрне өйрәнү һәм редакцияләү процессының күзгә күренмәсрәк якларын күрсәтеп бирү җәһәтеннән кызыклы. Шуларны күздә тотып, без редакция архивында сакланган кайбер хатларны укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.**

*

«Казан утлары» редакциясенә
Мирсәй Әмирдән

Иптәш редактор!

Редколлегия члennары, редакция работниклары, каләмдәш дусларым!

Барыбызга да диярлек билгеле булганча, минем 1969 елның май аенда, ягъни моннан 15 ай элек редакциягә тапшырылган «Җан көеге» исемле повестем шушы көнгә кадәр басылмый ята. Хәлбуки, шул 1969 елның 3 нче июлендә үк булган редколлегия утырышында повесть турында житди фикер алышу булып, протоколга мондый сүзләр язылган иде: «Редколлегия члennары М. Әмир повестен журналда бастырып чыгарырга дигән фикергә килделәр». Редколлегия членнарыннан утырышта катнаша алмаган иптәшләрнең дә күбесе повестьны укып чыктылар. Күп кенә иптәшләр, әсәрнең идея эчтәлеге һәм әдәби эшләнеше ягыннан чыгып, аңа югары бәя бирделәр. Һәм, гомумән, әсәр турында идея ягыннан яраксыз дигән фикер әйтүче булмады. Булган замечаниеләр әсәрне басудан тыярлык күләмдә түгел, бәлки кульъязманы редакцияләү процессында хәл кылына торган характерда иделәр (аларның мин килешкән кадәресе күптән төзәтелде дә). Миңа ишеттерүләренә караганда, кемдер әсәрне татар халкына яла ягуда гаепләгән, имеш. Янәсе, сугыш вакытында татарлардан дезертирлар булмаган, янәсе, татар халкы намус ягыннан башка халыкларга караганда өстен тора. Мондый гаепләнүне мин, әлбәттә, кире кагам. Кайбер иптәшләр Камәреттиннең берничә ай буена өйдә качып ятып та хатыны белән җенси мөнәсәбәттә булмавын табигый хәл түгел дип табалар. Мин бу фикер белән дә килешә алмадым. Чөнки бу фактта Хәтирәнең рухи ныклыгы, аның гражданлык хисенең көчен күрәм мин. Әгәр Хәтирә ире белән андый мөнәсәбәткә керергә юл куйса,

бу анын дезертирлыкны гафу итүе булыр иде. Алай булган сурәттә миңа бу әсәрне язу да кирәк булмас иде.

Әсәрнең вакытында басылмавына төп мотив итеп, редактор аның темасын гаепләгән иде. Ягъни, зур юбилейлар чорында дезертир турындагы әсәрне басу уңайсыз, диде. Мин артык настаивать итмәдем. Гәрчә партияле позициядән торып язылган, намуслы хезмәткә, советчыл патриотлык хисләренә мәхәббәт, гражданлык бурычын онытучылыкка, түбән җанлылык, куркаклык кебек әшәке күренешләргә аяусыз нәфрәт рухы белән сугарылган әсәрнең теләсә нинди тантана көннәрендә дә басылырга хаклы икәнлегенә иманым камил булса да, юбилейлар узганчы көтәргә каршы килмәдем. Юбилей саннарына яхшырак әсәрләр бар икән, бик әйбәт, аларга торткарлык булмасын, дидем. Басылдылар. Күрдек. Ләкин юбилейләр дә узып китте. Минем повестьны басарга җыену сизелми. Әйтерсең, ул бөтенләй юк. Һәм бу редакция работникларын да, редколлегия членнарын да борчымый кебек. Бу хәл мине бик каты рәнҗетә.

Мин, рәхәтләнеп яңадан-яңа әсәрләр язар вакытымда, җиде ел гомеремне Союзда җитәкчелек итү эшенә бирдем. Партия һәм каләмдәш иптәшләрем тапшырган бу авыр, җаваплы эшне намус белән, хәлемнән килгән кадәр тырышып башкардым. Өлкән һәм яшь язучыларга карата, аларның иҗатларына бәя бирүдә мөмкин кадәр гадел, объектив булырга тырыштым. Миңа өч тапкыр хисап доклады белән чыгарга туры килде. Гражданлык намусым кушканча, эстетик белемем, әдәбиятне аңлау дәрәҗәм мөмкинлек биргән күләмдә яхшыны яхшы дип, начарны начар дип бәяләргә тартынмадым. Җиңел булмады. Чорыбыздагы катлаулы әдәби хәрәкәт һәм четерекле иҗат эшләребез турында хисап доклады белән чыгуның минем өчен повесть яки роман язуга караганда да авыррак булганлыгын үзем генә беләм.

Ниһаять, иҗат эшенә бушагач, сугыш чорында үзем күргән, күп еллар буе онытылмыйча һаман күңелемне билән, җанымны тынгысызлап килгән вакыйга һәм кешеләрне нигезгә алып, шул повестьны яздым. Әсәремнең әдәбият алдына партия тарафыннан, халык тарафыннан куелган таләпләргә җавап бирүенә шикләнмим. Миннән яңа әсәр көтүче укучыларымның да аны хуп күреп кабул итәчәгенә ышанам (повестьның «Соц. Татарстан»да басылган өзекләре буенча миңа фикерләрен әйтүчеләр, аның тулы килеш басылып чыгуын көтүчеләр күп).

Кайбер иптәшләрнең повестьны сугыш чоры колхозының кара якларын нигезгә алган итеп кенә күрергә теләүчеләре белән һич килешә алмыйм. Хәтирәнең, иске йола богаулары астында газапланган хәлдә, башына килгән шәхси фаҗигагә җиңелмичә, патриотик хезмәтендә нык торучы, үзенең генә түгел, иренең дә исәнлегеннән бигрәк намусы өчен фидакарь көрәшүче татар хатыны образының язмышы әдәби әсәр өчен әһәмиятле түгелмени? Корбангали? Бернинди ялган авторитетлар, тормышка хилаф, ялгыш күрсәтмәләр белән исәпләшмичә, барыннан да элек үзенең коммунистлык намусына таянып, колхоз белән җитәкчелек итүче председатель образы әһәмиятле түгелмени? Авыр сугыш чорында колхозларны аяктан екмыйча, фронтны һәм тылны икмәк белән тәэмин итүдә шундый коммунист председательле колхозлар хәл кылгыч роль уйнамадымыни?»

*(Шушы урында, билгесез сәбәпләр аркасында, хат өзелә.)*

## Язучы Рафаил Төхфәтуллинга баш редактор хаты

Рафаил дус!

Ниһаять, кул җитеп, мин синең «Акбүз ат»ыңны укып чыктым. Яңа, кызыклы повесть язгансың. Яңалыгы шунда — сугышта һәлак булганнарга мөнәсәбәт (битарафлык бу очракта) солдат улының протестлары аша бирелгән. Ә шул вакыйгаларны сөйләүче кеше солдат булганга, аны аңа сөйләүче кеше солдат улының анасы булганга, тормышның катлаулылыгы тагын да раслана төшә.

Минем өчен солдат улы Әсгать тә, солдат хатыны тол Әкълимә дә — яңа образлар. Әдәбиятта сугышта үлгән ирен сагынып, көтеп яшәүче пассив образлар булгалады. Синең Әкълимәң — сагышланып, кул кушырып утыручы түгел, исән калганнар җаны өчен, аларның канатлары сынып үсмәсен өчен бар булган гомерен багышлаган кеше. Син аның гөлдерәп кенә көлеп куюын, капыл гына кабалана, өтәләнә, каушап кала алуларын бик дөрес тотып алгансың, алар нәкъ

мена балалары язмышын бер генә секундка да исләреннән чыгармаган кешеләрдә була. Мин ятим үскән кеше, мин аны үз әнием мисалында беләм, һәм синең шул сыйфатларны солдатка Әкълимәдә күрүеңне, язучы буларак, уңышын дип, тормышны әле һаман күзәтүдән туктамаган Рафаил Төхфәтуллинның тагын да әйбәт әсәрләр яза алачагына мөмкинлеге зур дип аңлыйм.

Сәеттәрәйнең Әкълимәгә кызыгып йөрүе, аны төпсез калушка утыртып китүе, соңыннан Сәетгәрәй кызы Зөлфиягә Әсгатьнең өйләнүе — болар барысы сюжетны баета, катлауландыра, әмма детектив ясамый. Сәеттәрәй карага манылмаган. Соңыннан бит ул үзе иң бәхетсез кеше булып кала. Әсгать, Зөлфия — икәү бәхетле, шул икәүнең бәхетенә, иренең һәйкәлдә исеме язылуга Әкълимә бәхетле, бөтенесе ташлаган, берәүгә дә кирәге калмаган Сәеттәрәй бәхетсез.

Повестьны төзәткәндә тагын бер нәрсәне искә ал әле. Әсәр болай озын түгел, нибары 80 бит. Миңа калса, таркаурак, таралыбрак торган урыннарын җыйнасаң, аның тәэсир итүе тагын да арта төшәр иде. Тыгызлауны син әсәрнең буеннан-буена үзең эшлә инде, һәрхәлдә, андый урыннар 15 биткә җыела ала дип исәплим мин. Яңа күз белән, читтән торып карап чык. Бу киңәшне мин практик яктан да чыгып әйтәм. Быелга безнең журналның һәр саны планлаштырылып, идарәдә расланды. Аңа хәзер күләмле зур әсәрләрне кертү, өстәү мөмкин түгел. Сиңа гыйнварда 50 яшь тулуны искә алып, бу повестьны (әйтик, ул 60 бит булса) 1973 елның 12 санына кертүне мин редколлегия алдына кискен итеп куя алыр идем. Китабыңа керткәндә син аны әле, бәлки, 100 битле итеп тә эшли алырсың, андый — җәеп күрсәтердәй — урыннар юк түгел. Безгә аның 60 биткә сыеп беткән булуы бик мөһим.



*Язучылар Аяз Гыйләҗев (сулда), Мөхәммәт Мәһдиев (уртада), Гариф Ахунов. 1994 ел.*

Рафаил дус, син «Бәтнек үләне»нә бик кыска язгансың дип үпкәләгән идең. Менә монысын озын яздым. Повестьны карап чыгуны тизләт. Без инде 7 санны әзерләп бетердек. Журнал бит 4—5 ай алдан әзерләнә хәзер.

Хәзергә сау бул. Рәзинәгә, балаларга сәлам.

Бәйрәмеңне повесть белән каршылату теләгем зур булганны аңлата алдыммы?

Дусларча кочаклап:

**Гарифҗан Ахунов,**
*16 март, 1973 ел.*
*Казан.*

**R. S.** Машинкада язган дип үпкәләмә. Кулым авырта, бу арада романым белән утырдым, кулга каләм тотар чама калмады. Каләмдәшләргә, Әлмәттәге яхшы кешеләргә сәлам әйт.

## «Казан утлары»ның баш редакторы ип. Р. М. Харисовка

Хөрмәтле Ренат Мәгъсумович!

Бу араларда мин сезнең редакциягә тапшырылган «Агат» повестемне яңадан карап, күзәтеп чыктым. Кабатланган сүзләрдән, җөмләләрдән арындыру теләге белән шактый вакыт бирергә туры килде. Моның белән мин редакцияне «кара эштән» беркадәр коткарырга тырыштым.

Шул ук вакытта әсәрне ничек кенә булса да кыскарту турында да уй йөреттем. Кызганычка каршы, әллә ни маташтырып булмады.

Шулай да «Барлас истәлекләре» һәм «Үлек сәгать» дигән бүлекләрне төшереп калдырырга мөмкин булыр шикелле. Әмма бу барлыгы 20 бит, журналны канәгатьләндермәс дип уйлыйм.

Инде «Ялкын»да һәм башка газета һәм өлешчә җыентыкларда чыккан өлешен бөтенләй төшереп калдырсак, шактый зур әсәр үзенең эчтәлеге белән юкка чыгар төслерәк сизелә миңа.

Алга куйган бурычларым, теләкләрем әсәрнең әнә шул өлешендә. Алда язылган өлешләре хәзерлек төсендә генә язылдылар.

Ничек кенә уйласак та әсәр сезнең журналның укучылары өчен яп-яңа әсәр. Алар бит повестьны тулысынча укыр өчен «Ялкын» журналын эзләп йөрмәсләр. Тулы басылган әсәр укучылар интересын да канәгатьләндерер дип уйлыйм. Яртылаш кына басылган әсәр укучыларның күңелен китеп калдырыр.

Яхшы әсәр ничә генә кабат басылса да язык булмастыр, мөгаен. Бирәдә мин «яхшы» дигән сүзне кулландым. Гафу итегез, бу сүзне укучылар хатларына таянып әйттем. Укучылар бу повестьны тулысынча укып чыксалар, шатланырлар, журналга да рәхмәт әйтерләр. Журнал хәзер шундый дәрәҗәгә менеп бара.

Укучылар үз хатларында да, мине урамнарда очраткан чакларында да: «Кайчан китапның дәвамы чыга инде?» — дип сорыйлар. Бу юкка түгел, моның үз сәбәбе бар. Әсәрнең геройлары, элекке шпаналар нишләп кенә беттеләр икән, инде чын кешеләргә охшап киләләрме? дип борчылалар алар. Укучылар минем геройларымның язмышлары белән кызыксыналар. Әсәрнең көче әнә шунда.

Бигрәк тә, үзләре дә дөнья күргән кешеләр ятим балаларның ничек итеп кешелеккә баруларын күрергә, белергә телиләр.

Әсәрдә бит тагын бер, безнең әдәбиятта бик сирәк очрап торган тема бар. Сизәсездер, повестьта Агат исемле ат юкка гына алынмаган. Ул да, ягъни хәйван да ятим балаларны, шпаналарны тәрбияләүдә булыша. Ничек кенә әле! Хәйванга ихтирам аша бала үзенә дә ихтирамлы булырга, яхшы кеше булырга өйрәнә. Повестьның бу өлеше тулысынча шуңа багышланган.

Инде минем фикерләрем белән килешә алмасагыз, Сезгә үпкә белдерәсем юк. «Казан утлары» редакциясе миңа онытылмаслык ихтирам күрсәтеп килә. Рәхмәттән башка бер сүзем дә юк.

Сез мәсьәләне ничек хәл итсәгез, мин шуңа риза.

Уңышлар теләп, **Нәби Дәүли.**

*15 март, 1987.*

## «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рашат Низамиевка килгән хатлардан.

*24 февраль, 1988 ел. Голицыно*

Хөрмәтле Рашат туган!

Рәхмәт яусын сиңа җылы хат өчен. Рәсми җавапка өстәп шундый әйбәт хат язгансың. Язмасаң да белән минем иҗатка җылы, изге карашта икәнлегеңне. Миңа карата игелек эшләвең өчен рәхмәт сиңа һәм аны кайтарып булсын иде әле.

Марсель Галиевкә дә миннән рәхмәт тапшыр. Рецензиясе миңа ошады. Шундый изге теләк белән тәнкыйтьләүчеләр безнең әдәбиятка өстәлеп торсыннар иде әле. Безгә нәкъ шундый кешеләр һәм шундый мөнәсәбәт җитми. Әгәр «Европа ат сагына» планга кереп, аның басылуы хәл ителсә, мин аны баштан-аяк карап, төзәтеп, яхшыртып чыгам. Ләкин... Журналда бит синнән башка кешеләр

дә, хәтта бераз югарырак утыручылар да бар бит әле. Аларның миңа карата карашлары үзгәрүен тоймыйм мин. Бу тойгы ялгыш булса, минем өчен дә, журнал өчен дә файдалы булыр иде. Власть дигән нәрсә бит ул... Син иҗат кешесе, беләсең, иҗат эшенә власть катнаша башласа, аннан игелек көтеп булмый. Белмим, ни сәбәптер, әдәбият начальникларына минем әсәрләрем, аларның сыйфаты, алардагы иман гайрәте, алардагы хакыйкать кирәк түгел, минем алар чанасына утырып алар җырын җырлавым кирәк шикелле. Иҗат кешесе иң беренче чиратта шәхес булырга тиеш. Шәхеснең, билгеле, үз карашы, үзе зәвыгы һәм позициясе була. Шәхес булган кешене теләсә кем җырын җырларга мәҗбүр итү дөрес түгел ул. Андый таләп эшкә, мөнәсәбәткә зыян гына китерә торгандыр дип уйлыйм.

Монда татарлар юк иде, әле шушы көннәрдә генә Казаннан Нурмөхәммәт Хисам атлы кеше килде. Хәзер инде сөйләшергә кеше бар. Әгәр Голицынога путевка алып булса, баш тартмаска кирәк.Монда эшләргә рәхәт.Барлыгы 34 кеше, тыныч, Мәскәүгә бары тик 45 минутлык юл. «Казан утлары» егетләренә һәм кызларына миннән кайнар сәлам.

Ихтирам белән, кулыңны кысып, иҗат уңышлыклары, сәламәтлек теләп, **Миргазиян Юныс.**

*26 март, 1988. Переделкино.*

Рашат дус!

Хатың килде, рәхмәт. Көтә идем...

Соңгы айларда өстәмә яуган баллы яңгырларны — мактау сүзләрен үзең дә белеп торасың... Газеталар мактады, журналларның кайберләре сыртыма май сөртте, үзем дә мактандым, мактау сүзләрен авызымны ерып, колагымны шәңкәйтеп тыңлап утырдым... Кыеклап яуган төче яңгырның үтеп китәсен, аның тирәнгә, тамырларга шифа бирмәячәген бик яхшы аңлый идем!.. Алай да, «Яра» повестьын сиңа җибәргәч, әйбәтрәк фикер ишетәсе килә иде! Атны солы белән ку дигәннәр, скрипка шәп уйнасын өчен кылларын канифольләп торырга кирәк... Күңел бит, повестьның әллә кем түгеллеген дә чамалыйм, әмма җылы сүз ишетәсе килә... Бигрәк тә яңа әсәр белән җенләнеп утырганда, анысы элеккесенә караганда да авыррак, газаплырак язылганда мин дә шәфкать-мәрхәмәткә мохтаҗ идем! Хатлар озак йөри, хатың иртәрәк килгән булса да ярыйсы иде. Син



*Күренекле әдипләр «Казан утлары»нда кунакта. Сулдан — уңга. Утырганнар: Ә. Баянов, Г. Бәширов, З. Нури, А. Шамов, М. Әмир, Р. Ишморат; 2 рәт: сулдан — уңга. Ш. Бикчурин, Р. Мостафин. 1966 еллар.*

хатынны 15 елдә язгансың, ә мин шул төнне төш күреп, төшемне сиңа язып та җибәргән идем! Бар ул Алла, бар!..

Романның беренче җитди өлешен караламада язып чыгам кебек... Авыр бара, авыр! Читен! Хәзерге чорда төрле тарафлардан халыклар күңеленә бик күп яңа информация яуды, укучылар публицистика, документальлек белән мавыктылар. Алга, күңелләрнең алласы, җаннарның кәгъбәсе булып, тарихи документлар чыкты. Гомергә китап-журнал тотмаган кешеләр укырга ябышты, абруйлы журналларның тиражы өч-дүрт мәртәбәгә артты, китапханәләрдә озын-озын чиратлар тезелде. Татар укучысының зәвыгы да шушы тәэсирле үзгәрешләрдән коры калмады. Хәзер бер кавымга кадәр укучы бездән төгәллек, тарихи дөреслек, ачы хакыйкать көтәчәк. Ләкин «бум» үтәр, әдәбият элекке хәленә кайтыр, гаделлек һәм чынлык сакчысы булып, халык күңеленә хис, хиссият һәм тәэсирләр төрлелеге илтер. Хәзер кеше күңеленә тәэсирле кагыла торган әсәрләр чоры башланачак... Яңа әсәр өстендә утырганда мин моны бик нык истә тотам. Әдәби әсәр акылга нигезләнгән күңел җимеше булса да, кай арада укучы турында да уйламыйча ярамый!..

Казаннан киткәнгә дә байтак узды, язны тәмам җиткереп, кышны Переделкино урманнарында адаштырып калдырып кайтам бугай инде. Сагындым димим, сагынмадым, өйдә эшләп булмый. Олыгайган саен күңел ялгызлыкка тартыла. Дәрвишләр, монахлар ничек япа-ялгыз яшәгәннәр, хөҗрәләрдә гомер кичергәннәр дип шакката торган идек, картлыкта ялгызлык бәхет тә икән ул! (Әлбәттә, сау-сәламәт булганда!) Сез, мөгаен, ел йомгаклары үткәрергә җыенып ятасыздыр...

Исемә төшә дә көлеп җибәрәм: безнекеләр тезелеп утырган зал, күркә кебек кабарынган, важный кайберәүләр күз алдыма килгәч, көлмичә түзеп булмый! Нинди буш, юк кешеләрне дә кертеп тутырдык бит союзга! Исемнәре кеше рәтеннән матбугатта чагылып китсә, алар өчен иң олы бәхет шул!... Аңламыйм. Һәм бу арада союз тирәсендә булмавыма, еракган көлемсерәп карап торырга җаем барына куанам... Эш кирәк, Рашат дус, эш! Документаль повесть синең аякны шактый тышаулап торды, алынган темаң үтә мөһим булса да, давай, үз сукмагыңа кайт әле син, сукмагыңны киңәйт, юл яса.

Сезгә хөрлек заманы, иркен заман килде! Шуның рәхәтен белеп, аңлап эшләп калыгыз. Бөтенесен дә картлыкка калдырырга ярамый...

Хуш булып тор. Хатың өчен рәхмәт.

Гаиләңә миннән сәлам.

Иң яхшы теләкләр белән пенсионер

Аяз дәдәң.[1]

## «Казан утлары» журналының баш мөхәррире шагыйрь Равил Фәйзуллинга килгән хатлардан

Хөрмәтле Равил Габдрахманович!

Татарстан Республикасының Мәскәүдәге Вәкаләтле вәкиллегендә китапханә оештырылып килә. Аның фондларыннан Республика Президенты һәм Татарстанның башка җитәкчеләре, шулай ук Вәкиллекнең җаваплы хезмәткәрләре файдалана. Сирәк очрый торган әдәбият-сәнгать әсәрләреннән, Татарстан тарихы буенча китаплардан, махсус әдәбияттан, видео һәм аудиокессеталардан тыш, биредә Татарстанның вакытлы матбугаты да киң урын алачак. Вәкиллек китапханәсе фондларында Сезнең ихтирамга лаек журналыгызны булдыру икс якның мәнфәгатьләренә дә туры килер иде.

Бер үк вакытта без Сезнең белән иҗади хезмәттәшлек итәргә һәм Сезнең басманың эшчәнлегендә катнашырга да әзер. Мәскәүнең татар җәмәгатьчелеге арасында якты талантлар, зур рухи һәм тормыш тәҗрибәсенә, иҗади һәм

[1] Язучы Аяз Гыйләҗев.

интеллектуаль потенциалга ия булган шәхесләр аз түгел. Алар Сезнең журналның геройлары һәм авторлары була алырлар иде. Журналыгызны кызыксындырган темалар белән таныштырган очракта, Вәкаләтле вәкиллек хезмәткәрләре үзләре дә Сезнең белән хезмәттәшлек итә, шулай ук лаеклы геройларны һәм компетентлы авторларны күрсәтә ала.

Мөмкинлектән файдаланып, Сезгә һәм редакция хезмәткәрләренә эчкерсез хөрмәтемне белдерәм, сәламәтлек һәм иҗади уңышлар теләп калам. Ихтирам белән,

**Фәрит Мөхәммәтшин,**
Татарстан Республикасының
Русия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиле.
*Мәскәү шәһәре.*
*07.12.1995*

Равил туган!

Менә «Кызыл таң»ны җибәрәм. Анда «Казан утлары» рекламасы бар. Сезнең рәсем. Рашат Низаминың хикәясе. Шуларга ияртеп, «Өмет», «Азатлык нуры»н салам. Алары болай гына. Карар өчен.

Шөкер, бездә дә төрле газета, журналлар чыга башлады. «Азатлык нуры» — шуның бер үрнәге. Дөрес, бик хата белән чыга әле. Чөнки редактор берүзе диярлек. Корректорлары да юк.

Тугызынчы санны алдык. Андагы рекламада (шулай дип әйтергә ярый микән?) романның икенче кисәге турында әйтелгән. Машинкада 200 бит чамасы басылды инде. Мин Тәүфикъка ноябрь азакларында йә үзем бару, йә почта аша җибәрү турында язган идем.

Ышанычыгыз өчен зур рәхмәт! Ул мине канатландыра, дәртләнеп эшләргә яңа ялкын бирә, җаваплылыкны да арттыра.

«Казан утлары» яратылган журнал инде ул! Кулдан килгәнчә без дә монда аны тарату белән шөгыльләнәбез. Үз журналыбыз бит! Студентлар арасында да эш алып барабыз.

Хәзергә шулар. Бездә әллә ни яңалыклар юк.

Кайнар сәлам, хөрмәт һәм ихтирам белән —

**Суфиян** абыегыз **Поварисов.**
*23.X.1996*
*Уфа.*



# Миргазиян Юныска — 70 яшь



Күренекле прозаик һәм публицист Миргазиян Юныс 1927 елның 25 маенда Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында крестьян гаиләсендә туган. Авыл мәктәбенең алты классын тәмамлаганнан соң, ике ел колхозда эшли. 1944 елның августында армиягә алынып, хәрби авиация мәктәбенә укырга җибәрелә, аннары укчы-радист сыйфатында бомбардировщикларда оча. 1950 елда экстерн тәртибендә Харьков хәрби-авиация училищесын тәмамлагач, авиаэскадрильяларда элемтә начальнигы булып хезмәт итә, бер үк вакытта кичке мәктәптә укып гомуми урта белем ала.

1955 елда сәламәтлеге начараю аркасында очу эшеннән азат ителгәч, М. Юныс демобилизацияләнә һәм М. Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. Бераздан университетның читтән торып уку бүлегенә күчеп (аны ул 1961 елда тәмамлый), Кара диңгез дәүләт пароходчылыгында навигатор булып эшли башлый. 1957 елда кыска сроклы курсларны тәмамлагач, М. Юнысны чит илгә йөри торган сәүдә корабы капитанының политик тәрбия эше буенча беренче ярдәмчесе итеп билгелиләр. Бу эштә ул 1968 елга кадәр була. 1968—1977 елларда М. Юныс Мәскәүдә Бөтенсоюз диңгез транспорты фәнни-тикшеренү институтында өлкән белгеч, СССР Диңгез флоты министрлыгында бүлек начальнигы һәм «Наука и религия» журналы редакциядә бүлек мөдире вазифаларын башкара. 1977 елдан бирле ул яңадан әүвәлге хезмәтендә — Кара диңгез һәм Азов диңгезе дәүләт пароходчылыгында сәүдә корабы капитанының беренче ярдәмчесе булып эшли.

М. Юныс — әдәбиятка зур тормыш тәҗрибәсе туплап килгән прозаикларның берсе. Ул алтмышынчы елларда яза башлый. Диңгезче хезмәтенә, чит илләрдә яшәүче халыкларның тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә бәйле кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгаларны тасвирлаган «Безнең өй өянке астында иде...», «Тимер фил», «Кочегар», «Әти оҗмахка киткәч», «Ямәнгә сәяхәт», «Зәңгәр дөнья», «Яңар таулар», «Диңгез чакыра» кебек беренче хикәя, очерклары һәм романтик рухлы «Занзибәр зәңгәр болытлар артында» исемле повесте белән ул укучыларның һәм әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын үзенә җәлеп итә. Авторның шуннан соң язылган әсәрләре — «Тозлы җил» (1973), «Теләп алган давыл» (1975) повестьлары һәм «Энҗе эзләүчеләр», «Табу һәм югалту», «Биектә калу» һ. б. укучылар тарафыннан җылы каршылана.

М. Юныс, язучы-художник буларак, темаларның колачы, чынбарлыкны заманның олы проблемалары, тарихи тенденцияләре җирлегенә куеп яктыртырга омтылуы, вакыйга-хәлләрне, кеше характерларын ачуда, тормыш конфликтларын чишүдә психологик, әхлакый-фәлсәфи анализга киң урын бирүе белән бүгенге татар прозасында үзенчәлекле урын тота.

Әдипне олы юбилее белән кайнар котлыйбыз!

## Бари Рәхмәт

(1897—1957)

Әдәбият мәйданында артык шауламыйча, дан-дәрәҗәләр дауламыйча, үз урынын белеп кенә яшәгән һәм иҗат иткән шәхесләр бар. Гадәттә, алар табигый талантка ия, тормышта да бернинди көчәнүсез-ясалмалыксыз гади яшәүче затлар, андый кешеләр белән аралашуы да җиңел-күңелле була.

Безнең буын күреп-белеп, азмы-күпме танышып-аралашып калган шундый өлкән язучыларыбызның берсе татар балалар шигъриятенең күренекле вәкиле Бари ага Рәхмәт иде.

Быел шагыйрьнең тууына 100 ел тула.

Бари Сибгатулла улы Рәхмәтуллин, «чәчелгән татарның» бер баласы буларак, 1897 елның 29 маенда элекке Урал губернасы, Гурьев өязенең Жилая Коса поселогында (хәзерге Казакъстан җирләре) дөньяга килә. Шунда мәдрәсәдә укый, Г. Тукай шигырьләрен яратып үсә, тәэсирләнеп үзе дә каләм тибрәтә башлый. Озакламый Казанда чыга торган «Ак юл» исемле балалар журналында (1913—1918) унҗиде яшьлек Бариның беренче шигыре басыла. Шуннан соң Бари Рәхмәт әлеге журналның даими язышып торучы авторы булып китә.

1918 елда Б. Рәхмәтне Кызыл Армия сафларына алалар һәм ул өч ел дәвамында Казандагы татар запас батальонында хезмәт итә. Тиздән аны Үзәк Мөселман хәрби коллегиясенең «Кызыл Армия» исемле газета редакциясенә әдәби бүлек мөдире итеп билгелиләр. Үз газетасыннан тыш, Б. Рәхмәт шул елларда Казанда чыгып килгән башка басмаларда да («Эш», «Эшче», «Кызыл Шәрекъ») актив язышa.

1921 ел. Идел буйларында коточкыч ачлык хөкем сөрә. Армия сафларыннан демобилизацияләнгән Бари Рәхмәт, каләмхакка гына тамак туйдырып булмаячагын аңлый, күрәсең: ул үз туган якларына кайтып китә. Анда да тормыш алып барулары бик авыр, яшь шагыйрьгә хәтта иҗатын да «онытып» торырга туры килә. Ул бары тик 1932 елда гына гаиләсе белән Казанга күченә. Әле анда да башта төзү трестларының берсендә гади эшче, аннары бухгалтер булып эшли.

Әдәби иҗат ялкыны шулай шактый озак сүнеп-сүрелеп торганнан соң, Бари Рәхмәтнең сатирик һәм лирик шигырьләре 1939 елдан «Чаян» һәм «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналларында янадан күренә башлыйлар. Шагыйрь әдәбиятка әйләнеп кайта.

Әмма Б. Рәхмәткә иҗатында иркенләп ачылып китәргә һаман да язмаган икән шул әле. Дөнья янә болгана. Бөек Ватан сугышы башлана. Кырык биш яшьлек Бари Рәхмәт 1942 елда — сугыш кырында. Ул Украина, Молдавия, Болгария һәм Венгрия җирләрен азат итү сугышларында катнаша. Инде 1945 елның язы якынлаша. Менә-менә җиңү таңы атар, туган илгә, гаиләләребезгә кайтырбыз, дип алгысынып йөргәндә генә Бари Рәхмәт яралана. Госпитальдә ятып чыкканнан соң, ул Өченче Украина фронты газетасы «Совет сугышчысы» редакциясендә хәрби хәбәрче була.

Ниһаять, Җиңү! Бари Рәхмәткә дә, фронтовиклар әйтмешли, «фашистларның муенын борып, орден-медальләрен чыңлатып» Казанга — гаиләсенә әйләнеп кайту бәхете тия. Алда — тыныч тормыш, алда — иҗат...

Бари Рәхмәтнең сугыш чоры лирикасы да, сугыштан соңгы юмор-сатирасы да бик табигый, халыкчан рух белән сугарылган иде. Аның ул чордагы иҗат җимешләре татар шигъриятенең матур үрнәкләре булдылар. Алар шагыйрьнең «Шигырьләр» (1957) китабында шактый тулы тупланып дөнья күрделәр.

Язмыш дигәнең гаҗәп бит ул. Шагыйрь Бари Рәхмәтне иҗатында янә бер матур борылыш көтеп торган икән. Ул, илле яшьләре тулып киткәннән соң, дәртләнеп-тәмләп нәниләр өчен шигырьләр яза башлый. Һәм ничек кенә яза әле! Бик тиз арада ул балаларның иң яраткан шагыйрь абыйларына әйләнде, илленче

елларда әдәбиятка аяк баскан Шәүкәт Галиев кебек яшьләргә остаз булды. Әгәр чагыштырулар эзләсәк, Бари Рәхмәт татар балалар шигъриятендә урыс балалар шигъриятенең Корней Чуковский, Самуил Маршак, Агния Барто кебек талантларына тиңләшә алыр иде.

Шулай итеп, татар балалар шигъриятенә соңлап аяк басса да, бер дистә ел эчендә берсеннән-берсе матур-кызыклы байтак китаплар биреп өлгерде Бари Рәхмәт.

Аны 1952 елда (инде илле биш яшенә җиткәч) нәкъ менә балалар шагыйре буларак СССР Язучылар союзында әгъза итеп алалар.

Бари Рәхмәт эчкерсез-риясыз, нечкә-үткен юмор хисле, сабыйларча куанып-шатланып яши белә торган садә җанлы бер шәхес иде. Дөньядан да ул, куана-куана, көтмәгәндә генә китеп барды...

1957 ел. Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәре. Шыгырым тулы залда Бари Рәхмәт, тыңлаучыларын көлдерә-көлдерә, шигырь укый. Аны көчле алкышларга күмәләр. Ул тагын укый, тагын... Аннары куанычы эченә сыймаган хәлдә сәхнә артына чыгып китә һәм шунда... аның йөрәге тибүдән туктый... Бу хәл 1957 елның 26 маенда була. Шагыйрьгә 60 яшь тулырга нибары өч көн калган булган...

Журналыбыз укучыларына шагыйрь Бари Рәхмәтнең табигый-саф, якты шигъри үрнәкләреннән берничәсен тәкъдим итәбез.

**Марс ШАБАЕВ.**

# Бари Рәхмәт

## Бармагыңа акча түлим

Басып торам алдыңда,
Күзем бармакларыңда,
Бар икән бармакларыңда
Алтын балдакларың да.

Күмәч үлчисең «шарт» та «шырт»,
Карап торам шаккатып:
Бер аласың, бер саласың
Сыныкларны «шылт» та «шылт».

Бармакларыңны, җанашым,
Күмәч белән саласың,
«Шалт» иттереп саласың да,
«Ялт» иттереп аласың.

Бармагыңны ник саласың?
Салгач кире аласың.
Мин бит аңа акча түлим,
Алмасана, җанашым!

Сугыштан соңгы авыр елларда икмәк-күмәчләрне норма белән генә, шакмак-кисәкләрен дә өстәп, үлчәп саталар иде. *Ред.*

## Тәмәкене ничек ташларга?

Тәмәкене ташларга
Кушалар врачлар да.
«Лекция» укый хатын да

Шул тәмәке хакында.
— Сиңа нәрсә булгандыр,
Ике пачка «Беломор»
Көн саен син ашыйсың,
Күпме расход ясыйсың,
Бик күп китә акча,— ди,—
Җитәр инде, ташла! — ди.
Ике пачка «Беломор»
Җитми әле миңа ул.
Мин ташламакчы булып,
Йөрдем конфит тә суырып.
Канәфер чәйнәп бактым,
Чиманкәсен дә чактым,
Һич тә ташлап булмый бит,
Көн дә бер кило конфит,
Яхшы шоколад ашыйм,
Имеш, тәмәке ташлыйм.
Өйрәнеп китте авыз,
Тәмлесен тели явыз,
«Беломор»ны ташладым,
«Казбек» тарта башладым.

## Зәңгәр күл

Әкияттәге күлләр күк,
Бар бик матур зәңгәр күл.
Әйтерсең лә күк шәүләсе
Төшеп зәңгәрләнгән күк.

Суы чиста, топ-тонык,
Гөлгә кунган чык кебек.
Шундый тонык: күренә төбе...
Анда су да юк кебек.

Җем-җем итеп җемелдәп,
Якты кояшлы көндә
Ак таңкәләр, вак-вак ташлар
Күренеп ята төбендә.

Анда зәңгәр төннәрдә
Ай да төшеп тирбәлә;
Сайрап туймый таң алдында
Кошлар якын-тирәдә.

Атлас җыерылган кебек,
Куйгалый күл селкенеп,
Бит уртасын уеп көлеп,
Елмаеп куйган кебек.

Ялт иттереп су өстен,
Көндез кояш та төшеп,
Матур итеп күзен кысып,
Күлдә ята су эчеп.

# УКУЧЫ СҮЗЕ

* * *

Йөрәкләребезгә якын «Казан утлары»!

Синең изге-тансык сәхифәләреңдә чит җирләргә сибелгән милләттәшләребез турында кызыклы-гыйбрәтле язмалар еш бирелә. Бу юлы без Карелиянең Суоярви районында оешкан үзебезнең «Казан» җәмгыяте турында сөйләргә булдык әле.

Бирегә милләттәшләребезнең күпчелеге, 1939—1940 еллардагы фин сугышыннан соң, Карелия өлешенә тигән яңа җирләрне үзләштерү, табигый байлыклардан тулырак файдалану өчен, Татарстанның төрле районнарыннан күченеп килә.

Безнең Тәтеш районының Кызыл Йолдыз авылыннан килүчеләр, мәсәлән, Тойвола дигән урында тулы бер поселокка — җәнлек үрчетү белән шөгыльләнүче «Таң» совхозына нигез салалар. Аңа Мөхәммәтҗан Гыйззәтуллин җитәкчелек итә. Аннары эстафетаны кызы Дилбәр Садыйкова ала. Бирдә карел-фин дуслар белән бергә иңгә-иң торып, тырышып эшләүче, үзара ярдәмләшеп гомер кичерүче Нурия Галиева, Рауза Гафиятуллина, Разия Кәлимуллина, Гөлсем Гашигуллина, Фәхрибану Гобәйдуллина, Кәлсум Фәхретдинова, Шәһәрбану Гобәйдуллина, Мөбәрәкҗан Ризаев, Гарифулла Садыйков кебек якташларыбызның исемнәрен зур горурлык хисләре белән телгә аласыбыз килә. Чөнки алар татар халкының намуслы, эшчән, булдыклы булуын, үз мисалларында бик ачык күрсәтеп, милләтебезне данлыйлар. Шундый ук сүзләрне Актаныштан Мәмдүдә Сәхәбетдинова, Апастан ирле-хатынлы Фурия һәм Габделсамат Латыйповлар, Мамадыштан Әсбидә һәм Әгъләм Мисбаховлар, Тәтештән Наил Шакирҗанов, Казаннан Гыйззебану һәм Шәехҗан Шәкертҗановлар һ. б. адресына да әйтәсебез килә. Халык хуҗалыгының төрле тармакларында фидакарьләрчә эшләүче бу якташларыбыз — чын мәгънәсендә, милләтебезнең йөзек кашы, йөз аклыгы!..

Әлеге ватандашларыбыз Карелия җирендә барган сугышларда һәлак булган якташларыбызның каберләрен эзләп табып, аларның якты истәлекләрен мәңгеләштерү юнәлешендә дә мактауга лаек эшләр башкаралар. Татарстаннан 4 мәртәбә килеп, Суоярви һәм Медвежьегорск районнарында зур эзләнүләр алып барган «Хәтер яктысы» экспедициясе әгъзаларына да бик теләп булыштылар алар. Түбән Кама районында туып-үскән чик сакчысы — Советлар Союзы Герое Никита Кайманов, зур батырлыклар күрсәткән офицер-шагыйрь Нух Идрисов, взвод командиры Хаҗи Закиров, язучы Габдрахман Әпсәләмовның «Ак төннәр» китабына кертелгән Әтнә егете Нургали Хәсбиуллин кебек каһарманнарга һәйкәлләр куюда, исемнәрен урамнарга бирүдә, музейларда экспонатларын булдыруда, аларга багышлап спорт ярышлары, мәдәни чаралар үткәрүдә дә безнең «Казан» җәмгыяте әгъзалары башлап йөрделәр.

Үзебез яратып укый торган «Казан утлары» журналы аша Татарстанда яшәүче якташларыбызга кайнар сәламнәребезне, изге теләкләребезне юллыйбыз. Инде бездә бер мәртәбә кунакта булган, һәммәбезне тирәнтен сокландырган, бушлай шефлык концертлары биргән Фән Вәлиәхмәтов кебек талантлы җырчыларның, музыкантларның, артистларның безнең якларга да килеп чыгуларын көтеп калабыз!..

Шәмсия һәм Шәяхмәт ИДИЯТУЛЛИННАР,

Суоярви шәһәре, Карелия Республикасы.

* * *

Кадерле редакция!

Моннан алты ел элек безнең Күкчетау өлкәсендә Татар мәдәнияте үзәге оешкан иде. Шул чор эчендә ул күп кенә мөһим чараларны тормышка ашырды. Безнең үзәк милләттәшләребезне татар халкының данлы үткәне, шанлы бүгенгесе, өметле киләчәге, әдәбияты-сәнгате, гореф-гадәтләре, милли йолалары белән якыннанрак таныштырырга омтыла. Шул уңайдан без татар халкының «аксакал» журналы «Казан утлары»ннан бик теләп файдаланабыз. Әлеге академик басманы безгә Казанда яшәүче мөселман кардәшләребез Гайшә ханым Сиражетдинова, Зәкия ханым Садыйкова, Арнольд әфәнде Кәбиров даими җибәреп тора. Алар — өлкәбездәге Кызыл Яр авылында яшәүче өлкән әдибебез — Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, безнең үзәкнең мактаулы президенты Ибраһим ага Сәлаховның якын дуслары. Тегe яки бу йомыш белән Казагыстаннан Казанга килгәч тә без шушы искиткеч якты, яхшы күңелле олуг затларның кунакчыл фатирларында тукталабыз. Алар безнең мәдәният үзәге өчен әллә никадәр рухи байлык хәзерләп куйган булалар. Шулар арасыннан иң кадерлесе, әлбәттә инде, «Казан утлары» журналының яңа саннары!..

Соңгы вакытта безнең үзәк урта мәктәпләрдә татар телен, әдәбиятын укыту эшен җайга салды. Җирле телевидение һәм радио аша да файдалы-мавыктыргыч тапшырулар алып барабыз. Танылган татар язучыларының, шагыйрьләрнең иҗат үрнәкләрен милләттәшләребезгә җиткерәбез. Күренекле композиторлар, артистлар, җырчылар белән таныштырабыз. Үзәк каршында зурлар өчен «Галиябану» фольклор ансамблебез эшли. Балаларның «Тамчылар» ансамбле чыгышларын да тамашачыларыбыз бик яратып кабул итәләр. Шул ансамбльләр белән күп кенә шәһәр-авылларда, күрше өлкәләрдә дә булырга өлгердек инде. Мөмкинлектән файдаланып, без хаклы рәвештә татар халкының төп әдәбимәдәни учагы саналган «Казан утлары» турында да халыкка сөйлибез, анда дөнья күргән яңа әсәрләр белән якыннан таныштырабыз...

Инде менә яраткан журналыбызның 75 еллык матур бәйрәме дә килеп җиткән. Олуг юбилееңң котлы булсын, «Казан утлары»! Гел шулай балкып, милләттәшләребезнең йөзләренә нур сибеп, күңелләрен җылытып яшә...

Әския ӘХМӘТШИНА,

Күкчетау Татар мәдәнияте үзәгенең идарә әгъзасы.

* * *

Без, Татарстанның Чаллыяр шәһәреннән килеп, Төркия Республикасының данлыклы Сәлҗүк университетында белем алучы яшьләр, «Казан утлары» журналын даими укып барабыз. Чөнки монда — Туган илебездән еракта — ул безгә Татарстаныбызның җылы сулышын тоярга ярдәм итә. Шул кадерле-газиз журнал битләре аша без күренекле шагыйрьләребезнең, әдипләребезнең, галимнәребезнең берсеннән-берсе кызыклы язмалары белән танышабыз. Укыган-белгәннәребез турында иптәшләребезгә дә сөйлибез, төрек дусларыбызга да тәфсилләп аңлатабыз. Әнә шулай, күңелләрне күңелләргә тоташтыручы салават күперeдәй тылсымлы көчкә ия ул «Казан утлары»!

Айдар ӘХМӘТГАЛИЕВ,
Ришат ТИМЕРБАЕВ,
Айдар ШАКИРОВ,

Конья шәһәре. Төркия.

# Маннур Саттаров

## Җырлыйк Арча көйләренә

Җырлыйк Арча көйләренә,
Без бит Арча яклары.
Уйларымның Рәсәй буйлап
Сәфәр кылган чаклары.

Тальянски гармуныңны
Тартып уйна уйнасаң.
Җылау түгел еларсың да,
Ил хәлләрен уйласаң.

Күк читеннән болыт килә,
Яңгыр микән, кар микән?
Үз нигезен үзе сүткән
Тагын бер ил бар микән?

Агыйдел сулары кебек
Тар сулар булмас инде.
Рәсәйдә күк кысыр калган
Басулар булмас инде.

Житен башын жил кисәрме,
Жилбер-жилбер исмәсә?
Белгечләр илдән китәрме,
Дәүләт үги итмәсә?

Чит сериаллар карыйбыз,
Карый-карый арыйбыз.
Кино йолдызларыбызны
Рекламада таныйбыз.

Идел буе ком гына,
Ял урныбыз шул гына.
Жиде сумлык путевкалар
Хәзер миллион сум гына.

Алма сатучылар килгән,
Бар микән үлчәүләре?
Ярым эшсез, ярым ашсыз
Бүген ил эшчәннәре.

Бажам күмер шахтасында,
Сирәк яза хатларын.

Ачлык игълан итми торып,
Күрми хезмәт хакларын.

Агыйделнең аръягыннан
Ташлар алдым беләүгә
Триллионнар комга сеңгән,
Эзен тапмый берәү дә.

Башкаланың йортлары,
Җем-җем итә уллары.
Бүген Рәсәй үзәгендә
Җинаять рекордлары.

Сандугачның балалары
Сары була микәнни?
Башлыклар бер дә пошынмый,
Сабыр була микәнни?

Агым суларны кичкәндә
Агыздым кул яулыгын.
Илне байлар туйдырыр, дип,
Бүлделәр ил байлыгын.

Гармуныңны тартып уйна
Үрләргә менгәндә дә.
Бай бүлешмәс малы белән
Гүрләргә кергәндә дә.

## Килештерү

*(Мәсәл)*

Бүре бәрәнне ашаган,
Күреп торган куяннар...
(Еллар үткәч, икесенә
Уртак һәйкәл куйганнар.)

Бүрене җәзага тарту
Ашмый калган гамәлгә:
Указ чыккан дус яшәргә
Бүре белән Бәрәнгә.

## Җилбер-җилбер җил искәндә

Җилбер-җилбер җил искәндә
Җил ача юрганымны.
Нурлы Казан каласына
Багышлыйм җырларымны.

И Казан син, Казан син,
Белем биргән калам син.
Тар кетәктәй фатирларда
Гомер сөргән калам син.

Гөл булсам үсәр идем,
Җил булсам исәр идем.
Тайгак тротуарларыңа
Ком сибеп үтәр идем.

Абау алла уфларда,
Мин янамын утларда.
Килмәгән автобусларны
Көтәм тукталышларда.

Кулымдагы йөзегемнең
Таный алмыйм исемен.
Пассажирларны сөймәсәң,
Таш ташырга күч, энем.

Ай түгәрәк, ай түгәрәк,
Айларның тулган көне.
Лифтлар кайтса Казанга,
Ватыла куйган көнне.

Биек тауның башларыннан
Күренә чыршы рәтләре.
Казандагы биек йортлар —
Альпинистлар мәктәбе.

Алдыр ал гәрәбәләр,
Гөлдер гөл гәрәбәләр.
Читлекләрне хәтерләтә
Тимерле тәрәзәләр.

Исә җилләр, исә җилләр
Идел сулыкларыннан.
Төнлекләрне ябып ятам
Завод сулышларыннан.

Аргы якның казлары
Бар да кызыл тамгалы.
Бәбиләр фондына тия
Түрәләрнең азганы.

Казандагы абзыйлар
Махсус юллар салмыйлар.
Махсус юллар да салалар,
Килсә Мәскәү абзыйлар.

Мэр урамны төзәткән,
Акча каян юнәткән?
Шәһәребез төзек булыр,
Еш килсәләр үзәктән.

## Ай думбыр-думбра

Хәйдәр абзый эшкуар,
Тотмый балта-пычкылар,
Җиде кибет арасында
Машинасын еш куар.

Ай думбыр-думбра,
Вай думбыр-думбра.
Кибеттәге малларына
Әкәмәт хак куйдыра.

Тора иртә таңнардан,
Чыга костюм-чалбардан.
Иң үтемле товарларны
Таба әллә кайлардан.
Ай думбыр-думбра,
Вай думбыр-думбра.
Киң хокук биргән кәгазьгә
Башлыктан кул куйдыра.

Дәүләт мөлкәт өләшә,
Үзенә салым түләтә.
Киң колачлы «яңа руслар»
Түләмичә йөдәтә.
Ай думбыр-думбра,
Вай думбыр-думбра.
Хәйдәр абзый салымнарның
Өчәр нулен сыздыра.

Әй бу баю юллары,
Сикәлтәле, бормалы.
Хәйдәр абзый тизрәк баер,
Еш «әйләнсә» сумнары.
Ай думбыр-думбра,
Вай думбыр-думбра.
Түләр хакны кичектереп,
Әйләнештән уздыра.

Хәйдәр абзый белемле,
Хөрмәт итә белемне.
Белем алган эшкуарның
Киләчәге керемле.
Ай думбыр-думбра,
Вай думбыр-думбра.
Авторитетлы ВУЗларга
Балаларын уздыра.

Өметен җуеп мөдирләр
Хөкүмәт акчасына,
Хәйдәрдән хәер сорыйлар
Балалар бакчасына.
Ай думбыр-думбра,
Вай думбыр-думбра.
Вәгъдә иткән акчаларын
Ресторанда туздыра.

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### ТАТАРСТАН — МАЛАЙЗИЯ: ДУСЛЫК КҮПЕРЕ

8—11 апрель көннәрендә Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев җитәкчелегендәге рәсми делегация Малайзиядә булды. Делегация составына ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Р. Моратов, икътисад министры Д. Бикбов, тышкы икътисади элемтәләр министры Р. Ахунов һәм башка рәсми кешеләр, эре промышленность предприятиеләре җитәкчеләре кертелгән иде.

Татарстан делегациясен Малайзия короле Туанку Җаффар, варис принц Тунку Нәкыетдин, Премьер-министр Махатхир Бин Мөхәммәт югары дәрәҗәдә кабул итте. Әлеге очрашулар вакытында һәр ике як өчен дә файдалы күп кенә килешүләргә кул куелды. Шулай итеп, Татарстан Көньяк-көнчыгыш Азия капкасын ачты.

### ИРАН ДЕЛЕГАЦИЯСЕ — КАЗАНДА

13 апрельдә Татарстан башкаласында Иран Ислам Республикасының рәсми делегациясе булып китте. Ислам Советы Җыелышы рәисе Али Әкбәр Натек-Нури җитәкләгән делегацияне Казан Кремлендә Татарстан Республкасы Президенты М. Шәймиев кабул итте. Аннары олы кунаклар төрле промышленность предприятиеләрендә, Татарстан Дәүләт Советында булдылар. «Казан» милли-мәдәният үзәгендә түгәрәк өстәл артында үткән әңгәмәдә катнаштылар. Соңыннан ике ил арасында сәүдә өлкәсендә хезмәттәшлек турындагы килешүгә, шулай ук башка мөһим документларга кул куелды. Татарстан, Россия, Иран журналистлары өчен матбугат конференциясе үткәрелде. Аэропортка китәр алдыннан делегация башлыгы һәм аны озатып йөрүчеләр Мәрҗани мәчетендә намаз укыдылар.

### ИЧКЕРИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ РӘХМӘТЕ

Чаллы шәһәрендә яшәүче танылган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Айдар Хәлимгә Чечен Республикасы Президенты Аслан Масхадовтан рәхмәт хаты килеп төште. Анда болай диелә:

«Рус-чечен сугышы турында, «Аргамак» журналында 1995—1996 елларда басылган язмалардан торучы «Этот непобедимый чеченец...» («Кайся, Русь») китабын укып чыктым. Кечкенә генә чечен халкын юк итү максаты белән башланган коточкыч сугыш юлыннан, ике ел озынлыгындагы хәрби юлдан кабат үткән кебек булдым. Сезнең китабыгызда әйтелгәнчә, дөньядагы сугышлар тарихында чечен сугышыннан да мәгънәсез, ачыктан-ачык расачыл-шовинистик сугышның әле булганы юк иде.

Бу сугыш Рәсәйнең массакүләм матбугат чаралары тарафыннан ачыктан-ачык ялган, каршылыклы төстә яктыртылган иң авыр көннәрдә минем халкыма күрсәткән рухи ярдәмегез өчен, мин «Аргамак» журналы редакциясенә, китапның авторы Айдар Хәлимгә һәм бөтен татар халкына рәхмәтлемен».

### ЖУРНАЛЫБЫЗ ТУРЫНДА — ФРАНЦИЯ МАТБУГАТЫ

Февраль аенда «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин, Франциядә чыга торган «Ле Монд» газетасының үз хәбәрчесе Софа Шиһап һәм Парижда яшәүче милләттәшебез Җасмин Паскольне кабул итеп, әңгәмә үткәргән иде. Күптән түгел генә «Ле Монд» газетасында татар әдәбияты һәм журналыбыз турында язма дөнья күрде.

### ИҖАДИ БАГЛАНЫШЛАР НЫГЫЙ

Узган ел Татарстанның матбугат әһелләреннән торган зур бер делегация тугандаш Башкортстанның Янаул районында истәлекле очрашуда булган иде. Быел исә башкорт дусларны бай тарихлы Алабуга каласы (хакимият башлыгы — Илдар Ишков) үзенә кунакка дәште. 27—29 март көннәрендә биредә Башкортстан һәм Татарстан республикаларының массакүләм мәгълүмат һәм матбугат чаралары җитәкчеләре очраштылар. Делегация башлыклары — һәр ике республиканың да премьер-министрлары урынбасарлары Хәләф Ишмуратов, Илгиз Хәйруллин, мәгълүмат һәм матбугат министрлары Галим Хисамов, Ислам Әхмәтҗанов, китап нәшриятлары директорлары Кадим Аралбаев, Харис Әшрафҗанов, журналистлар берлекләре җитәкчеләре Марсель Сәлимов, Римма Ратникова, шулай ук газета-журналлар редакцияләренең баш мөхәррирләре, телерадиокомпанияләр җитәкчеләре урынбасарлары, район газеталары мөхәррирләре үзара иҗади багланышларны тагын да ныгыту турында фикер алыштылар, киләчәктә башкарылырга тиешле мөһим эшләрне ачыкладылар. Очрашуда Татарстан Дәүләт Советының даими комиссия рәисе, шагыйрь Роберт Миңнуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, шагыйрь Равил Фәйзуллин да катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## ЯШИБЕЗ КИТАПЛАР АЛМАШЫП

Моннан берничә ел элек Татарстан белән Башкортстан арасында үзара хезмәттәшлек шартнамәсе төзелгән иде. Бу килешүнең конкрет нәтиҗәләре мәдәният өлкәсендә, бигрәк тә нәшрият эшләрендә күркәм чагылыш таба да башлады инде. Соңгы елларда башкорт язучыларының (Мостай Кәрим, Зәйнәп Биешева, Рәми Гарипов, Яныбай Хамматов, Равил Бикбай, Кадим Аралбаев, Тимер Йосып) әсәрләре татарча Казанда, ә татар әдипләренең (Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Рәшит Әхмәтҗанов, Гәрәй Рәхим, Рөстәм Мингалимов, Харрас Әюпов, Роберт Миңнуллин) китаплары башкортча Уфада басылып чыкты. Апрель аенда Башкортстан китап нәшриятында истәлекле очрашу, китапларны тәкъдир итү кичәсе булды. Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов һәм шагыйрь Равил Фәйзуллинның китаплары башкорт телендә чыгу уңае белән оештырылган бу очрашуда китап авторларыннан һәм нәшрият хезмәткәрләреннән тыш, Башкортстанның күренекле әдипләре М. Кәрим, Г. Игебаев, К. Аралбаев, С. Шәрипов һ. б. катнашты.

## КОЛ ГАЛИ КИТАБЫНЫҢ ЯҢА БАСМАСЫ

Икенче Бөтендөнья татар конгрессына хәзерлек йөзеннән, Татарстан китап нәшрияты борынгы бөек шагыйребез Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын яңадан бастырып чыгарды. Бу юлы әсәрнең тексты төрки халыклар үзара килешкән төрек-латин әлифбасындагы хәрефләр белән бирелгән — чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез аны җиңел укыячак. Кыйссаны хәзерге әдәби телгә һәм латин әлифбасына күчерү эшен филология фәннәре докторы, шагыйрь Нурмөхәммәт Хисамов башкарган.

Әлеге китап Төркиядәге милләттәшебез Әхмәтвәли Меңгәр вакыфы (фонды) хисабына нәшер ителде.

## «ТАТАР МИФЛАРЫ»НЫҢ БЕРЕНЧЕ ТОМЫ

Татарстан китап нәшрияты өч томнан торачак «Татар мифлары» басмасының беренче китабын бастырып чыгарды. Аны нәшрият өчен галим һәм язучы Галимҗан Гыйльманов әзерләгән.

## *ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ*

### ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

11 апрельдә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Иң элек идарә рәисе Р. Мөхәммәдиев үткән ай дәвамында башкарылган эшләргә йомгак ясады. Аннары апрель — июнь айларында туган язучыларның юбилейларын үткәрү һәм аларның комиссияләрен раслау, Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге бүләгенә кандидатлар күрсәтү, берлеккә яңа әгъзалар кабул итү булды. Утырыш барышында шулай ук «Татар пьесасы — 97» конкурсының положениесе расланды. Аеруча мохтаҗ әдипләргә быелның икенче кварталы өчен акчалата ярдәм күрсәтелде, стипендияләр билгеләнде.

### ТАГЫН БЕР ӘГЪЗА-МӨХБИР

Язучы Р. Мөхәммәдиевнең татар, төрек, француз телләрендә дөнья күргән «Сират күпере» романы Мәскәүдә «Голос» нәшриятында «Мост над адом» исеме белән рус телендә басылып чыкты. Шул уңайдан Казанда «Образование» корпорациясенең картиналар галереясында әлеге китапны тәгъдир итү булды.

Тантанада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев, тарихчы Б. Солтанбәков, язучылардан Т. Галиуллин, В. Корчагин, академик Э. Таһиров, халык артисты Р. Таҗетдинов һ. б. язучы-галим адресына тәбрикләү сүзләре белән чыктылар. Р. Мөхәммәдиевка «Россия Фәннәр академиясенең гуманитар фәннәр буенча әгъза-мөхбире» таныклыгы тапшырылды.

### Г. ИСХАКЫЙ БҮЛӘГЕНЕҢ ЯҢА ЛАУРЕАТЫ

Татарстан Язучылар берлегенең атаклы милләттәшебез Гаяз Исхакый исемендәге бүләгенә быел Казан дәүләт университеты галиме, язучы-академик, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы Тәлгат Галиуллин лаек булды. Аңа бу мәртәбәле бүләк үткән ел журналыбызда дөнья күргән һәм күптән түгел генә Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Тәүбә» романы өчен бирелде.

### КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ САФЫНА

Яшь авторларны Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе (җитәкчесе — Татарстанның халык шагыйре Ш. Галиев) 9 апрельдә бер төркем шагыйрьләрнең, прозаикларның, драматургларның, әдәби тәнкыйтьчеләрнең иҗатларын тикшереп, идарә утырышына тәкъдим итү өчен кандидатуралар күрсәтте. Шулар арасыннан Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында яшәүче шагыйрь, прозаик һәм әдәби тәнкыйтьче Рафаэль Сибат, Казаннан — «Мирас» журналының баш мөхәррире, әдәби тәнкыйтьче Әхмәт Сәхапов, шагыйрә һәм публицист Нәҗибә Сафина, рус телендә иҗат итүче шагыйрә Наилә Ахунова, Әлмәттән драматург Хамис Яһүдин (Эсфир) 11 апрельдә, күпчелек тавыш белән, Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителделәр.

### ИҖАТ ОСТАХАНӘЛӘРЕНДӘ

15 апрельдә «Проза, драматургия һәм публицистика Остаханәсе»нең чираттагы утырышы булып үтте. Анда Казан шәһәрендәге Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче гимназиянең соңгы сыйныфы укучысы — тылсымлы әкиятләр, хикәяләр язучы Сөмбел Гаффарованың һәм К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында эшләүче драматург һәм прозаик Радиф Сәгъдинең иҗат-

ларын тикшерү булды. 17 яшьлек С. Гаффарова 1996 елда «Мәгариф» нәшриятында балалар өчен «Сезнең-безнең заманда» дигән беренче китабын чыгарып өлгергән. Р. Сәгъдинең исә 4 пьесасы (соңгысы — «Сынган беләзек») К. Тинчурин театрында сәхнәгә куелган, «Идел» журналында 3 детектив повесте басылган. Чыгыш ясаучылардан «Остаханә» җитәкчесе — Татарстанның халык язучысы Г. Ахунов, язучылардан Р. Даутов, Ә. Баянов, Батулла, М. Галиев, Хәйдәр, Л. Лерон, драматурглардан Т. Миңнуллин, Р. Мингалимов, Р. Хәмид һ. б. һәр ике автор турында да үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар, иҗатларына уңай бәя бирделәр. С. Гаффарова белән Р. Сәгъди, бертавыштан, Татарстан Язучылар берлегенә әгъзалеккә тәкъдим ителделәр.

## ЧАЛЛЫНЫҢ МАКТАУЛЫ ГРАЖДАНИНЫ

Танылган язучы һәм җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның милли китапханәсе директоры Разил Вәлиевнең 50 яшьлек юбилее уңаеннан, Чаллының С. Садыкова исемендәге концертлар залында әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Юбилярны котларга Татарстан Дәүләт Советыннан халык депутатлары Т. Миңнуллин, Ф. Сафиуллин һәм сәнгать осталарыннан И. Шакиров, В. Ганиева, Р. Миндияр, Рөстәм Вәлиев, К. Сатиев кебек билгеле шәхесләр килгән иде. Разил әфәндегә әлеге истәлекле кичәдә «Чаллы шәһәренең мактаулы гражданины» дигән махсус диплом тапшырылды.

## АПАСЛЫЛАР ГОРУРЛЫГЫ

30 мартта башкалабызның Тукай музеенда күренекле рәссам-график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эрот Зариповның чираттагы яңа күргәзмәсе ачылды. Бу юлы ул Татарстанның халык шагыйре, Тукай премиясе лауреаты, Г.-Х. Андерсен исемендәге халыкара бүләк хуҗасы Шәүкәт Галиевка һәм аның данлыклы якташларына багышланган иде. Күргәзмәгә рәссамның 40 тан артык сәнгать әсәре куелган — алар Шәүкәт аганың «Минем беренче гомерем» дигән автобиографик әсәре геройларына нигезләнеп эшләнгән иде (Музейда әлеге китапны тәгъдир итү дә булды). Күргәзмәдәге рәсемнәр киләчәктә олуг шагыйребезнең Апас төбәгендә ачылачак әдәби музеенда урын алачаклар.

## ШАГЫЙРЬ-РӘССАМ КҮРГӘЗМӘСЕ

4—26 апрель көннәрендә мәркәзебездәге М. Горький музеенда күренекле шагыйрь Ренат Харис ясаган дисталәрчә рәсемнәрдән торган күргәзмә эшләде. Шигърият белән сынлы сәнгатьне үзенә генә хас илаһи туганлык тамырлары белән бәйләгән әлеге күргәзмәне бик күп кешеләр карады. Шагыйрь-рәссамның график әсәрләре һәм күргәзмәгә куелган бихисап китаплары тамашачы-укучыларда зур кызыксыну, купкырлы талантына (ул бит әле — маһир гармунчы да!) ихлас соклану хисләре уятты.


## БӘЛӘБӘЙДӘ ШИГЪРИЯТ БӘЙРӘМЕ

Тугандаш Башкортстанның Бәләбәй каласында күп кенә милләтләребез яши. Күптән түгел генә бу шәһәрдә башкорт, татар, чуваш халыклары вәкилләренең уртак шигърият бәйрәме үткәрелде. Әлеге тантанада Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары — шагыйрь Әхмәт Гадел, Әдәбият фонды директоры — драматург Данил Салихов, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты рәисе урынбасары, «Ватан» җәмгыяте президенты Римзил Вәлиев, «Татарстан яшьләре» газетасыннан шагыйрә һәм җырчы Гадел Низам катнаштылар һәм чыгыш ясадылар.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** «Казан утлары» журналы редакциясе хезмәткәрләре (беренче рәттә сулдан уңга): гамәли хезмәткәр Гөлзадә Моратова, мөхәррир Марс Шабаев, баш мөхәррир Равил Фәйзуллин, мөхәррир Шамил Маннапов, гамәли хезмәткәр Тәслимә Сибгатуллина, мөхәррир Шаһинур Мостафин; (икенче рәттә сулдан уңга): мөхәррир Тәүфикъ Әйди, җаваплы сәркатип Камил Сәгадәт, гамәли хезмәткәр Лилия Гатауллина, мөхәррир Мансур Вәли, гамәли хезмәткәр Флера Сабирова, мөхәррир Наис Гамбәр, баш бухгалтер Флера Гафурова, шофер Рәмис Гәрәев, гамәли хезмәткәр Тәгъзимә Шиһабиева, мөхәррир Рәдиф Гаташ.

Наил КУРАМШИН фотосурәте.


1797
1860
ГАБДЕЛҖАББАР КАНДАЛЫЙ

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)